

# КАЗАН УТЛАРЫ

9
СЕНТЯБРЬ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

9
СЕНТЯБРЬ
1981

## Бу санда

ИЛГӘ — ИКЕ МИЛЛИАРД ТОННА ТАТАРСТАН НЕФТЕ

И. ЗАРИПОВ. Нефтькә табан. Очерк . . . . . 3

М. ӘМИР. Казан. Автобиографик повесть . . . 10
М. ШАБАЕВ. Карт солдат монологы. Шигырьләр . 65
Р. КӘРАМИ. Сагышлы кояш. Повесть . . . . 67
Р. ХӘМИД. Синең урыныңа кайттым. Пьеса . . 95
М. ХӨСӘЕН. Ике сонет . . . . . . . . 127
К. ЛАТЫЙП. Дүрт җыр. Шигырьләр . . . . . 128
Г. МИНСКИЙ. Канәфер чәчәге. Хикәя . . . . 130
А. МИНҺАҖЕВА. Болгарда уйланулар. Шигырьләр 135
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Себер урманы. Шигырьләр . 139
И. БАБЕЛЬ. Мопассан. Хикәя . . . . . . . 141

КПСС-ның XXVI СЪЕЗДЫ ДЕЛЕГАТЫ

М. ГӘРӘЕВ. Горурлык. Очерк . . . . . . . 147

Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Рәхмәт сүзе. Шигырьләр . 152

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ЮНЫС. Еллар, гасырлар, сулар . . . . . 158
Ф. ЯРКИМБАЕВА. Йомшак җилләр булып исәрмен . . . . . . . . . . . 163

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Р. НӘФИКОВ. Габдулла Тукай һәм аның даирәсе 165
А. ШАМОВ. Хатирәләрдән берсе . . . . . . 172

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Камиллек һәм тирәнлек . . . . 177
С. МАННАПОВ. Дулкыннар ни сөйли... . . . . 181

КПСС-ның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Кечкенә рецензияләр . . . . . . . . . . 184

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ф. ГАНИЕВА. Хәниф Хәйруллинга 50 яшь . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** (баш редактор урынбасары), **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

---

Производствога бирелде 20/V-1981 ел. Басарга кул куелды 13/VIII-1981 ел. ПФ 09044 Кәгазь форматы $70\times108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 102944 экз. Заказ Д-200. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

## ИЛГӘ — ИКЕ МИЛЛИАРД ТОННА ТАТАРСТАН НЕФТЕ

Изаил Зарипов

# НЕФТЬКӘ ТАБАН

ОЧЕРК



Чишмә мәйданында иң алдынгы бораулау бригадалары да «сөртенеп» кала. Графикка керә алмый интегәләр. Геология шартлары катлаулы: бораулаганда җир ишелеп төшә, җир асты бушлыклары очрый, скважинадан су бәреп чыга. Менә шушы мәкере өчен бораулаучылар аны «штраф мәйданы» дип йөртәләр. Азнакай бораулау эшләре идарәсендә бу чыганакның шушы якларын истә тотып, әзлекле бер тәртип урнаша: һәр бригада бу мәйданда елына бер скважина борауларга тиеш. Мондый тәртип керткәндә бәхәс килеп чыга. Кайчан борауларга: җәйме яки кышмы, язмы яки көзме, ел башындамы, әллә азагындамы? Чишмә мәйданына күчкәндә бригаданың планнан тыш бораулаган берничә мең метр скважинасы булса ярый әле. Ә алар булмаса? Әгәр бригаданы бирегә ел башында ук эшләтә башласалар?

Социалистик Хезмәт Герое Матвей Гринь бригадасын монда ел башында китерергә тиеш түгелләр иде. Чөнки коллективның Азнакай бораулаучыларыннан беренче булып яңача — скважиналарны агым ысулы белән төзүгә күчкән чагы. СССР Нефть чыгару промышленностеның мәрхүм министры Валентин Дмитриевич Шашинның Мәскәүдә бер киңәшмәдә әйткән сүзен бораулау мастерлары бүген дә яхшы хәтерлиләр: яңа ысулга күчү элеккеге «оҗмах тормышына» чик куярга тиеш. Чыннан да, бораулаучыларның җәннәттә яшәгән чаклары бар иде. Бораулаган һәр метр өчен көне-сәгате белән эш хакы алалар. Скважина нефть бирәме-юкмы — бораулаучының моңа исе китми. Тик метрлар гына күбрәк булсын. Скважинаны бораулап бетергәч, бригада җиһазларын җыя да, метрлар артыннан куып, икенче урынга китеп бара. Соңыннан бригада отчетларында һәм рапортларында уннарча һәм йөзләрчә мең метр бораулаган җир калкып чыга. Тантаналы җыелышларда җитәкчеләр шушы метрлар белән Җир шарын ничә мәртәбә әйләнеп чыгарга була дип чагыштырып сөйләргә күнегеп китәләр.

Вакытында скважиналардан алынмыйча калган нефтьне төяп, шуның эшелоннары белән дә планетаны күпме урарга мөмкин ләбаса! Әмма бу хакта киңәшмәләрдә ләм-мим, ә андый скважиналар ул чакта тармакта тугыз мең исәпләнә иде. Дәүләт акчасын әрәм-шәрәм итүгә, метрлар артыннан кууга чик куярга вакыт җитә. Министр әлеге проблема турында бораулау осталары белән ачыктан-ачык һәм бик җитди итеп сөйләшә. Матвей Гринь дикъкать белән аны тыңлый, ә үзе киләчәк эше турында уйлый: «Кайтуга, агым ысулына тотынам. Искечә эшләү җитте. Кешедән оят».

Азнакайда министрлыкта җитди сөйләшү булуын беләләр иде инде. Матвей Петровичка скважина бораулаганда нефть чыга башлаганчы эшләргә тәкъдим иттеләр. Гринь моңа әзер иде. Бригада членнары белән киңәште. Егетләрнең фикере аныкы белән теләктәш. Яңа эшкә беренче мәртәбә генә тотынулары түгел. Моңа кадәр сынатмадылар. Бу юлы эш нәрсә белән бетәр? Әмма Матвей Петрович, яңа ысулны Чишмә мәйданында үзләштерүгә керешәчәкләре турында әйткәч, егетләр сүзсез генә бер-берләренә карашып алдылар. Берьюлы ике имтихан булмый. Агым ысулын башта гадәти мәйданда үзләштерергә кирәк, аннан карарбыз... Бригада членнары мастерга күз ташлыйлар. Ул җавап көтә, ә үзе хәйләкәр елмая. Аның елмаюында Гриньның ышанычы да, тәвәккәллеге дә, җилле чаялыгы да чагыла иде. Менә шушы сыйфатлары аны ничәмә-ничә тапкыр хезмәт батырлыгына өндәде. Гринь — җиңәргә өйрәнгән кеше. Мастерның хезмәттәшләре белән сөйләшкәнче үк, начальство янында җитди сынауга ризалык бирүе ап-ачык иде.

«Алла каргаган» бу мәйданда эш башлау белән, көймә комга терәлеп кала. Гринь бригадасы яңа скважина бораулауга керешкән җирдә су бик күп булып чыга. Коралны җир астыннан күтәргәндә тозлы су бөтен буровойны баса. Торбаны борганда бораулаучылар салкын суда коеналар. Январь суыкларында киемгә боз ката, борылып та булмый.

Сулы катламны үтүләре була, көпшәк токымга килеп эләгәләр. Ул ишелеп, бораулау коралларын киләшчә белән эләктергән шикелле кысып ала. Гринь ишелә торган токымнарны үтүгә аеруча әһәмият бирә. Забойдан коралны алып, торба өстәргә, токым ишелгәнче, борау туктаган урынга яңадан төшеп җитәргә кирәк. Моны менә-менә шартларга торган күпердән чыгып калырга ашыгу белән генә чагыштырырга була.

Осталык бу юлы да үз сүзен әйтә. Бораулаучылар чокырлы-чакырлы юлдан асфальтка чыккан төсле булалар. Ләкин бөтен нәрсәне йота торган катламда юдыру сыекчасыз каласын да беләләр. Бу нинди тирәнлектә булыр? Көндезме, төнләме? Җир астындагы сер. Андый күңелсез хәл кötелгәндә, мастерга буровойдан китәргә ярамый. Вахтада яшь бораулаучы Сәгадәт Рамазанов. Аңа ярдәм кирәк.

Сәгадәтнең үзен генә калдырырга Гринь батырчылык итми. Башка коллективлар шактый алга киткән. Василий Шинкин егетләре, яңа елга кергәч, икенче меңне саный башладылар. Таһир Габдуллин бригадасы да узып китте.

Матвей бияләйләрен салды. Борауны әйләндерүче корыч штанганы капшап карады. Борау токымнар ваттыра. Индикатор угы кинәт, уңга борылып, югары күтәрелә башлады. Димәк, борау бушлыкка очраган, җир астында күктә асылынып калгандай булган. Өстәге сыекча ике-өч минут эчендә җир астына агып бетәчәк. Ә ул бораулаганда йөрәкнең тибүе өчен кан кирәк булган төсле таләп ителә.

Ул зонаны каплау өчен бернichә көн үтте һәм бер генә метр да бораулanмады. Башкалар, Гриньны узып, метрлар санын арттыра бара. Мастер, үзенең дулкынлануын белдермәскә тырышып, бораулаучыларын күзәтә, аларның фикерен беләсе килә. Мастерны ачуланалар булса кирәк. Бу мәйданга җәй көне килергә ярамаганмыни? Графиктан калу иң алдынгы бригадаларны да психологик яктан төшенкелеккә бирелдергәли. Егетләрнең ышанычын ничек саклап калырга? Мастерны әнә шул борчый. Сыекча агу юлын ябарбыз ябуын, ә эш алга китәрме соң? Яңадан шундый катламга эләксәк? Үзең күрмәгән «дошман» белән эш итүдән дә хәтәре юк.

Бораулаучы егет Илдус Батыршин мастерын беренче булып юата:

— Кайгырма, Петрович.

Гриньның йөзе яктырып китә. Батыршин артыннан бригада профоргы электрик Хадис Гайнуллин үз сүзен әйтә:

— Күр дә тор, Петрович, үз дигәнебезне итми калмабыз.

Ниһаять, бу мәкерле катламны үтеп китәләр. Сәгадәт Рамазанов шатлыгын кая куярга белми. Малайларга хас беркатлылык белән ул барчасы алдында ярып сала:

— Петрович, без дә бораулaмагач!..

Өстән тау төшкән кебек була. Ул төнне Гринь изелеп йоклый. Календарь февраль көннәрен саный башлаган була инде. Бер көн тыныч кына үтеп китә. Әмма ул озакка булмаган икән. Төн уртасында уяталар:

— Авария!

Вахтада Сәгадәт Рамазанов иде. «Бораулаган, ишкән ишәк чумарын». Борауны мең метр ярым тирәнлектәге забойда калдырган. Күбесе гаепнең егет өстенә төшкәнен белә. Рамазанов үзе дә акланырга теләми. Шушы очрактан соң, тормоз чыгырын ташлап китәргә карар итә. Гринь буровойга килгәч, ул мастерга күтәрелеп карарга да базмый. Хәзер, мөгаен аны бораулаучы ярдәмчесе итеп күчерерләр.

— Гаеп анда түгел, егетләр. Начар сыйфатлы металл эләккән, — ди мастер.

Матвей Гринь бригадасына койрыкта сөйрәлергә генә кала. Нефтьле катламга юл салу өчен Гриньга бораучы берничә кисәккә ватарга тәкъдим итәләр. Бу күп вакыт сорый. Гринь тәкъдимне кире кага.

— Бораулау эзеннән читкә тайпылабыз.

Шактый тирәндә нефть ятмасына икенче эздән барырга берәүнең дә батырчылык иткәне юк әле. Авышу почмагын кискен үзгәртү, ай-һай, яхшылыкка илтерме? Нефтьле катламга барып җитмәвең ихтимал. Авышу почмагын кечерәк итеп алсаң, иске эзгә кайтуың бар. Авышу почмагын кечерәйтү өчен яңа эзне өстәнрәк бораулый башларга кирәк. Бораулаган скважинаның кимендә 100 метрын цемент белән тутырасы бар.

Иөз метрдан озынрак цемент стаканы таш кебек каткач, Гринь тормозны үз кулына ала. Борауны цемент өстенә утыртып, аңа аз-азлап кына көч бирә башлый. Яңабаштан бораулау, хирургларның операция ясавы кебек, саклык сорый. Врачлар операция ясаганда эшләрен үз күзләре белән күреп торсалар, бораулаучы катламны мең метрлы торба аша җир астында «кисә».

Элек бораулап үткән ноктага ике тәүлек дигәндә барып җитәләр. Гринь борауны 15 тонна авырлык белән бастырып, тормозны бораулаучыга тоттыра.

— Шулай дәвам ит.

Икенче эз уйлаган юнәлештән китә. Матвей Петровичның тәвәккәллеге һәм осталыгы аркасында аварияне бетерү вакыты кими, бораулаучылар бик кадерле булган берничә көнне оталар, нефтьле катламга февраль ахырында төшеп җитәләр. Бүтән авария дә, катлаулы хәл дә килеп чыкмый. Ләкин кешегә үз күңеленең психологик киртәсен узып китүе кыен. Гадәттә бораулаучылар бер скважинаны тәмамлагач, бүтән урынга күчеп, яңаны бораулый башлыйлар. Бу урыннан бер тамчы нефть алынмаса да премия бирелә. Яңа урында бораулап, метрлар исәбен саный башлау Гринь егетләренең дә канына сеңгән. Ә алар скважина нефть бирә башлаганчы үз эш урыннарында калырга тиеш.

Гринь бу киртәне алдан ук күргән иде. Министр үткәргән киңәшмәдән соң ук, мастер коллективны бу психологик каршылыкны үтәргә әзерли башлады. Егетләр яңа скважинаны нефть бирә башлаганчы бораударга риза булдылар. Тик бер нәрсә күздә тотылмаган. Чишмә мәйданында аларны күңелсез хәлләр көтәсен хәтердән чыгарганнар. Катлаулы шартларда бораулау бригаданы ахыргы урынга алып ташлый. Коллектив моңа күнекмәгән. Соңгы биш елда аның хезмәт даны Татарстанда гына түгел, бәлки бөтен илдә шаулый. Беренчелек гел аның кулында.

Азнакай бораулау эшләре идарәсендәге яңалыклар соңыннан илнең башка бораулау предприятиеләрендә дә кулланыла. Ул әле дә шулай. Мондый хәл зур әһәмияткә ия, әлбәттә. Иң алдынгы бригаданы ярышучыларның «койрыгына» бәйләсеннәр әле! Бораулау бригадалары арасында шундый фикер йөри: коллектив алга чыктымы, аның яхшы эшләве өчен бөтен шартлар булдырыла. Һәм бу чыннан да шулай иде. Мондый фикер бригада намусына тап төшермәсен өчен, Гринь бораударга кыен булган Чишмә мәйданында күрә торып утка керергә риза була.

Бервакыт вокзалда бригадирлар бәхәсләшә. Матвей Петрович колагына ятышсыз сүзләр ишетелә:

— Гриньның көймәсе тәмам комга терәлде бугай...

Ул сагаеп кала. Моны һаман уртача эшләүче бригада җитәкчесе сөйли. Шул фикерне бригадада әйтсәләр? Шулай булып чыга да. Тәҗрибәле бораулаучылардан берсе сорап куймасмы?

— Петрович, син Мәскәүдә ялгышмадыңмы соң?

— Юк.

Ничек кенә булмасын, скважинаны үзләштерергә егетләр теләп керешмиләр. Тиешле операцияләрне башкаргач, сынап карыйлар. Скважинаны су белән юдыралар, нефть агышына юл ачалар. Барысы да Гринь бригадасы членнары кулы белән беренче тапкыр эшләнә. Беренче мәртәбә булса да, билгеләнгән вакытта эшләргә өлгерәләр. Шулай булгач, үзең бораулаган скважинаны үзең үзләштерә аласың икән!

Иң мөһиме, иң кызыгы, беләсегез килсә, көлкелесе шул иде: инде ничәмә-ничә мең метрлар бораулаган өлкән бораулаучылар үзләре чыгарган нефтьне үз күзләре белән беренче мәртәбә күрәләр. Майлы, коңгырт-кара, каймак төсле сузылып агучы куе сыекча аларга кәгазьгә язылган һәртөрле актларга кул куюдан күбрәк тәэсир итә. Йөрәккә җиңел булып китә, күңелдә ташкындай көчле хисләр уяна. Моңа чаклы бораулаучының осталыгын билгели торган үлчәү берәмлекләре — тизлек тә, бораулаган скважиналар саны да, җир эченә үтеп кергән метрлар да кинәт әһәмиятен җуя. Алар күп еллар дәвамында законлаштырылып лаексыз алынган эш хакында, премияләрдә һәм башка бүләкләрдә гаепләрен таныйлар. Ләкин монда аларның бернинди гаебе юк иде.

Бездә никтер бүгенге көннең мөһим мәсьәләләре үз вакытында чишелми. Турысын әйтик, эшкә хуҗаларча караш җитенкерәми. Агым ысулы белән беренче скважинаны бораулап бетергәч, бу фикер Матвей Петрович башыннан тагын бер кат үтеп китә. Моннан 20 еллар чамасы элек шушы фикерне республикабызның яшьләр газеталары күтәреп чыккан иде. Ул чакта яшь мастер Александр Подберезный, геолог Василий Базин һәм нефть чыгаручылар бригадиры Юрий Корчагин скважиналар коруда агым ысулы кертү, вышканы корудан нефть килә башлауга кадәр бораулаучының контроле астында торырга тиеш дигән бурычны куялар. Бу вакыт эчендә күпме нефть акты инде. Әле ул елларда яшь бораулаучы Матвей бөтен йөрәге белән Подберезный фикерен куәтләгән иде.

Илленче елларда «Скважиналар эстафетасы» дип аталган тулы бер цикл белән бораулауны үзләштерергә нәрсә комачаулады соң? Төп производство куәтләрен үз вакытында хәрәкәткә китерү һәм табигый байлыктан тулы файдалану нәтиҗәсендә зур экономия вәгъдә иткән новаторлыкны тормышка ашыру юлында нәрсә киртә булды? Беренчедән, бораулаучылар моңа әзер түгел иде. Икенчедән, югары коммерческий тизлек артыннан кудылар. Бораулаучылар алдында зур дәрәҗә булып саналган бу ясалма күрсәткеч бораулау эшләрен оештыручы кайбер җитәкчеләрнең үзмаксатына әверелде, күп кенә рекордлар барлыкка китерде. Рекорд хакына бөтенесенә бардылар, аңа җентекләп әзерләнделәр. Нефтьсез рекордлар җиңел атлетларның финишы булмаган арада йөгерүенә охшаш мәгънәсез бер күренеш иде. Ләкин алар кирәк иде. Республикабызда нефть промышленносте үсешенең беренче чорында рекордлар «кара алтын» ятмаларын ачуны тизләтүдә торган рольләре белән акланалар. Шундый ук рекордлар белән бүген Төмән нефтьчеләре дә Себердәге нефть индустриясен үзләштерүдә моңа кадәр күрелмәгән үсешкә ирешәләр.

Мин рекордларга каршы түгел. Чын рекордлар, дистанциядәге кыен финишка каршылыклар аша тулы нәтиҗә белән килүче рекордлар ягында торам. Бу очракта скважиналарны нефть чыгару белән тәмамлап куелган рекордларны хуплыйм.

Сүз уңаенда Төмән нефтьчеләре турында да әйтеп үтик. Көнбатыш Себер нефтьчеләре скважиналар төзүдә элек Татарстанда кулланылган агым ысулын үзләштерделәр. Ләкин рекорд артыннан куучылар, кирәгеннән артык мавыгып китеп, яңалыкка игътибар биреп җиткерә алмадылар. Нефтьле Көнбатыш Себер җирендә мондый күңелсез хәлне күрүе җиңел түгел. Себер җире гаять бай. Анда Татарстан нефтьчеләренә караганда берничә мәртәбә күбрәк бораулыйлар. Шулай булгач, «Нефть скважиналарын — агым ысулына!» — дип аталган тулы цикллы эшне тормышка ашырудан килә торган файда да берничә тапкыр артыграк, зуррак булыр иде. Илнең төп ике нефть районы булган Татарстан белән Төмән бораулаучыларының социалистик ярыш килешүенә кул куелгач, нәтиҗәле эшкә юл ачылды. Ярыш илгә күпме файда китерер! Бу хакта без Матвей Петрович белән аның фатирында озаклап сөйләшеп утырдык. Мәсьәлә аны да дулкынландыра һәм борчый. Сөйләшүне Самотлорның бораулау мастерлары белән ярыш башлау

өчен вакыт житкәнлеген раслау өчен китерәм. Тәҗрибәле мастер уй-фикерләрен түземичә ачып сала:

— Быел Төмәнгә җыенган идем. Петров һәм Миронов бригадалары белән ярышны дәвам иттерергә дип. Формаль ярышны чын ярыш итү мәсьәләсен хәл итәсе иде. Кире уйладым, бармадым. Ник дип беләсеңме? Шартлар төрлечә — шуңа. Анда токымнар йомшак, борау бер төшерүдә йөзәр метр тишеп үтә, бораулауда тизлек югары. Бер скважинаны бораулау өчен 4—5 борау да җитә.

Татарстан җирендә бер скважина бораулауга утызлап борау кирәк. Безнең республикада токымнар Себердәгедән ун мәртәбә катырак. Шулай да андагы бер бригаданың ел буе бораулап үткән җире безнекеләрдән уртача ике тапкырдан да артыграк. Бу Себернең кырыс климаты, бораулау бригадаларының базалардан ерак эшләве белән аңлатыла. Шушы нәрсәләрне исәпкә алып һәм токымнарның катылыгын шартлы берәмлек белән үлчәсәк, ике районлагы бригадаларның да күрсәткечләре тигез. Татарстанда 10 метр скважина бораулау өчен никадәр хезмәт, осталык таләп ителсә, Себердә шуның кадәр көч белән 100 метр бораулыйлар. Татарстан бораулаучылары моңа кимсенми. Киресенчә, еpaктагы хезмәттәшләренең югары нәтиҗәләргә ирешүләренә шатланып яшиләр. Татарстаннан анда килгән осталар Урал—Идел бассейнының катлаулы токымнарын бораулап тупланган тәҗрибәләрен нефтьчеләргә бик теләп бирәләр. Ике регион нефтьчеләре арасында социалистик ярышның акрын җәелүенә шушы шартлар да сәбәп. Кайбер бригадаларның формаль социалистик ярыш килешүе исәпкә керми, әлбәттә. Шунлыктан аларның йогынты көче дә йомшак.

— Бүген төмәнлеләр белән ярыша алмавыбызның төп сәбәбе — күрсәткечләренең төрлечә булуында,— дип сөйли Матвей Петрович.— Себер бораулаучылары скважиналарны ахырынача үзләштермиләр, продукция алуга ирешмиләр. Безнең арада социалистик ярыш ялкыны моңарчы да сүлпән иде. Хәзер ярышу бөтенләй мөмкин түгел. Үзегез уйлап карагыз: алар бер тәбәктә 8—10 скважина бораулый. Соңгысын тәмамламыйча, промыселчылар ул участокларга якын да килә алмый. Үзләре дә үзләштерми, башкаларга да эшләргә мөмкинлек бирмиләр. Бу — дәүләт акчасын кайчандыр безгә караганда да күбрәк әрәм-шәрәм итү ләбаса. Бер бригада бораулаган берничә скважина тик тора. Аларны вакытыннан элек бораулап бетергән өчен премиясен алганнар инде. Менә шуңа да мин Төмәнгә ярыш килешүе төзергә бармадым. Мондый эшкә кулым тартмый. Бригада егетләре дә хупламаган булыр иде.

Скважиналарның бөтенесе Чишмә мәйданындагы кебек авыр бораулланмый. Җиңелрәкләре дә очрый, кыенраклары да булмый түгел. Гринь өчен ул да иң авыры иде. Хәер, чагыштырмача җиңел бораулланганы да мастердан бөтен көчен һәм осталыгын сорый. Шулай эшләмәгәндә, нефтьле катламга юл никадәр такыр һәм якын булмасын, аңа барып җитә алмыйсың.

Күпләр Матвей Гринь уңышларын аның бай тәҗрибәсе белән аңлаталар. Әйе, ул бөтен хезмәт тормышын диярлек бораулау эшенә багышлады. Михаил Петрович эшкә дизелист булып тотынган иде. Абыйсының һәр хәрәкәтен күзәтте. Михаил эштә бер секундны да югалтмау өчен дизель моторының тигез ритмын тәэмин итәргә тырыша иде. Ул елларда аның күңелен бораулау тормозында тору, аннан абыйсы кебек танылган мастер булу хыялы били. Ул эштә тоткан дәрәҗәсе белән генә түгел, профессиональ осталыгы ягыннан да чын мастер булу турында хыяллана. Матвейны Василий Ермаков бригадасына күчерәләр. Илленче елларда Ермаков егетләре Михаил Гринь бригадасы үкчәсенә басып килә. Беренче сменада ук мастер Матвейда өлкән Гринь оеткысы күрә. Берәр атна үткәч, Матвей Василий Ермаковның эш һәм бригадага җитәкчелек итү алымнарын тик шереп чыга. Үз коллективының абыйсы бригадасы кебек уңышларга ирешә алачагын тоя. Бу абыйлы-энеле бораулаучыларның рәсмиләштерелгән ярышы төсен ала. Аерма шунда гына: Михаил — бригадага, Матвей вахтага җитәкчелек итә. Абыйсын Ермаков белән чагыштырып, Матвей үзенчә фикер йөртә: «Әйтик, Михаилның иҗади акылына Ермаковның оештыру көчен өстәсәң, Михаил Петровичның новаторлык рухын, кыюлыгын һәм тәвәккәллеген Василий Иосифовичның

производстводагы югары культурасына кушсаң...» Шушы ике останың уңай сыйфатларын үзендә туплый алучы һәм бу кешеләрне бик әйбәт белүче генә танылган мастер була ала. Һәм ул кеше кече Гринь була.

Матвей Петрович егерме ел эшләү дәверендә, абыйсы һәм остазы тәҗрибәләрен өйрәнеп һәм кулланып, бораулау эшенең ил күләмендә танылган чын мастеры дәрәҗәсенә үсә. Азнакай бораулау эшләре идарәсе бригадаларының социалистик ярыш исемлегендә Гриньнар фамилиясе берничә ел рәттән тора. Алтмышынчы еллар уртасында Матвей Гринь егетләре, үзләреннән алга Михаил Гринь бригадасын гына уздырып, Азнакай бораулаучылары ярышында икенче урында баралар. Михаил Гринь икенче эшкә күчкәч, Матвей Гринь ярышучылар исемлегенең беренче юлына күтәрелә.

Хезмәттә ирешкән казанышлары, социалистик ярыш оештыруда инициатива күрсәтүе, производство куәтләрен вакытыннан элек үзләштерүе һәм аларны тулы көченә файдалануы, эшчеләр һәм белгечләрнең иҗади дуслыгын ныгытуга керткән өлеше өчен бораулау мастеры Матвей Петрович Гриньга КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы карары белән 1977 елны СССР Дәүләт премиясе бирелә. Новаторның иҗади эше, оештыру сәләте һәм таланты ил күләмендә таныла.

Мин Матвей Гринь турында язганда абыйсының эшенә очраклы рәвештә генә тукталмыйм. Туган-тумачалыктан чыгып түгел, әлбәттә. Чөнки абыйлы-энеле мастерларның яңалыкка омтылуы ярылып ята, нефть промышленностен үстерүгә керткән өлешләре чиксез зур. Социалистик ярышта осталыкка өйрәтү, тәҗрибә уртаклашу һәм аны илнең башка нефть районнарында куллануда Гриньнарның зур бер мәктәбе барлыкка килде. Ул бүген яңа буын вәкилләренә бораулау эше серләрен тирәнрәк өйрәтүдә ачык дәресләр бирә.

Бер урында чагыштырмача җиңел бораулана торган скважиналар турында искәрткән идем. Бу җиңеллек Матвей Петровичның сәләте һәм таланты белән тәэмин ителә. Бригаданы оста җитәкләмәсә, һәр скважина Чишмә мәйданындагы беренчесе кебек каты чикләвек булыр иде. Һәр скважинаны бораулаганда туган кыенлыкларны мастер үзе генә белә.

Бертуган Гриньнарның алдынгы тәҗрибә мәктәбе программасы белән танышам. Бер нәрсә күзгә бик ачык ташлана: өлкән Петрович рецепты белән бораулауда кулланыла торган измә әзерләү ысулы. Ул аңа зур игътибар бирә, скважинаны уңышлы бораулауның төп серен измә сыйфатыннан күрә.

— Тиз һәм яхшы бораударга телисең икән, измә әзерләүгә көчеңне һәм вакытыңны кызганма, — дип өйрәтә Михаил Петрович.

Хәзер, катлаулы шартларда скважиналар бораулаганда өстәмә кыенлыклар килеп чыкмасын өчен, яшь мастерлар аның бу эшлекле тәкъдимен эштә кулланма итеп алалар. Измә әзерләүне, аш пешергән төсле, үзләре карап тора. Аның яхшы булуы катлаулы геология кыенлыкларны җиңү белән генә чикләнми, агым ысулы белән эшләп, скважиналар үзләштерүгә дә уңай йогынты ясый.

Конструкторлар Матвей Гринь коллективына бораулауда куллану өчен иҗат ителгән яңа техниканы сынау бурычын йөклиләр. Шул вакытта мин уйлап куйдым: моннан утыз ел элек Кырым-Сарай мәйданында разведка эшләре барганда бу осталар күпме яңалыкны кулларыннан үткәрделәр икән?! Санап бетерүе кыен. Әмма кайберләрен әйтмичә булмый. Турбобурлар, чыгырлар, насослар, камилләшкән бораулар, төрле диаметрлы кораллар, измә әзерләүнең яңа алымнары. Боларның барысына да республикабыз һәм илебез нефтьчеләренең көндәлек эшендә куллануга фатиханы Гриньнар бирде. Соңгысы ил бораулаучылары алдына КПССның XXV съезды куйган бурычларны уңышлы үтәүдә ярдәм итәчәк техниканың яраклылыгын ачыклау. Съезд карарларында универсаль бораулау установкалары, яңа тип бораулар һәм забой двигательләре, юдыру сыекчалары, үтә чыдам торбалар куллану, эшне оештыруны яхшырту нәтиҗәсендә скважиналар төзү вакытын 25-30 процентка киметү кирәклеге күрсәтелде.

Матвей Петрович винтлы двигательләр ярдәмендә эшләүче яңа бораулар, үтә чыдам алюминий торбалар турында күптән ишеткән иде. Бораулаучылар аларны тугызынчы бишьеллыкта ук көттеләр. Конструкторлар һәм машина төзүчеләр

арасында ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыккан булса кирәк. Галимнәр производствода эшләүчеләр белән дә уртак бер фикергә килә алмыйлар. Аларны сынауны тәэмин итүнең кайсыдыр звеносы эшен җиренә җиткереп башкармый. Яңа техниканы эшкә җигү елдан-ел кичектерелә. Ниһаять, бораулар һәм торбалар кече Гринь бригадасына килеп җитә.

Вакыт бик кадерле булса да, Гринь эшкә керешә. Бораулаучылар сынауда бөтен җаваплылыкны үз өсләренә алалар. Төп нәтиҗәне Гринь ясый. Борауларның һәм торбаларның уңай якларын һәм кимчелекләрен күрсәтеп бирә. Шул кимчелекләрне истә тотып, тагын да камилләштергәч, заводта күпләп җитештерүне җайга салырга мөмкин булуын әйтә. Галимнәр дә, конструкторлар да мастер фикере белән килешә.

— Галимнәрнең, яңа техниканы иҗат итүче конструкторларның производство белән элемтәләре акрын ныгый. Аларны безгә, бораулаучыларга, якынлаштыру турында аз уйлыйлар, — дип, дөресен сөйли Гринь.

Мастерның шушы сүзләрен куәтләгәндәй буровойның берсендә скважинаны тәмамларга 200 метр калгач, кондуктор өзелә. Бу хәл бораулау эшләрендә файдалануга тәкъдим ителгән яңа торбада була. Гриньга хәбәр итәләр.

— Мин килмичә кагылмагыз, — ди ул һәм буровойга ашыга.

Белгечләр һәм башлыклардан берничә кеше килә. Кабул иткән карарны үтәү өчен мастерның ризалыгы кирәк, аны көтәләр. Мондый хәл кайчандыр Ермаков бригадасында булган иде. Кондуктор өзелү — коралны торбадан җир астына төшерү юлы ябылу дигән сүз. Аны бораулаучылар «скважина тыгылу» дип атыйлар. Ул чакта Ермаков тормозга Матвей Гринь урынына үзе баскан һәм скважинаны коткарып калган иде. Матвей Петровичка Ермаковның бу алымын кулланырга туры килгәне булмады. Хәзер я мастердан үзенә зур ышанганлык, тәвәккәллек, кыюлык һәм башкару осталыгы сорый торган шул алымны куллану таләп ителә, я булмаса берничә көнне югалтуга китерә торган вариант белән килешәсең. Гринь беренчесен сайлый. Борауны тиешле юнәлештә төшерә, калган метрларны бораулау әллә ни авыр булмый, скважинаны коткаралар. Аннан нефть бәреп чыга.

Мастерның һәм бөтен бригаданың җыйнак һәм бик төгәл эшли белүе, бөртекләп җыйган тәҗрибәне һәр очракта иҗади файдалануы Гринь егетләренә өченче кварталда алга таба шундый сикереш ясарга мөмкинлек бирә ки, аның талантын тагын да бер кат танымый булдыра алмыйлар: «Гринь — Гринь инде ул!»

Дүртенче кварталда ике скважина бораулау һәм үзләштерү эшләрен тәмамлый. Ноябрьда ике еллык план үтәү турында рапорт бирә. Коллективның вахта дәфтәренә тулысынча үзләштерелгән унсигезенче скважина языла.

Гринь беркайчан да рекордлар артыннан куммый. Рекордларга карата аның төпле фикере бар: «Алар тигез эшләү ритмын боза. Рекордтан соң скважина хәрәкәтсез кала».

Аның үз осталыгын һәм бораулаучыларның сәләтен билгеләүдә үлчәү берәмлеге булып ел буена эшләнгән эш, «Татнефть» берләшмәсе бригадалары ярышында тоткан урыны санала. Гринь үз шәкерте Сәгадәт Рамазановның республиканың иң яхшы бораулаучыларыннан берсе булып танылуы белән горурлана. Ул югарыда телгә алынган авариядән сабак ала. Авыр көннәр артта калды инде. Рамазанов хәзер Гриньның беренче ярдәмчесе. Алар унынчы бишьеллыкта елына уртача 30 мең метр җир борауладылар. Мастер бу җансыз метрлар белән түгел, бәлки үзе бораулаган җанлы скважиналар белән куана. Коллективның осталыгын, аның хезмәт данын илдә беренче булып агым ысулын куллануда һәм нәтиҗәле эшли белүдә күрә.

Унынчы бишьеллыкта Гринь егетләре шундый цикл белән 150 скважина борауладылар.

«Шунысына куанып бетә алмыйм — барысы да күз алдымда нефть бирделәр». Республиканың атаклы мастеры Матвей Петрович Гринь бригадасы КПССның XXVI съезды куйган бурычларны тормышка ашыра барып, Татарстанда ике миллиард тонна нефть чыгаруга үзенең лаеклы өлешен кертте.

Мирсәй Әмир

# КАЗАН

## АВТОБИОГРАФИК ПОВЕСТЬ

### ӨЧЕНЧЕ КИСӘК



Трамвай турында ишеткәнем бар иде инде. Иң башлап «Яңа кисекбаш»тан укып.

Баш килә шундый каты, шундый кызып,
Полный ход килгән трамвайдан узып...

Алдарак тагы:

Кузгалып китте вагон, җилдәй бара...

Ничек кенә бара әле:

Ул барадыр йөгерек аттан да каты
Һәм җәядән аткан уктан да каты...

Ягъни, иң тиз йөри торган атсыз арба сыйфатында күз алдыма килә иде трамвай. Шуңа бинаән булса кирәк, «Чаян» журналында басылган бер карикатураның да мәгънәсен ялгыш аңлаганмын булып чыкты. Картаеп тәмам эштән чыккан бер әби сурәтен ясаганнар. Таякка таянган, бөкерәйгән хәлдә, рельслар буйлап көчкә атлап бара. Вагон ишегеннән башын тыккан вожатый аны трамвайга чакыра: «Әйдә, әби, утыр!». «Юк бәбкәм, утырып тормыйм, мин ашыгам», дип җавап бирә әби. Рәхәтләнеп көлдем. Янәсе, менә тиле карчык, ашыккач, трамвайга утырырга кирәк иде бит инде. Ә ул!.. Баксаң, Арсланов ясаган бу рәсем «Чаян»ның әбидән түгел, трамвайдан көлүе булган икән. Соңыннан миңа матбугат битләрендә Казан трамваеның акрын йөрүеннән көлеп ясалган бик күп рәсемнәр күрергә, шул ук мәсьәләгә багышланган фельетон яки хәбәрләр дә укырга туры килде.

Казан пристанена килеп төшү белән игътибарымны җәлеп иткән беренче яңалык — трамвай булды. Иң башлап, звоногы колагыма керде.

— Чаң! Чаң! Чаң!..

Звонок кына түгел, набат кебек яңгырый иде трамвай тавышы ул елларда. Вагон йөртүче аны идәндә торган металл төймәгә аягы белән басып-басып кына түгел, бар көченә тибеп хәрәкәткә китерә иде.

---

Мәрхүм әдипнең тәмамланып өлгермәгән бу әсәре архивыннан алып басыла.

— Чаң!-Чаң-чаң!.. «Юлымда торма, кач, жаныңны сакла!» — дип кычкыра кебек.

Кәрзин-чумаданнарыбызны тотып, Идел ярын күтәрелүгә, трамвай үзе күзгә ташланды. Берсенә-берсе ялганган ике кызыл вагон, чаң сукмаган чакларында да, колакны тондырырлык кына түгел, күз алларын да томанландырырлык дәрәҗәдә каты металл тавышы чыгарып, йөзләрчә кешеләр төркеме арасына килеп керде. Каршы яктан тагы икәү...

Каты үкерү, тешкә тиярлек шагырдаулар өстенә:

— Чаң-чаң-чаң!..

Колакларың гына түзсен.

Хәер, хәзер генә шулай дим. Ул вакытта бу тавышлар минем өчен тансык булып ишетелде. Үзеңне зур шәһәр шау-шуы эчендә хис итү күңелле иде.

Кая барганыбызны аңлап та житмәгән хәлдә, трамвайларга таба ашыктык. Үзебез дә сизмәстән, бөтен көчкә кычкырып сөйләшәбез.

— Туктагыз! — дип акырды Барый.— Карагыз, бөтен кеше теге вагонга йөгерә ич.

— Әһә, Казанга теге якка!..

Каршы якта торган трамвайга таба ташландык. Ә бу якка китәсе трамвай рельс аша чыгуыбызны көтеп тормый. Котны алырлык ачулы тавыш белән «Чаң-чаң» килеп, кузгалып та китте. Барый белән Мөкаддәс чыгып өлгерделәр, ә мин бүленеп калдым. Вагон, шундый кабаланып чаң сукса да, кузгалып киткәч, ашыкмый, шыгыр-шыгыр килеп, минем алдымнан иренеп кенә узып бара. Тәгәрмәчләрне күздән югалтмасам ярар иде дип, җан калтырап торам.

Ниһаять, узып китте. Карыйм, тегеләр юк. Каршы якта — сулдарак торган вагонга таба йөгердем. Мөгаен шуның теге як ишегеннән кергәләрдер. Әйе шул, әнә Мөкаддәс кереп бара. Барый да шунда. Кереп баскан да, ишектән башын тыгып, күзләре белән мине эзли. Әһә, күреп алды. Кычкыра:

— Йөгер тизрәк!

Җан-фәрман чапсам да өлгерә алмый калдым бит, кузгалды китте трамвай. Йөрәгем ярылырдай булып, куркып кычкырып җибәрдем.

— Тукта-а!

Трамвайның исендә дә юк. Йөрешен тизләтә генә бара. Шашып чабам вагон артыннан. Күңелемне хәвефле уйлар чыбыркылый: юк, калырга ярамый миңа, иптәшләремнән аерылсам, мондый мәхшәрдә мин аларны кайдан табармын?..

Бәхеткә каршы, шәһәр тәртипләрен белеп бетермәүче безнең кебек тәҗрибәсезләр коткарды. Авылдан килгән бер мужик, бөтен гаиләсе һәм зур-зур капчыклары-төенчекләре белән тиешсез урыннан юл аркылы чыгып бара икән. Трамвай, ачуына чыдаша алмагандай, котырып набат сукса да, туктамый булдыра алмады. Атылып барып кердем. Ул вакытта вагоннарның ишекләре ябылмый, кайда туры килсә, шунда утырырга була, хәленнән килгән кешеләр өчен полный ходка барган трамвайга сикереп менү дә, үзеңә кирәк урында аңардан ыргып төшеп калу да зур гаеп саналмый, яшьрәкләр өчен хәтта егетлек тә исәпләнә иде.

Билгеле, бу кадәресен соңыннан белдем. Ә ул көнне, Казан туфрагына беренче аяк баскан минутларда, югалта язган иптәшләрем янына килеп басу — көтелмәгән зур шатлык булды. Барый белән Мөкаддәснең дә авызлары ерылды. «Што син дә што син! — диләр.— Рәзе ярый монда авызыңны ачып йөрергә?»

Әле генә йөрәк яргыч булып тоелган маҗара шунда ук онытылды. Хәзер инде безне Казан чаклы Казан белән танышу бәхетенә ирешү шатлыгы биләгән. Дөрес, трамвай тәрәзәләре аша күзләребезгә таш-

ланган беренче күренешләр Казан үзе түгел иде әле. Ләкин барыбер безнең өчен күңелле яңалык — Казанга керү юлларын күрәбез. Күрәбез генә түгел, өйрәнәбез, сорашабыз.

Каршыбызга кондуктор килеп басты. Муенына әллә ничә кесәле күн сумка аскан. Кесәләре тулы вак акча — бакыр да көмеш, чалтыр-чолтыр. Сумкасы янына тәгәрмәч-тәгәрмәч итеп төрелгән билет тасмалары таккан. Тасмалары төрле төстә: аклары бар, зәңгәрләре, сарылары... Пристаньнан Казанга кадәр җиде чакрым исәпләнә икән. Билетлар Петрушкин разъезд тукталышына (ягъни Бишбалтага) кадәр бер хак, шәһәр үзәгенә — ике хак тора икән. Багаж өчен, балалар өчен аерым билетлар.

Пристаньнан Бишбалтага кадәр араны, сирәк-мирәк очрый торган ниндидер койма яки склад кебек каралтыларын исәпкә алмаганда, трамвай бөтенләй диярлек буш кырдан үтә иде. Хәзер инде ул җирләр, ул кырлар күптән су астында.

Шәһәрдән бигрәк зуррак авылга охшаган Бишбалта урамнарын уздык. Казанка күперен чыктык. Эре-эре таш түшәлгән дамбаның сул ягындагы әһрам шәкелендә ясалган ак һәйкәлгә игътибар иттек. Казанны Россиягә кушу сугышларына багышланган ул тарихи һәйкәл әле дә үз урынында. Хәзер ул төзекләндерелгән, әкияттәгечә серле атау булып, диңгез эчендә утыра. Теге вакытта үзе шактый ташландык хәлдә, ә әйләнә-тирәсен бәрәңге басуы уратып алган иде.

Ә дамбаны уң яклап, хәзерге көндә һәркем сокланып уза торган әрәмәле-үләнле яңа яр буе паркы урынында шактый тирән чокыр иде. Бишбалтадан башлап Казанга кадәр сузылган ул уйсулыкта тоташ кәбестә кыры җәелеп ята. Кәбестә кыры бетүгә... чүплек! Әйе, туры мәгънәсендә чүплек башы! Тиреслек дисәң дә ярый. Шунда яланаяклы бала-чага чүп-чар арасыннан тәти ташландыклар эзли, тимер-томыр җыя. Шунда озын-озын кармак саплары тоткан малайлар, малайлар гына түгел, олы-олы агайлар да тирес өемнәре арасында суалчан эзләп казыйлар...

Татар мәдәниятының үзәге булган зур, данлы таш каланы сагынып читтән килгән кеше күзенә шактый ямьсез, ямансу тоелган бу күренеш турында үзара бер-ике сүз алышырга өлгермәдек, чүплеккә терәлеп торган иске-моски ызбалар яныннан үтеп, икешәр катлы таш өйләр тезелгән урамга кереп киттек. Мәскәүски! Тагы Тукай исемә төште.

Мәскәүски якка күз салсам, күрәм...

Тукай үзе юк инде. Ә менә Такташ очравы мөмкин. Чын-чынлап ышанып, урамнан узучы кешеләрне карап барам. Мөгаен ул шунда, Казан кешеләре арасында йөридер. Рәсемнәрен күреп тә, шигырьләре буенча да портреты күз алдымда торган сары чәчле, зәңгәр күзле шагыйрьне, күренсә, һичшиксез танырмын төсле. Тик күренми генә... Әйе, ул елларда Казан минем өчен барыннан да элек Такташ иде...

Тәрәзә аша күзләрем белән Такташны шулай эзләп бара торгач, хәтта атаклы печән базары яныннан да игътибарсыз үтеп киткәнмен булып чыкты.

Минем күңел Такташта, ә Барыйның күзләре вывескаларда икән. Трамвай тавышын җиңәргә тырышып, колагыма кычкыра:

— Кара теге вывесканы,— ди.— Нинди оригинал! Шәп художниклар бар, димәк, Казанда, ә?

«Чаян» буенча күңелгә күптән таныш булган Болак күпере аша мәшһүр Кабан күле кырыеннан узып, Казанның уртасына — Балык базарына килеп төштек. Хәзерге «Балалар дөньясы» магазины һәм «Татарстан» кунакханәсе урнашкан мәйдан ул вакытта шулай «Балык базары» дип йөртелә, бөтен мәйданны тутырган кибет-алачыкларда

балык кына түгел, башка бик күп төрле галантерея һәм бакалея товарлары да сатыла иде. Базар булгач, әлбәттә, кибетләр арасында һәр вакыт кеше мыжгып тора, кибет артларында гади авыл арбасына җигелгән атлар кайнаша иде.

Болар бары да Казан иде безгә. Ләкин алар белән мавыгып, авыз ачып гамьсез йөрергә вакытыбыз юк, иң элек кая булса да урнашырга кирәк. Крестьян йорты номерларын барып таптык. Шул Балык базарыннан ерак түгел икән. Проломный буйлап ике-өч йорт үтүгә, сулга борыласы да, урам аша гына чыгасы (хәзерге «Совет» кунакханәсе).

Унлап карават куелган бүлмәгә китереп керттеләр. Безгә бирелгәннәреннән башка караватлар буш булмаса да, бүлмәдә беркем дә юк: шәһәргә эш белән килгән авыл кешеләре барысы да диярлек монда кунарга гына кайталар икән.

Безгә дә тизрәк чыгып китәргә, художество техникумын эзләп табарга, анда керү шартлары белән танышырга, ничек тә аның торагына урнашу ягын карарга кирәк иде. Ләкин минем күңелдә һаман да иң элек Такташны күрү кайгысы. Барый белән Мөкаддәс техникумны эзләп чыгып киттеләр, ә мин — Такташны.

Газеталардан күреп, ГАЖУРның (газета-журналлар чыгара торган нәшрият ул елларда шулай атала иде) адресын беләм: Воскресенский урамы, 21 нче йорт. Эзләп таптым. Хәзерге Ленин урамында, заманына күрә зур гына итеп салынган ике катлы бина. Берьюлы эченә үк кереп китәргә кыюлык җитмәде. Иң элек, почта ишеге янында тукталып, урам аша күзәтеп тордым. Кечкенә-кечкенә вывескалар. Казанда чыга торган газета-журналларның — мин белгәннәренең генә түгел, мин белмәгәннәренең дә — әллә тагы барсының да редакцияләре шушы йортта инде. Өстәвенә, шунда ук Фильзер фамилияле фотограф та яши, имеш. Урамга күрсәтеп куйган фото-витринасында чибәр-чибәр кызлар, купшы-купшы егетләр яки Казанның атаклы кешеләре төшерелгән төрле зурлыктагы карточкалар, урамнан узучыларның игътибарын җәлеп итеп, портретка төшәргә чакырып торалар.

Мәшһүр йортның ишеге һәркемгә ачык, кергән-чыкканга игътибар итүче юк: теләсә нинди кибеткә яки почтага кергән кебек. Болай булгач, куркып, тартынып торасы түгел. Исәбем: хәзергә Такташның кайда утырганын читтән генә күреп, күреп үк булмаса, белеп кенә чыгарга.

Тиз генә урам аша чыктым. Акыл көчем белән үземә үзем кыюлык биреп, изге йортка кереп киттем. Ишектән кергәч тә кечкенә мәйдан. Сул як стена буйлап өске катка ачык баскыч менеп китә. Икенче катта урам-ишеккә караган ягы рәшәткә белән генә киртәләнгән ачык коридор буйлап уңга таба юнәлдем. Сул ягымда фотограф ишеге калды. Ниһаять, зур гына бүлмәгә килеп кердем. Бүлмә эчендә тагы бүлмәләр бар икән: уңга бер ишек кереп китә, сулга бер ишек. Дүрт почмакта дүрт өстәл. Өстәл янында утыручылар бары да үз эшләренә чумган. Миңа игътибар иткән кеше дә юк. Һәркайсына күз йөртеп чыктым. Берсе дә Такташка охшамаган.

— Эһем!..

Сул як почмактагы өстәл телгә килде.

— Сезгә кем?

— «Авыл яшьләре» редакциясе кирәк иде.

— Менә бу бүлмәгә кер.

Такташның «Авыл яшьләре» редакциясендә эшләве турында ишеткән идем. Йөрәгемнең котырып тибүен тыярга тырышып, сул як бүлмәгә уздым. Монда да дүрт почмакта дүрт өстәл. Өчесе буш. Тагы да түргәрәк уза торган ишекнең сул ягындагы өстәлдә генә бер Борын утыра. Әйе, иң элек борыны күземә бәрелде. Сырты калкып, бөкерәеп

килгән зур борын! Кечкенә авыз. Сыек кына сары чәч. Тавыш-тынсыз гына карап торам. Неужели Такташ? Күзләре нинди икән?

Әйтерсең, күңелемдә туган бу сорауны Борын дигәнем йөрәге белән сизеп алды: алдындагы кәгазьгә төбәлгән күзләрен күтәреп, миңа карады. Тоныграк кына яшькелт-зәңгәр күзләр... Неужели шул? Бер дә ышанасым килми. Булмас. Бу бит хәрби киемдә. Булса соң! Армиягә чакырылган булса, гаҗәп мени? Ай-һай, шундый шаян, күңелле шигырьләр язган кеше бу тикле җитди булыр микән?

— Ни йомыш?

Куркып киткәндәй булдым. Ни әйтергә белми торам. «Такташ кирәк» дияр идем... «Мин» дисә? «Сезне күрергә килдем» дияргәме? Юләр кеше кебек...

Сүзсез торуымны күреп, Борын кычкырыбрак дәште. Нечкәрәк кенә, сабыр гына тавыш.

— Кем кирәк?

— «Авыл яшьләре» редакциясе кирәк иде.

— Әнә шул өстәл,— диде,— көтегез, Такташ озакламый килер.

Эчкә җылы керде, иркенрәк сулап куйдым. Шөкер әле, үзе Такташ түгел икән. Икеләнсәм дә, күңелем бу кешенең Такташ булуын теләми иде. Бер күрүдән үк хәтеремә сеңеп калган бу үтә үзенчәлекле борын иясе белән киләчәктә шактый якыннан очрашасым барлыгы һәм аның, атаклы исеме булмаса да, хөрмәткә лаеклы кеше булып чыгасы хакында ул минутларда мин бөтенләй уйламадым. Чөнки күңелем Такташта.

Озакламый килер диде бит. Чынлап та хәзер килеп керсә?.. Үз-үземә хисап биреп тормастан, тизрәк чыгып китәргә ашыктым. Кайда эшләгәнен белдем — хәзергә миңа шул җиткән. Ә аның белән болай гына күрешергә ярамый. Үзенә сиздермичә, читтән генә карап торсаң, бер хәл иде, ә болай!.. Юк. Аның белән күрешеп сөйләшү өчен бер сылтау тапмый ярамый. Нәрсә булса да эшләргә кирәк...

Нишләргә кирәген крестьян йортына кайтып җиткәнче хәл иткән идем инде: тиз генә бер хикәя язып алырга да, шуны тотып барырга...

Утырдым хикәя язарга.

Кечкенә чагымда ук безгә шактый якыннан таныш булган бер хатынның кырда, урак урганда бала табуы турында ишеткәнем бар иде. Шул уңай белән сөйләнгән сүзләрдән мондый хәлнең тагы берничә хатын башыннан кичкәнлеге турында колакка кереп калган.

Кулыма каләм тотып, нәрсә турында язарга белмичә, күңел төбемдә казынып утырган чакларда шул вакыйга исемә төште һәм һәр вакыт диярлек, моны язарга кирәк дип уйлыйм, ләкин ни өчендер язарга ашыкмыйм, аны һаман алдагы көнгә калдыра килә идем. Бу юлы күп уйлап тормадым, тоттым да шул вакыйгадан башлап киттем. Артык озак баш ватмастан, зурат ышыгында туган кыз баланың язмышын үз хыялымда туган вакыйгалар белән үстереп, аны сыйнфый көрәш мотивлары белән үземчә бәйләп, яздым да чыктым. Басмасалар басмаслар. Миңа нәрсә булса да тотып, Такташ янына бару, табынган шагыйремне якыннан күрү, аның белән сөйләшү кыйбат...

Икенче килүемдә дә Такташ үз урынында юк иде. Аңа, күрше өстәлдә утыручыларның киңәше буенча, хикәямне калдырып китәргә туры килде. Монысы өчен куандым гына: бигрәк яхшы, мин килүгә укып куяр.

Ниһаять, өченче килүемдә миңа кирәкле өстәл буш түгел иде. Ләкин анда утыручы кеше кем соң ул? Нәрсәседер мин рәсемдә күргән Такташка ошый да кебек. Алай дисәң, чәче юк: машинка белән кыркылган такыр баш. Өстәвенә, соңгы елларлагы шаян шигырьләрен уку

нәтиҗәсендә булса кирәк, мин аны һаман көлеп, шаярып, гел кызык сүзләр генә сөйләп утыручы бер кеше сыйфатында күрергә әзерләнгән идем. Ә бу шундый җитди чырайлы...

Аңа каршы як стена буендагы өстәлдә утыручы теге олы борынлы хәрби мине танып калган булган икән, кемгә мөрәҗәгать итәргә белмәгәндәй таптанып торуымны күреп, миңа ярдәмгә килде:

— Хикәяң Такташта,— диде.— Әнә үзе белән сөйләш! — һәм ул борыны белән генә әлеге такырбашка ымлап күрсәтте.

Такырбаш күтәрелеп миңа карады. Күзләре чынлап та зәңгәр. Шул икән. Үз исеме чыкканын ишетсә дә, хикәя турында колагына кермәгән күрәсең:

— Нәрсә? — диде күзләрен миннән алмыйча.— Шигырь китердеңме?

— Юк, мин сезгә бер хикәя калдырып киткән идем.

— Хикәя? Исемегез ничек? Хикәягез ничек атала?

Әйттем.

— «Көннәр архивында»? Хәзер табарбыз.— Ул, өстәл тартмасын ачып, кәгазьләр актара башлады.— Утырыгыз!..

Өстәл каршысына куелган урындыкка утырдым. Ул арада Такташ, хикәямне табып, өстәлгә чыгарып та салды. Кулъязмага тиз-тиз генә күз йөртеп алды. Көрсенеп куйды.

— Хикәягез барырлык түгел, егет.

Бу сүзләрне ул шундый гади итеп әйтте, гүя ул мин айлар буе күрергә хыялланып йөргән зур шагыйрь дә түгел, ә Барый яки Мөкаддәс кебек, әллә кайчаннан белгән якын дустым. Гадәттә мондый очрашу вакытларында мине буа торган каушау, тартыну хисләрем кая китте, белмәдем, ул турыда хәтта уема да килмәде. Такташ чаклы Такташ белән тигез хокуклы кеше кебек, иркенләп сөйләшергә керештем. Үзем дә көтмәгән бер тынычлык белән:

— Ник бармый? Нәрсәсе ярамый?

Такташ беренче җөмләдән үк гаеп тапты.

— Менә бит,— диде.— «Авыл яланы миллионнарланган эш халкы белән чуарланган» дип язасыз. Каян килгән ул авылга миллион кеше? Әле миллионлаган гына да түгел, миллионнарланган?!. Казан тикле Казанның үзендә халык ике йөз меңнән артмый.

Бирешергә теләмәдем.

— Мин бит бер авыл яланын гына әйтмим, бөтен илебездәге авылларны күздә тотып язам. Шулай булгач, нишләп миллионга тулмасын авыл халкы?

— Ярар,— диде Такташ,— бусы синеңчә булсын ди. Ә бусы...

Ул тәртип буенча башка җөмләләргә күчте. Һәрбер җөмлә буенча диярлек я мәгънә, я тел ягыннан булган хаталарымны күрсәтә башлады. Мин үз чиратымда аларны яклый барам...

Такташ минем хикәямне әле бөтенләй укымаган да икән. Бераз күз йөрткәч, кызыксына төшкәндәй булды. Ара-тирә, «бу урыны ярый сы»,— дип тә куйгалый башлады. Бәхәсләшә-бәхәсләшә, ахырына кадәр укып чыктык.

Атаклы шагыйрь белән шулай үз кешеләрчә сөйләшеп, хәтта аның белән сүз көрәштереп утыру гаҗәп рәхәт иде миңа. Аның белән көне буе сөйләшергә, хикәямә кагылышлы булмаган сораулар да бирергә хәзер идем. Ләкин бәхетле минутлар артык дәвам итә алмады. Кулъязмамны укып чыккач, Такташ аны яңадан өстәл тартмасына салды да:

— Ярар, карарбыз,— диде.— Үз сүзеңдә нык торырга яратасың икән, синнән рәт чыгарга тиеш,— дип тә куйды.

Тәмам канатланып, үсеп чыгып киттем. Иптәшләрем янына атлап кына түгел, очып кайттым кебек. Алар да минем уңышыма үземнән ким куанмаганнардыр. Хәтта Мөкаддәс үзе дә шигырь язарга утырды. Дәминов кына бирешмәде. Бөтен күңелен сынлы сәнгатькә биргән

кеше арабызда ул гына булгандыр. Мин Такташ белән мавыгып, хикәя язып йөргән арада ул художество техникумына керү юлларын ачыклап бетергән, техникумның уку-укыту эшләре бүлеге мөдире кем икәнлеген дә белеп кайткан иде.

Ниһаять, без үзебезне Казанга тартып китергән изге бина каршында. Грузинский белән Толстой урамы чатына салынган бу йорт үзенең тышкы күренеше белән үк аерылып тора: аны ике катлы дисәң дә ярый, кайбер урыннарына карап, өч катлы дияргә дә була. Түбәсенең магистраль урамга караган ягы зур-зур тәрәзәләргә охшатып, ярты-лаш пыяла белән ябылган.

Мәһабәт имән ишекләрне ачып, эчкә керәбез. Эчтәрәк тагы шундый ук имән ишек. Ике ягында ике сакчы булып, таш арслан сыннары тора. Алардан да узгач, киң, иркен зал-коридорга килеп керәсең. Ул алга таба бинаның аргы башына кадәр сузылган. Сулга борылган өлеше икенче катка күтәрелә торган киң баскычка барып терәлә. Баскыч янында — каравыт биеклек постамент өстендә — йөзтүбән капланып яткан баһадир сыны. Әйе, бетмәс көч, куәт иясе икәнлеге — тәнендәге бөтен мускулларыннан сизелеп тора. Йөзе бөтенләй күренмәсә дә, бар хәрәкәтеннән аның авыр, газаплы уйлар кичерүен бик ачык тоясың.

Ул вакытта мин бу скульптурада борынгы яһүд легендасыннан алынган Самсон батыр образы гәүдәләнгәнлеген белми идем әле. Өчәүләшеп, исебез китеп карап торабыз.

— Нихәл, егетләр!

Артыбызга борылдык. Кем бу безгә карап шулай елмая? Бу нинди якты чырай?

Җавап кайтарырга өлгермәдек, таныш түгел кешенең ягымлы тавышы тагы яңгырады.

— Нишләп йөрисез? Кайдан килдегез?

Шушы уку йортын эзләп Башкортстаннан махсус килгәнебезне белгәч, аның болай да ачык чырае тагын да яктыра төште.

— Бик хуп,— диде.— Мин сезне укытасы кешеләрнең берсе булам. Әйдәгез әле...

Ул безне өске катка чакырды. Канцеляриегә — үз бүлмәсенә алып керде. Мин аның йөзенә дә, кигән киемнәренә дә сокланып утырдым. Кара ефәктәй чәч, бераз кабарыбрак торган һәм сизелер-сизелмәс кенә җирәнсу шәүлә йөгертелгән кара мыек җирлегендә аның ике як почмагы эчкәрәк уелып кергән киң маңгае да, йөз чәһрәсе дә аеруча алсу ак булып, яктырып күренә. Өстендәге киеме дә менә дигән: соргылт кара пинжәк, түш кесәсеннән, ап-ак чәчәк кебек булып, кульяулык почмагы чыгып тора. Муенында төрле төстә аркылы бизәкләр төшкән ефәк галстук. Ә күлмәге! Сирәк-сирәк буйлы ак күлмәк. Ул вакытта мин зефир дип аталган материя барлыгын белми идем әле. Шулай да каршыбызда утырган бу мөләем кешенең якасы белән бераз изү чите генә күренеп торган күлмәге гади ситсыдан яки сатиннан гына түгел, ә ниндидер бөтенләй бүтән, затлы товардан тегелгәнлеген бик ачык тойдым. Сирәк-сирәк кенә булып нечкәле-калынлы карасу буй төшкән ак зефир — ирләр күлмәге өчен иң лаек, иң килешле материал дигән караш гомеремә калды.

Укытучыбыз буласы кеше, болай да зур, таза гәүдә өстенә шундый килешле итеп киенгән дә булгач, ыспай, зифа буйлы күренә, җыйнаклык, нәфислек сөюче зыялыга охшап тора.

Ул тагы бер тапкыр безнең кайлардан килүебезне ачыклады, моңарчы нишләгәнебезне, кайда укыганлыгыбызны сорашты.

— Рәсем мәктәбенә килергә ниятләп, бик яхшы эшләгәнсез,— диде. Аның саф тавышы да, һәр сүзне ачык итеп җиренә җиткереп әйтүе дә күңелебезгә бик ятышлы яңгырый иде. Бераз гына тынлыктан соң ул,

безгә сер итеп кенә әйткәндәй, тавышын әкренәйтә төшеп, дәвам итте.— Беләсезме, сез эзләп килгән бу уку йорты элек «Казанская императорская художественная школа» дип атала иде. Әмма Казанская булса да, анда бер генә татар да укымаган. Бу хәлгә бәлки патша хөкүмәте генә түгел, һәр сурәтне рус алласы итеп күрүче надан дин әһелләре дә сәбәпче булгандыр. Мәгәр ни генә булмасын, сынлы сәнгать бабында мәдәниятыбыз артта калган. Махсус белем хасил иткән, чын мәгънәсендә рәссам диярлек осталарыбыз юк...

Аннары ул безгә бу мәсьәләне юлга салырга күптән вакыт житкәнлеген әйтте. Художество техникумына быел керәсе татар яшьләре арасыннан бөтен көчләрен рәсем сәнгатенә багышлаган беренче карлыгачлар чыгарга тиешлеген аңлатты, бөтен көчебезне, барлык уй-ниятләребезне шул изге эшкә багышларга чакырды.

— Ният изге дә бит, техникумга керәсе бар әле,— диде Барый Дәминов,— сынау үтәсе бар.

— Әйе шул.

«Керә алырбыз микән?» дип икеләнүебезнең, үзебезчә, шактый житди сәбәбе бар иде. Дәминов бер көнне әлеге Яхшыбаевны очраткан, теге Стәрлетамактан киткән художникны. Ул да Казанга килеп укырга кермәкче булган икән. Ләкин сынау имтиханнарын үтә алмаган. «Анда бик каты таләпләр куялар»,— дип аңлаткан Яхшыбаев.

Яхшыбаев чаклы Яхшыбаевны алмагач — Стәрлетамакта даны чыккан художникны!.. Безгә ни сан?..

Ләкин бу турыда бирәдә әйтергә ашыкмадык, бары көрсенеп кенә куйдык.

— Әйе, сынау үтәсе бар шул әле.

— Бер дә курыкмагыз,— диде безгә укытучыбыз буласы кеше.— Ниятегез нык булса, кире борып жибәрмәбез. Стипендия вәгъдә итәләр. Торак мәсьәләсе дә хәл кылыныр.

Бер күрүдән безне үзенә гашыйк иткән бу кеше — хәзерге көндә даны бөтен илгә билгеле булган зур рәссамыбыз Бакый ага Урманче иде.

Ул вакытта мин аны бары шул елны укуын тәмамлап Мәскәүдән Казанга кайткан яшь рәссам булуын гына беләм һәм, әле өйләнмәгән егет чагы булса да, карап торуга житди, үзенә карата һәркемдә ихтирам хисе уята торган могтәбәр кеше икәнлеген генә күрә идем. Әмма кече яшеннән үк бөтен рухи көчен сынлы сәнгатькә багышлаганлыгы һәм, бу дәрәжәгә күтәрелү өчен, аңа нинди юллар үтәргә туры килгәнлеге турында хәбәрем юк иде. Шулай ук бу әле аның гүзәллек дөньясына керү юлындагы беренче адымнары гына булуы, алда аның шактый сикәлтәле юллар узасы, сынлы сәнгатебезнең нигезен ташкыл итәрлек бик күп картиналар, скульптура әсәрләре иҗат итәсе барлыгы турында да уйламый идем. Тора-бара белергә насыйп булды: аның тормыш юлы да иҗаты кебек бай һәм катлаулы булып чыкты.

Ул 1897 нче елның 23 нче февралендә Буа янындагы Күл Черкене авылында дөньяга килә. Аңа Габделбакый дип исем кушалар. Гадәттәгечә, «габдел»е әлбәттә, метрикада гына сакланачак. Башлангыч белемне ул әтисеннән ала. Мәдрәсәдән имам-мөгаллим исеме белән чыккан Идрис хәлфә заманына күрә хөр фикерле укытучы була: газета-журналлар яздыра, китаплар ала. Кечкенә Бакыйның рәсем белән мавыгуына, аның балчыктан төрле җәнлек һәм кеше сыннары әвәләп уйнавына сүз әйтми. Ун яше тулганда, булачак рәссамны Казанга — Мөхәммәдия мәдрәсәсенә китереп тапшыралар. Өендә үк китап-журналлар күреп үскән булу өстенә, Мөхәммәдия биргән белем дә аның дөньяга карашын киңәйтә. Ул инде мәдрәсә белән генә канәгатьләнми башлый. Аның русча укыйсы, күбрәк дөнья белеме аласы килә. Һаман рәссам булу турында хыяллана. Хәтта бер көнне, шәриге Әхәт Багда-

нов белән, ул вакытта императорская дип аталган рәсем мәктәбенә бара. Аларга уку йортына керү шартлары язылган кәгазь тоттырып чыгаралар. Танышалар. Бөтен шартларына риза, тик менә бер пункты?.. Закон божийдан имтихан бирергә кирәк. Юк, бусы булмый. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тәрбияләнгән яшьләрне иманнарына зарар килү куркыта.

Шулай да егет үз уеннан чигенми. Игъдадиянын[1] икенче сыйныфыннан мәдрәсәне ташлап, русча укыр өчен акча рәтләү чарасына керешә. Өйдән өмет итәргә урын юк: күп балалы семьядан бер тиен дә артырлык түгел. Бакый Уралга китә. Металл заводына керә. Көненә унике сәгать кара эш. Ниндидер теләге белән исәпләшмәүләреннән ризасызлык күрсәтеп, штрафка эләгә. Тайгага — урман эшенә китә, черкиләр дөньясына. Акча эшләү урынына малярия ияртеп, авылына кире кайта. Аннары Тамбов губернасындагы Тархан авылында укытучы булып эшли. Ниһаять, беркадәр акча рәтләп алгач, Тәтешкә бара, бер мөгаллимә яллап, хосусый рәвештә русча укый башлый. Ул вакытта инде егетнең каралыр вакыты якынлаша. Шахтерларны солдатка алмыйлар икән дигәч, Донбасска юл тота Бакый. Аңа шахта тормышының нәрсә икәнлеген күреп кенә түгел, үз җилкәсендә татып белергә туры килә. Язын, туган якларын сагынып, авылына кайта. Нәкъ шул вакытта аны солдатка алалар...

Февраль революциясеннән соң булган үзгәрешләр вакытында җаен табып, Казан ягына кайта. Аны мәгариф эшенә җибәрәләр. Сембер, Тәтеш, Казан, Мәскәүгә эвакуация, тагын Казан... Яңа мәктәпләргә укытучылар хәзерләү өчен ачылган махсус курслар...

Шул курсларда укып йөргән чагында Бакый, ниһаять, гомер буе хыял иткән төп теләгенә ирешә: Казанның рәсем мәктәбенә дә керә. Хәзер инде Архумас дип аталган бу уку йортының мәһабәт ишекләрен тутырып ачып, хаклы рәвештә аның түренә узучы татарлардан беренче кеше ул була. Рәсемгә булган сүрелмәс мәхәббәте егеткә бер үк вакытта ике мәктәптә уку өстенә, укытучылык эше дә алып барырга, ягъни һәр көнне җәяүләп Яңа бистә мәктәбенә йөгерергә, аннан шәһәрнең бөтенләй икенче читенә — Грузинскийдагы Архумаска чабарга, аннан педкурсларга өлгерергә дәрт һәм көч бирә.

1919 нчы ел. Илнең авыр көннәр кичергән чагы. Казанга Колчак якынлашып килә. Мәгариф комиссариаты белән бергә эвакуация.

Бакыйны кире Казанга — Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясенә чакыралар. Редакциядә эшләү белән бергә Архумаста уку яңадан дәвам итә. Егерменче елда ул Хәрби Коллегия политбүлегендә Шамил Усманов кул астында художество секциясенең мөдире булып эшли.

Шул ук елның ахырында, Мөселман Хәрби Коллегиясе үзгәртелгәч, аның кешеләрен дә Мәскәүгә — Кызыл Армия политуправлениесының көнчыгыш бүлегенә күчерәләр. Бакый художество секциясе штабына керә һәм шуннан Вхутемаска гариза бирә. Тулысынча булмаса да, Казан мәктәбен үткән егетнең рәсемнәрен күрү белән, аны бер сүзсез кабул итәләр.

Мәскәүдә электән яшәп килгән сынлы сәнгать мәктәпләрен берләштерү нигезендә оештырылган сәнгать ВУЗы — Вхутемас беренче елларында бөтенләе белән диярлек формалистлар житәкчелегендә бара. Кубизм кирәкме, конструктивизм дисеңме, импрессионизммы... Нинди генә измнар юк анда!

Сынлы сәнгатьтә идеялелекне инкяр итү, реализмны кире кагу нигезендә барган бәхәсләр яшь Урманченың да колагына керә. Һәр кайсы үзләренчә яңалык, киләчәк яулаучы тенденцияләр аны уйландыра. Ләкин бу вакытта инде анда реализм нигезендә торучы рәссамнарны

[1] Игъдадия — мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү курслары.

оештырган мастерскойлар да шактый нык позиция яулап алган булалар. Өстәвенә Бакый, Казан мәктәбендә чагында ук, чын сәнгатьнең нинди икәнен күреп, чамалап өлгергән кеше. Күңелендә онытылмас эз калдырган Фешин полотноларын хәтерли. Николай Иванович Фешин — шул ук Казан мәктәбен бетергән, аннары Петербург академиясендә укыган һәм исеме дөнья күләмендә зур дан алган атаклы художник — ул елларда Казан мәктәбендә укыта иде. Аның дөнья игътибарын җәлеп иткән картиналары үзләренең яңалыклары, үзенчәлекләре белән, шул ук вакытта үлмәс классиклардан килгән реалистик традицияләрне дә инкяр итмәүләре, аларны үстерүләре, баетулары — чын мәгънәсендә тормышчан булулары белән характерлы.

Бер үк вакытта Мәскәүнең дөньякүләм әһәмияткә ия булган сәнгать җәүһәрләре белән тулы музейлары, галереялары Бакыйга иң кыйммәтле җан азыгы булалар, сәнгать дәреслеген аңлауда аның өчен мәктәп хезмәтен дә үтиләр.

Үтелгән катлаулы тормыш мәктәбенең дә ролен онытып булмый. Ләкин халык белән якыннан аралашу, тормышның ачысын-төчесен хезмәт кешеләре белән бергә тату булачак рәссамның дөньяга карашын, эстетик принципларын формалаштыруда, әлбәттә, уңай йогынты ясамый калмаганнардыр.

Укып йөргән чакларында ук Бакый Урманченың тагы бер өстенлеге шунда була: ул сынлы сәнгатьнең берничә төрен үзләштерергә омтыла. Нигездә, скульптура һәм живопись буенча уку йортын уңышлы тәмамлау белән бергә, графикадан, шулай ук сынлы сәнгатьнең гамәли төрләренә караган керамика, архитектурадан да шактый мәгълүмат алып, Казанга кайта. Алай гына да түгел, белемгә туймас Урманчебыз, Вхутемас белән бер үк вакытта Мәскәүнең шәрыкны өйрәнү институтында укып, фарсы теле буенча аның ике курсын бетереп чыга.

Рәссамның шулай күпкырлы оста булырга омтылуын культурабызның тарихи үзенчәлегенә дә бәйләнгән дип уйлыйм. Моңарчы күренгән барлы-юклы рәссамнарыбыздан аермалы буларак, үз халкының үткәнен-бүгенгесен дә, аның тарихыбызда прогрессив урын тоткан алдынгы шәхесләрен дә яхшы белүче Урманче үз язмышы турында гына уйламый, аңа, Тукай әйтмешли, «коеп куйган» рәссам булу гына җитми, аны сынлы сәнгать дөньябызның гомуми язмышы да борчый. Вхутемаста укыган чагында ук аның татар телендә «Балалар тәрбияләүдә сынлы сәнгать» (Мәскәү, 1924) дигән китап чыгару факты үзе генә дә моңа бик ачык ишарә. Минемчә ул, бу яңа һәм изге эшкә чынлап тотынган беренче кеше буларак, аңа татар сынлы сәнгатенең нигезен салучылар миссиясе йөкләнгәнлеген үзе дә тоя.

Казан художество техникумына кайтып, уку-укыту эшләре бүлеге мөдире сыйфатында эшли башлау белән ул иң элек шуны ачыклый: укытучылар арасында Беньков, Тимофеев кебек зур осталар бар. Төп укучылар җөмләсендә бер генә татар баласы да юк. Фәкать ирекле тыңлаучылар исемлегендә генә дүрт фамилия күзгә чалына: Мортаза Абдуллин, Зәки Мөхәммәтшин, Алмаев, Дәүләтшин. Ирекле тыңлаучылар? Теләсәләр киләләр дәрескә, теләмәсәләр — юк. Алардан имтихан да таләп ителми. Эшләренә караганда, араларында өметле пумалалар бар. Ни өчен алар төп укучылар җөмләсендә түгел?

Бакый аларның үзләрен күреп сөйләшә. Барсының да аңлатмасы бер: тамак туйдырырга, өс-башыбызны карарга кирәк. Квартирага да бушка кертмиләр. Эшләп табарга туры килә.

— Яхшы,— ди Урманче,— мин сезне төп укучылар рәтенә кертәм,— ди. Һәм имтихан урынына, һәркайсының чамасына карап, аларга конкрет заданиелар бирә.— Үтмәсәгез, үзегезгә ү[illegible].

Өчесе, бирелгән заданиены үтәп, техникумда к[illegible]. Ләкин болар

белән генә эш бетми бит әле. Бакый Кремльгә юнәлә. Мәгариф комиссариатында өлкән инспектор булып эшләүче Давыт Яналиев рәссамның теләк һәм ниятләрен бик яхшы аңлый һәм аңа кулыннан килгән кадәр булышырга вәгъдә итә. Һәм сүзендә тора. Вакытлыча булса да, торак мәсьәләсе хәл кылына. Тик аны лаеклы кешеләр белән тутыру мәсьәләсе читенрәк: рәсем мәктәбенә атап килүчеләр аз күренә.

— Табарбыз,— ди Яналиев,— борчылмагыз!..

Ул елларда Татарстанның үзеннән генә түгел, төрле чит өлкәләрдән дә бик күп татар яшьләре, укырга дип, Казанга киләләр иде. Күбесе нинди уку йортына керәселәрен дә белми. Шундыйлар белән сөйләшкәндә Яналиев һәр кайсыннан диярлек сорый:

— Рәсем ясарга яратасызмы?

Һәм сынлы сәнгатькә күңеле ятканрак яшьләргә Художество техникумын тәкъдим итә. Тулырак сөйләшү өчен исә, аларны Урманченың үзенә җибәрә...

Без Казанга техникум әнә шундый көннәр кичергән чакта килеп төшкәнбез икән. Кабул итү имтиханнары бирергә байтак вакыт бар иде әле. Берничә көн шәһәр белән танышып йөрдек. Иң башлап атаклы Кабан күленә төштек. Прокатка бер көймә алып, су өстенә чыгып киттек. Ниятебез күлнең аргы башына кадәр барып әйләнергә иде. Ләкин аргы Кабан белән бергә Кабанны аерып торган бугаз аша салынган күпергә дә барып җитә алмадык, күл өстенә мунча пары сыман юеш томан таралды. Юеш кенә түгел, ниндидер суларга биргесез авыр исле, майлы томан иде ул.

— Борылыйк, егетләр,— дидем,— исе бер дә җанга рәхәтлек бирә торган түгел.

— Миңа да ошамый бу Кабан исе,— диде Мөкаддәс.— Борылыйк.

Ләкин Дәминнең ул кадәр исе китмәде.

— Ни булган? — диде.— Әйдә, бер чыккач, аргы Кабанын да күреп кайтыйк.

— Тын алырга авыр бит.

— Ничава, ияләшербез. Нинди генә искә күнекми адәм баласы!

Әйе шул, алай бик тиз сынатырга ярамас, түзим. Түздем. Ләкин ияләштем дип әйтә алмыйм. Кабан күленнән соң без бакчалар белән танышып йөрдек. Пароходта килгән чакта ук берәүдән «Казанда ике ятажлы бакча бар» дигәнне ишеткәч, бик гаҗәпләнгән идек. Ленин бакчасын әйтүе булган икән. Аның, без уйлаганча, аслы-өсле итеп ясалган түгел, ә бер өлеше түбәндә, икенче бүлеге тау өстендә урнашкан бер бакча икәнен күргәч, аңладык — гаҗәпләнергә урын юк икән.

Болай бик матур булса да, безнең өчен артык чиста һәм тәртипле бакча иде ул. Анда күбесенчә яхшы-яхшы киенешкән әдәпле, могтәбәр кешеләр йөри, өстәвенә югарыгы өлешенә, ягъни Ленин һәйкәле янына күтәрелү өчен, кайвакыт билет алырга да кирәк була — чөнки анда кино-театр да бар. Черек күл урамы аша (хәзерге Опера һәм балет театры бинасы урынында) тагы бер бакча күрдек. Аның төньяк-көнбатыш почмагында бик мәһабәт итеп бакырдан коелган Державин һәйкәле тора, һәм татарлар аны Бакыр-бабай бакчасы дип йөриләр иде. Шунда ияләшеп киттек. Казан кешеләренең әйтүенә караганда, элек бу бакчаның ишегенә «Собакам и татарам вход воспрещен» дигән язу кадакланган булган ди. Хәзер анда кичләрен яшьләр җыела: ул вакыттагы модага туры китереп, егетләр дә, кызлары да күк блуза кигән укучылар, үзләрен һәр кайда хуҗа итеп тоючы эшче яшьләр, өр-яңа гимнастеркаларын киеп чыккан хәрби курсантлар, бармак күрсәткәнгә дә сыннары катып көлүче асрау кызлар үзара бик тиз танышып китәләр, төн уртасына кадәр диярлек шунда теләгәнчә күңел ачалар иде.

Зур исәпләнмәсә дә, агач-әрәмәләргә бай, үзенә күрә тын, аулак урыннары да житәрлек булган, саф һавалы, күңелле бакча иде ул. Ә бер кичне, күтәренке кәефемне бозып, борыныма әлеге авыр ис килеп керде. Кабан исе генә түгел, димәк, Казан исе!

Соңыннан ишетүемчә, сабын заводыннанмы, мех фабрикасыннанмы чыгып, вакыт-вакыт бөтен шәһәргә тарала торган ул ис — иске Казан исе — бәхеткә каршы елдан елга кими-азая барды. Әмма бөтенләй юкка чыкты дип әйтә алмыйм. Хәтта хәзерге көндә дә, инде ярты гасырдан артык вакыт узгач та, үзен сиздерми тора-тора да, тәмам оныттылып бетте дигәндә борынга килеп кереп, сикәлтәле яшьлек елларын искә төшереп куйгалый.

Билгеле, безгә гамьсез «гүләйт итеп» кенә йөрергә туры килмәде. Хәтта печән базарына да без, Казанның атаклы урынын күрер өчен дип түгел, азрак түләүле ашханә эзләп бардык. Дөрес, кибетләрдә, базарларда ашау-эчү әйберләре. Рестораннары турында уйлаган да юк, гади ашханәләрдә дә өч төрле обед. Иң шәбе житмеш биш тиен тора, кайтышырагы — илле, иң арзанлысы — егерме биш тиенлек. Әмма безнең хәлдәге кешегә анысына акча житкерү мөмкин түгел. Печән базарында бик арзанга ашап була, диделәр.

Киттек шунда. Казан матбугатында күптән яман аты чыккан мәшһүр печән базарының нинди икәнен күрергә дә кирәк бит! Күрдек билгеле. Тукай заманындагы кебек үк мөселман оясы түгел иде инде ул. Шулай да бик күп атрибутлары сакланган иде әле. Минем өчен көтелмәгәне шул булды: печән базары дип даны чыккан бу «толчокта» җанына ни кирәк — бары да бар, тик печән генә юк иде...

Аеруча хәтеремдә калганы: анда чынлап та бик җүн бәягә ашаталар. «Обжорный рәт» дип йөртелгән почмакта тезелеп торган кечкенә-кечкенә агач хәрчәүнәләрнең кайсына керсәң дә ун тиенгә туйганчы шулпа эчәргә, туйганчы ботка бүсәргә була иде. Ун тиен зур акча түгел. Ләкин аны да табарга кирәк бит. Өйдән алып чыккан запасыбыз бетте. Кара көнгә дип, бишмәт чабуына тегелгән бер червонецым бар барын. Ләкин мин аны барга санамыйм. Аңа иң актык чиккә житкән суратта гена кагылырга мөмкин — бер кайдан бер тиен табарга чара калмаганда гына. Ә безнең хәл андый ук түгел әле.

Мәгариф комиссариатында уку йортларына кабул итү имтиханнарын көтеп ятучы яшьләргә вакытлыча ярдәм күрсәтү чарасы бар икән, шуны белеп алдык. Йөгердек Кремльгә.

— Яналиевка мөрәҗәгать итегез,— диделәр.

Безнең кебекләр хәтсез булып чыкты. Яналиевка тын алырга да ирек юк. Өстәле янында утырса, өстәлен урап алабыз, коридорга чыкса — үзен.

— Ашарыбызга юк!
— Торыр урын кирәк.
— Кая барыйк?

Давыт Яналиев, хәтеремдә калганча, какча гына гәүдәле, ачык чырайлы мөлаем кеше иде. Аны чолгап алган йөзләп яшь-җилкенчәк арасында төрле кешеләр бар. Берәүләре, үзләрен кызгандырырга теләп, ялына-ялвара. Икенче берәүләр исә, ачуланып, эш хакын даулагандай, тавышларын күтәреп таптыралар. Инспекторны бюрократлыкта гаепләп, янап сөйләшүчеләр дә юк түгел. Ә Яналиев берәүгә дә ачуланмый. Акча сораучыларның күплегенә шатлангандай, көлеп-елмаеп кына сөйләшә.

Сорап килүчеләрнең барысын да канәгатьләндерә алгандырмы-юкмы, мәгәр безгә ярдәме тиде. Безнең художество техникумына кил-

гәнлегебезне белгәч, ул хәтта аеруча игътибар иткән кебек тоелды. Бәлки чынлап та шулай булгандыр. Урманче белән сөйләшүләренең ярдәме тигәндер. Һәр кайсыбызга икешәр сум акча бирдертте.

Шуның белән без кабул итү имтиханнары көненә килеп җиттек. Имтихан дигәнебез: парталар урынына мольбертлар куеп эшләнгән махсус мастерскойга кертеп, гипстан ясалган хайван сыннарын, геометрик шәкелләр төшерергә куштылар. Хәтерем ялгыштырмаса, ирекле темага да нәрсәдер ясадык шикелле. Мине гаҗәпләндергәне шул булды — һәр рәсемне ясау өчен ике көнме, өч көнме, һәрхәлдә бик озак вакыт бирделәр. Минем аларны, бер дә ашыкмый эшләсәм дә, күп дигәндә бер сәгать эчендә тәмамлап, буш калган вакытны нишләтергә белми аптырап йөрүем хәтеремдә. Кайбер рус малайларының көннәр буе мольбертлары яныннан китмичә, һаман шул бер рәсем өстендә казынулары, хәтта бирелгән вакыт беткәндә дә эшләрен тәмамлап өлгерә алмаган булулары сәер иде миңа. Янәсе, шул кадәр азаплана торган булгач, нигә бу мәктәпкә кызыктылар икән алар?

Техникумга алыну белән безгә торак та табылды. Торак дигәнебез Касаткин белән Бассейнная урамнары чатындагы ике катлы таш йортның өске катында кола ялан бер бүлмә иде. Стеналары патша заманыннан бирле агартылмаган, идәннәре дә тузган булу өстенә, бернинди җиһаз заты юк иде анда: нә карават, нә урындык, нә өстәл...

Ул елларда без ерак юлга чыккан чакларда сандык яки чумадан янына мендәр, юрган кебек әйберләрне дә, кирәгү ихтималы булган кышкы киемнәребезне дә үзебез белән алып йөри идек. Әз генә дә аптырап калмадык. Сандыгыбыз булганнар — сандыкларны, капчыклылар — капчыкларыбызны стена буена салып куйдык та — шул турыдагы как идән ятагыбыз булды.

Стипендия мәсьәләсе хәл ителмәгән иде әле. Акча сорап тагы Яналиевка барырга әрсезлегебез җитмәде, укулар башланганчы дип, нинди дә булса эш эзләргә керештек. Бәхетебезгә каршы, техникум бинасының үзендә үк ремонт бара иде, шунда ялланып, өченче кат чардагына носилка белән балчык ташыдык. Көннеке көнгә килеп торган акчасы ашханәдә тукланып чыгарга гына түгел, үзебезчә «фарчит» итеп, кичләрен берәр кружка сыра эчеп кайтырга да җитә иде.

Укулар башлангач, безне Касаткин урамындагы торактан техникум бинасының подвалына күчерделәр. Монда инде, үзенә күрә ятак урыннары, ягъни тимердән ясалган такта түпле тар карават яки гади топчан кебекләре дә бар, алар өстенә барлы-юклы гына постель кирәк-яраклары да җәелгән иде. Бернична табуретка белән зур гына өстәле дә булгач, тегендәге шәрә бүлмәдән соң бу торак безгә бик әйбәт булып күренде. Дөрес, тәрәзәләре кечкенә һәм алар да түшәм янында гына булганлыктан, яктылык җитәрлек түгел иде анда. Ләкин түшәмендә, абажурсыз гына булса да, электр лампасы янып тора, тагы ни кирәк?

Тагынмы? Тагы җылылык кирәк булган икән. Көннәр салкыная башлагач игътибар иттек: торагыбыз бөтенләй ягылмый торган булып чыкты. Гади миче дә, пар батареялары да юк. Монысына да артык хафаланырга туры килмәде, кечкенә тимер мич кертеп куйдылар. Ягып җибәрү белән минут эчендә җылына башлый, озын булып, урта бер җиреннән кәкрәеп, тәрәзәгә барып тоташкан морҗасына кадәр кыза. Тик ягулык мәсьәләсе читенрәк иде. Махсус хәзерләп куелган бернинди утын юк. Тегендә-монда аунап яткан агач-ботакларны ягып бетерүгә, ишек алдыбызның нәкъ уртасында бер люк таптык. Ачып карасак — җир астына зур чан төшереп куелган икән. Төбендә — мазут. Чиләк тутырып, мич янына кертеп куябыз да, үзе генә яна алмый яткан тумрау өстенә сибәбез. Чатырдап кабына. Мазут янып бетә, тумрау кала. Тагы сибәбез. Шулай итеп, ике-өч чи тумрау әллә тагы кыш буена җиткәндер.

Бу торакта яши башлаганда без, техникумга шул көзне килгән укучылар, бер-беребез белән танышып, шактый үзләшеп беткән идек инде. Татарлар да, руслар да житәрлек. Үзара бик тату һәм шат яшәдек. Бүгенге күзлектән караганда коточкыч булып күренгән хәлләр дә кызык һәм көлке генә иде безгә. Кичләрен ятарга ашыкмыйбыз, үзара кызык сүзләр сөйләшеп утырабыз. Мичне өзлексез ягып тормасак та, аңа бөтенләй суынырга ирек бирелми: пыскып яткан тумрауны мазут сибеп гөрләтеп жибәрергә иренүче юк. Иң соңга калып ятучы кеше мичне ныгытып кыздырырга, аны озаккарак житәрлек ут белән дөрләтеп ятырга тиеш. Тиеш. Һәм ул шулай эшли дә. Тик, ничек кенә тырышмасын, барыбер аны иртәнгә кадәр житәрлек итеп жылыта алмый. Мазут янып бетүгә мич сүнә, бүлмә суына. Рәхәтләнеп, жәелеп йоклап киткән егетләр аяк-кулларын жыеп, бөрешә башлыйлар, йомарланып яткан кыр куяны кебек кенә булып калалар. Ләкин минут саен көчәя барган суыктан бөрешеп кенә дә, барлы-юклы юрган кебегеңне тартыбрак ябыну белән генә дә котыла алмыйсың. Аркаң туңа. Аякларың өши. Аның белән генә калмый, рәхимсез суык куеныңа керә. Әйтерсең, йөрәгеңә үтеп, эчтән калтырата башлый. Шулай да яшь йокы тиз генә бирешергә теләми, уянмыйсың. Уянсаң да сикереп торасы килми. Менә шунда ныклыгың сынала инде. Салкынга чыдар әмәле калмаган кеше, калтырана-калтырана торып, мичне ягып жибәрергә мәжбүр була...

Иртән торуга тагы суынып өлгергән мичне яңадан тергезеп жибәрергә иренмибез инде. Шаярган булып, бер-береңне барлау башлана:

— Нихәл, Барый, катмадыңмы?

— Шәп! — ди Барый. — Бер матур кыз керде төшемә, шуның куенында жылынып яттым.

— Мөхәммәтша ни хәлдә? Исәнме?

— Үзем исән, мендәрем стенага ябышып туңган.

— Ә Комаров?

— Аңа ни булсын, чыныккан егет.

— Мансур нишли, Мансур?

Мансуров юрган астыннан көлеп кенә жавап бирә:

— Тизрәк ягыгыз, юрган асты жәннәтеннән чыгар хәлем юк.

Урал ягыннан килгән бу егетнең чынлап та жылы одеалы бар иде. Рәсемгә үзлегеннән генә өйрәнгән булса да, кулы шактый шомарган, хәтта «Шәпи агай» журналында карикатураларын бастырып, гонорар тәмен татырга да өлгергән кешә. Техникумга килгәч тә редакцияләр белән элемтә тоту тәжрибәсен ташлыйсы килмәде. «Чаян»нан яки башка редакцияләрдән заказлар алып кайтып, шуларны безнең алда кара тушь белән ясап утыра.

Кара тушьның нинди көчкә ия булганлыгын шунда белдем. Тушь белән ясасаң, алама гына рәсем дә чем-кара булып, нәкъ ташка баскан шикелле матур булып күренә икән. Ватман кәгазенә төшерсәң — бигрәк тә. Карыйбыз, Мансуров рәсемнәренең дә безнең кебекләр ясаганнан арткан жирләре юк. Шулай да басылып чыгалар. Ә басылып чыккан рәсемне инде, минем ул көннәрдәге караш буенча фикер йөрткәндә, бернигә яраксыз дип булмый. Андый булса, басмаслар иде, яңа заказлар да бирмәсләр иде.

Бер көнне шулай, «Авыл яшьләре» редакциясеннән яңа заказ биреп жибәргәннәр. Ә мин ул журналның чыкканын дүрт күз белән көтеп йөрим. Чөнки Такташ кулына тоттырып калдырган хикәямнең язмышы турында кызыксынган саен, «Басылыр, басылыр» дип, мине һаман өметләндереп киләләр. Хәзер ул редакциядә Такташ күренми дә. Ничә барсаң, Исхак Хәйруллин дигән шагыйрь утыра. Кечкенә буйлы булса да, бик житди кеше. Журналның даими секретаре шул, диләр. Такташ анда, минем бәхеткә каршыдыр инде, жәйге ял айларында гына эшләп торган булса кирәк. Аны ярар, Хәйруллин да игътибарлы кеше

күренә. Тик журналлары бик озак-әкрен чыга. Август саны сентябрьнең азакларында гына күзгә күренде. Ә хәзер әнә тышта кыш. Ноябрь азаклары житеп килә, октябрь саны һаман юк әле. Кызык, кайсы өчен рәсем ясарга заказ бирделәр икән? Нинди рәсемнәр?

— Авыл уку өен ясарга куштылар, — диде Мансуров, — яхшы уку залы менә шушындый булырга тиеш диярлек булсын. Журналның тышына басарга. Кайсы номергадыр, тагын бер хикәягә иллюстрация кирәк.

— Нинди хикәя?

— «Дуслар һәм дошманнар» дип атала.

Күңелемә: «Әллә минем хикәяне басарга жыеналар микән?»— дигән уй килгән иде дә, «Дуслар һәм дошманнар» дигәч, эчтән генә үз-үземне мыскыл итеп, битәрләп куйдым. Синекеннән башка хикәя беткән иде ди анда. Әзерләгән, тот капчыгыңны... Лутче рәсем ясавыңны бел әнә Мансуров кебек!

Мансуровтан күрмәкче вакытлы матбугат өчен рәсем ясау белән мәшгыльчылар күбәя башлаган иде дә, бу эшне гаепкә санаучылар табылды. Тәҗрибәлерәк укучылар Мансуров рәсемнәреннән көләләр генә, аларны наданлык үрнәге саныйлар иде.

«Халтура» дигән сүзне мин башлап шул көннәрдә ишеттем. Белербелмәс көенә, акча эшләүгә кызыгып, заказ буенча теләсә нинди рәсем ясап йөрү чын рәссам эше түгел, имеш. Халтура белән шөгыльләнү — чын сәнгатькә хыянәт. Рәссам булырга теләгән кешенең үзе өчен — һәлакәт.

Яхшыбаевның үз трагедиясе шунда булган икән. Бу турыда Мортазадан белдек. Моңарчы ирекле тыңлаучы булып йөргән әлеге дүрт кешенең берсе шул — Мортаза Абдуллин булып чыкты. Стәрлетамакта безнең белән бергә укыган егет. Бер-беребезне электән белсәк тә, ул интернат малае булмаганлыктан, танышлыгыбыз дуслык дәрәҗәсенә үк барып житмәгән иде. Баксаң, Стәрлетамактан Казандагы рәсем мәктәбенә башлап юл салучыбыз шул булган икән.

Казанда бер уку йортында очрашу безне шактый якынайтты. Техникумдагы хәлләр, андагы традицияләр, тенденцияләр турында сөйләде ул безгә, күренеклерәк укучылар һәм күп кенә яңалыклар белән таныштырды. Яхшыбаев чынлап та Казанга Мортазага кадәр үк килгән булган икән. Сынлы сәнгать буенча тәҗрибәле педагоглар аның художник буларак профессиональ яктан житлекмәгән килеш, һәвәскәр-һөнәрче хәлендә формалашканлыгын күргәннәр. Үзен теләсә нинди заказны үти алырлык оста художникка санарга гадәтләнгән, өстәвенә тәхилшәрап белән дә дуслашып өлгергән Яхшыбаевның моны аңлыйсы килмәгән. Һөнәрен кабат әлифбадан башларга теләмәгән.

Мортаза үзе исә, безнең уебызча, яшьтән үк сынлы сәнгатьне изге итеп таныган һәм, башка бернигә карамый, рухына тәңгәл килгән шул һөнәрне нәкъ вакытында сайлый белгән бәхетле кеше. Безнең белән очрашканда ул төп укучылар исемлегенә күчкән, техникумның икенче курсында укый иде инде. Ләкин ул монда да безнең белән бер торакта булмады — квартирада яшәгәндер ахрысы. Бездән аермалы буларак бай, купшы киенә, хәтта аны бизәнеп йөри дип тә әйтәләр иде. Булса да булгандыр, йөзе һәрвакыт саф, матур булыр иде аның. Әмма ул безгә пижон булып күренмәде. Аның шулай пөхтә йөрүе, күрәсең, сынлы сәнгатькә хөрмәт белән каравыннан, тышкы кыяфәте һәм йөреш-торышы белән дә үзен шул нәфис һөнәргә лаеклы тотарга тырышуыннан килгәндер. Шундый булуы белән ул үз шәхесенә карата да кешеләрдә ихтирам хисе уяткандыр бәлки.

Техникумны уңышлы тәмамлап чыккач, Мортаза, декорацияләр остасы буларак, Татар Дәүләт академия театрында эшләде. Театр дигәч, тагын бер шәригыбыз — Сутюшев хәтергә килде. Бусы инде безнең

белән бергә имтихан тотып кергән, безнең белән бергә шушы салкын подвалда кыш чыккан егет. Иң башлап исеме сәер тоелды аның ми…

— Мәэ-мүн? Кызык. Каян тапканнар мондый исемне!

— Ә ул исем түгел.

— Ничек инде исем түгел?

— Шундый хикмәтле сүз.

Чынлап та бу исемнең үзенә күрә тарихы бар икән. Мәэмүннең беренче абыйсы Хәсән дә, икенчесе — Хөсәен дә сабый килеш вафат булганнар. Әченче малае дөньяга килгәч, әтиләре муллага барган. Бу улым да үлмәгәе дип куркам, аны яшәтер өчен нишлим икән?» — дип киңәш сораган. Мулла, үзенең яшел тышлы китабын актара-актара, озак кына уйланып утыргач, әйткән: «Улыңа Мәэмүн куш», — дигән.

— Ни дигән сүз соң ул?

— Бернинди авырлыкка да, үлемгә дә бирешми торган кеше! — диде яна танышыбыз һәм, ап-ак тешләрен күрсәтеп, көлеп куйды. Сабыйларча саф, гөнаһсыз егет! Шунда мин бу егетнең матурлыгына игътибар иттем. Матур гына түгел, ягымлы. Һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән диярлек, аның башкаларга карата ихтирамлы, саф күңелле кеше икәнлеге сизелеп тора. Андый кеше белән дус буласы, аның турында күбрәк беләсе килә. Тора-бара белдек тә.

Сутюшев Петропавловскидан килгән булып чыкты. Миңа яшьтәш диярлек икән. Гали исемле хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килгән. Әтисе ягыннан туган абыйсы — Кәрим Сутюшев күренекле революционер булган. Мәэмүн әти-әнисе тәрбиясендә, ике апасы канат астында иркәләнеп үскән. Бер вакыт аны апалары театрга алып барганнар. Һәвәскәрләр куйган спектакльдә апасының иптәш кызы да катнаша икән. Пьеса буенча бу кызны җәберләгәннәр күрәсең, сабый моны чынга алган, таныш апаны яклап, кычкырып җибәргән.

— Тимәгез!..

Апалары аңа театрның нәрсә икәнен аңлатып биргәннәр. Шуннан ук Мәэмүн театр белән кызыксынып калган. Төрле катыргылардан, китап тышларыннан сәхнә корып уйный, рәсем-декорацияләр ясый торган булган. Җидене бетереп, Казанга җыенгач, аңа «менә шушы кешегә мөрәҗәгать итәрсең» дип, Кәрим Тинчуринның адресын биргәннәр. Үзенең рәсем төшерергә яратуын һәм театрда эшлисе килүен әйткәч, атаклы драматург, записка тоттырып, яшь Сутюшевны театрга җибәрә. Ул елларда Татар театрының декораторы булып Казанның иң зур художнигы Беньков эшли иде. Аңа ярдәмче кирәк булмый да, Мәэмүн художество техникумына заявление бирә. Анда керә алмасам дип, бер үк вакытта театр техникумына да биреп куя.

Һәм әнә ул безнең белән бер подвалда. Сынлы сәнгатьне яратып, күңел биреп укый, нәкыш белән генә канәгатьләнмичә, Урманче кул астындагы керамика мастерскоенда да сабаклар алып, утызынчы елны техникумны тәмамлый. Аннары хәрби хезмәт. Ниһаять, ул художник Әсгат Мәҗит җитәкчелегендәге эшче яшьләр театрында эшли.

Заманында яналык сөюче булып танылган үзенчәлекле режиссер Сөләйман Вәлиев (Сульва) утыз сигезенче елда Сутюшевны Татар академия театрына чакырып, аңа «Матур туганда» спектаклен бизәүне тапшыра. Художник бу җаваплы заказны илһамланып башкарып чыга. Эшен яратылар һәм аңа бөтенләйгә шушы театрда калырга тәкъдим итәләр. Кызыктыра төшү өчен булса кирәк, «эш хакың җиде йөз илле сум булыр» дип тә өстиләр. Сутюшев бу тәкъдимне үзе өчен дәрәҗә күреп, шатланып кабул итә. Тик...

— Нәрсәсе тик?

— Тик миңа хезмәт хакы гына...

— Азсынасыңмы?! — ди Сульва гаҗәпләнеп. — Мәҗит театрында күпме түлиләр соң сиңа?

— Што сез!— ди Сутюшев ашыгып.— Хәзергә биш йөз дә житеп торыр дим. Берәр ел эшләп күрсәтим. Аклый алсам, анда карарсыз.

Аңардан кычкырып көләләр генә. Ләкин Сутюшевның кеше күңелен сихерли торган тылсымлы көче шунда икәне турында уйламыйлар. Шундый табигый тыйнаклыгы белән хезмәттәшләре, иптәшләре каршында ни кадәр мәхәббәт казануы турында художник үзе дә уйламый.

Сутюшев тыйнак кына түгел, таләпчән дә. Кирәк чагында, дөреслек, гаделлек өчен кырыс та була белә. Ватан сугышы елларында ул, яраткан хезмәтеннән аерылып, фронтка китәргә тиеш була. Мәскәү янында аңа артдивизион тупларга боералар. Ләкин бу җаваплы эш өчен аңа җибәрелгән солдатларның яртысыннан күбе артиллерияны белми торган егетләр булып чыга. Сутюшев аларны яратмыйча кире борып җибәрә. Хезмәттәш иптәшләре аның бу эшен күреп гаҗәпләнәләр.

— Нишлисең син, беркатлы юләр,— диләр.— Фронтта икәнеңне оныттыңмы әллә? Сугыш вакыты! Командованиегә буйсынмыйча, трибуналга эләгәсең киләме?

— Артиллерияне белмәгән кешеләрдән дивизион төзесәм? — ди Сутюшев.— Сугышта подводить итсәм, жинаять түгелме?

Мәсьәлә Үзәк Комитет вәкиленә барып житә, Мәэмүннең таләбен урынлы табып, канәгатьләндерәләр...

Чынлап та егет «Мәэмүн» исемен юкка гына күтәреп йөрми икән: ил иң авыр көннәр кичергәндә, сугыш кырында партия сафына кереп, граждайлык бурычын намус белән үтәп, коточкыч җәһәннәмнәр эченнән исән чыга. Дөрес, аягы яралана, ләкин бу аңа сөйгән театрына кайтып, тагы күп еллар буена яраткан эшен дәвам иттерергә комачаулый алмый.

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның халык художнигы Мәэмүн Сутюшевның исемен ишетсәм дә, үзен очратсам да, аның салкын, караңгы подвал шартларында ап-ак тешләрен күрсәтеп, кайнар елмайган чагы күз алдыма килә.

Ә бит ул подвалның шундый самими егетләрне харап итә язып калган чаклары да булды. Әнә Мөхәммәтша! Әлеге, мендәре стенага ябышып туңган егет, Сверловскидан, балалар йортында үсеп, шунда жидееллыкны бетереп килгән малай. Туберкулез белән авырый башлады.

Мәэмүн шикелле үк тыйнаклыгы, башкаларга карата ихтирамлы, олы җанлы булуы белән күңелләрне үзенә караткан егетнең мондый аянычлы хәлгә төшүе барыбызны да тирән борчуга салды. Бердән үзе кызганыч, икенчедән, мондый шартларда башкаларыбызның да шул хәлгә калу ихтималы куркыныч иде.

Шулай да, яшьлегебез юл куймагандыр күрәсең, беребез дә өметсезлеккә бирелмәде. Хәтта озакламый Мөхәммәтшаның хәленә кызыга башладык. Күрәбез: авызыбыздан сулар китерерлек итеп, күпереп торган калачка менә дигән ак май ягып ашый Мөхәммәтша, сөт эчә, колбаса сыптыра, күкәй... Ул көннәрдә безнең төшкә дә керми торган кадерле сыйлар. Авыруы билгеле булгач, врачлар аңа дару урынына яхшы ашамлык бирергә язганнар икән. Бөтенләй түләүсез. Биш сумлык күләмдә. Биш сум! Ә бит ул вакытта безнең айлык стипендиябезнең бары жиде сум иде.

Шулай итеп, оптимистлык янына диспансердан бирелгән махсус паек та килеп кушылгач, Мөхәммәтшабыз хәтәр чирне тәки җиңеп чыкты бит. Техникумны уңышлы тәмамлаганнан соң, ул Казан музееның сәнгать бүлегендә эшли. Графика һәм керамика буенча халыкара күргәзмәләрдә катнашырлык әсәрләр иҗат итү белән бергә, музейларда, галереяларда тупланган сынлы сәнгать әсәрләрен, кыйммәтле нәкыш шедеврларын, скульптура һәм керамика җәүһәрләрен рәхимсез вакыт һөҗүменнән саклау, бозыла башлаганнарын яңарту —

элекке хәлләренә кайтару остасы булып китә. Бу катлаулы һөнәр буенча белемен арттыра барып, Мәскәүгә күтәрелә. Дәүләт керамика музеенда эшли, графика, керамика әсәрләре белән халыкара күргәзмәләрдә катнаша. Париж, Филадельфия... Даны дөньяга таралган Третьяков галлереясында, аннары Революция музеенда хезмәт итә. Кыскасы: Уралдан килгән чирләшкә генә татар малае Мөхәммәтша Зариф улы Кәримов союз күләмендәге реставраторларның, консервация осталарының берсе булып үсә.

Шул ук подвалдан күтәрелеп чыккан художник-график Шакир Мөхәммәтҗанов, Гата Юсупов, Госман Мусиннар, соңгы елларын Госзнак басмаханәсендә эшләгән художник-полиграфист Барый Дәминов, мәктәпләрдә балаларга күп еллар рәсем дәресе укыткан педагог-рәссам Зәки Мөхәммәтшин кебекләр... Талант дәрәҗәләре төрле, ләкин бары да татар сынлы сәнгать дөньясына беренче булып аяк басучылар җөмләсенә кергән профессионал рәсем осталары. Һәр кайсы үз урынында игътибарга лаек шәхес булу белән бергә, минем карамакта алар шул ук Бакый Урманченың әдәби портретын тулыландырырга хезмәт итүче әһәмиятле штрихлар да. Барысы да аның шәкертләре бит. Аларның әле мин белмәгәннәре, ягъни, миңа болай яшьтән таныш булмаганнары күпмедер?!.

Подвалда кыш чыккан укучылар арасында башка уку йортларына үтә алмаганга гына килеп кергән кешеләр дә бар иде. Андыйлар, әлбәттә, икенче елга калмады.

Ә соң Мирсәяф?

Үземне бу уку йорты өчен очраклы кешеләр җөмләсенә кертә алмыйм. Начар укучы да исәпләнми идем. Әдәбиятка, язу эшенә булган мәхәббәтем арага керде. Әдәбият, язучылар, журналистлар дөньясы күбрәк кызыксындырды мине. Вакытлы матбугат битләрендә чыккан һәр исем — минем өчен әһәмияткә лаек шәхес, андыйларның үзләрен күрү — бәхет иде.

«Авыл яшьләре» редакциясендә калдырылган хикәям турында сорашкан булып, әледән-әле ГАЖУРга барам, барган саен диярлек берәр атаклы кешене күреп кайтам. Әйе, күрешеп түгел, читтән генә күрел. Кайвакыт атаклы кешенең икенче берәүгә әйткән сүзен ишетеп калырга да насыйп була.

Шундыйларның берсе Галиәсгар Камал булгандыр. Редакциягә керүгә үк, беренче бүлмәнең уң як стена буендагы кечкенә өстәл янында утыра иде ул. Төймәләре ычкындырып җибәрелгән пинжәк эченнән шактый искергән жилеты күренеп тора. Пеләшләнгән башы белән кабарып торган мыегы аны миңа бик олы кеше итеп күрсәтә. Кузгалып йөрегән чакларында да олыларча акырын кыймылдый, ашыкмыйча гына сөйләшә. Ләкин күз карашы үткен, бераз усал да кебек. Аның берәрсе белән сөйләшкән вакытына туры килеп, тавышын ишеткән чакларым да була. Әкрен генә сөйләшкәндә дә ишетелә торган куе, калын тавыш. Бервакыт кемнеңдер аның белән бик үз кешеләрчә кычкырып исәнләшкәне хәтеремдә калган.

— Нихә-әл, Галиәсгар абзый! Бик картаймыйсыңмы әле?

— Картаюдан куркасы түгел! — ди атаклы драматург.— Карт аю монда юк. Карт аю урманда була ул!

Бу бәлки аның шул мизгелдә генә уйлап табылган үз сүзе дә булмагандыр. Ләкин башлап аңардан ишеткәч, ул минем күңелемдә Галиәсгар абзый каламбуры булып калды.

Шул ук бүлмәдә, шундый ук кечкенә өстәл янында утыручы тагын берәү тышкы кыяфәте белән игътибарны җәлеп итә иде. Зур, төз-таза гәүдә. Мәһабәт сакал-мыегы белән дә, үткен-кырыс күз карашлары

белән дә татардан битрәк зур рус түрәсенә охшаган кеше. Шундый кыяфәте белән нишләп болай ишек төбендәге кечкенә өстәл янында утыра? Кем икән ул?

— Камил Мотыйгый,— диделәр.

Җиргәндә чакта ук аның граммофонда җырлаганын ишеткән идем. Нindидер бер көлке журналда: «Камил абзаң шәп җырлады, нәкъ Шәләпин шикелле» дигән шаян җыр да укыганым бар иде. Ни җиттс кеше түгел, димәк. Әйтәм, тавышы гади сүзләр сөйләшкән чагында да әллә кая ишетелеп, яңгырап тора. Шундый күкрәк тавышы!

Ул вакытта мин Мотыйгыйның татар матбугаты тарихында шактый күренекле урын тоткан журналист, Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән якын бәйләнештә булган эшлеклеләрнең берсе икәнлеген дә юньләп белмим әле. Тавышы бөтен илгә яңгыраган атаклы җырчы икәнен белү дә җиткән иде. Миңа бик сәер тоелды. Галиәсгар Камал! Камил Мотыйгый! Нишләп соң алар монда шундый гади бәндәләр рәтендә йөри? Берсе газета өчен игъланнар җыя, ди. Икенчесе — хатлар бүлегендә, законга бәгълы мәсьәләләр буенча җаваплар биреп утыра?..

Тагы шул ук бүлмәнең сул як почмагында, эчкә уза торган ишек катындагы өстәл янында утыручы кеше үтә үзенчәлекле тип булып күренде миңа. «Бюрократ!» — күңелемә килгән беренче уй шул булды. Ул елларда бюрократ исеме бик еш телгә алына һәм һаман бер төрле сурәтләнә иде. Көлү-елмаюның ни икәнен дә белми торган аеруча җитди, хәтта ачулы, кырыс чырай. Кешегә күтәрелеп карамас. Авызыннан бер сүз тартып алалмассың. Аның беркемдә дә эше юк. Шундый эре...

«Чаян» битләрендәге рәсемнәрдә булсын, газеталарда язылган фельетоннарда булсын, нәкъ шундый кыяфәттә тасвирлана һәм совет халкының явыз дошманы сыйфатында тәнкыйть ителә торган бюрократка ошаган бер тип, баксаң, редакциянең үзендә утыра? Гаҗәп? Ә ул кешенең кем икәнен белгәч, тагын да гаҗәпләнә төштем: Ганкәбут булып чыкты. Ганкәбутнең үрмәкүч дигән сүз икәнлеген белә идем. Хәзер инде миңа бу сәер кеше бюрократка түгел, үрмәкүчкә ошаган булып күренә башлады. Чынлап та, зур үрмәкүч кебек, аның бөтен җире түгәрәк. Бөкерәя биреп хәрәкәтсез генә утырган гәүдәсе шундый. Чокыраебрак торган оялары белән бергә ике түгәрәк булып күренгән ике күз. Ике як читеннән тирән сызыклар белән әйләндереп алынган һәм шар кырые кебек алга таба кабарыбрак торган авызы да түгәрәк. Хәзер инде ул миңа салкын җанлы бюрократ түгел, кешеләрне көлдерү өчен юри шундый кыяфәткә кергән шаян адәм булып күренә. Стәрлетамакта чакта ук аның «Чаян»да басылган шаян язмаларын сыным катып укый торган идем. Мин гениме? Бер сәүдәгәрнең рус сүзләрен нәкъ татарча җимереп-ватып, революция көннәрендә Мәскәүдә күргәннәрен сөйләве турындагы шигырен генә кара!

Митрапул нумирында ләжим,
Чириз акно ми гләжим...

Бервакыт шуны[illegible]ман Биктаһиров сәхнәгә чыгып сөйләде. Көлеп бөтен залның эче кат[illegible]

Минем өчен Ганкә[illegible]тнең көлкеле әйберләр язучы буларак кына да даны җиткән иде. То[illegible]-бара белдем: Ганкәбут — Исмәгыйль Рәмиевнең псевдонимы булга[illegible]чкән. Якынрак белгән саен бу кешенең минем каршыда кадере арта һ[illegible]м мөбаләгасез әйтәм, аның йөз чәһрәсе дә матурланганна[illegible] матурлана, сөйкемлеләнә, кыланышлары да ягымлылына барды. Чын мәгънәсендә тыйнак, искиткеч хезмәт сөючән һәм кеше җанлы бу журналистның әдәби культурабыз тарихына күрсәткән хезмәтләре әйтеп бетергесез. Ул төзегән «Вакытлы татар матбугаты альбомы» гына да ни тора! 1926 елда чыккан ул хезмәттә татар телендә

нәшер ителгән барлык газета-журналларның кайчан, кайда чыгулары, аларда кемнәр катнашуы бары да бәйнә-бәйнә язылган, барының да диярлек фотолары да бирелгән...

Исемнәре таныш булган яшьрәк каләм әһелләрен күрү дә кызык иде миңа. Бу йортта үзләрен тулы хокуклы хуҗадай тоеп күкрәк киереп керүче яки үтә мөһим эшкә кичегергә курыккандай, ашыгып чыгып китүче, очраган танышларына узып барышлый гына кычкырып сүз кушарга яратучы Сафа Борһан кебекләр, Закир Гали, Мөхәммәт Персин, Гомәр Толымбайскийлар...

Гомәр Толымбайский ул елларда матбугат битләрендә исеме еш күренә торган язучы иде. «Кызыл Армиядән кайткач» дигән китабын укып белү өстенә, аның «Крәстиян гәзите» өстәлендә эшләп утырганын күргәнем дә бар иде. Ә бер көнне мин аны... мунчада очратып, еракттан ук танып алдым. Шактый озын буйлы, эре сөякле мужик бәдәнле кеше. Ике як почмагы уелып эчкә кергән киң маңгай. Коңгырт-кара чәч һәм шундый ук төстәге каш-күзләр. Заманына хас булганча, сакал-мыек кырылган. Бер кулына мунчала белән сабын, икенчесенә ләгән тотып, ашыкмыйча гына юыну бүлмәсенә кереп бара.

Күзәтеп торам, мунчала-сабыннарын пар бүлмәсенә кер торган ишек янындагы буш эскәмиягә куйды да, ләгәнен тотып, кран янына юнәлде. Хәзер миңа артык мыштырдарга ярамый, бәхетле эскәмиянең икенче башына бүтән кеше килеп утыруы бар. Берни белмәгән булып кына мунчаламны илтеп куйдым. Әлэкте. Менә юынып утырабыз. Киң эскәмиянең бер башында танылган язучы, икенче башында — мин, язучы булырга әле хыялланып кына йөрүче кызыл авыз. Үзенә сиздерми генә тегенең бөтен хәрәкәтләрен күзәтеп утырам. Иң элек башларын-түшләрен, бөтен гәүдәсен чылатып чыкты да, ләгән төбенә әз генә кайнар су алып, мунчаласы белән сабын күпертергә тотынды. Эх, сабынының исе! Әй күпертә, әй күпертә. Ак күбек белән бөтен тазы тулды. Ташып чыга башлады. Һаман күпертә. Исле сабын бит! Ничек җәлләми? Бай, димәк. Ниһаять, булды дигән кебек, күпертүеннән туктады да миңа күтәрелеп карады.

— Нихәл, егет,— диде,—аркаларны юышабызмы?

— Давай!— дигәнемне сизми дә калдым.

Менә ул, тәпи басып, ике кулы белән эскәмиягә таянды. Мин аның мунчаласын күбеккә манып, аркасын ышкырга тотындым. Язучы кешене рәнҗетмәскә тырышып, иркәләп кенә юам.

— Җәлләмә! Катырак бас!

Тырышыбрак ышкырга керештем. Шундый киң, таза арка. Шоп-шома. Алсуланып, матураеп китте.

— Ярар, җитеп торыр,— диде Толымбайский,— рәхмәт, матур кыз гашыйк булсын үзеңә.

Язучының аркасын юу бәхетенә ирешү үзе дә житкән иде инде. Өстәвенә шундый матур теләк! Шулай да нәфес дигән нәрсә туя беләмени? Үземнең дә арканы ышкытасы килә бит. Кайткач, иптәшләргә «Толымбайскийдан арка юдырдым» дип мактану үзе ни тора!

Сасы кер сабыны дип тормадым, мунчаламны тиз генә күпертеп алдым да, әйттем:

— Минем арканы да сыдыргалап алыгыз инде. Әз генә...

— Нигә әз генә? Давай, күпме кирәк!

Шундый каты итеп ышкырга тотынды бу, чыда гына! Әллә әрсезләнүем өчен юри шулай үч ала инде? Әллә, минем җәлләп ышкыганны яратмыйча, менә шулай ышкырга кирәк аны дип, акылга утыртуы? Аркам суелып чыкмаса ярар иде дип, чак чыдап торам. Шулай да сынатмадым, түздем...

Гомәр Толымбайскийны хәзерге яшьләрнең күбесе белми дә торгандыр. Әсәрләрен табып, укып караучы булса да, аны зур каләм остасы

итеп таныр микән? Ләкин егерменче елларда әдәбият дөньясында зур фигура иде ул. Галимҗан Нигъмәти тарафыннан биш йолдызның берсе итеп танылган кеше! Юкка түгелдер: маңгайга бәреп әйтелгән агитсүзләр пәрдәсе аша булса да, аның әсәрләрендә революциядән соңгы авыл кешесенең реалистик образлары шактый ачык күренә иде. Алда бу язучы белән якыннанрак очрашасылар бар әле.

Икенче зур вакыйга — хикәям басылу булды. Теге вакытта юкка җәберләгәнмен үземне, яшь күңел белеп сизенгән икән: Мансуров иллюстрацияләргә алынган хикәя чынлап та минеке булган. «Авыл яшьләре»нең ноябрь санында басылып чыкты. Исемен үзгәрткәннәр икән. «Көннәр архивында»ны ошатмыйча, «Дуслар һәм дошманнар» дип атаганнар.

— Яхшы иткәннәр,— дип кенә куйдым.

Бу вакытларда мин «Кызыл яшьләр» редакциясе каршында оешкан язучылар түгәрәгенә йөри башлаган идем инде.

Кайчан эзләп таптым мин ул түгәрәкне, кайда? Башлап кемнәрне очраттым — белмим. Тик шунысы ачык: аның утырышлары якшәмбе саен була, мин аларны зарыгып көтеп алам. Даими урыны да юк, бер атнаны шунда — ГАҖУРда булса, икенче атнаны комклуб бинасының берәр бүлмәсендә җыелабыз. Кемнәр? Барыбыз да диярлек шул берике ел арасында кулларына каләм тота башлаган яшьләр. Ләкин активлык ягыннан барыбыз да бер дәрәҗәдә үк түгел әле. Бар арада үзләрен әдәбият фронтында комиссар позасындарак тотучы көр тавышлы ТКУ егетләре. Бар, азмы-күпме шәһәр тәрбиясе күргәнгә булса кирәк, просто кыюрак булулары белән үзләрен өстенрәк хис итүче чая егетләр — Демьян Фәтхи, Габдрахман Минский, Әсгать Айдар кебекләр. Бергә җыелган чакларда алар инде күбесенчә өлкәнрәкләр янында, «Кызыл яшьләр» редакторы Мөбәракшин, түгәрәк җитәкчесе Исхак Хәйруллин тирәсендә булалар, яныбызга килеп йөрүче исемлерәк язучылар белән дә бик иркен сөйләшәләр.

Исемнәре күптән матбугатка чыккан язучылардан ул чорда яшьләр арасында иң еш күренүчеләр Гадел Кутуй белән Хәйретдин Вәли булгандыр.

Кутуй исеме, ул еллардагы матбугатта күбесенчә Һади Такташ, Кави Нәҗмиләр белән бер рәттән телгә алынганга күрә, миңа күптән таныш иде. Әсәрләрен укудан да бигрәк, аның футурист булуына ымлап язылган мәкаләләр, «Чаян»да чыккан көлке рәсемнәр буенча белә идем. Кулга төшкән шигырьләрен дә, әлбәттә, укымыйм түгел, ләкин алар, үтә яңача язылганга булса кирәк — ә бәлки үтә яңача күренергә тырышып язылгангадыр? — миңа җан азыгы була алмыйлар, күңелгә хуш килмиләр иде.

Кутуйга булган мәхәббәтем аның үзен күргәч уянды. Аның һәр вакыт көләч, шат чырайлы булуы, әдәби түгәрәккә яңа гына аяк баскан яшьләр белән дә, күптәнге танышы кебек якын күреп, үз итеп сөйләшүе күңелне әсир итә иде.

Өстәвенә чибәр. Аның чибәрлеген тәфсилләү өчен, «кара кашлы, кара күзле» кебек традицион сыйфатлаулар гына җитми. Анысы шулай, кашы да, күзе дә кара. Таманча авыз-борын, маңгай, яңак, ияклəре дә тигез килгән озынчарак йөз. Ләкин шәхес буларак аның үзенчәлеге күзгә бәрелеп торган терелегендә, җанлылыгында. Чын Кутуй күзләрен син аның үзеңә төбәлеп караган чагында гына күрәсең. Ул күзләрдән нинди дер үткен, кыю уйлар нуры бөркелә. Алар карый гына түгел, сөйли. Аларның каралыгын күрмисең, ни әйткәннәрен генә тоясың: «Мин бит сине үтә күрәм,— ди ул күзләр.— Нигә тартынасың? Начар уең юк бит күңелеңдә,— ди,— мин дә бит сиңа явызлык телә-

мим, нигә күңел серләреңне ачмыйсың?.. Күлсәм соң!.. Мыскыл итеп түгел бит, үз итеп, оялчанлыгыңнан көләм...»

Борын астында калдырып кына үстерелгән кара мыек кисәге аның күз нурларын үткенәйтергә булыша, шаян иреннәре дә күзләре белән бер сүздә:

— Кыюрак бул!..

Мондый караштан соң, атаклы доктордан сәламәтлегең турында яхшы сүз ишеткәндәге кебек, җиңеләеп китәсең, үз шәхесеңә карата хөрмәт хисе уяна, ышанычың арта.

Ул аның сүзгә осталыгы!..

Трибунага чыккач ачыла иде аның илһам чишмәсе. Башындагы фикере, теленә күчә башлау белән, тармаклана, чәчәк ата. Сүзе сүзгә шул кадәр шома ялганып бара, аны тыңлап туя алмыйсың. Соңыннан, аны ишетә алмый калган берәр танышың очрап, синнән «Кутуй ни турыда сөйләде?» дип сораса, уйлап та тормыйча аның фикерләрен әйтеп бирә аласың. Алар шундый ачык аңлаешлы да, хәтердә калучан да була.

Әдәби түгәрәкнең төп эш формасы яшь язучыларның яңа язган әсәрләрен укып, шулар турында фикер алышудан гыйбарәт иде. Гадәттә иң элек бер яки ике хикәя укыла, аннары берничә шигырь. Кагыйдә буларак, аларны авторның үзеннән башка берәү дә укып килмәгән. Һәркем өчен бары да яңа.

Тыңлаучылар арасында Кутуй бар икән, ул инде ишеткән әсәре турында фикерен әйтми калмый. Мактаса, ышандырырлык итеп мактый, яманласа, ышандырырлык итеп яманлый. Аның фикере автор өчен дә, тыңлаучылар өчен дә иң әһәмиятлеләрдән саналгандыр. Чөнки ул шигырьдәге һәр җөмләдән генә түгел, һәр сүздән диярлек, аның туры мәгънәсеннән тыш, эчке, әдәби мәгънәсен таба. Күп вакытта яшь авторның үзе дә белмичә әйткән идеяларын ачып бирә.

Тагы да әһәмиятлерәге, кечкенә бер шигырь турында сөйләгәндә дә күбесенчә рус һәм дөнья әдәбияты әсәрләреннән мисаллар китерә. Тарих өчен иске, ә синең өчен яңа булган афоризмнар ишетәсең... Алар турында күбрәк, тирәнрәк беләсең килә башлый. Чыганакларын эзлисең. Табасың. Кутуй телгә алган әсәрләрне табып уку теләге туа. Тапканнан соң авторлары белән тулырак танышу чарасына керешәсең. Димәк, сәләтле әдип-оратор яшь язучыны күбрәк укырга өнди генә түгел, мәҗбүр итә.

Белмим, аның сөйләгәннәре, теге яки бу әсәргә биргән бәяләре ни дәрәҗәдә дөрес булгандыр, һәрхәлдә бүгенге көндә әдәбиятыбызда хаклы рәвештә үз урыннарын алган, хәтта кайберләре инде халык күңелендә онытылмас эз калдырып, арабыздан китәргә дә өлгергән бик күп язучыларга: Гази Кашшаф, Фатих Кәрим, Демьян Фәтхи, Әсгать Айдар һәм Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Габдрахман Минский кебекләргә беренче адымнарында Кутуйның уңай йогынтысы аз булмагандыр.

Аның тәнкыйте нәтиҗәсендә каләмнәрен ташлап, башка юл сайлаган яшьләр булса, алар да бу түләүсез остазга рәнҗеп китмәгәннәрдер дип уйлыйм: Кутуй һәр яшь язучыга карата чын иптәшләрчә турысын әйтергә ярата иде.

Тагын өлкәнрәк, революциянең теге ягыннан ук килгән әдәбиятчылардан яшь язучылар түгәрәгенә иң актив йөрүче кеше Хәйретдин Вәли иде. Башлап мин аны шул түгәрәктә күрдем, Казанда андый кеше барлыгын да шунда белдем.

Сөйләгән чагында әледән әле «Э... э... э...» дип озак-озак паузалар ясый торган иде. Өстәвенә пеләш башлы да булгач, ул безгә бәлки үз яшеннән картрак та булып күренгәндер. Шулай да һәр утырышка килә, укылган һәр әсәр турында диярлек фикерен әйтми калмый.

Күбесенчә әдәби әсәрнең техника ягына туктала иде ул. Шигырьдә булса, вәзен, кафия, чәчмәдә булса — сюжет, композиция, әдәби типлар механизмы... Язган мәкаләләре дә шул характерда. Шуңа булса кирәк, Кутуй аны бик яратып бетерми, аның чыгышларын тәнкыйть итә. Түгәрәктә үзләрен алдынгылар җөмләсендә хис итүче яшьләр дә аны формализмда гаеплиләр, аның һәр чыгышын диярлек бәхәскә мохтаҗ санныйлар иде.

Вакытында күп кенә тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр язган, әдәбият теориясе буенча китаплар да чыгарган бу кеше тарихыбызда онытылмаслык урын алырлык әсәрләр калдыра алдымы-юкмы, гомеренең азаккы елларында әдәби җәмәгатьчелектән читләшүе аның үз гаебе генә идеме, кирәк булса, заман бабай белән бергәләп, тарихчыларыбыз ачыклар. Мәгәр минем өчен шунысы бәхәссез: Хәйретдин Вәли, әдәбият укытучысы буларак та, олы башын кече итеп, яшь язучылар түгәрәгендә актив катнашып йөрүе белән дә минем буын каләм ияләрен ничек язарга өйрәтүдә күп һәм кирәкле эш башкарды.

Әле утызга да житмәгән булсалар да, укучылар каршында танылып, популярлашып өлгергән һәм безнең карамакта инде өлкән буын исәпләнгән язучылардан Такташ, Нәжми, Толымбай, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали кебекләр яшь язучылар түгәрәгенә йөрми иде. Әгәр инде берәрсе ничектер килеп чыга калса, безнең өчен ул кичә — бәйрәм, тарихи вакыйга!..

Чираттагы якшәмбе.

Комклуб бинасының бер бүлмәсендә утырабыз. Шактый кеше жыелган. Күбесен белеп тә бетермим. Көн тәртибендә гадәттәгечә яңа әсәрләрне укып тикшерү генә түгел, әдәбият алдында торган актуаль мәсьәләләр турында доклад та бар. Инде тыңлаганбыз. Фикер алышулар бара. Гальгаф көлдерә. Әйе, сөйли генә түгел, көлдерә.

Карсак кына буйлы, кин җилкәле бу егетнең Гали Галиев исемле икәнен дә, студент икәнен дә белми идем әле. Мәгәр яшь язучылар арасында Гальгаф буларак билгеле кеше иде. Хикәяләре хәтеремдә калмаган. «Ил бирәннәре» дигән роман яза дип сөйлиләр иде. Ни дәрәҗәдә дөрес булгандыр, анысы да дөньяга күренмәде. Әсәрләре белән түгел, жыелышлардагы чыгышлары белән танылган иде. Анда да көлдерә белүе белән. Үзе болай карап торуга гаять житди кыяфәтле. Хәтта кырыс, ачулы чырай. Ә сөйләргә керешсә, беренче сүзләреннән үк көлә башлыйсың. Күренеп тора: тыңлаучыларны көлдерүдән ул ләззәт таба. Рухы күтәрелеп, һөҗүм дәрте үсеп китә. Ләкин кырыс чыраена ник аз гына көлү-елмаю билгесе чыксын! Ә көлдерүе көлдерү. Аның нинди максат белән сөйләвен аңлау да кыен. Берәр доклад буенча сүз алса, докладчыны мыскыл итә, аның һәркемгә күренеп бетми торган физик кимчелекләрен таба, әйткән фикерләреннән көлке мәгънәләр чыгара. Берәр шигырь яки хикәя турында сөйли башласа да шулай. Сәяси киртәгә сыймый торган анекдотлар сөйләп ташлаудан да тартынмый... Үзенә тиешне шул теленнән тапты да булса кирәк: бер-ике елдан соң ул бөтенләй күренмәс булды.

Ләкин ул вакытта мин аның кинаяләренә артык игътибар итмим, аны тыңлау минем өчен клоун караган кебек кызык иде...

Менә ул, ниһаять, сөйләүдән туктады. Тыңлаучылар көлүдән тыелып та өлгермәгән иде әле.

— Кави Нәжмигә сүз бирелә! — диделәр.

Минем өчен сенсация иде бу. Бер минем өчен генә микән? Гальгаф шунда ук онытылды. Өс киемнәрен салмый гына жыелышкан төрле кешеләр белән тулы бүлмә тынып калды.

Ул чорда Кави Нәҗми минем өчен, Такташтан кала — ә бәлки аның белән бер дәрәҗәдә үктер әле — иң кызыклы язучы булгандыр. Аның гадәти булмаган шигырьләре, көтелмәгән кызык гыйбрәтләр, шаккатыргыч чагыштырулар белән тулы хикәяләре... Моңарчы мин белгән әдәби әсәрләрдә очрамаган, ләкин миңа, Җиргән малаена, аңлаешлы һәм якын булган ни русча, ни татарча сүзләр: почти, пожалый... бары да кызык, бары да яңа. Эх, үзен күрәсе иде. Хикәяләрендә, шигырьләрендә (ягъни, күп сүзләрне кәгазьгә язарга ярамый торган шартларда) шундый икән, сөйләгәндә ниндидер ул? Үзен ишетәсе иде!



Һәм менә, көтмәгәндә-уйламаганда, Кави Нәҗми үзе! Янымда гына диярлек өстәл,кырында утырган икән. Торып басты. Өстендә шинель. Фигурасы бик үк коеп куйганнардан түгел. Иңбашлары төшенкерәк тә булганга, ул җыйнаксыз солдат кебегрәк күренә. Яланбаш. Алгы ягы шактый озын калдырып, под польку алынган ялтыр кара чәченең яртысы, бөгәрләнеп маңгаена төшкән. Моңарчы күргән рәсемнәре буенча, ул минем күз алдыма матур кеше булып килә иде. Дөрес, Казанга килгәч, аның шадра икәнлеге турында ишеткән идем инде. Ләкин бу кадәр үк булыр дип уйланылмаган. Җиргәнчә әйтсәк, ертлач-ертлач шадра битле кеше икән. Каш-күз коерыклары чикәгә таба кыекланып, түбәнгә тартылган. Кыскасы: төскә-биткә бик үк матур түгел. Ләкин аны ямьсез дип әйтәсе дә килми. Шундый үзенчәлекле, шундый кызык итеп яза белә торган каләм остасы әлбәттә ямьсез булырга тиеш түгел! Юк, юк! Ямьсез түгел ул. Кави Нәҗми булгач, ул нәкъ менә шундый булырга тиештер дә.

Менә аның күзләре, мин көткән Кави Нәҗмигә хас булмаганча, нәрсәдәндер куркынган сыман, ашыгып-ашыгып, бүлмә буенча йөгереп алдылар. Менә ул авызын бер ачты, бер йомды, әйтәсе сүзен тәмләп караган кебек, иреннәрен бөрә биреп, бер-ике рәт суырып куйды. Ниһаять, әйтте. Нәкъ мин көткәнчә, нәкъ Кави Нәҗмичә, кызык итеп әйтте:

— Көлә белеп көлсәң, унсигез еллык бүсер төзәлә, ди...

Бөтен бүлмә шаркылдап көлеп җибәрде. Шунда ук, тагы да кызыграк сүзләр ишетергә әзерләнеп, тынып калдык. Ләкин язучының бу чыгыш өчен әзерләгән көлке запасы шуның белән бетте күрәсең, ул инде ир кешегә бик үк хас булмаган нечкәрәк тавыш белән үтә эшлекле тонда дәвам итте:

— Әмма Гальгаф чыгышын шифалы көлү дип булмый,— диде.— Доклад җитди иде. Көн тәртибенә гаять мөһим мәсьәләләр куелган иде. Гальгаф иптәш аларны кәмиткә әйләндерде...

Ул шулай, бернинди көлү-шаярусыз, әдәбият фронтындагы көрәшләр, алда торган бурычлар турында сөйләп китте. Хәзер ул минем өчен, оригинал Кави Нәҗми булудан бигрәк, кырыс комиссар иде инде...

Икенче бер утырышта, үзләрен әле монда тулы хокуклы хис итеп җитмәүче минем ише тыйнаграк егетләр арасында серле пышылдаулар ишетелде: «Туфан!.. Туфан?!»

Туфан?!

Авылда чакта аның турында берни ишеткәнем юк иде. Казанга килгәч тә шигырьләрен укыганымны хәтерләмим әле. Бары яшь язучылар арасында бу сәер фамилиянең ниндидер әһәмиятле яңалык төсендә телгә алынуына гына игътибар итә идем.

— Әйе, Туфан килгән! Яңа шигырен укыячак!

Минем өчен кызыклы да, серле дә яңалык иде бу. Кем икән? Нинди икән?..

Әнә ул, өстәл янына утырып, алдында, яткан язуы өстенә иелгән. Ике ягыннан да, арттан да аны кысып, уратып алганнар. Тырышыбрак карамасаң, юньләп күрерлек тә түгел. Үрелебрәк, төркемгә җайлашыбрак карыйм. Иң элек пумала башы күзгә бәрелде. Куе булып, тузылып торган, шактый күп өлеше маңгаена төшкән саргылт-коңгырт чәч. Тузган, ләкин тәртипсез дип булмый, ничектер килешле булып, табигый булып тузган. Ямьле булсын өчен, үзенчә булсын өчен, юри шулай туздырган кебек. Күргән кеше ах итәрлек: «Чәчең шундый булса икән!»— диярлек...

Башын әз генә күтәрә төшүгә, мин аның аркылыга да, буйга да җыерылган маңгаен күрдем. Әченә ниндидер тирән уйлар, фәлсәфи фикерләр яшергән кыяфәтле җитди маңгай. Каш-күзләре дә, авыз-борыннары да бер яссылыкта урнашкан һәм гадәттәгедән таррак озынча йөз. Чырае? Ак дисәм... юк, ниндидер, киндер төслерәк нурсыз чырай. Көне-төне баш күтәрми эшләп йончыган кеше кебек! Менә ул кемгәдер борылып елмайды. Һәм шул әз генә елмаю аның чыраена нур кертеп, җанландырып җибәрде. Шундый, кешегә хөрмәт белән тулы, кешелекле елмаю!.. Юк, буш кеше түгел бу! Күренеп тора, мие тулы, йөрәге, күңеле тулы гамь!..

Түземсезлек белән көткән минутыбыз җитте. Яңа язган шигырен укырга Туфанга сүз бирелде. Менә ул җайлап кына тәпи басты.

Шунда гына күрдем: өстендә кара күн тужурка.

Сабыйларча саф күңелдән, беткәнче ышанып, мотлак тирән мәгънәле, кызыклы яңа сүз көтеп, чын шагыйрьнең яңа әсәрен үзе укыганны тыңлау! Әдәбиятка гашыйк яшь кеше өчен шуннан да бәхетлерәк тамаша юктыр кебек...

Әнә ул үзенең «Козырь-туз» дигән шигырен укый. Үзенчә, карт эшчегә ошатып, тавышын калынайтып, тупасландырып, сөйләгән кебек итеп укырга тырыша. Декламаторлык куәсе әллә ни дә түгел ахрысы: һәр җөмләсен калын, күтәренке тавыш белән кычкырып башлый да, азаккы сүзләрен, чак ишетелерлек итеп, йотып куя. Әз генә игътибарсызрак булсаң, хәтта бөтенләй ишетми үткәреп җибәрүең дә мөмкин. Ләкин ишетмәгән кая! Шул кадәр бирелеп, тын калып тыңлыйбыз, пышылдап кына сөйләсә дә һич бер сүзен ычкындырасы түгелбез. Берәрсен ишетми калмыйк дип, кызык урыннарында көлергә дә куркабыз. Ә көләрлек урыннар җитәрлек ул шигырьдә. Мулла турында сөйләгәндә карт эшченең: «Примергә сүрә китерә», дип әйтүе үзе генә дә ни тора!

Җор зимагур Хабул сурәте тагы!

Телгә дисәң — гармун,
Ә гәүдәгә — мартин торбасы!..

— Муллабзый! — ди.—
Син мактадың инде алланы,
Вот әйт әле: алла
Козырь-тузны каплый аламы?

Еллар үтеп, әдәбият-матбугат дөньясында инде үз кеше булып, тәмам «эт каешы»на әйләнгәч, бәлки бу шигырьдән дә гаеп тапкан чакларыбыз булгандыр. Әмма ул вакытта, бигрәк тә шул чор өчен, миңа шигырьнең шуннан да шәбе булмыйдыр кебек тоела иде.

Һәм шул көннән башлап, мин Туфан шигырьләрен эзләп, әле чыкмаганнарын көтеп алып укый башладым. «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады» кебекләр... Укылган бер куплеты ятлана бара иде аларның. Атом энергиясен ачу кебек, космоска очу кебек зур яңалык иде алар миңа!

Бер миңа гынамы? Яшьләр, көтүләре белән ябырылып, Туфанга

нярә башлады. Шигырьләрен барысы да диярлек Туфанча язарга тырыша иде. Казанда гына түгел, Уфада да...

Ләкин иярүчеләрнең күбесе Туфан шигырьләрендәге яңалыкны бары рифмада гына күрделәр бугай, эпигонлыктан ары китә алмадылар. Дөрес, Туфан татар поэзиясенә кафия запасының чиксез бай яңа чыганакларын ачты. Кирәк булганда ул хәзинәдән бүгенге шагыйрьләребез дә бик уңышлы файдалана. Ләкин Туфанның Туфанлыгы аның яңа рифмаларында гына түгел. Хәтта поэзиябезгә заман таләп иткән иң яңа тема алып килүендә генә дә түгел, аның Туфанлыгы фикер тирәнлегендә, образлар системасының яңалыгында аларның интеллектуаль катлаулы, шуның белән бергә, халыкчан да, гади дә булуында.

Чү! Профессионал тәнкыйтьче кебек сайрый башладым түгелме соң? Юк, белгечлек дәгъва итмим. Тәнкыйтьче түгелмен... Шигырь турында бары үз зәвыгыма таянып кына сөйлим. Беләм, Белинскийны укыганым да хәтеремдә: әдәбият, сәнгать әсәре турында сүз барганда, үз зәвыгыңнан гына чыгып, бу миңа ошый, бусы ошамый дип кенә хөкем итәргә ярамый. Берәүне дә хөкем итмим, сүз уңаенда бары Мирсаиф буларак кына кайбер фикерләр әйтеп үтәсем килә.

Бәләкәйдән үк яраттым шигырьне. Хәзер дә яратам. Күземә яки колагыма чалынганнарын читләтеп үтә алмыйм. Кызганычка каршы, аларның бик күбе үзләре минем игътибар үзәгемне читләтеп үтәләр. Һаваларда очкан кошлар кебек. Күздән югалуга аларны онытасың.

Укыган яки тыңлаган вакытта күңелгә хуш килгәннәре дә аз түгелдер. Болары инде сине бөтенләй читләтеп узмый. Бакчадагы тирәгенә кунып сайраган сандугач кебек, нәфис авазы, нечкә моңы белән җаныңны рәхәтләндерә, дөнья кайгыларыңны таратып тора. Ләкин очып китү белән ул да онытыла. Шулай да күңелеңдә кабатланмас бер эз кала, әйтеп аңлатып булмый торган ләззәтле эз. Яратам андый шигырьләрне.

Ә була шундый шигырьләр... Яки логать мәгънәсендәгечә бөтен шигырь дә түгел, ә нинди дер поэзия әсәре эчендәге куплетлар, хәтта аерым юллар! Якын туганың яки һәр эштә сиңа теләктәш дустың кебек, сорамыйча күңел түреңә узалар алар, ми тартмаларыңны актарып йөриләр. Ниһаять, сораусыз-нисез, хәтер бүлмәңә кереп урнашалар һәм китәргә дә ашыкмыйлар. Үзләренең һаман «өйдә» икәнлекләрен сиздереп, сиңа нәрсәгә омтылырга, нәрсәдән сакланырга кирәклекне, нәрсәгә куанырга, нәрсәгә шөкер итәргә, нәрсәгә борчылырга кирәклекне әледән-әле исеңә төшереп, уйландырып торалар.

Барыннан да бигрәк әнә шулай, миеңә кергәч, фейерверк шикелле шартлап, мең мәгънә чәчә торган куплетларны, мәкаль булып китәрлек юлларны эченә алган шигырьләрне яратам.

Шигырь укый башлаган чагымнан гына санасаң да ике Тукташ гомереннән артык вакыт узган. Тукай заманыннан, Сәгыйт Рәмиев, Дәрдмәнд, Бабичлардан башлап, совет чоры шагыйрьләре аша, шушы көнгә кадәр сузылган заман эчендә тула белмәс хәтер сандыгына җыелган мисаллар аз түгелдер. Берничәсен генә булса да, классикларыбыздан яки кордашларым серләреннән алсам, хәзерге таләпчән һәм күпне дәгъва итүче укучы дөрес аңламас дип куркам. Үзең карт булганга, яшь чагында укылганга алар сиңа шулай тоела, диярләр кебек. Авторлары үзеңә якын кеше булганга шулайдыр, диючеләр дә табылуы мөмкин. Кулымны күкрәгемә куеп әйтәм: андый шигырьләрнең авторы кем булуы һәм аларның кайчан язылуы бу очракта минем өчен әһәмиятсез. Соңгы елларда, инде пенсиягә чыккач укылган, авторлары миңа бөтенләй таныш булмаган шигырьләр арасында да очрый карт хәтерне уятып җибәрә торган юллар.

Мәсәлән:

Хиросима,
Син үткәне микән,
Киләчәге микән дөньяның?

Хиросима фаҗигасы турында дистәләрчә шигырьләр укыганым бар. Берсе дә хәтердә калмаган. Ә бу юллар минем хәтердә. Чынлап та, Хиросиманы ничек тә дөньяның үткәне хәлендә калдырасы иде, киләчәгебез булмасын иде ул! Моның өчен мин нишли алам? Илебез нишли ала? Кешелек нишли ала?.. Җавап эзләргә, уйланырга мәҗбүрмен.

Яки:

Син үзеңчә яшәмисең икән,
Яшәмисең, димәк, кешечә!

Яки:

Җир казуны авыр эш диләр,
Казый алмау авыр, минемчә.

Яки:

Ургып торган кайнар чишмәләр дә
Корый икән, суын эчмәсәң.

Яки:

Исемсез килдек дөньяга,
Исем алып китәргә.

Яки:

Чәнчелеп китсен
Булыйк без табигать яклы.
Гомер бакый булган адәм
Эреле-ваклы...

Ни өчен хәтердә калган бу юллар? Шәрехләп торуның кирәге юк. Җавапны, аңлаган кешегә, алар үзләре бирә.

Шунысы кызганыч: мондый, хәтердә калып, уйда тармакланып күңелдә чәчәк ата, гамәлендә орлык бирә торган юллар еш очрамый...

Тукта, тагы читкә киттем бугай? Читкә түгел, алга йөгердем. Соңрак әйтәсе фикерләрне әйтергә ашыгам. Хәерлегә булсын. Туфан гаепледер ахрысы, уй-тойгыларымны әнә кайларга алып китте. Ә бит аны беренче күрүем турында гына язмакчы идем.

Әйе, биредә мин Казанга килгәч беренче очраган кайбер язучылар, беренче күрүдә аларның, шәхес буларак, миндә нинди тәэсир калдырулары турында гына яздым. Тора-бара, активлаша башлагач, түгәрәк утырышларында укыган хикәяләрем турында әзме-күпме мактау сүзләре дә ишетеп, кыюлана, хәтта әрсезләнә төшкәч, тагы берничә елдан моңарчы табынып килгән әдипләрем белән бер хокукта аралаша башлагач, аларга карата тәнкыйть сүзләре әйткән чагым да, урынлы-урынсыз тупаслык күрсәтү кебек гөнаһларым да булыр. Әйе, алда, яңа әдәбиятка юл ярганда очраган хәтәр чокырлар, четерекле урманнар үтәсе, кайчандыр үзем хөрмәт иткән каләм ияләре белән дә «сугышасы»лар, алар белән бергә адашасылар, ялгышасылар, хур буласылар, шундый юллар белән булса да, азмы-күпме җиңүгә ирешәселәр бар әле. Алары алда, ә хәзергә...

Ә хәзергә мин, берәү тарафыннан да чакырылмаган кунак сыйфатында, яшьләр матбугаты каршында яшәп килгән әдәбият түгәрәге уты-

рышларына килеп, каләм иләренең яшен-картын, чынын-ялганын, яхшысын-яманын аермыйча, беркатлы сабыйларча күзәтеп, ишеткән бер шигырьгә колак салып, кирәген-кирәкмәгәнен күңелемә алып, хәтер сандыгына җыя баручы, шул ук вакытта, өзлексез «кычытып» торганга чыдый алмыйча, әледән-әле кечкенә-кечкенә хикәяләр дә яза торучы һәвәскәр генә. Төп эшем — художество техникумында уку.

Рәсем сәнгатенә өйрәнү, мин элегрәк уйлаганча, өзлексез сурәт төшереп утырудан гына гыйбарәт булып чыкмады. Дөрес, рәсем дәресенә күп урын бирелә иде.

Натюрморттан башладык. Ягъни остазыбыз өстәлгә куйган җансыз әйберләрне — геометрик шәкелләрне, көнкүрештә кулланыла торган төрле коралларны, гипстан әвәләнгән җиләк-җимеш яки хайван сыннарын — кәгазьгә төшерергә өйрәнәбез.

Натурадан алу — ниндидер журналда басылып чыккан әзер рәсемне күчереп ясау гына түгел, монда инде синең күз алдыңдагы әйберләрне ни дәрәҗәдә дөрес күрүең, алар арасындагы аерманы, хәтта бер үк әйбердәге төрле почмак яки кабыргаларын, калкулык-батынкылыкларның бер-берсенә нинди мөнәсәбәттә булуын дөрес чамалый алуың, аның өстенә күзләрең дөрес күргәнне бозмыйча кәгазьгә төшерә белүең хәл кыла. Бер атна үтәр-үтмәстән аңлап алдым: теге вакыттагы сынау дәресләрендә мин бер сәгатьтә эшләп бетергән рәсем өстендә ике-өч көн буе казынып та, эшнең азагына житә алмый азапланучы сүзсез егетләр (егетләр генә түгел, кызлар да) рәсем сәнгатенең нәрсә икәнен монда килгәнче үк аңлап өлгергән, ягъни арабыздагы иң өметле кешеләр булган икән.

Озакламый үземә дә бер натюрмортка бер атна вакыт аз тоела башлады. Натураны дөрес күрә белү бер хәл. Күргәнеңне бозмыйча кәгазьгә күчерә белү — бөтенләй икенче эш. Җыр кебек. Яңа көйне яратып тыңлыйсың, күңелеңнән инде аны көйли дә беләсең. Ә кычкырып җырлый башласаң — бөтенләй икенче, син теләмәгән авазлар килеп чыга. Яки сандугачны син тыңлап кара да, үзең сандугач булып сайрап кара!.. Натурадан рәсем төшергәндә дә шулай. Күрәсең — бер рәвеш. Сызасың — бөтенләй икенче килеп чыга. Бозасың, тагын сызасың, тагын...

Ниһаять, инде булды бугай дисең. Остазың килә дә (остазың кем диген? Кайвакытта ул атаклы художник академик Беньков үзе була) дәшмичә генә бер өстәлдәге натюрмортка, бер син ясаган рәсемгә карап ала. Дәшмичә генә яки үзалдына нидер мыгырдагандай итеп, синең сызыкларыңны барга да санамыйча, алар өстеннән үз күреме белән бөтенләй син көтмәгән юнәлештә яңа сызыклар сызып китә. Күп тә түгел — бер сызык сала, күпкә китсә — ике. Ләкин шул бер яки ике сызык синең натюрмортыңны янадан үзгәртеп ясарга нигез булып кала. Тагы бозарга тотынасың. Ярый әле, күмер белән төшерәбез.

Күмер!

Беренче ишетүгә миңа бу сәер тоелган иде. Күмер белән рәсем төшерүне мин койма такталарын яки мич стеналарын пычратып йөрүче тыйнаксыз бала-чага һөнәре дип кенә белә идем. Баксаң-күрсәң, Казан чаклы Казанның бөтен Россиягә дан тоткан махсус рәсем мәктәбендә, Беньков кебек, Тимофеев кебек атаклы художниклар үзләренең шәкертләрен күмер белән рәсем ясарга өйрәтеп яталар.

Карандаш калынлык кына өянке чыбыкларыннан махсус яндырып алынган йомшак күмер оста рәссам кулына туры килсә, бер ягы юри кытыршы итеп эшләнгән слоновый кәгазь өстендә могҗизалар тудыра ала икән.

Рәссам өчен, аеруча безнең кебек өйрәнчекләр өчен, уңай ягы: ялгыш сызылган очракта аны, күмерне, ак күмәч йомшагы белән бик ансат сөртеп алып була. Күмер белән ясалган рәсемнең үзенә генә хас өстен-

леге тагы шунда: анда ярым тоннарны, төрле куелыктагы күләгәләрне бик әйбәт, йомшак итеп бирергә мөмкин.— Озакка барамы соң ул күмер белән ясалган рәсем? Бик тиз очып бетмиме? Тузан кунса-нитсә, аны сөртеп тә булмый торгандыр? — Беренче мәлдә минем үземә дә килде бу сорау. Андый куркыныч юк икән. Өстенә махсус сыекча бөркесәң, күмер белән эшләнгән рәсем дә ныгый һәм озак саклана.

Рәсем остасы булу өчен натураны дөрес күчереп ала белү генә җитми. Әйберләрнең, бигрәк тә җан ияләренең, аеруча кешеләрнең тышкы күренешләрен генә түгел, эчке механизмнарын яхшы белү мәҗбүри.

Кеше! Һәр сәнгать әсәренең төп объектларыннан берсе, иң зурысы һәм әһәмиятлесе. Аны төрле хәрәкәттә чагында натурадан карап дөрес төшерә белү дә зур осталык сорый. Ләкин художник буласы кешегә, үз хыялында туган дөньяны, үз фаразында яралган образларны үзе теләгән хәрәкәтләрдә иҗат итәргә ниятләгән рәссамга ул гына җитми. Кешегә хас нечкә кыланышларны, чырай үзгәрешләрен, вакыты белән гадәттән тыш рәвеш ала торган кискен хәрәкәтләрне, сәнгать әсәре таләп иткәнчә, чынбарлыкта булганыннан арттыра төшеп, эффектлырак итеп бирергә батырчылык итү, бер үк вакытта табигый дөреслеккә дә турылыклы булып кала белү өчен рәссамга кешенең анатомиясен яхшы белү кирәк.

Техникумның уку программасында пластик анатомия дәресенә дә күп урын бирелә иде. Кеше организмындагы санап бетергесез дәрәҗәдә күп булган мускулларның латинча исемнәрен хәтердә калдыру өчен, өстәвенә башка уку йортларында укучы танышларыбыз белән очрашкан чакларда белемле булып купшырак күренергә тырышудан да булса кирәк, без үзара сөйләшкән чакларда да, бицепс-трицепс, мускулиссирратус, мускулис-пекторалис, стерно-клейдо-мостейдеус кебек «серле» сүзләрне кыстырып сөйләргә яратабыз. Укытучыларыбыз безне һәркайда, һәркайчан һәр күргән кешенең хәрәкәтләренә, йөз-чырай үзгәрешләренә игътибар итә йөрергә киңәш бирәләр, кешенең киемен түгел, кием үтәли аның тән төзелешен, фигура үзенчәлекләрен күрә белергә өйрәтәләр. Аларның бу киңәшләре безгә, аеруча ир-ат затына бик ошый, һәм без, аларны һәр вакытта, һәр очракта хәтердә тота алмасак та, кыз-кыркын күргән чакларда онытмыйбыз, күңелебезгә аеруча хуш килгәннәрен күзебез белән «чишендереп» карарга иренмибез.

Ләкин мондый күңелле занятиеләрнең зачет биргән чакларда әллә ни файдасы тими, безгә барыбер бик күңелсез телдә язылган дәреслекләр, тиресе туналган кеше сурәтләре, тешләрен ыржайтып көлеп торган скелетлар өстендә казынырга туры килә иде.

Бер дәрестә бездән анатомия укытучыбыз каршыбызда елмаеп торган скелетның кемнеке булуын чамалавыбызны сорады. Скелетка карап, аның исән чагында кем булганлыгын ничек беләсең? Хәтта ирмехатынмы икәнен дә билгели алмыйбыз. Картмы-яшьме булганлыгын да әйтү кыен. Тик ыржаеп торган тешләре бары да исән булуына карап кына, бик үк карт кешенеке булмаска тиеш, дип әйтә алдык.

Укытучыбыз шуңа да канәгать булды:

— Дөрес чамалыйсыз— диде. Калганын үзе аныклап бирде.— Бу — хатын-кыз скелеты,— диде.— Үлгән вакытта унсигез яшендә булган...

Тәҗрибәле карт укытучы (илледән узган кеше ул елларда безнең өчен карт иде) дөресен әйткәндерме, күпчелеге егетләрдән яки малайлардан гыйбарәт булган укучыларының игътибарын ныграк җәлеп итү өчен әз генә ялганлагандырмы, анысын белмәдек. Дөресен әйткән булса да гаҗәп түгел. Хәзер бит инде бездә кем икәне билгеле булмаган килеш скелетка калган мәетләрнең баш сөякләренә карап, фотога тиң портретларын ясау күптән гамәлгә кергән эш.

Ялганлаган булса, да, укытучыбыз максатына ирешкән: менә бит,

төрле вакытта күрергә туры килгән дистәләрчә скелетларның барын да онытканмын, ә бу «унсигез яшьлек кыз» скелеты һаман хәтердә.

Живопись.

Сынлы сәнгатебез әүвәле гомумән бик түбән баскычта торганлыктан, бу сүзнең татарчасы бездә тумаган. Хәтта аны тәрҗемә итү өчен шундый аз хәреф белән күп мәгънә аңлата торган сүз табу да читен. Бакый ага Урманче аны «нәкыш» дип ала алуын да, ләкин, минемчә, татар укучысы аны дөрес аңласын өчен, янына җәяләр эчендә русчасын да язып куймыйча, барыбер тынычланып булмый. Сынлы сәнгатькә кагылышлы башка бик күп терминнарга карата да хәлебез шундый.

Живопись — тормышны, табигатьне төсләр, буяулар ярдәмендә гәүдәләндерү. Бу инде сынлы сәнгатьнең тагын да нечкәрәк, тагын да катлаулырак төре. Монда да уңышны, әлбәттә, художник күзе, художник хисләре, аның төсләрне, буяуларны үз пумаласына буйсындыра белү куәтенә ия булуы хәл итә. Ләкин чын художник бу өлкәдә фәнгә нигезләнгән җитди белем белән коралланмаса теләгенә ирешә алмый. Буяулар исә, үзләре бер дөнья. Үзеңә кирәкле төсне табар өчен нинди буяуларны бер-берсенә кушарга яраганын яки ярамаганын белү — элементар закон. Моның өчен художник аларның химик составын, физик үзенчәлекләрен белергә тиеш. Әзер буяулар белән генә эш итсәң, язган минутларда бер төсле булган буявың азмы-күпме вакыт үтү белән икенче төскә керергә мөмкин. Борынгы заманнарда иҗат иткән чын художниклар буяуны үзләре ясый, ясый гына түгел, кәшеф итә торган булган. Мең еллар буенча төсен һәм сафлыгын җуймый саклангaн буяулар арасында шушы көнгә кадәр рецептлары билгеле булмаган серле буяулар бар. Буяудан буяуны аера белергә генә түгел, чын художник аны кирәк булганда үзе ясый белергә тиеш. Технология живописи дәресендә безне буяу ясарга өйрәтәләр иде. Әзер рецептлар белән булса да, буяу ясау үзе бер мавыктыргач эш. Әйтик, синең алдыңда ике пробирка. Карап торуга икесенә дә саф чиста су салынган. Ә химик составлары төрле. Икесе дә бер үк су булып күренгән ике сыекчаны бергә кушсаң, ул шунда ук үзеннән-үзе кып-кызыл төскә керә. Мондый минутларда инде син үзеңне Әбугалисина кебек хис итәсең...

Техникумның үзенә генә хас булган бу дәресләре бары да минем өчен яңа, бары да мавыктыргыч иде. Шуны аңладым: кайчандыр иптәшләрем арасында рәсемгә осталыгым белән дан алган малай исәпләнсәм дә, бу техникумга килгәнче рәсем сәнгатенең нәрсә икәнен белмәгәнмен, аның шундый катлаулы фәннәр, техник белемнәр белән дә бәйле һөнәр икәнлеге турында хәбәрем булмаган.

Живописьтан дәрес ала башлаган көннәрдә хәтта көлкегә калган чакларым булды. Майлы буяуны бик кысып тота идем. Аны палитрама азлап-азлап кына сыгам, натюрмортымның иң кирәк урыннарына да мөмкин кадәр юка итеп сылыйм. Башкаларга карыйм, бер дә жәлләп тормыйлар. Тәҗрибәлерәк шәһәр егетләре аеруча юмарт кылана. Балчык белән абзар читәне сылыйлармыни? Белеп кыланамы соң болар? Әллә акчаларын кая куярга белмәүче бай балаларымы? Ышанмыйча, югарырак курсларда укучыларның ничек эшләүләренә күз салам. Анда да шул хәл. Киндер өстенә салган буяуларын пумала белән ышкып җәеп тә тормыйлар. Кайберләре хәтта пумала да кулланмый, мастихины белән генә чәпи. Түзмәдем, сорадым берсеннән:

— Ник буяуны бу кадәр әрәм итәсез?

Смирнов иде бугай, башта, бу нинди мәгънәсез сорау дигән сыман, беравык гаҗәпләнеп миңа карап торды. Аннары, кем икәнемне чамалап алды ахрысы, гадәтенчә ачы гына тамак тавышы белән кычкырып көлеп җибәрде:

— Буяу кызгансаң, гомереңдә художник була алмассың, мужик!

...Шул «мужиклыгым» чыгып бетмәү аркасында адәм хуры була

язуым турындагы бер вакыйга гомергә онытылмаслык булып хәтердә калган. Әлеге салкын подвалда торган чак иде. Бер малайның ун сум акчасы югалды.

— Кем урлаган?

Тентү башланды. Ә минем бишмәт чабуында, кара көнгә дип, Карамалыда чакта ук тегеп куелган червонец ята. Тентегән вакытта китереп чыгарсалар, үземнеке дип, ничек исбат итәрсең. Әйтергә дә соң, барыбер ышанмаячаклар, тентү башланган. Хәзер инде минем, ничә айлар буе саклап килгән яшерен байлыгымны югалтудан бигрәк, нахакка карак исеме алып, хурлыкка калу ихтималы куркыта. Нишләргә? Минем өчен ерып чыккысыз кара кайгы иде бу. Аптырагач, нәзер әйттем, исән-сау котылсам, ул акчага Мөкаддәс белән Барыйны сыйлар идем...

Уф! Ниһаять, сират күперен кичтем бугай. Миңа карата шик тотучылар юк иде, артык нечкәләп тентеп тә тормадылар. Котылдым дияр идем, шунда ук икенче кайгы менде: әйткән нәзеремне ничек гамәлгә ашырырга? Урлаган акча табылмаса, ә мин тик торганнан юмартланып китсәм, бу хәл үзе иптәшләрдә шик уятмасмы? Ничек котылырга бу яшерен чирдән?

Өч көн буена ашым — аш, йокым — йокы булмады. Ниләр генә кичмәгәндер күңелемнән? Теге акчасын югалткан ачык авызны тиргәп эшен китердем. Кеше башына хәсрәт өчен туган нәрсә! Җыя белгәч, әнә минекен, урлау түгел, тентеп тә таба алмадылар...

Бер уңайдан шунда үземә дә эләкте: «мужик» дип белеп әйтәләр сине, хосусый милекче калдыгы! Үзеңнән-үзең шул кадәр яшермәсәң! Шушындый торакка эләгеп тә! Инде стипендия ала башлагач та! Күптән расходка җибәргән булсаң бит!.. Әнә, Мөхәммәтша кебек, ак май ашасаң! Кеше шикелле кубрәк буяу алган булсаң! Шәһәр малайларыныкы төсле этюдник булдырсаң! Мастихиның да юк бит, адәм актыгы!..

Белмим, ни белән беткән булыр иде бу «кара көн», бәхеткә каршы, югалган акча табылып өлгерде. Беркем дә урламаган, югалтучы имгәк үзе гаепле булып чыкты. Акчасы табылганга үзе ни дәрәҗәдә куана алгандыр (тынычлыкны бозган өчен аңа ачы-ачы әрләү сүзләрен аз ишеттермәделәр), әмма минем өчен шатлык өстенә шатлык: акчам янга калды, аннан да бигрәк вөҗданым тынычланды. Якташ дусларымның да бәхете бар икән, житмеш биш тиенлек обедның тәме нинди икәнен белдек. Сырасын әйтеп тә тормыйм. Этюдник алып җибәрдем, симез-симез тюбиклы буяулар, модага кергән чагы булганга, шотландка күлмәк!..

Подвал чорында минем өчен тагын бер зур вакыйга булган икән. Ул турыда бөтенләй онытканмын, Мәрьям апаның иске кәгазьләре арасында ничектер бер хатым сакланып калган, шул искә төшерде. 1927 нче елның егерме бишенче мартында язылган шул хатның берничә юлын үзгәртүсез күчереп кенә алам:

«Мәрьям!

Исән-сау гына торасыңмы соң әле? Мин үзем сау гына инде хәзергә. Менә беренче апрельдә диспансерга барам. Шуннан соң сәламәтлегемнең ничеклеге турында полный иттереп язармын. Хәзергә зур хәбәрләрдән шул бар: 23 нче мартта синнән посылка алдым. Көтә-көтә тәмам саргайган идем, бик әйбәт булып калды. Юрганың әйбәт икән, сатарга кызганыч, оҗмахта йоклаган кебек йокладым. Простыняны да яраттым. Тик хәзергә файдаланмыйм әле, на всякий случай дип, кәрзингә салып куйдым. Тастымалың да шәп булды. Гомумән ярады инде, рәхмәт. Житмәсә, чалбар турында да өмит нервларын калтыратып куйдың, тик алдама инде. Тизрәк акчаңны җибәр. Җибәргәндә хат та җибәр, ләкин хатыңда болай диген: «менә, чалбарыңны саттым да акчасын җибәрәм, чалбар сатып алырсың, чалбар көйгә җибәрсәм акча күп китә» диген вә башка шундый бөтенләй ярдәм итүгә ерак булган

сүзләр белән тутыр, ягъни чит кешеләрчәрәк яз. Юкса монда аны-моны белмиләр, тоталар да отвод бирә башлыйлар. Алла сакласын, стипендияңнән колак кактырырлар...»

Бу юлларны шәрехләп торуның кирәге юктыр дип беләм. Ягылмаган подвал кышы бөтенләй эзсез үтмәгән икән, диспансер шуны күрсәтте: туберкулез ук булмаса да, үпкәләргә саф һава, канны күбәйтергә сөт-катык кирәк диделәр. Өстәвенә ул чакта туган якларны сагыну хисе дә яшьрәк, үткенрәк иде күрәсең әле, беренче курс өчен имтиханнарны биреп, икенчегә күчкәч, Җиргәнгә кайтып килергә булдым.

Ләкин бер ел диярлек читтә йөреп, Казан чаклы Казан каласында булып, авылдан киткәндәге кисемнәрем белән генә кайтып керәсе килми иде. Яңалык дип әйтерлек бердәнбер шотландка күлмәгем бар. Алмашсыз кигәч, ул да искереп өлгергән. Берәр ай эшләп алсам, шәт... Устьеда грузчик булыпмы анда, урам төзелешендәме...

Бәхет ишеге көтмәгән җирдән ачылып китте. Рәсем ясап та, хикәя язып та редакция тирәсендә йөри торгач, «Авыл яшьләре» журналында «Дуслар һәм дошманнар»дан соң тагы ике хикәям басылып өлгергән иде: «Сәйфулла», «Әби васыяте» (икесе дә үз иллюстрацияләрем белән). Соңгысы яшь язучыларның да, редакция кешеләренең дә игътибарын җәлеп итте — мине өметле каләмнәр җөмләсенә кертә башладылар. Аеруча Исхак Хәйруллинга ошаган иде ул хикәя. Бер баруымда әйтә бу миңа:

— Мин курортка китәм,— ди.— Давай минем урынга калып тор әле, егет. Бер айга гына.

Минем өчен дан иде бу тәкъдим. Әле кайчан гына шул урында Такташ утыра иде бит! Бөтен тәнемә ут капкандай булды: куанудан да, куркудан да...

— Булдыра алырмын микән?

— Булдырасың,— диде Хәйруллин.— Булдыра алмастай булсаң, әйтеп тә тормас идем.

Бер ай редакция секретаре урынында эшләү мине ул вакыттагы әдәбият, матбугат дөньясына якынайтуга зур этәргеч булды. Үзем кебек яшь язучылар каршында дәрәҗәмне күтәрде. Редакциягә әледән-әле кереп-чыгып йөрүчеләр арасында Демьян Фәтхи, Габдрахман Минский, Әсгать Айдар, Сәгыйть Агиш еш булалар, өлкәнрәкләрдән Кутуй көн саен диярлек хәлемне белеп чыга, туры килгәндә Такташ, Кави Нәҗмиләр дә сәлам биреп үтә иде.

Дәрәҗәсеннән дә бигрәк, хезмәт хакы ярап куйды. Җитмеш сум ул еллар өчен шактый зур сумма иде.

Кесәгә акча керү миңа бераз шөһрәтләшә төшәргә дә ярдәм итте бугай. Шундый бер деталь истә калган, кызык өчен генә булса да язарга ярый торгандыр дип беләм.

Техникум ишегалдындагы кечкенә өйдә ирле-хатынлы дворниклар тора иде. Аларның балалыктан аерылып җитмәгән, шулай да безнең кебекләрнең күзе төшәрлек формага кергән нәфис кенә кызлары бар иде. Очраганда шаяртырга, аның күңеленә хуш килерлек берәр уенсүз кушарга, җае чыкса, ачуын китермәслек кенә итеп, кагылып үтәргә дә ярата идек. Кесәгә акча кергәндәй булгач, шул сөйкемле кызны сыйлыйсым килеп китте. Беркөнне кәнфит тоттырдым үзенә. Рәхмәт әйтеп алды.

— Кәнфитне яратасыңмы син, Верочка?

— Мин пирожный яратам,— ди бу.

«Пирожный» турында монарчы ишеткәнем булса да, аның нәрсә икәнен белми йөргәнмен икән. Мин аны, аталуына карап, пирожкиның бер сыйфатында күз алдыма китерә идем. Ягъни ит бөккәнеме анда, кәбестәнекеме. Нәрсә булса да тамак туйдыра торган ризык. «Мин

пирожный яратам» дигәч, ач йөри күрәсең бу мескен дип, кыз баланы күңелемнән генә кызганып куйдым. Моны, әлбәттә, үзенә сиздермәдем.

— Пирожный?— дигән булдым.— Ярар, учтем!

Икенче көнне редакция буфетыннан ике данә ит бөккәне алып кайтып тәкъдим иткәч, кызымның күзләре шар булды.

— Вы что,— ди миңа,— мине ач дип beләсезме әллә?

Аптырый калдым.

— Үзең бит, пирожный яратам дидең!

— Пирожный булса бер хәл иде.

— Бу сиңа пирожный түгел мени?

Сыны катты.

— Пирожный шундый була мени?

— Нинди була соң?

— Әйдә күрсәтәм.

Якындагы урам чатында калач, клиндер һәм төрле тәмле-томлы әйберләр сата торган ларек бар иде. Шунда алып килде Верочка.

— Әнә!

Шунда белдем пирожныйның нәрсә икәнен. Моңарчы күземә чалынган булса да, минем кебекләрнең көче җитмәслек кыйммәтле ризыкка санап, андый әйберләр яныннан бөтенләй игътибарсыз үтә идем. Һәм чынлап та бик үк арзанлы сый булмаган икән ул. Ипинең кадагы ике тиен торганда, пирожныйга ун тиен алдылар. Кыйбат булуына карамастан, үземнең дә ашап карыйсым килгән иде дә, кыз кеше алдында җөрьәт итмәдем: мондый нәфис нигъмәт бәлки ир кешегә килешми торгандыр, белмәссең?

Шулай да соңыннан, таныш-белеш күрмәгәндә генә булса да мин аны ашап карамыйча булдыра алмадым. Ә ашап карагач... Кесәм рөхсәт иткән саен үземне пирожный белән сыйлаудан тыела алмый башладым. Шушы көнгә кадәр яратам тәмле пирожныйны, яхшы тортларны. Тик хәзер инде, аларда холестерин күп дип, өстәвенә симертә дип, медицина кушмаганга күрә генә тыелыбрак ашарга туры килә...

Билгеле, бер ай эшләп алган хезмәт хакын сыйлануларга гына тотып бетермәдем. Өс-башымны ярыйсы гына рәтләп, җиңгиләргә әз-мәз бүләкләр дә алып, тыныч күңел белән туган авылыма кайтып киттем.

Җиргәндә әле мине берәү дә язучы дип уйламый, тик рәсем мәктәбендә укуымны гына беләләр иде. Агай-эне, дус-иш, чын художник сыйфатында каршы алды.

— Давай минем портретны яса! — дип бәйләнә башладылар.

Теләсә кемне үзенә охшатып рәсемгә ясау! Бик ансат күрәләр. Дөрес, була шундый кешеләр, һәркемне, карау белән таныргык итеп, охшатып ясый беләләр. Андый портретларның күбесенчә сәнгать әсәре буларак әйтерлек кыйммәте булмый. Шулай да андый һөнәр ияләренә кызыгып карый идем. Чөнки үзем һәрвакытта да охшатып ясый алмыйм. Аерым очракларда (анда да йөз сызыклары артык күзгә бәрелеп торган үзенчәлекле, дөресрәге — ямьсез чырайлы кешеләрне ясаганда) уңышка ирешкән чакларым булса да, күп вакытта эшем барып чыкмый, бигрәк тә матур йөзле кешеләрне охшату кыен иде. Монда үзенә күрә бер закончалык та бар күрәсең: әдәби әсәр язганда да бит, күбесенчә уңай образларга караганда кире образларны иҗат итү ансатрак бирелә, уңышлырак та чыга.

Авылдашларым каршында дәрәҗәмне төшермәс өчен, берәүнең дә портретын ясап азапланмаска булдым.

— Юкны сөйләмә сәнә. Казан чаклы Казанда, махсус сурәт төшерү школасында кыш буе укып, нәрсәгә генә өйрәндең соң?

— Табигать күренешләрен ясарга була: әрәмәләрне, су буйларын. Өйләрне... беткән мени?

Һәм чынлап та этюдлар ясый башладым. Гади өчаяк принцибында мольберт әтмәләп алдым. Иске-москы әрҗәдән калган фанера кисәкләре җыйдым. Индә этюдник. Агыйдел буена чыгам да күңелемә хуш килгән берәр күренешне сайлап алып, буярга тотынам. Матур гына чыгалар. Үтеп-сүтеп йөрүчеләр арасыннан яныма тукталып, карап торучылар өзелми. Мин аларга игътибар итмәскә тырышам. Әйтерсең, күрмим дә үзләрен. Тамашачыларның да күбесе, тынлыкны бозарга җөрьәт итмичә, сүзсез генә торалар да берни әйтмичә китеп баралар. Арада соклану хисләрен эчләрендә генә калдыра алмыйча, берәр мактау сүзе әйтеп куючылар да була.

Нинди күренешләр буяганмындыр, ачыграк хәтеремдә калганы шул: авылыбызны ясадым. Беренче планда — Биргидел. Идел арьягында — Җиргән. Түбән урыннан карау өстенә, су буенда үскән усаклар булганлыктан, авылның калку урындагы өлеше генә күренә. Аеруча күзгә бәрелеп торганы — чиркәү.

«Шәп!» диючеләр байтак булды. Ләкин картинам Ахун абзыйга бер дә ошамады.

— Ә мәчет кайда?

— Ул урыннан караганда күренми.

— Өч мәчетнең берсе дәме?

— Берсе дә.

Ахун абзый, ризасызлыгын ачыграк сиздерергә тырышып, башын чайкады.

— Күренмәсә дә күрсәтеп ясарга кирәк аны. Бар бит ул. Җиргән рус авылы гына түгел ич!

Дөрес сүзгә җавап юк. Дәшмим.

— Ә соң биегрәк урыннан карап эшләргә булмыймыни? Авыл тулырак күренгән җирдән?

Хәзер искә төшереп хәйран калам: нинди дөрес, нинди мәгънәле тәнкыйть фикере әйткән Ахун абый. Бар әйберне күренеп тормаса да күрсәтә белергә кирәк. Рәсемне ясала торган объектың тулырак күренгән югарырак ноктадан карап эшлә! Бүгенге көндә дә төп закон бит болар. Рәссамга гына түгел, язучыга да.

Үзем теләгәнчә табигать күренешләрен төшереп, гамьсез генә ял итеп йөрергә ирек бирмәделәр. Рәсемнәремне күреп алучылар арасында бу «оста» егеттән файдаланырлык нәрсәләр ясатырга теләүчеләр табылды. Үгетләүләр өстенә, акчасына да кызыгып, рус урамындагы кооператив кибетенә зур итеп вывеска язып бирдем.

Моны күреп, икенче көнне үк яныма самавар төзәтүче килде. Мастерскоена шәп итеп вывеска бирергә куша. Әйе, сорамый, үтенми, байлар тоны белән боера. Аның болай кылануы миңа бер дә ошамады. Дөресрәге, сәер тоелды. Ничек инде ул миңа боера? Кем соң ул? Карыйм: тышкы кыяфәтенең үк ата-анасы юк. Кечкенә буйлы, зур борынлы. Камытланып калган аяклары шундый кәкре, арасыннан рәхәтләнеп кәҗә үтеп йөрерлек. Җитмәсә, галифе чалбар белән тар кунычлы күн итек кигән, мәнсез. Күренеп тора — читтән килгән кеше.

— Булмый, абзый кеше,— дидем, — андый эшне өстемә ала алмыйм.

— Ничек булмый? — диде «бай» чын-чынлап гаҗәпләнгән кыяфәттә. Мин бит сиңа акча бирәм, дурак!

— Акча кирәкми миңа.

Теге тагын да гаҗәпләнә төште.

— Ә ничек инде акча кирәкми?

— Шулай. Мин акча эшләргә кайтмадым, ял итәргә кайттым.

Акча кирәк иде., әлбәттә. Сер бирмәс өчен генә шундый горурлык күрсәттем. Дөрес эшләгәнмен булып чыкты. «Бай» капыл йомшарып китте.

— Ясап бир, егет,— диде,— Хәдичә дә бик мактап сөйләде үзеңне.

Хәдичә? Ачлык елны үлгән Хәйруш дустымның сеңелесе. Үсеп җитеп, шушы зур борынлы кечкенә кешегә кияүгә чыккан икән. Ярар, алай булгач, карарбыз.

Кулымнан килгән кадәр тырышып, комган, ләгән сурәтләре төшерелгән вывеска ясап бирдем. Хәдичә хәзер нинди булды икән, күрим әле дип, вывесканы үзем илтеп тапшырырга булдым. Мине күргәч, ачылып, йөзе яктырып китер, вывескага да сокланып туя алмас дип уйлаган идем. Кая ул! Бай бичәсе үзенең ялчы малае белән сөйләшкән кебек кылана. Әйтерсең минем белән гомерендә таныш булмаган кеше. Исәнме-саумы юк. Вывескага җитди генә карап торды да, кырыс, ачулы тавыш белән тотынды яманларга. Самавырның нигә бер ягы кара? Комганның борыны кыеш. Ләгәне тегенди, язуы мондый. Төзәтергә кирәк, яхшылап ясарга... Кара син аны! Ничек онытканн ул теге елларны? Каян килеп өлгергән кешегә мондый һавалылык? Тагы сер бирәсем килмәде:

— Юк,— дидем,— төзәтер урын юк. Дөрес эшләнгән. Һәр нәрсәнең күләгәле ягы караңгы була.

— Акчасын алгач...

— Кирәкми акчагыз.

— Аба-а-а, син бигрәк икән...

Хәдичәнең, ире кебек үк йомшарып, кешечә сөйләшә башлавы мине дә тынычландырды. Килештек. Вывеска үзгәртелгән килеш «байлар» торган йортның урам як стенасына чыгарып эленде.

Мин Казанга кайтканда безнең уку йорты театр техникумы белән берләшкән, торагыбыз Комлев урамындагы ике катлы ак йортка күчкән иде.

Подвалдан соң бөтенләй бүтән, яңа дөнья иде бу. Якты, җылы, иркен бүлмәләр. Чын мәгънәсендә ятак әсбаплары белән тәэмин ителгән тимер караватлар. Менә дигән ашханә. Атна-ун көнгә бер кухняда дежур торырга туры килә икән, анысына авырсынмыйбыз. Хәтта киресенчә. Кемнәрнең тырышлыгы белән булгандыр, безнең егетләргә дежурлык күбесенчә булачак артисткалар белән бергә туры килә һәм без бу көнне көнне көтеп ала торган идек.

Рәсемгә мөкиббән китеп, дөньясын оныткан егетләр йөрәгенә дә йокы бирмәслек асыл кызлар җитәрлек иде анда. Чибәрлеге, нәфислеге, нәзакәтлеге белән әкиятләрдәге хур кызларын хәтерләткән Галимә Ибраһимова, гади татар кызына хас бар матурлыкны: тазалыкны, янып торган алсулыкны үзенә җыйган булу өстенә, башына чиккән түбәтәй дә киеп җибәрүе белән тагы да ягымлылана төшкән Мәрзия Миңлебаева кебекләре турында әйтәсе юк. Чөһрәләрендә гүзәллек җитмәсә, буйларының зифалыгы белән алдыручы, алай да булмаса, ташып торган дәртләре, җырга-биюгә осталыклары, һич югында балдан татлы телләре белән һәркемнең дикъкатен җәлеп итәрлек кызлар да аз түгел иде.

Ә егетләре? Сәхнә кешесе буларак формалашып җитүдән әле ерак торсалар да, һәркайсы үзенә бер шәхес булган хөр күңелле егетләр дә җитәрлек булгандыр. Соңыннан театр дөньябызның күренекле кешеләре булып үскән Шириаздан Сарымсаков, Габдулла Юсупов; бу дөньядан бик яшьли китсәләр дә, сәхнәбез күгендә ялтырап, якты эз калдырып өлгергән Сәгыйтов һәм Газизовлар... Гомумән, барысы да йолдыз була алмаса да, татар театрларын озак еллар үз җилкәләрендә күтәреп килгән артист һәм артисткаларыбызның күбесе шул елларда театр техникумында укып йөргән яшьләрдән булды.

1928-нче елны шул торакта каршыладым. Радио-тапшыруларның яңа гына гамәлгә кергән еллары иде: кичләрен ял бүлмәсенә җыелып, җыр-музыка тыңлыйбыз. Күбесенчә Гөлсем Сөләйманова, Галия Кайбицкая, Ситдыйк Айдаров җырларыннан торган программа тәмамлангач та таралырга ашыкмыйча, шунда үзара гәп корып, төрле мәзәкләр, тәмле-татлы гайбәтләр сөйләшеп утырабыз. Һиһаять төн уртасы якынлаша. Яшькә дә, гәүдәгә дә барыбыздан олы булган шаян телле кырым татары, бәдәненә тиң килгән калын тавышы белән аталарча җитди тонда, ләкин «с», «з» авазларын сабыйларча сакау әйтә-әйтә:

— Ягедз, балалар, барыгыдз, пес итеп керегез дә, ятыгыз! — дип көлдерә дә, таралышабыз.

Башкалар ята, мин язарга утырам. Бүлмәдәшләремә комачауламас өчен, түшәм уртасында асылынып торган ялгыз лампочканы өстәл турысына тартып, өстенә кыек якалы кара сатин күлмәгемне кидерәм. Менә дигән абажур: яктылык нәкъ дәфтәрем өстенә төшә. Язам, рәсемнәр ясыйм.

Нәрсә язам? Уема, күңелемә ни килсә, шуны. Кулга каләм тотып утыргач, ниләр генә кылмы күңелгә? Баштан үткәннәр дә, күз алдында булып торган хәлләр дә, алда буласылары да. Язганнарымны мотлак бастыру турында хыялланмыйм. Иң якын максат: чираттагы «Якшәмбе»дә катнашу. Нәрсә булса да язып, аны каләмдәшләрем һәм гомумән әдәбият сөюче яшьләр хөкеменә чыгару. Хәтта алай да димәс идем. Гомумән, булды микән ул чакта алга куелган ачык бер максат? Юктыр, булмагандыр кебек. Ник язам? Язасы килгәнгә. Яшь чагында ник йөгерә кеше, ник бии? Яки нигә абзар башыннан сикерә? Нигә су коена? Кайчак хәтта чиркана-чиркана, кычкыра-кычкыра салкын суга керә? Тукта, сәламәтлегемне ныгытыйм, тәнемне чыныктырыйм дигән максат белән генәме? Юк бит!

Язасы килү дә миңа шулай күңел тансыклап торган табигый ихтыяҗга әйләнгән иде. Нәрсә турында языйм дигән сорау юк иде хәзер миңа. Бу сорауга җавап әзли торгач, шундый фикергә килгәнгән: теләсәң ни турында хикәя язарга мөмкин, яза гына бел! Әйтик менә шуны, янында үзем утыра торган өстәл. Гади агач өстәл. Ниләр генә күрмәгән дисең? Әнә аның өсте төрле язулар, сызыклар, шәкелләр белән сырланып беткән. Төрле төстә, төрле куелыкта буяу таплары, пәке эзләре, кнопка тишекләре, янып күмерләнгән таплар — Кытай картасыннан да чуаррак! Уйлап карасаң, һәркайсы билгенең артында конкрет кеше характеры һәм ул кешегә баглы вакыйгалар, тарихлар юк мени? Дөрес, мин аларны күрмәгәнмен. Белмим. Әмма ләкин язучыга фараз итү хокукы бирелгән бит! Хыялың гына эшләсен. Чынлыкта булганыннан да шәбрәк, кызыклырак, мәгънәлерәк вакыйга уйлап тап!..

Өйрәтелмәгән тай шикелле ирекле хыялымны эшкә җигеп, «Безнең өстәл» дигән нәрсә яздым. Хикәя идеме ул, нәсерме? фельетонмы? Әллә бәлки моңарчы булган теория кысаларына сыймый торган яңа бер төр әдәби әсәр килеп чыгар дип уйлаганмындыр? Әдәбиятка үз юлың белән, үз тавышың, үз алымнарың белән килергә кирәк диләр бит.

Чыкмады күрәсең. Язганымны укып карадым. Юк, кешегә күрсәтерлек әйбер түгел. Чүп савытына! Ләкин югалту түгел, табыш иде бу миңа. Әйе, тема хакында мондый фикергә килү ул вакытта минем өчен үземә күрә бер ачыш кебек иде.

Әнә бит, күрәм, идәндә бер төймә ята. Ә бәлки ул төймә генә түгелдер, менә дигән хикәядер. Гаҗәп түгел. Җитмәсә, Корноухов караваты янында. Өченче көн генә бакали кибетендә ялган чек ясап тотылган малай. Караклыктан да түгел, аның бары, рәссам буларак, үзенең осталыгын сынап карыйсы гына килгән. Мин хикәя язып караган кебек. Ләкин барып чыкмаган эшен йомарлап ыргытырга зиһене җитмәгән. Ярты

кадак колбаса өчен кулга алмаганнар алуын, шулай да якасыннан тотып селеккәннәр. Бәлки нәкъ шул минутта аның бишмәт төймәсе бушап калган булгандыр да, бүген өзелеп төшкәндер?.. Мавыгып, онытылып укырлык хикәя язып була ич моңардан. Малайның ничек итеп әзерләнүләре, иске касса чекларын табып, аларны өйрәнүе: нинди кәгазьгә сугылган ул, нинди зурлыкта, нинди хәреф, нинди цифрлар белән? Нинди кара яки буяу. Аннары аны, төн йокыларын калдырып, нечкәләп ясап утырулары, барып чыкмаганнарын берничә кат ертып ташлап, яңадан керешүләре. Инде барып чыкты дигәч, аны ничек итеп гамәлгә ашыру турындагы хыяллары. Магазинга кергәч, тәвәккәлли алмыйча азапланулары, ниһаять, сатучыга килеп тераләгәч дулкынланулары... Аның белән бергә, янәсе, әлбәттә, укучы да дулкынлана. Нишләр инде мескен? Ярты кадак колбаса өчен бит? Эләкмәсә генә ярар иде... Уф!

Әйе, искиткеч итеп язарга була моны! Шулай да язмадым. Ялган документ ясарга ниятләсәң, теләсә кемне ышандырырлык итеп яса, дип әйтергә телиме укучыга? Янәсе, җинаять эшләсәң, бөтен шартын китереп, жиренә җиткереп эшлә! Андый батырлыкка тәвәккәлләгәнсең икән инде, үзеңне фаш итмә, кыюрак бул...

Күңелемдә бөтен нечкәлекләренә кадәр эшләнеп беткән хикәя, кәгазьгә бер хәрефе дә язылмаган килеш, чүплеккә ыргытылды.

Ләкин төймә һаман урынында. Хәзер инде мин аны хыялымнан урамга күчерәм. Әнә ул, безнең торакка каршы чат аша гына гөрләп утырган Лядской бакчасы буенда ята. Әнә, шул бакча юлында көн саен диярлек миңа очрый торган бер татар малае килеп чыкты. Башына түбәтәй киеп йөргәнгә аеруча танылып торган бөҗәк малай. Юл өстендә яткан төймәне күреп, шып тукталды. Иелеп аны кулына алды. Әйләндереп-әйләндереп карады да, елмаеп, җан-фарман өенә чапты. Өйләре шунда, Эт тыкырыгында гына икән, минем хыял канатына утырып, шул секунд эчендә кайтып та җитте. «Әби!» дип кычкырып та җибәрде.

— Ни булды? Ник болай тының-көнең бетеп чаптың?

— Әби, син әйткәниең, тишекле төймә җирдә ятмас, дигән иең, менә тишекле төймә таптым, җирдә ята иде.

— Әнә бит, җирдә ятып калмаган, күтәреп алгансың! — ди әбисе, кет-кет көлә...

Хыялымдагы әбигә кушылып, мин дә көләм. Янәсе, балалар өчен менә дигән хикәя түгел мени?

Ныклабрак уйлап карагач, «менә дигән» булып күренмәгәндер, ахрысы, бусы да язылмаган килеш ташланды.

Ул чорда язылып яки язылмаган килеш ташланган хикәяләрнең саны күпмегә тулгандыр, исәбе алынмаган. Ташланмый калганнарыннан: «Үткәннәр», «Куркыныч урыннар», «Хафиз бармагы», «Җанлы бүкән», «Әбелгата күпере», «Бәхет порошогы» кебек хикәяләр «Авыл яшьләре», «Яңалиф» яки «Безнең юл» битләрендә дөнья күрделәр. Аннан җыентыкларга күчтеләр. Хәтта әле дә исәннәр. Заманында миңа алар турында азмы-күпме мактаулар да, каты-каты гына тәнкыйть сүзләре дә ишетергә туры килде. Аеруча «Бәхет порошогы» өчен орыштылар. Әмма мактау сүзләре генә түгел, кимчелекләремне, хаталарымны, күрсәтеп язылган тәнкыйть тә куандыра иде мине. Игътибарсыз калдырсалар гына күңелсез.

Иң шатландырганы һәм гомер буена онытылмаслык булып хәтердә калганы шул булды: «Безнең юл» журналының шул чактагы редакторы Гомәр Гали Кырымда — Галимҗан Ибраһимов янында булып кайткан иде, үзе әйтте. Галимҗан ага «Бәхет порошогы» турында кызыксынган икән.

— Бу хикәя чынлап та яшь язучы әсәреме, Мирсәй Әмир берәр өлкән язучының псевдонимы түгелме? — дип сораган.

Гомәр Гали артыгын әйтеп тормады. Минем өчен әйткән кадәресе дә бик житкән иде.

Язам гына түгел, рәсемнәр дә ясыйм дигән идем. Әйе, ул вакытта мин бит әле һаман да художество техникумы укучысы. Көндезләрен шунда укып йөрим. Кичләрен исә, ни дә булса язмаган чакларымда, басарга алынган хикәяләремә иллюстрацияләр эшлим. Үзем дә сизәм, рәсемнәрем камил түгел, үзебездә үк укучы Гата Юсупов яки Дмитрий Красильниковның рәсемнәре белән чагыштырганда түбән икәнлекләре күренеп тора, ләкин ясыйсы килә, үз хикәяләремне үз иллюстрацияләрем белән чыгару кызыктыра. Ихтимал, яратып, мавыгып эшләсәм дә, күңелемне канәгатьләндереп бетмәгән бу гамәлдән тыелырга да көчем житәр иде. Редакциядә эшләүче иптәшләр кисәтә белмәде. Күрәсең, үзләренең дә бу бабта аңлау яки тою дәрәҗәләре шундыйрак булгандыр, китергән рәсемнәремне сүзсез кабул итеп торалар, мактап җибәргән чаклары да булгалый. Хәтта үз әсәрләремә кагылышлы булмаган башка темаларга да заказлар бирә башладылар. Егерме жиде — егерме сигезенче елларда чыккан «Авыл яшьләре»н актарып карасаң, чынлап та алар арасында минем рәсемнәр кермәгән саннар аз булыр. Ул елларда чыккан «Чаян», «Азат хатын» битләрендә дә тырышып эзләгән кешегә М. Ә. рәсемнәре очрамый калмас...

Ләкин язу эшенә булган дәртем көчлерәк тә, әрсезрәк тә булып чыкты күрәсең. Техникумда без, сынлы сәнгатьнең үзенә генә хас практика һәм фәннәр өстенә, гомуми белемгә нигезләнгән дәресләр дә үтәбез. Матур әдәбиятка баглы дәресләр — миңа иң якыны, иң кадерлесе. Урманче аганың тырышлыгы белән булса кирәк, безнең өчен — ягъни нигездә бөтен фәннәр рус телендә генә үткәрелә торган техникумда укучы татарлар өчен — шундый махсус дәресләр булдырылган иде. Бу хәл үзе генә дә зур шатлык иде миңа. Аны укытучыбыз кем икәнлеген белгәч, кызыксынуым тагын да арта төште. Садри Җәләл, диделәр. Казанга килгәнче мин бу язучының әле исәнме-түгелме икәнлеген дә белми идем. Һаман яза һәм әдәби хәрәкәттә ярыйсы катнашып баручылардан икән. Тик попутчиклар җөмләсендә йөри,— ягъни, совет язучысы буларак, бик үк ышанычлылардан исәпләнми. Җитмәсә, революциягә кадәр офицер чинында булган имеш. Шуңа күрә, аның исеме матбугат битләрендә артык күзгә ташланмый. Кызыклы-кызыклы гына кәлке хикәяләре басылса да, үз исеме белән түгел, күбрәк «Тимер ага баласы» дигән псевдонимы белән чыга икән.

Боларын мин соңрак белдем. Ә беренче күргәндә ул минем өчен барыннан да элек кайчандыр Жиргәндә чагымда ук яратып мавыгып укылган «Дим буенда» китабының авторы иде. Тора-бара, әлбәттә, «Дим буенда»ның да әдәби кыйммәте теге вакытта мине мавыктырган дәрәҗәдә үк әһәмияткә ия түгеллеген аңладым. Шулай да укучыны мавыктыру көче тышкы эффектларга түгел, ә кешеләрнең эчке кичерешләрен, рухи дөньяларын ачуга нигезләнеп язылган әсәр буларак, ул әдәбиятыбыз тарихында бөтенләй үк эзсез кала торган китап түгел дип беләм.

Садри Җәләл шәхес буларак та ягымлы кеше булып чыкты. Буйга уртачадан бик аз гына калкурак булгандыр кебек хәтердә калган. Бәлки әйбәт, төзек сынлы булганга шулай күренгәндер. Хәрәкәтләре житез. Беренче карауга яшьлек алсулыгы инде уңа төшкән булса да, йөзе матур, һәм ул — сөйләгән саен җанлана, алсулана бара. Күзләре үткен, тере. Төркем эчендә утырсаң да һаман ул сиңа гына карап сөйли кебек. Аз гына карлыкканга тартым көр тавыш белән, фикерләрен ачык, аңлаешлы итеп әйтә, җөмләләре бер-берсенә язгандагы кебек шома ялганып бара. Бер кыш эчендә ул безгә нича тапкыр кереп өлгергәндер,

мәгәр әдәбиятыбызның тарихы, күренекле язучыларыбыз турында мин аның дәресләреннән байтак мәгълүмат алдым.

Уку елының буеннан буена рәссам пумаласы белән язучы каләме арасында көрәш барды. Көрәш мәйданы — минем күңел. Берсен дә җәберләргә теләмим, аларны үзара килештерәсем килә. Нигә сугыштырырга? — дим. — Рәсем ясап арыган чакларда язармын, язудан туеп киткән чакларда — рәсем белән юанырмын.

Уку елы тәмамланды. Икенче курс имтиханнарын биреп, өченчегә күчтем. Егерме җиденче елның көзендә үк Казанда татар мәдәнияты йорты ачылып эшли башлаган иде инде. «Безнең юл» редакциясе дә шунда күчкән, яшь язучылар түгәрәгенең утырышлары да һәр якшәмбе көнне, даими рәвештә шунда уза иде. Аларны калдырмыйм гына түгел, һәр кайсын сагынып, көтеп ала идем.

Укулар тукталу белән ГАЖУР юлын таптый башладым. Ниятләгәнемчә, язып арыган чакларда рәсем ясап, рәсемнән ялыккан араларда хикәя язып, юллык акча рәтләгәч, җәй урталарында тагын Башкортстанга кайтып килдем. Кайтмыйсым калган икән: мин югында Казанга Максим Горький килеп киткән булып чыкты.

Газета-журнал битләре Горькийга багышланган мәкаләләр, аның әсәрләреннән тәрҗемәләр белән тулган иде. Берсен калдырмый йотлыгып уку, атаклы язучының үзен күрү бәхетенә ирешкән иптәшләрнең дәртләнеп сөйләүләрен ишетү мине дулкынландырдылар да, беркадәр оялттылар да. Чөнки ул чорда әле мин, Горький турында күп ишеткән булсам да, аның иҗатын житәрлек күләмдә белми идем. Тотындым укырга. Оригиналыннан укырга тырышам, татарча тәрҗемәләрен дә калдырмыйм. Болай эшләү миңа, ул вакытта әле рус әдәби теленең бөтен нечкәлекләренә төшенү дәрәҗәм чамалырак булган авыл малаена, Горький әсәрләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә иде.

Язучының көче — тормышның, бигрәк тә кеше характерының һәркем күреп бетерә алмаган яки күреп тә һәркем игътибар итми торган әһәмиятле якларын, катлаулы нечкәлекләрне күрә, ача белүдә икән. Горький әсәрләре миңа менә шушы хакыйкатьне тирәнрәк аңларга ярдәм итте, язу эшенә булган мәхәббәтем тагын да арта төшкән кебек булды.

Укый торган мәктәбемнән бигрәк, мине Казан сагындырган иде. Җитмәсә, шуны белгәндәй, үземне тагы яшьләр матбугатына эшкә чакырдылар. Исхак Хәйруллин башка эшкә күчә икән, аның урынына секретарь булырга тәкъдим иттеләр. Худтехникум укучысы буларак, беркадәр икеләнсәм дә, әдәбият җенс кагылган күңелемә хуш килгән бу тәкъдимне кире кагарга көчем житмәде. Шул ук вакытта сынлы сәнгатькә булган мәхәббәт хисләремне дә җәберлисем килми иде. Чарасын таптым: сәламәтлегем какшауга сылтаган булып, техникумнан бер елга академик ял алырга булдым.

«Кызыл яшьләр» — атнага, «Авыл яшьләре» — айга бер тапкыр гына чыга торган булсалар да, икесенә бердәнбер булган секретарьга эш житәрлек иде. Җитәкче органнар белән җанлы элемтә редактор өстендә[1], тематик планнар да аның белән бергә төзелә. Ул планны тормышка ашыру исә, ягъни авторлар белән сөйләшеп, актуаль мәсьәләләр буенча материаллар оештыру, мәкаләләр, очерклар, махсус шигырь яки хикәяләр яздыру башлыча секретарьга йөкләнгән. Хәбәрчеләрдән килгән хатларның басардайларын аерып алып, калганнарына җавап язу да аның эше.

Басардай дигәннәре дә, әлбәттә, шул килеш типографиягә җибәрерлек булмый. Дөрес, без аларны, кагыйдә буларак, күчереп язып тор-

---

[1] Редактор Фазыл Мөбәракшин иде.

мыйбыз, (язу машинабыз юк та юк инде), кульъязманы, өстендә генә төзәтеп чуарлап чыгабыз да, шул хәлендә типографиягә җибәрәбез. Ләкин авылдан килгән хәбәрләрнең күбесе, ярым-йорты грамота өстенә, кәгазьнең ике ягына да язылган була. Андый кульъязманы типография кабул итми, күчереп чыгарга туры килә. Инде әзер булган материалны Чернышевский (хәзерге Ленин) урамындагы редакциядән Тукай урамындагы типографиягә илтеп тапшыручы курьер да үзем. Җыелган материалларны биткә салып чыгару эшендә метранпажга күрсәтмәләр биреп торучы да мин. Бу үземә күрә гаять җаваплы һәм четерекле эш. Макет буенча алдан билгеләнгән материаллар һәрвакытта да юлга юл килеп, үз урынына сыеп кына тормый. Андый чакта кульъязманы, укучыга сизелмәслек итеп кенә түгел, автор да сүз әйтмәслек итеп кыскарта белергә кирәк. Кайбер язмалар үзенә билгеләнгән урынны тутыра алмый икән, ул урынны тутыру чарасын тап. Теләсә ничек итеп түгел, әлбәттә, укучы да сизмәслек, редактор да бәйләнмәслек булсын!

Типография тормышы минем өчен яңа иде әле. Хәреф җыючылар арасында эшләп йөрү кызыклы да, гаять күңелле дә. Наборщиклар алар — ул чорда минем ише авылдан килгән малайлар өчен аеруча мөхтәрәм булган эшче сыйныфының каләм әһеленә иң якын торган катлавы. Язучылар белән алар арасында дуслык элек-электән килгән традиция икән. Типографиядә корректор булып эшләүче Мостакай аганың сөйләве буенча белдем: заманында Тукай да наборщиклар белән үз кешеләрчә якын мөнәсәбәттә булган. Такташның хәреф җыючылар белән һәр вакыт дус булуы үземнең үк күз алдымда. Иң матур поэмасында «Зөбәйдәнең наборщикка булган көчле гыйшкы турында» җырлавы да юкка гына түгелдер.

Ул чакта «Кызыл армеец» газетасының редакторы Кави Нәҗмине дә типографиядә еш очрата идем. Шунысы кызык, үзе редактор, үзе типографиягә йөри. Кулында коточкыч зур портфель. Верстка вакытларында выпускающий хезмәтен күбесенчә үзе башкара. Һәм ул моны шул кадәр яратып, шул кадәр мавыгып эшли, хәтта кайвакыт метранпаж эшенә тыгылудан да тыела алмый иде. Бергә туры килгән чакларда мин аның эшләгәнен җентекләп карап торам, кыен хәлгә калганда нинди чаралар табуын күзәтәм... Күрәм, бервакыт: подвал өстендәге баганаңы тутырырга ун-унбиш юл чамасы гранкасы җитми. Нишләр икән? Нәрсә белән тутырыр икән?.. Кайдандыр, үзе үк яшереп куйган урыннан алып булса кирәк, иске клишеләр китереп чыгарды. Берсен куеп карады буш урынга, икенчесен... берсе дә туры килми, кечкенәләр. Аптырап калгандай булды. Юк, озак баш ватмады, күрше өстәлгә тезеп куйган гранкалар янына килде. Күрә карау буларак, алар өстенә бик нык иелеп, үзенә кирәкне эзли башлады. Тапты. Аерым итеп бәйләп куелган кечкенә наборны, метранпажга әйтеп тә тормыйча, үз кулларына белән күтәреп алып, кирәк урынга китереп куйды.

Метранпаж, болай бик киң күңелле, редакция кешеләре, бигрәк тә язучылар, шагыйрьләр белән яхшы мөгамәләле кеше булса да, редактор-«выпускающий»ның бу эшен яратмады.

— Нишләвең инде бу, Кави,— диде. — Крәстиән гәзите гранкалары ич ул!

— Шаулама, Исмәгыйль абый, нинди гәзиттә басылып чыкса, шул гәзитнеке булыр.

— Толымбайский [1] белеп алса бу эшеңне...

— Җавабын үзем бирермен, курыкма. Мин аны бурычка гына алып торам ич, икенче хәбәр белән түләрмен! — Кави үзенең бу шук тапкыр-

[1] Ул вакытта «Крәстиән гәзите»нең редакторы.

лыгына каефе килеп, пырхылдап көлеп куйды. Исмәгыйль абый да йомшарды.

— Хет миңа әйткән булыр идең,— диде,— үз кулың белән тотынасың. Наборны чәчкән булсаң әгәр...

— Чәчте ди. Мин бит аны ничек чеметеп тотарга кирәген синнән өйрәнгән кеше.

«Шук редактор»ның бу «тәҗрибәсе» миңа да ярап куйды. Верстка вакытларында буш калган урынны тутырырга материал җитми торса, «Кызыл армеец» өчен җыеп куелган наборларга кул сузам. Әгәр Кави Нәҗми сизеп, әрли-нитә калса, күңелдә җавап әзер: бу гадәткә мин сездән өйрәндем, дияргә торам. Һәм, нәкъ Кавиның үзе кебек, үз алдыма үзем каефләнеп көлеп куям.

Секретарьлык вазифамны тырышып үтәп бару өстенә, әлбәттә, хикәяләр язудан да туктаган юк. Шул ук вакытта, рәсем мәктәбе укучысы икәнлегемне дә онытып бетермим. График рәсемнәр ясау эшем һаман бара, шул мәсьәләгә баглы җәмәгать эшләреннән дә читтә калмаска тырышам: яшь рәссамнар иҗаты турында мәкаләләр яза, мәдәният йорты каршында оештырылган сынлы сәнгать җәмгыяте идарәсендә секретарьлык итә идем. Ләкин тора-бара шуны аңладым: язу эше дә, сынлы сәнгать тә гаять үз сүзле, кире беткән һөнәрләр икән, ярты-йорты гына мәхәббәткә риза түгелләр, һәркайсы үзенә бөтен күңелеңне бирүне таләп итә.

Ахыр чиктә каләм пумаланы җиңде. Яңадан техникумга кайтмаска булдым. Җайлы сылтау да табылды: академик ял срогым тулуга хәрби хезмәткә барыр вакытым җитә иде.

Секретарь буларак, эшем хәбәрче хатлары, типография мәшәкатьләре белән генә чикләнми дигән идем. Иң әһәмиятлесе — газетаны — газета, журналны — журнал итә торган материаллар оештыру. Бусы инде авторлар табу дигән сүз. Ни җитте автор гына түгел, журналның, газетаның дәрәҗәсен күтәрерлек исем булсын. Такташ кебек, Кави Нәҗми, Кутуй кебек яки Гомәр Гали, Ғалимҗан Нигъмәти, Сафа Борһан кебек...

Дөрес, бу вакытта Казанда ТАПП оештырылган, һәм, яшь язучылар түгәрәгендә актив катнашып килүчеләрдән буларак, механик рәвештә диярлек, мин дә аның члены булып киткән идем. Өстәвенә редакция кешесе дә булгач, өлкәннәр белән аралашу хәзер миңа артык кыен түгел инде. Бервакыт, ниндидер актуаль темага мәкалә язуын сорап, Сафа Борһанга мөрәҗәгать иттем. Ул үзенең гаять пөхтә, нәфис тышкы кыяфәте белән дә, һәр сүзеннән сизелеп торган укымышлы, мәдәни кеше булуы белән дә, чины ягыннан да минем кебек оялчанрак егетләр өчен янына барырга кыймаслык абруйлы кеше иде. Өлкәнрәк язучылар да аны яратып, безнең Кольцов, дип йөртәләр, һәм ул чынлап та, нәфис-чибәр йөзе, үзенә бик килешеп торган пенснесы белән генә түгел, һәр хәрәкәтеннән сизелеп торган житезлеге, өлгерлеге өстенә бик актуаль темаларга яза торган подвал-подвал мәкаләләре, фельетоннары белән дә шул заманның иң атаклы журналисты Михаил Кольцовны хәтерләтә иде.

Яшьләр газетасына мәкалә сорап шул кешегә мөрәҗәгать итү минем өчен зур кыюлык кына түгел, әрсезлек тә күрсәтү кебек иде. Оялчанлыгыма түгел, үземне үзем кыюлыкка өйрәтү өчен, юри шулай тәвәккәллеккә бардым. Әлбәттә, отказ көткән идем. Яхшы дигәндә дә — «Син кем? Нинди газета өчен?» кебек сораулар биреп оялтыр дип уйлаган идем. Ә ул:

— Кайчанга кирәк?

Шундый гади, шундый табигый итеп сорады, әйтерсең мин аның,

руслар әйтмешли, үзе белән бергә бер пот тоз ашаган якын дусты. Зинһенем таралып китә язды. Срок кую турында уемда да юк иде. Шулай да югалып калмадым, аңардагы төгәллек, эшлеклелек шул секундта миңа да йоккан кебек булды:

— Берсекөнгә! — дидем.

— Ничә юл?

Бусы турында да уйламаган идем. Тагын аның йогынтысы ярдәмгә килде. Үзенчә төгәл итеп:

— Йөз илле,— дидем, чөнки подвалга шул чама материал кирәклеген беләм.

Ихтимал, бу сөйләшү онытылган да булыр иде. Өлкә газетасы редакторы, обком члены булган Сафа Борһанның шулай, үтеп барышлый гына биргән вәгъдәсен онытмыйча, мәкаләсен нәкъ әйткән вакытка, нәкъ әйткән күләмдә үзе китереп тапшыруы гомергә хәтеремдә калды.

Тагы Кави Нәҗмине ничек итеп «оештыруым» кызыклы һәм истәлекле булды. Редакция өстәлләре янында, типография кассалары арасында әледән-әле очрашулар мине аңа шактый иялләндергән иде инде. Мин аңардан «Авыл яшьләре» өчен хикәя язуны сорый башладым. Соравымны кире какмый, шул ук вакытта бик үк өметләндереп тә бетерми — вакыт булганда уйлап карармын,— дип кенә куя.

Ул чордагы кумирларымның берсе булган бу язучының көндәлек тормышта шукланырга, якын танышларын кызык итәргә ярата торган гадәте барлыгын белә идем. Үзенә карата башкалар тарафыннан эшләнә торган гөнаһсыз шуклыкларын гафу итә белүе дә миңа сер түгел иде. Үзен кызык итәргә булдым. Тоттым да, «Авыл яшьләре»нең киләсе номерында Кави Нәҗминең яңа хикәясе басылачак дигән белдерү чыгардым.

Күзләре шар булды.

— Што син,— ди бу миңа, әллә ачуланып, әллә куркынып,— рәҗе шулай подводить итәргә ярый?

— Вәгъдә иттегез бит!

— Нинди вәгъдә? Язылганы юк, бу арада гына яңа хикәя язарга да уйлаганым юк.

— Болай булгач, уйларга туры килер шул инде.

— Мине дә хур иттең, үзең дә хур буласың.

— Нигә мин хур булыйм. Хикәя булмаса, Кави Нәҗми вәгъдәсендә тормады дип язам да чыгарам...

Кыскасы, «Яр буенда учаклар» хикәясен язып китерде бу. Хикәя тәмамланудан ерак иде әле, шулай да, дәвамы киләсе санда дип, башын вәгъдә ителгән санга басып чыгардык. Дәвамы да вакытында өлгерде, азагы да.

Шундый юл белән язылган булуына карамастан, бу хикәясен Кави үзе дә бик яратты. Шундый яхшы нәтиҗә белән тәмамланган шуклыгымны гомер буена диярлек яратып искә төшерә торган булды.

Билгеле, күренекле авторларны тарту эше һәрвакытта да болай «уйнап» кына барып чыкмый, ялыну-ялварулар да, тырышып-тырышып дәгъвалаәүләр дә теләгән нәтиҗәне бирмичә, күңелгә борчу салган чаклар һаман була торган иде.

Андый чакларда тагы таякның авыр башы үз җилкәңә төшә. Һәм редакциядә эшләүнең шунысы әйбәт тә: ул сине үзең яшәгән чорның актуаль мәсьәләләре белән якыннан танышып барырга өйрәтә. Шәһәр яки республика тормышында көн саен диярлек алмашынып торган яңалыкларның эчендә кайнарга, аларга карата актив мөнәсәбәттә булырга мәҗбүр итә. Үзеңә дә әледән-әле публицистик характердагы мәкаләләр, фельетоннар, рецензияләр язарга туры килә.

Егерме тугызынчы елның февраль башлары иде. «Шәрык кичәсе» турында афишалар чыкты. Атаклы җырчылар, күренекле музыкантлар, мәшһүр артистлар исеме белән бизәлгән матур-матур афишалар. Обязательно барырга кирәк! Җитәр, афишалар белән генә канәгатьләнеп күп йөрдем...

Чынлап та, редакциягә кереп эшли башлаганчы театрга бару минем өчен кесәм күтәрә алмаслык зур расход иде. Ләкин үземне шушы көнгә кадәр гафу итә алмыйм: егерме алтынчы, егерме җиденче елларда, хәтта егерме сигезенче елның да беренче яртысында куелган спектакльләрнең күбесен күрмәгәнмен. Ел саен зур-зур концертлар булып тора, бөтен Казанны шаулаткан «шәрык кичәләре»... Аларыннан да читтә кала килгәнмен. Контрамарка алырга танышлыгым җитмәсә, этләшеп, хәрәмләшеп булса да, ниһаять, кайвакыт тамакны бераз тыеп булса да, керү юлларын табасым калган.

Хәзер, ягъни яшь язучы дигән исемем булу өстенә, редакциядә дә эшләгәч, минем өчен театр ишекләре ачык иде инде. Хәтта тора-бара түләүсез үк керә башладым. Чөнки...

Тукта. Көләсем килеп китте. Буратино исемә төште. Әле күптән дә түгел бугай, киноэкранда күрсәткәннәр иде. Итальян язучысы Коллоди иҗат иткән, Алексей Толстой үзенчәләштереп русча вариантын язган бу искиткеч әкиятне, олыгайгач булса да, бала чактагыдан болайрак кызыксынып, рәхәтләнеп укыганым бар иде инде. Кино сәнгате тагын да кызыклырак һәм мәгънәлерәк детальләр өстәгән булып чыкты. Әнә Папа Карло утын агачыннан курчак ясап утыра. Буратино инде тәмам әзер диярлек. Кыю-елгыр карашлы күзләре дә, югарыга чөелгән гадәттән тыш озын, без кебек очлы борыны да урында. Тик авызы гына юк әле. Папа Карло аңа авыз куярга керешә. Үткен пычагының очын тидереп, бер як ирен читен кисә башлауга, агач курчак телгә килә, үзен ясап утыручы Папа Карлоны өйрәтә дә башлый. Бик хаклы рәвештә, боерган тавыш белән әрсезләнеп кычкырып җибәрә:

— До ушей, до ушей!.. — ди, ягъни авызны колакка җитәрлек итеп ясарга куша.

Үзем дә шул Буратино кебегрәк булганмын ахры: кулыма каләм тоту белән диярлек, язучы сыйфатында авызымны ачарга өйрәткән хөрмәтле абыйларымны тәнкыйтьләп, мәкаләләр яза башлаганмын. Тәүбә итүем дип аңларга ашыкмагыз. Әдәби балалык чорындагы, акыл белән йөрәк бер хокукта булган чактагы ялгышулар әллә ни куркыныч түгел. Аларны гафу итү җиңел. Үз-үзеңә дә, синең тарафтан җәберләнгән мәсләктәшләреңә дә. Тәүбә кылырлык эшләр булса, соңрак, акыл «күбәйгәчрәк» булгандыр...

Ә «чөнки» дигәнем шул: театр әһелләре язучыларның спектакль карап, күңел ачып китүләре белән генә канәгатьләнмиләр, теге яки бу тамашаларына рецензия язып чыгучыларны исә, һәр премьерага кунак итеп, чакырып алырга әзер торалар иде. Мин дә шундыйлар җөмләсенә эләгеп киттем. Чөнки күргәннәрем турында фикер әйтергә яратам, кирәк табылганда язып чыгарга да иренми идем.

«Шәрык кичәсе»нә килгәндә бу дәрәҗәгә ирешмәгән идем әле. Ул кадәресенең минем өчен әһәмияте юк, билетны чиратсыз сатып алырга хәлемнән килүе дә җиткән иде.

Кичәне беренче күрүем. Минем өчен мещанлык, буржуа калдыгы саналган күренешләр мыжгып тора иде анда. Башларына энҗеле калфак кигән, күзгә бәрелерлек итеп иннек-кершән яккан, колакларына алкалар таккан кызлар. Кулларында беләзек, аякларында чәмчәле итек. Бүртмәч-бүртмәч итеп бәйләнгән, озын-озын чачаклы ак ефәк шәл бөркәнгән юан-юан абыстайлар: хәтфә кәләпүшле егетләр, җилбәгәй җибәрелгән пинжәк эченнән жилет кесәләрендәге сәгать чылбырла-

рын күрсәтеп масаеп йөрүче шома битле, бармак басым гына итеп калдырылган кара мыеклы, елтыр күзле абыйлар...

Ничектер ихтыярсыз Такташның «Казан» дигән шигыре исемә төште.

Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамында
Мин гыйсъянчы кереп адаштым.
Череп беткән мещан баткагында
Иркен уйларымнан саташтым...

Күрәсең, шагыйрь бу коточкыч юлларны бер дә юкка гына язмагандыр? Чынлап та ул Казанга килгән елларда ниләр кыланмагандыр болар? Әнә бит! Хәзер инде егерме тугызынчы ел. Хуҗалык өлкәсендә хосусый секторларга каршы актив һөҗүм башланган чор. Культура фронтында социализм хөкем сөрә. Меңәрләгән укучы яшьләр армиясе өстендә комсомол байрагы. Әдәбият дөньясы да бөтенләй бүтән, тегe вакытта Такташ язганча, «Шагыйрьләрең бардак җырлый синең, әдипләрең эчеп тилергән» диярлек түгел. Ә шулай да НЭП калдыклары монда үзләрен ничек иркен тота!..

Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Газиз Әлмөхәммәтов кебек атаклы җырчылардан халык моңнарын ишеткәч, җаным эреп киткәндәй булды. Милли киемнәргә карап кына нигә болай борчылып яшәдем соң әле мин? Шушындый моңлы җырлар иҗат иткән халыкның гореф-гадәтләренә, аның купшы киемнәренә хөрмәт белән караучылар бар икән, бәлки моңа куанырга кирәктер? Нигә бу кадәр кызылланам? Кайдан килгән революционер?..

Шундый уйларга килеп, күңелемнән үземне гаепли дә башлаган идем инде.

— Бөдәйли чыга! — диделәр.

Мәхмүт Бөдәйлине күргәләгәнем бар иде инде. Кайбер техникум яки институт каршындагы әдәби кичәләрдә чыгып, көлке шигырьләрен укый, «Миңлебикә душа мой» җыры белән дә халыкны көлдерергә ярата иде. Моңарчы ул чыгышларның мәгънә ягына әһәмият бирмим, башкалар белән беррәттән көлеп кенә үткәрә торган идем. Редакциядә эшли башлагач, ихтыярсыздан аның әсәрләренең идея эчтәлегенә игътибар итәргә мәҗбүр булдым. «Чаян»да чыккан шигырь яки фельетоннары турында редакциягә берничә хат килде. «Ни өчен ул «Кигәвен» дигән контрның комсомолларны мыскыл итеп, көтүчеләрдән көлеп язган нәрсәләрен басалар? — дип сорыйлар иде ул хатларда. — Аның шигырьләрен укыгач, кызларны әниләре клубка җибәрми. Хәтта комсомолга кергән кызлар үзләре дә кире чыгу ягын карыйлар».

Сәхнәдә Бөдәйли күренүгә үк тамаша залы көлә башлады. Мин аптыраудамын, тукта, нәрсә сөйләр бит әле?.. «Татар студентына» дигән шигырен укырга кереште. Һәр куплетыннан соң диярлек зал шаулап көлә. Ә мин җитдиләнә барам. Ачуым кабара. Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» дигән шигыренә ошатып язылган бу әсәрдә шул еллардагы татар студентының кызганыч хәле тасвирлана. Ул степкомга сөялеп кипкән. Яфрак төсле сары йөзле. Тук кешегә мәэюс карый. Аның гомерендә дә уку йортын бетереп чыгу ихтималы юк. Бетереп чыккан тәкъдирдә дә ни файда? Барыбер безработный булып кала...

Тамаша залы миңа яңадан җыен мещан, буржуа калдыгы белән тулган булып күренә башлады. Шуларны көлдерәм дип, безнең студентлар турында бу кадәр нахак сөйләүгә барып җитү?!.. «Кигәвен» дигән контр» дип юкка гына язмыйлармы әллә?

Бөдәйли чыгышыннан соң минем өчен кичәнең кызыгы бетте. Шундый атаклы кешенең шундый тотнаксыз чыгыш ясавына, җыен мещан

өерен, нэпман калдыкларын көлдерәм дип, уку йортларыбызга карата кара яла ягуына җаным газаплана: чын ихластан комсомол рухы белән сугарылган, изге максат өчен көрәштә беренчеләр булырга, кешеләргә рәхимсез гаделлеккә җилкенгән йөрәгемдә ачу кайный иде...

Сизенәм: бүгенге укучылардан кайбер иптәшләргә, хәтта яшьрәк буынга кергән каләмдәшләремнең дә кайберләренә бу юллар артык «кызыл» булып тоелыр. Ихтимал, дөньяда гыйшык-мәхәббәттән өстен башка бернинди көч юк дип ышандырырга теләүче кайбер иптәшләргә минем ул тойгыларым ясалма, ялган булып та күренер. Ләкин чын иде алар, бернинди шәхси мәнфәгатькә, кемгәдер ярарга тырышуга яки кемнәрдәндер куркуга нигезләнмәгән саф, самими тойгылар иде. Шулар уты белән ярсып, ялкынланып, өемә кайттым. Өй дигәнем — кеше фатиры эчендә шырпы кабы кадәр генә бүлмә. Такта төпле тар тимер карават белән сыңар тумбалы өстәле янына тагы бер урындык сыйган. Бик каһәрләсәң, ишекнең уң ягында этажерка куярлык урын да бар. Ләкин әлегә ул этажерка базарда. Аның урынында турыдан-туры идәнгә өелә башлаган китап чүмәләсе.

Бүлмәмнең тар, җиһазларымның ярлы булганлыгын хәзер генә, бүгенге заман түбәсеннән карап кына күрәм. Ул вакытта исә дөнья киң иде миңа, кайда булсам да суларга иркен иде. Барлык уй-тойгылар, әйтәсе фикерләремне яктыртырга җиделе лампа нуры да җитә, кәгазь абажурдан аңкыган җиңелчә көек исе ашыга-ашыга язарга илһам биреп тора кебек иде.

Озакка сузылган «шәрык кичәсен»нән кайтып кергәндә, әлбәттә, вакыт соң булгандыр инде. Ләкин ятып тору кая ул! Утырдым язарга. Бөдәйли кузгаткан нәфрәт хисе әрнетүенә чыдый алмыйча, фельетон язам. Ачы булсын. Бөдәйлинең генә түгел, аның пролетариат студентын мыскыл итүенә кәефләнеп, авызларын ерып утырган буржуа калдыкларының да бәгырьләренә үтәрлек булсын! Мондый җавапсыз чыгышларга юл куйган гамьсез администраторлар да терсәкләрен тешләсеннәр!..

Сыйнфый көрәш аеруча идеология фронтында кискен төс алган чорның рухы шундый булгандыр күрәсең: фельетоннар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре коточкыч каты, рәхимсез стильдә язылалар иде. Шул ук Кави Нәҗми, Гомәр Гали, Гомәр Толымбайский, Г. Кутуй, С. Борһан кебек язучы һәм журналистларның үз каләмдәшләре турында ук язган мәкаләләрен кире кайтып укып карасаң, бүгенге укучы өчен чәчләр үрә торырлык!

Билгеле, ул рәхимсез чыгышлар арасында, чынлап та гадел сыйнфый принципка нигезләнгәннәре белән беррәттән, модага ияреп дуамалланган авторлар да, «син минем борынга бирсәң, мин синең авызыңа!» дигән принциптан чыгып чәкәләшүчеләр дә, кибәнгә кунган каргага туптан атып гайрәт күрсәтүчеләр дә аз булмагандыр. Шулай да хәзерге яшь язучыларыбызны кызганып куям: күбесе утызынчы елларга кадәр чыккан газета-журналларыбызны укый белми бит. Китапларыбызның да бүгенге көн өчен әдәби әһәмияте бар дип табылганнары гына хәзерге алфавитка күчереп басыла. Ә калганнары? Алар арасында әдәбиятыбызның тарихын тулырак белергә т е л ә ү ч е л ә р өчен генә түгел, аны мотлак белергә т и е ш л е кешеләр өчен никадәр бай, никадәр кызыклы, әһәмиятле материал! Ә бит үз әдәбиятыбызның чын патриоты булган татар язучысына гарәп алфавитын өйрәнү мөмкин булмаган эш түгел. Хәтта бик ансат дияр идем... Ярар, әйтү бездән булсын, ә аларга колак салуны бүгенге һәм иртәгә киләчәк язучыларыбыз намусына калдырыйк. Бөдәйлигә кайтам.

Яздым. Заман стиленнән калышмаска теләп, хәлемнән килгән кадәр каты итеп язарга тырыштым. Тамашачыга сатирик планда характерис-

тика. Бәдәйли шигыреннән өзекләр. Совет студентларының хәле турында рәсми-политик белешмәләр арасында рәхимсез нәтиҗәләр: «...алкышлар астына күмелгән тиле Бәдәйли инде тигәнә буе сикерә башлый. Шул кадәр сикерә кем, киракле киртәсеннән аша чыгып, контрреволюцион пропаганда баскычына барып житә... Пролетар студенты хакында бу кадәр нахак сөйләргә Чемберленның үзенең дә көче житмәс!... Сәяси жинаять!.. Безнең тарафтан якты йөз күрми торган типичный мещан, вак буржуа җәмгыяте кәефе өчен булган шундый әшәке чыгышлар бетсен!.. Долой!..»

• Иртәгесен, фельетонымны күтәреп, кердем «Кызыл Татарстан» редакциясенә. Турыдан-туры редакторның үзенә — Сафа Борһанга.

Язмамның исемен күргә үк сагая калды. Җитдиләнеп китте. Күз йөртеп кенә укырга керешге. Карап торам, укый, көлми дә, елмаймый да. Укып чыкты.

— Мә?

— Басмыйсызмы?

— Контрреволюционер дип әйтү белән килешә алмыйм.

Болай булыр дип көтмәгән идем. Сафа Борһан зур авторитет иде минем өчен. Өлкә газетасында редактор булганга гына түгел, зур культуралы кеше, талантлы, үткен каләмле журналист буларак хөрмәт итә идем мин аны. Үзе дә әдәбият, мәдәният мәсьәләләренә кагылган кимчелекләргә карата искиткеч каты, рәхимсез һәм ышандырырлык итеп, мәкаләләр язып чыга торган кеше бит! «Матур әдәбиятта кризис!» дигән мәкаләсендә Кави Нәҗми, Толымбай, Такташ кебек язучыларны ничек каты тәнкыйть иткән иде! «Бездә дә Совет властев» дигән мәкаләсен укып карасаң? Татарстан турында нахак сүзләр язган өчен Караев дигән берәүне ничек тетеп салды? Хәтта «Правда»да басылган дип куркып тормады. Нигә минем фельетонны чыгарырга теләми?

— Бәдәйлине тәнкыйть итәргә ярамыймыни?

— Ярый. Ләкин официаль органда шундый зур җаваплы урындагы коммунистны контрреволюционер дип чыгара алмыйм.

Мин дә бит анысы бөтенләй контрреволюционер дип үк атамыйм, бер чыгышын гына тәнкыйтьлим. Шулай да сүз көрәштерергә базмадым. Ярар, официаль органда ярамаса, безнең комсомол газетабыз бар.

«Кызыл яшьләр»дә үзем хуҗа диярлек. Редакторыбыз күптән түгел генә районнан килгән комсомол работнигы Барый Корбанов. Уку йортларына, совет учреждениеләренә елышкан чит элементларның килешмәс дошманы. Буржуй калдыкларына, милләтчеләргә, тотнаксыз чыгышларга каршы комсомолларча сугышчан рухта язылган мәкаләләрне тартып алып басарга әзер. Бастык та чыгардык. Гарәп хәрефләре белән әле! Монысының хикмәте шунда: яңа әлифбага күчү чоры иде. Газетага кергән материалларның бер өлеше искечә басыла, бер өлеше — яңача. Укучы масса әле латин хәрефләрен өйрәнеп тә житмәгән, аңа ияләшеп тә өлгермәгән, гарәп хәрефләре белән басылган язмалар күбрәк укыла, шуңа күрә һәр автор диярлек үз әсәренең иске хәрефләр белән чыгуын артыграк күрә иде.

Яңа гына типографиядән кайткан беренче нөсхәне кулга алуыма редакциягә Мөхәммәт Парсин килеп керде. Минем өчен бу кеше, редакция работнигы булудан бигрәк, яңа спектакльләргә рецензияләр язып килүе белән мәгълүм журналист иде. Җәнҗаллырак характердагы мәкаләләргә карата хиреслеген дә беләм. «Ялчы» газетасында эшләгән чагында Такташ белән судлашып йөрүләре хәтеремдә. Үзеннән сорамыйча гына басып чыгарылган бер шигыре өчен Такташ гонорар сорагач, Парсин аңа: «Ялчыдан акча сорарга ничек оялмыйсың?» дип ачуын китергән. Әлбәттә, редакциянең явыз нияте булгандыр дип уйламыйм. Чынлап та гонорар фондлары зур түгел, эшче-крестьян яки

ялчылар арасыннан чыккан хәбәрчеләрне кызыксындыру өчен, редакция тирәсендә эшләүчеләрнең үз гонорарларын кимету исәбенә аларга артыграк түләү практикасы бар иде. Такташ турында да, инде кайдадыр бер кат басылган шигыре өчен гонорар өмет итмәс дип уйлаганнардыр. Алдан әйткән булсалар, әлбәттә, шулай үтеп тә китәр иде. Ләкин, хаксызга оялтырга теләп ачуын китергәч!.. Такташ «Ялчы»ның да үзенә күрә гонорар фонды барлыгын белә. Автор хокукы турында да хәбәрдар. Тота да судка бирә. Эш болайга киткәч, Парсинның да дәшми генә каласы килми. Такташны оялта торган рухта хат язып, аңа берике хәбәрчесеннән дә кул куйдырып, «Ялчы»да бастырып чыгара. Янәсе, шундый атаклы кеше, шигырен баскан өчен акча даулап, батраклар газетасы белән судлашып йөри!

Казан укучылары өчен бөтенләй диярлек барлыгы да мәгълүм булмаган газета өчен сенсация! Тагы ни кирәк Парсинга? «Кәҗәсе түгел, мәзәге кыйбат!»...

Яңа гына «табадан төшкән» газетаның беренче битендә үк зур хәрефләр белән язылган «Долой!» сүзен күргәч, җәяләр эчендә «Бөдәйли репертуары турында» дигәнен дә укыгач, кәефләнеп, кычкырып җибәрде.

— Аһа! Бүрек салып укырлык нәрсә бар, болай булгач! — Һәм шул сүзләрне әйтү белән үк, башыннан бүреген тартып алып өстәлгә бәрде дә, утырып та тормыйча, фельетонга йотылды. Минут эчендә диярлек укып та чыкты.

— Молодец! Егет икәнсең. Шәп!

Ул көнне мин «молодец» сүзен күп ишеттем. Тик гел диярлек яшьләрдән. Дәрәҗәлерәк өлкәннәрнең игътибар күрсәтмәве бераз эчемне пошыргандай итте. Чынлап та укымаганнармы? Әллә юри күрмәгәнгә, ишетмәгәнгә салыналармы?

Күңелемдә туган бу шикле сорауларга Кутуй сүзләре ачы җавап булып ишетелде.

— Укыдым,— диде ул миңа нindидер мыскыл катыш елмаю белән,— «Моська»ны хәтерләттең...

Эсселе-суыклы булып киттем. Крылов бабайның атаклы мәсәле миңа таныш иде. «Ай, Моська! Знать она сильна, Коль лает на Слона» Менә ничек уйлый икән Кутуй! Янәсе мин, филгә өргән әнчек кебек, кемнәргәдер батыр каләм иясе булып күренү өчен, Бөдәйли чаклы Бөдәйлигә каршы тавыш күтәрәм?! Намусыма тиде. Мин бит аны, ул фельетонны, чын сыйнфый тойгылар ялкынында, нинди изге, революцион ниятләр белән янып яздым. Ә ул?!

Кутуй турында моңарчы кайберәүләрдән хөрмәтсезрәк сүзләр ишеткәнем булса да, аларга исем китми, үзенең җыелышлардагы мәгънәле чыгышлары белән дә, акыллы, эчтәлекле, үткен мәкаләләре, ниһаять, һәрвакыт шат, ачык чырае белән дә ул миңа бары хөрмәткә лаек кеше булып кына күренә иде. Намусыма кагыла торган мыскыл сүзен ишеткәч, уйлана калдым. Әллә ул чынлап та миңа күренгәнчә үк идеальный кеше түгелме? Хәйретдин Вәли белән аның арасында булган бер диалог турындагы анекдот исемә төште. «Кызыл Татарстан»да «Апасы чүп, матур сеңелесе» дигән бер фельетон чыккан иде. Анда Кутуй Хәйретдин Вәлинең апалы-сеңелле ике кыз белән чуалып, судка эләгүе турында әдәбиятчыны бик каты мыскыл итеп яза. Монда да ул миңа каләм әһелләре арасында мораль сафлык өчен көрәшүче яхшы күңелле кеше булып кына күренгән иде. Озакламый, кулуар гайбәтләреннән ишетеп, шуны белдем: элегрәк Х. Вәли Кутуйның футуристик шигырьләрен бөтенләй юкка чыгарып язган булган икән. Үзенең кызлар белән чуалуын тәнкыйть иткән фельетонны укыгач, Хәйретдин Вәли Кутуйга әйткән, имеш: «Мин, ичмасам, яхшымы-начармы, синең иҗатың турында әдә-

би тәнкыйть язганмын. Ә син минем... фәләнемне тәнкыйтьләп чыгасың!» дигән. Ләкин аны да шаян телләр чыгарган санап, көлеп кенә куйган идем. Барыбер Кутуй аны дөрес тәнкыйть иткән. Әдәбият кешесенең мораль йөзе әһәмиятсез мәсьәлә түгел... Шулай да җитәрлек беләммә соң әле мин аны? Пьесаларын дисәң, исемнәрен генә ишеткәнем бар. «Балдызкай», «Калфаклылар»... Нинди соң алар? «Гомумән алганда, пүчтәк!»

Язучылар, театр әһелләре арасында гына түгел, укымышлырак тамашачылар арасында да канатлы фраза булып киткән бу сүз шул «Калфаклылар» турында әйтелде бит. Кем тарафыннан диген? Сафа Борһан чаклы Сафа Борһан үзе шулай дип язып чыкты. Димәк... Кутуйга да тәнкыйть күзе белән карарга кирәк, дигән нәтиҗәгә килдем. Юк, бер Кутуйга гына түгел, шул ук Сафа Борһанга да, Гомәр Галигә дә, хәтта Такташка да, Кави Нәҗмигә, Толымбайскийларга да... Барына да. Комсомол ич мин!..

Ә минә Урманче мине бераз уйга калдырды. Рәсем мәктәбендә инде укымасам да, бер елга академик ял гына алган кеше буларак, сынлы сәнгатьтән бөтенләйгә китеп беткәнем юк иде әле. Үз хикәяләремә генә булса да, иллюстрацияләр ясыйм, яшь рәссамнарның иҗатлары турында мәкаләләр язам, Мәдәният йорты каршындагы сынлы сәнгать җәмгыяте идарәсендә секретарьлык эшен алып барам. Рәисебез Урманче булганга, миңа аның белән һаман да очрашып торырга туры килә.

Бөдәйли турындагы фельетонны ул да укыган булып чыкты.

— Тәтенен, ихтимал, туры да чыга торгандыр,— диде ул миңа.— Мәгәр, яшь кешегә үзеңнән өлкәннәргә карата алай тупас булу килешми. «Әдәбият», «әдәп» — бер тамырдан чыккан сүзләр. Әдәпле булырга кирәк.

Кызарганмындыр. Колакларым җылынудан сиздем.

Гаҗәпләндергәне Бөдәйли үзе булды. Әйе, үзе ничек кабул итте соң? Кутуй әйткәнчә булса, Бөдәйли дигән «фил» Мирсәй дигән «әнчек»нең ләңгелдәвен колагына да алмаска тиеш иде. Юк, алай булмады. Икенче көнне үк фельетонга җавап урынына озын мәкалә язып китерде. Ул анда сатира жанрының үзенчәлеге турында сөйли, үз шигыре белән студентларның тормышын яхшыртырга комачаулаучы бюрократларны камчылыйм дип аңлатырга тырыша. Монысына ышандыра алмаган иде. Ләкин гаять тыныч, шәфкатьле аталарча йомшак тоны белән күңелемне йомшартты. Мине өметле, талантлы яшь язучы дип бәяли, җитди мәсьәлә турында сүз барганда андый «ачы атамалар» белән мавыкмаска киңәш бирә. Җитмәсә, нәкъ шул көннәрдә үк, Мәдәният йортында атна саен уздырылып килә торган яшь язучылар оешмасының чираттагы утырышында, юмор-сатира турында шул ук Бөдәйлинең докладын тыңланды. Очраклы рәвештә шулай туры килдеме, махсус оештырылгандырмы, анысын белмәдем. Мәгәр, юмор-сатира турында бик әйбәт сөйләде. Бу жанрда эшләүче яшьләргә тукталып, миңа кагылырга да онытмады: — ...тиешле уйланып җитмәгән, акылсыз фельетон язып чыгуына карамастан,— диде,— Мирсәй Әмирне яшьләр арасында өметле каләмнәрнең берсе дип әйтер идем...»

Миңа бераз оят булды. Ләкин сиздермәскә тырышып, шаярып утырдым. Тамаша залы, гадәттәгечә, шыгрым тулы. Урта рәтләрнең берсендә, төрле уку йортларыннан килгән таныш кызлар янында утырам. Арада миңа Стәрлетамактан ук таныш булган, фамилиясе белән Галимҗан Ибраһимовка барып тоташкан Фәрдәнә исемле кыз да бар. Актив әдәбият сөюче. Көләргә дә, көлдерергә дә ярата торган кеше.

— Карале,— ди ул,— бу Бөдәйли сәхнәгә чыккан саен эчләрне катыра торган иде, нигә бүген болай бер дә көлдерми сөйли?

Чынлап та, юморист булып танылган язучының бу чыгышы бик җитди иде. Якташ кыз янында шаянлыгымны күрсәтәсем килде.

— Көлдерә алмаса, без аңа ярдәм итәргә можем,— дидем.

— Хәзер шундый сораулар яудырабыз...

Нинди кызыклы сорау бирим икән дип, уйланып утырганда бездән алдагы рәттә утыручылардан берәүнең күршесенә пышылдаганы колагыма керeп калды: «Карәле, әй, алтын тешле кеше үлсә, аның тешен нишләтәләр икән?». Булды, шул сорауны яздым да җибәрдем докладчыга. Аның белән генә канәгатьләнмәдем, әлбәттә. Тагы нинди сораулар биргәнмендер, хәтердә калганы: «Көлгән вакытта нигә кендек селкенә?»...

Докладчы залдан килгән язма сорауларга җавап биргәндә аларның һәммәсен кычкырып укыды. Җаваплары әйтерлек тапкыр булды микән? Мәгәр, сорауларның үзләреннән бөтен зал шаркылдап көлде. Имзасыз гына җибәрелгән ул записокаларның авторы кем икәнен янымда утырган таныш кызлар гына белә иде.

— Күрдегезме? Әйттем бит мин сезгә!..

«Кызыл яшьләр»нең чираттагы санында Бөдәйлинең җавап хатын бастырдык. Шул ук санда минем дә җавап хатка җавабым чыкты. Мин анда Бөдәйлинең юмор өлкәсендә җитди хезмәтләре барлыгын әйтәм, өлкән кеше буларак, аңа хөрмәт белән каравым турында белдерәм, тәҗрибәсезлегем сәбәпле, кирәкмәгән тупас сүзләр әйткәнем өчен гафу үтенәм. Шуның белән бергә, язучының зарарлы шигырьләрен дөрес тәнкыйть иткәнлегемне белдереп, андый чыгышларга бездә беркайда да урын бирелмәскә тиеш, дип куям. Кемнең кулында — шуның авызында дип юкка гына әйтмәгәннәр күрәсең: Бөдәйлинең хатын яңалиф белән, аңа җавап сүзен искечә басып чыгардык.

Үземнең беренче китабым язмышы да шулай булып чыкты. «Пар күгәрчен» турында әйтәм. Мин аны язганда барлык әдәби китаплар да башлыча гарәп хәрефләре белән басылалар иде әле. Ләкин аны, үзенә күрә повесть хәленә китереп, басарга тапшырганчы байтак вакыт үтеп китте. Башта ул яшьләр арасында балаларга яңа исем кушу белән мавыгып хурлыкка калучылардан көлеп язылган кечкенә хикәя иде. Укучыны көлдерәм дип, чамадан тыш арттырып җибәргәнмен булып чыкты. Шактый караңгы авыл. Комсомол егет белән комсомолка өйләнешеп, яңа тормыш коралар. Игез балалары туа. Малай белән кыз. Яңа исем кушарга кирәк. Моңарчы беркем дә кушмаган булсын: әйтелеше дә матур, яңгырашы да шәп! Төрле китаплардан, сүзлекләрдән эзли торгач табалар: малайны — Геморой, кызны — Гонорея дип атыйлар...

Яшь язучылар түгәрәге утырышында, гадәттәгечә, Мәдәният йортының тамаша залы тулып утырган әдәбият сөючеләр каршында кычкырып укып чыктым. Һәр җөмләдән диярлек көлеп утырдылар. Сабыйларга кушылган яңа исемнәрне ишеткәндә залның эче катты.

Монысына кәефем килде. Ләкин фикер алышуларда әйтелгән тәнкыйть сүзләре бик нык уйланырга мәҗбүр итте. Хикәя арзанлык көлкегә корылган, диделәр. Идея эчтәлеген тирәнәйтергә, социаль ягын киңәйтергә кирәк...

Боларны ишетү, әлбәттә, күңелле булмады. Ләкин тәнкыйтьнең файдасы тиде. Ул еллардагы комсомол хәрәкәтенә хас проблемаларга бәйләп, ягъни хәлемнән килгәнчә тирәнәйтеп, шул ук вакытта юмор стилен дә сакларга тырышып, ул вакыттагыча әйткәндә, озын хикәя (ягъни повесть) итеп эшләп чыктым. Арзанлы көлкедән арындыруым шул булды: Геморой белән Гонорея — Сәлим белән Сәлимәгә алмашындылар.

Бик әйбәтләп акка күчереп, аның янына «Гайнетдин хуҗалыгы» дигән кечкенә хикәямне дә кушып, Татарстан китап нәшриятына илтеп тапшырдым.

Матур әдәбият бүлегенең башында Галимҗан Нигъмәти.

Яше ягыннан шул ук Гомәр Галиләр, Кави Нәҗмиләр, Толымбайскийлар белән бер чамада йөресә дә, ул миңа өлкәнрәк күренә, кешеләр белән мөгамәләсендә дә, язу манерасында да тыныч табигатьле, сабыр, акыллы шәхес булуы белән аерылып тора иде.

Үзем катнашырга туры килгән берәр утырыш яки җыелышта Нигъмәти булса, мин аның барлыгын һәрвакыт тоеп торам, игътибарымның бер өлеше өзлексез аңарда була. Рәсем сәнгатенә төгәллекле[1] хисләрем кушкангадырмы, үзем дә белмәстән, мин аның йөз хәрәкәтләрен, утыру рәвешләрен, өстенә кигән киемнәрен күзәтәм. Буйга озын, чандыр, заманына хас булганча, сакал-мыек һәрвакыт кырган. Чәче, каш төкләре гадәттәгедән аз гына сыеграк коңгырт. Йөз сызыклары матур, нәфис. Әледән-әле җиңелчә генә итеп, борынын тартып кую гадәте бар. Борынын тарткан чакта кайвакыт әз генә тел очын да күрсәтеп ала. Ләкин бу аны ямьсезләми, ничектер үзенә килешеп тора кебек. Өстендә заманы өчен затлы трикодан тегелгән гади костюм. Галстуклы күлмәк. Аякларына игътибар итәм. Чалбар үтә дә нечкәлеге беленеп торган озын аяклар. Урындыкта утырган вакытта ул күбесенчә бер аягын икенче аягының тезе өстенә куеп утыра. Анда да кешечә генә түгел: икe аягын бергә ишеп утыра. Мин аның кебек утырырга тырышып карыйм, булдыра алмыйм: әллә аягым кыскарак, әллә ябыклыгым җитми. Тагы шунысын күрәм: аягын бер-берсенә ишеп утырганга бераз күтәрелә төшкән чалбар балагы астыннан ак кальсон очы һәм куныча сыдырыллып төшкән шакмаклы фельдиперс оекбашы күренә. Монысы, әлбәттә, җыйнаксызлык кебек, ләкин мин аны гафу итәм: безнең кебекләргә менә дигән дәреслек булырлык «Әдәбият мәйданында» дигән китабын чыгарган, «Безнең юл» журналына укып туйгысыз шәп мәкаләләр язып килгән әдәбиятчы галимгә андый гына вак-төяккә игътибар итеп бетермәсә дә ярый, хәтта килешә дә кебек...

Нигъмәти мине белә идеме соң? «Авыл яшьләре»нең редколлегиясендә бергә член булып торабыз. Ләкин редакциянең көндәлек эшендә актив катнашты дип әйтә алмыйм. Журналыбызны исеме белән бизәп торуы да җитәрлек иде безгә. «Төзү көннәрендә» дигән альманахка язган кереш сүзендә исемемне телгә алганы да бар. Шулай да мине белү дәрәҗәсе күрешкән чакларда исәнләшүдән ары китмәгәндер. Ләкин хикәяләрем турында аның фикерен ишетәсем килә, бик килә. Менә хәзер, кулъязмамны үз кулына китереп тапшыргач, ни дә булса әйтми калмас инде. Ни дияр?

Һәм озак зарыктырмады, әйтте. Әйтүе шул булды: китабымның язмышы ни хәлдә икәнен белергә килгәч, бер генә сорау бирде:

— Моны язган вакытта берәр рус язучысының әсәреннән файдаланмадыгызмы?

Хафага төшә яздым. Неужели мондый китап бар икән? Булмас! «Пушкага» алырга итүедер. Кем язсын андый китапны?

— Юк,— дидем,— бер кемнән дә файдаланмадым.

— Ярар, карарбыз.

Мактарга да, яманларга да ашыкмый торган Нигъмәти башка бер сүз дә әйтмәде. Ләкин аның яшь язучыга шундый ышанычсызлык күрсәтеп биргән соравы миңа мактау сүзе булып ишетелде. Димәк, китап игътибарга лаек. Әдәбият галиме күрә, тик ышанып кына бетәсе килми. Янәсе, ай-һай, бу малай үз акылы белән генә болай яза алдымы икән? «Бәхет порошогы» дигән хикәямне укыгач, Галимҗан Ибраһимовның: «Мирсәй Әмир берәр өлкән язучының псевдонимы түгелме?» дип шик-

[1] Бәйләнешле.

ләнү белдерүе мине ничек шатландырган булса, Галимҗан Нигъмәтинең ышанып җитмәве дә шуннан ким куандырмагандыр.

Шул ук 1929-нчы елда «Пар күгәрчен» Гата Юсупов үзенчәлекле итеп эшләгән бик матур тышлык белән басылып та чыкты. Яшь язучы өчен беренче китабы дөнья күрү, әлбәттә, бик зур шатлык. Ләкин шатлыгыма күләгә төшергәне шул булды: китабым латин хәрефләре белән басылган иде. Шунлыктан ул киң катлам укучылар массасына тиз генә барып җитә алмады.

Ләкин, әдәбият урамында сакта торган милиционер шикелле, һәр яңа әсәрне, аеруча яшьләр иҗатын, бер дә калдырмыйча, үзенә хас кырыс бер хирыслык белән күзәтеп баручы Мөсәгыйт күзеннән барыбер котыла алмаган булып чыкты. Башта бер җыелышта телгә алган иде, аннары «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» дигән җыентыкка кергән күзәтү мәкаләсендә язып чыкты. Анда ул авторны «шома, матур гына тел белән язылган бу хикәядә тормышны бөтенләй икенче төрле, уң оппортунистлар әйткәнчә гәүдәләндерүдә» гаепли.

Үз вакытында ук, яшь язучыга мондый печать басарга ашыгу ярамый дип, аңа каршы язып чыгучылар булса да (мәсәлән Ф. Мөбарәкшин. «Атака» № 1, 1930), бу кечкенә повесть матбугат битләрендә шуңардан да «җылы» сүз ишетмичә, онытылган иде. Ниһаять, утыз биш ел үткәч диярлек, мин аны күптән искәртеп, онытылып беткән «Яңалиф» хәрабәләре астыннан эзләп алып, сайланма әсәрләр җыентыгыма кертергә кирәк таптым. Мәскәүдә, русча тәрҗемәсе чыккач, аның исеменә үзәк матбугат битләрендә дә шактый җылы сүзләр әйтелгәнне күрергә насыйп булды.

Бу гыйбрәтле тарихны бүген килеп искә алуым Мөсәгыйткә карата нинди дә булса ачу саклаудан түгел. Бернинди ачуым юк. Шулай да, бер телгә алгач, бу исемгә бераз тукталмыйча уза алмыйм.

Фатих Мөсәгыйт — ул елларда иң күп шаулаган яшь тәнкыйтьчеләрнең берсе, аларның да аеруча аяусызы иде. Шундый бер эпизод хәтеремдә сакланган: Мәдәният йортының тамаша залы шыгрым тулы халык. Сәхнәдә — әдәби-музыкаль концерт. Әбүбәкиров дигән егет виолончельдә татар халык көйләрен башкара. Шулкадәр яратып, шулкадәр бирелеп уйный, тамаша залында аның моңына әсир булмаган күңел калмагандыр...

Кемдер кабыргама төрткәнгә исемә килдем. Карыйм: янымда утырган Мөсәгыйт икән. Ярым пышылдап, колагыма нидер әйтә. Аңламыйм.

— Нәрсә? Ни булды?

— Карәле,— ди миңа,— син белмисеңме, бу егетнең социаль чыгышы ничек икән?

Көл дә, ела да. Әле бит үзе, Мөсәгыйтне әйтәм, музыканы, моңны яратмый торган кеше дә түгел. Бергә күңел ачарга туры килгән чакларда, эчмәгән-нитмәгән килеш, Сәйдәш көйләрен бик матур итеп җырлый да белә. Ә монда? Бөтен кеше яшь музыкантның талантына сокланып, күңелләре белән татлы хыял дөньясында йөзгән сихри минутларда ул аның социаль чыгышы турында уйлап утыра икән ләбаса! Бары Мөсәгыйттән генә көтәргә мөмкин мондый хәлне!

Дөрес, ул вакытта гомумән һәркемнең нинди социаль катлаудан чыккан булуына нык әһәмият бирелә, эшче һәм хезмәтчел крестьян арасыннан күтәрелгән кадрлар җитештерү мәсьәләсе игътибар үзәгендә тора иде. Вульгар социологизм юлына баскан тәнкыйтьченең бәласе шунда — ул сыйнфый көрәш логикасын матур әдәбиятка, сәнгать әсәренә шәрә килеш күчереп карый. Сыйнфый көрәш рухы әсәрнең һәр җөмләсендә чекрәеп тормый икән, аныңча бу инде зур кимчелек... Ниндининди генә шартлар куелмый иде әдәби әсәргә, нинди-нинди генә гаепләр ташланмый иде!

Бүген безгә көлке һәм примитив булып күренгән, һәм, әлбәттә теге елларда да әдәбиятыбызны үстерүгә караганда күбрәк тоткарлауга гына хезмәт иткән андый таләпләрдән бөтенләй азат булган тәнкыйтьчеләребез бар иде микән? Ай-һай!.. Шулай да андый рухтагы мәкаләләрнең иң характерлы үрнәкләре шул Мөсәгыйт чыгышларында саклана дыр дисәм, хата булмастыр.

Ул елларда да редакциягә бик күп шигырьләр килә иде. Аларның күбесе, әлбәттә, басарлык дәрәҗәдә булмый. Барсына да аерым-аерым җавап язып өлгерергә дә мөмкин түгел. Шундый чара уйлап таптык: «Басарга ярамый торган шигырь» дигән баш астында «Эш фәрештәсе» дигән бер шигырьне бернинди үзгәртүсез «Авыл яшьләре»ндә басып чыгардык һәм укучылар каршысына: «Сез ничек карыйсыз? Мондый шигырьләрне басмыйча, редакция дөрес эшлиме?» дигән сорау куйдык. Укучылардан бик күп җавап хатлар килде. Берничәсе журналда да чыкты. «Басарга ярамый торган шигырь» дигәнебез үзе дә, аның турында әйтелгән фикерләрнең дә күбесе (фараздан, без аларны, бернинди үзгәреш кертмичә, «Казан утлары»ның юмор бүлегендә басып чыгарсак) бүгенге укучы өчен үзләрендә үк менә дигән пародия сыйфатында укылырлар иде.

Мисал өчен фикер алышуларга йомгак урынында басылган мәкаләдән берничә юл китерү дә җитәр дип уйлыйм: «... Буржуазия хатын-кызны ирләр белән тигез дәрәҗәдә, бердәй хокуклы кешеләр, җәмгыятьнең ярты өлеше дип карый алмый. Ул аларны ирләр кәефен ачар өчен яратылган мәхлук дип карый, аның күңелен күрер өчен уйный торган курчак урынында йөртә. Шуның өчен дә матуррак хатын-кыз күргәндә буржуаның каны кыза, күзләре тасырая, ул айгырланып кешни башлый. Аңа калку күкрәкләр — уар, матур күзләр — серләр эзләр өчен, таза беләкләр — кочаклар өчен генә булып күренә. Ул башкача уйлый да алмый. Ә без хатын-кызларга бөтенләй икенче төрле караштa. Алар да барыбер җәмгыятьнең тулы хокуклы, ирләр белән бер дәрәҗәдә торган әгъзалары, аларның тән ягыннан тазалыклары безнең кәефне ачар өчен түгел, ә бәлки яңа илне төзешүдә ныклап, батырларча катнашып, ил файдасына күп файдалар китерер өчен кирәк».

Юк, юк! Берәүнең дә моннан ярты гасыр элек булган яшьлек гөнаһларын бүген килеп тәнкыйть итәргә теләве түгел. Барыбызның да ул еллардагы гамәлләребезгә иң гадел бәяне заман үзе бирде һәм бирә килә. Хәтирәләр, истәлекләр урманы аша узганда очраган чытырманлыкларны читләтеп яки юлыма тап килгән түмгәкләргә тибеп кенә узасым килми.

Әйе, заманында Мөсәгыйт таягының ачысын татымаган язучы аз калгандыр. Хәзерге яшьләр (әдәбият тарихы белән махсус шөгыльләнүче галимнәрне әйтмим) ул еллардагы Мөсәгыйт турында белсәләр дә, күбесенчә өлкәннәрдән ишетеп кенә чамалый торганнардыр...

Шулай да кем соң ул Мөсәгыйт?

Заманында татар мәдәниятенең үзәк шәһәрләреннән берсе булган Оренбургның Мунча күле бистәсендә яшәүче итекче гаиләсендә туган бу егет, ибтидаи мәктәпне тәмамлагач, бер генә ел булса да, Хөсәения мәдрәсәсендә укып калырга да өлгерә. Революциядән соң, шул ук Оренбургта ачылган Татар Халык мәгарифе институтында (ТИНО) укый. Аны тәмамлагач, 1923 елда Фатихны Уфа губернасы каршындагы Татар-Башкорт бюросы, Заһид Шәркыйнең дә киңәше һәм ярдәме белән, Казанга җибәрә. Икътисади сәясәттән Галә Ходаяровка имтихан биреп, ТКУ[1]га керә. Киеп килгән киндер штаны белән киндер күлмәген дә

[1] ТКУ — татарский коммунистический университет

алыштырырга өлгермәстән диярлек, чирләп, кире Оренбургка кайта. Актүбә губернасында комсомол эшендә оештыру мәсьәләләре буенча тәҗрибә ала. Егерме бишенче елның көзендә — яңадан Казан. Шул ук ТКУ. Бу вакытта инде ул татар әдәбиятының революциягә кадәр чыккан әсәрләрен дә, яңа авторларын да укыган. Үзе дә шигырь чыгарып карамаган кеше түгел. ТИНОда чагында ук «Җен» дигән сәхнә әсәре дә язган. Революциядән соңгы әдәби хәрәкәтне күзәтеп бара, әдәбият-матбугат мәйданындагы рәхимсез көрәшләрдән хәбәрдар.

Комсомол матбугаты каршындагы «Яшь язучылар түгәрәге»н мин эзләп тапкан вакытта Мөсәгыйт аның бюро членнары арасында иде инде.

Менә без, бер төркем яшьләр, әйтик, Фатих Кәрим, Җәүдәт Фәйзи, Фатих Хөсниләр, театр фойесында йөрибез. Арабызда Мөсәгыйт тә бар. Менә Ф. Кәрим бәрхет кебек йомшак күкрәк тавышы белән сер сөйләгәндәй яшереп кенә ниндидер кызык сүз әйтә. Кычкырып көлеп җибәрәбез. Ә Мөсәгыйт барыбыздан да арттыра: Ха-ха-ха!.. Берәүдән дә тартынмыйча, ансыз да көр тавышын бер дә җәлләмичә яңгыратып, стеналарны сискәндерерлек итеп хихылдый. Фойены тутырган тамашачылар һәммәсе бердән безгә борыла. Кайсының йөзендә елмаю, кайсынысында аптырау катыш гаҗәпләнү... Танып калмый кара син Мөсәгыйтне бер күрүдә!

Трибунага чыккан чакларында сүзгә бер вакытта да аптырап тормый. Сөйләгән саен тәнкыйть хирыслыгы арта бара. Табигать кызганмый биргән тел мөмкинлекләреннән бер дә тартынмыйча файдалана. Тавыш көрәйгәннән көрәя:

— ... Әллә нинди илаһи нурлар, моңлы серләр безгә бөтенләй ят, пролетариат әдәбияты өчен бөтенләй юк нәрсәләр! — дип ул, үзенең хаклы икәнлегендә тамчы да шикләнмичә.— Алла, патша, брильянт, энҗе, мәрҗән, алтын, аллага шөкер, илаһи нур, кәгъбә, сәҗдә, иман... пролетариат әдәбияты өчен чит сүзләр. Бу сүзләрне татар матур әдәбиятыннан куарга, аларны күккә кире сөрергә кирәк, юкка монда эч пошырып йөрмәсеннәр! Һәрбер җөмлә идеологиягә бәйләнгән, нигезләнгән кебек, һәрбер аерым сүзләр дә, сурәтләр дә берәр идеологиянең вәкиле булмыйча булдыра алмыйлар!..

Болай уйлаучы тәнкыйтьче, әлбәттә, бер Мөсәгыйт кенә түгел иде. Аның көче фикер оригинальлыгында түгел, ә бәлки үз вакытында да күпләр өчен шикле булган фикерләрнең дөреслегенә фанатикларча ышанган булуында иде. Шуның өстенә тагы гадел: берәүгә карата да шәхси мөнәсәбәттән чыгып эш итмәс. Яраткан язучысының да аерым бер әсәрендә кимчелек күрсә, үз кеше дип, аяп тормас. Фатих Кәрим шигырьләрен ярата иде ул. Уңай яктан мисал кирәк булганда, шулардан өзекләр китерә. Ә менә «Кысыр чәчәкләр» поэмасын тетеп салды. Һәм ул вакыт өчен дөрес тәнкыйтьләмәде дип тә булмый.

Тагы шунысы бар: аның үзенә дә үзе кебек үк, хәтта үзеннән дә катырак җавап бирергә һәркем иректә, һәм ул үз исеменә булган нинди каты тәнкыйтьләргә дә үпкәли белми, үч алу юлына да басмый.

Гомумән тәнкыйтькә дөнья киң чак иде. Гражданнар сугышыннан соң НЭП шартларында, сыйнфый көрәш һәр өлкәдә аеруча катлаулы төс алган чорда Кави Нәҗмиләр, Фәтхи Бурнашлар, Гомәр Толымбайскийлар тарафыннан башланып киткән аяусыз каләм көрәшенең яңа чорда, НЭПтан реконструкция чорына күчү шартларында дәвам итүе иде.

Һәм тәнкыйтькә әләгү яшь язучы өчен дәрәҗә иде. Әйе, яманлаган булса да, Мөсәгыйт тәнкыйте булса да — бик хуп! Тик әсәрең турында дәшми генә калмасыннар! Тәнкыйтьтән түбәннәр җөмләсенә керү хур-

лык. Хәтта бераз соңрак Мөсәгыйтне сагынып искә алучылар да булмады түгел. Мисал өчен Ләбиб Гыйлминең ТАППка үпкә белдерү һәм аны тәнкыйтьләү рухында язылган шаян шигыреннән берничә юлын искә төшерү кызыклы булыр:

Үлчәүләргә салсаң, йөз пот тартыр
Чиле-пешле чыккан шигырьләр.
Укучыда сусау мең пот артык
Без язмаган яхшы шигырьгә.

Чакыру белән сиңа рекрут булдык,
Корал белән сафка әләктек.
Кайсы тәнкыйтьчең соң, «сүгенә-сүгенә»,
Командирдай безне өйрәтте?

Яшь кеше дип, Фатих Мөсәгыйткә
Тема бирдек, доклад сөйләттек.
Көткәнебез әрәм китә язды,
Әле дә ярый, Маннур әләкте.

Алты елга алтмыш жыелыш булды,
Гел Маннурдан сүзне башладың,
Кыйный-кыйный әллә хәлдән тайдың,
Ник, Мөсәгыйт, язмый башладың?..

Дөресен әйтим, үзем дә кайчак шул елларны сагынып искә алгалыйм. Әдәбиятка зур хәзерлек белән килгән яшь һәм яше үтеп баручы кайбер бүгенге язучыларыбызның заман рухына туры килми торган вак темаларга багышланган әсәрләрен, гаилә җәнҗалы, йөгәнсез мәхәббәт кебек «койрыксыз» темаларга язылган шигырь-хикәяләрен укыйм яки шундый рухтагы сәхнә әсәрләрен күрәм дә, эх, Мөсәгыйт булса! — дип куям. Бүгенге көннең Мөсәгыйте! Ул, әлбәттә, хәзерлеклерәк тә, тактлырак та булыр иде. Аллага шөкер, хәзер бездә бу әйбәт сыйфат житәрлек. Ә менә үзең күргән кимчелекләргә карата принципиальлек, аяусызлык? «Какма кеше капкасын, үз капкаңны кагарлар» дип, куркып тормау? Юк бит. Бу юнәлештә кыю омтылыш ясап караучы иптәшләр күренгәләп алса да, хуплаучы тапмыйча, томаланып калалар. Ә бер-береңне макташтырга дисәң — пожалсты. Уртакул югарылыкта торган, житди тәнкыйтькә мохтаҗ урыннары да житәрлек булган авторын очыртып мактаган мәкаләне укыйсың да — әдәби тәнкыйтьмә соң бу, әллә мәдхияме? — дип, аптырап каласың. Хәтта кайвакыт, әллә некрологмы дип, куркып киткән чаклар да була.

Нигә болай соң? Әллә бездә тәнкыйть итәрлек кимчелекләр, хаталар юкмы? Бар, әлбәттә. Хәтта авторның шәхесенә карамый әйтелә торган чәнечкеле тәнкыйть үзе дә бар. Тик ул үз урынында — матбугат битләрендә, әдәби утырыш трибуналарында түгел, күбрәк кулуарларда яши. Курыкмаска иде аны идән астыннан чыгарырга! Гайбәт белән кулга кул тотышып, идән астында яшәгән тәнкыйть Мөсәгыйт тәнкыйтеннән куркынычрак булуы мөмкин.

Әйе, яшь язучылар түгәрәге чорында Мөсәгыйт, усал булса да, куркыныч түгел иде әле. Ә менә иркле түгәрәгебез ТАППның яшь язучылар секциясенә әверелгәч, куркынычка әйләнде. Анда инде тәнкыйть әдәби тәрбия чарасы булу белән генә чикләнми, бик тиз «политика»га әйләнеп, административ нәтиҗәләргә барып җитә иде. ТАПП җитәкчелегендә Шәйхи Маннур, Әсгать Айдар кебек шагыйрьләргә карата эш-

ләнгән гөнаһларда, Такташ иҗатына бәя бирүдәге гаделсезлекләрдә Мөсәгыйт керткән өлеш кечкенә булмагандыр. Анысын онытып булмый.

Кая булды соң ул — Мөсәгыйт? Ләбиб Гыйлми аны нигә юксына? Бераз алга китеп булса да, әйтеп бетерик, ТКУның аспирантурасын тәмамлап, бер ел армия сафында булгач, ул, Г. Кутуйны алыштырып, «Кызыл Татарстан» газетасының культура бүлегенә керә — журналистлык эшенә чума. Утыз дүртенче елдан партмобилизация буенча армия сафына җибәрелә. Мин аны хәрби киемдә күргәндә ул бөтенләй икенче Мөсәгыйт иде. Ха-ха-халап, дөнья яңгыратып көлүе дә беткән — ул җыйнак, ягымлы офицер инде. Кырык алтынчы елда ул яңадан «Кызыл Татарстан» редакциясенә кайта һәм пенсиягә чыкканчы шунда эшли. Хәзер дә исән. Журналист-ветеран буларак, яшьләр арасында остазлык итә, тәрбия эшләре алып бара. Һаман да сүзгә оста...

*Әсәр шушында өзелә*

*20.05.80.*

## Марс Шабаев

### Карт солдат монологы

Утыз биш ел... Гүя вагоннар
Тезелешеп үтә алдымнан.

Ерак дүрт ел — сугыш еллары.
Яшьлегемнең матур чакларын
Ерак дүрт ел гына урлады.

Ерак дүрт ел — утлы ул еллар
Төшләремдә мине будылар.

Мина булып шартлый төшләрем —
Мин окопка чалкан төшәмен.
Упкын булып убыла төшләрем —
Утыз биш ел егылып төшәмен.
Әйтерсең мин һаман күтәмен.
Кайнар туфрак күмеп киткәнен...

Утыз биш ел курку миләрдә —
Ничек аны, ничек җиңәргә?!
Ничек аны, кайсы суларда
Тәннән, каннан, җаннан юарга?!
Ялган булыр:
«Тормыш юк...» — дисәм.
Рух үлмәде,
Рухым нык, исән!
Яшьлегемнең матур елларын
Илем өчен бирдем мин барын.

Үлем дүрт ел янда йөрсә дә,
Утыз биш ел төшкә керсә дә,
«Үлем» сүзен телгә алмадык —
«Илем» сүзе белән атладык.

Ил сакладык, намус сакладык —
Шуңа безнең рухи сафлар нык.

Кирәк икән әгәр —
Мең үлим:
Имин генә була күр, илем!

Утыз биш ел.
Гүя вагоннар,
Тезелешеп үтә алдымнан.

Салмаклансын, әйдә, адымнар...
Ил солдаты дигән даным бар.

## Бер кояш монологы

Зәңгәр күк йөзендә бер кояш,
Сөеклем, сиңа да, миңа да.
Әмма тик булмас дип башкача,
Син алай беркатлы уйлама.

Һәркемнең кояшы үзенчә
Җылыта, яктырта, ямь бирә.
Берәүгә тик аның кояшы
Батмастыр шикелле мәңгегә.

Берәүнең кояшы алтыннан:
Ул — алка, ул — йөзек, беләзек...
Берәүнең кояшы — тик вөҗдан:
Ә вөҗдан һәрвакыт бик нәзек.

Берәүнең кояшы — мәхәббәт,
Аңарга, шул булса, бик җиткән.
Ә берәү мәхәббәт хакына
Ил сатып... кояшсыз интеккән.

Кемгәдер кирәкми кояш та,
Ае да кирәкми аңарга.
Аңларлык зат түгел ул адәм,
Андыйны тырышма аңларга.

Әйе шул, һәркемгә бер кояш,
Башкача яшәргә тырышма:
Бары тик,
Бары тик үзеңнең
Кояшың җылытсын тормышта.

«Мин — синең кояшың»,— дип әйтмим.
Мәңгегә килмәгән бу башым —
Бервакыт егылгач,
Мине дә
Озатыр елмаеп кояшым...

Рәфкать Кәрами

# САГЫШЛЫ КОЯШ

ПОВЕСТЬ

## I



Фирдия элек көз айларын бик ярата иде. Бигрәк тә сентябрь урталары табигатьнең яме, яшәүнең хозурлыгы, тормышның муллыгы булып хәтердә уелып калган. Ул очына-очына авылга бәрәңге алырга кайтулар дисеңме, кайткач, аяк басу белән батып китә торган йоп-йомшак кара җирдән көянтә-чиләк белән йөгерә-атлый бәрәңге ташулар дисеңме, җеп өзәр хәлең калмаса да уйный-шаяра клубка барулар һәм таң әтәчләренә кадәр капка төбе саклаулар дисеңме — барысы да күңелле, рәхәт була торган иде. Кияүгә чыккач та ул елның елында кайтып әнкәсенә бәрәңге алышты. Ә быел — юк. Әнисе рәнҗер инде. Нишләсен, шулай килеп чыкты бит, хәзер аның үз хәле хәл.

Көзе дә әллә нинди быел. Көн аралаш яңгыр ява, әбиләр чуагы да сизелми үтте. Менә бүген дә кояш бераз гына чыгып каршыдагы балалар бакчасын, аның ихатасындагы яшел үләннәрне, юлның аргы ягындагы әле йортлар төзелмәгән иңкүлектәге аксыл әремнәрне, кибеп корый башлаган кураларны, көрән төс алган ат кузгалагы сабакларын, һаман ямен җуймаган аксыл тал куакларын — барысын-барысын нурландырып, аларга яктылык өстәп, баганалардан, биек агачлардан озын күләгәләр сузды да, ярар, җитәр, дигәндәй, тагын болытлар арасына посты. Аннан ул, чыгаргамы, юкмы дигән шикелле икеләнеп, качып тора башлады.

Кояш караганда беразга гына тынган җил тагын көчәеп, гайрәтләнеп исә. Яшь агачларның башларын гына түгел, кәүсәләрен дә чайкалдыра, җиргә нияргә азаплана. Каеннарның, өрәңгеләрнең сары инә башлаган вак яфраклары Фирдия күңелендәге уйлар кебек бертуктаусыз шыбырдаша, болай да алгысыган күңелгә шом салалар. «Утыз ел бер якка янтаеп үскән агачны утыз көндә генә төзәтеп булмый»,— ди торган иде Сәлим. Балконга чыгып, керләр элгәч, көзге табигатькә карап моңаеп утырган яшь хатынның кылт итеп исенә ире килеп төште. Фирдия, болай каңгырап утыруына үзе дә аптырап, көрсенеп куйды һәм бүлмәсенә кереп, ашыгып киенә башлады.

...Хөкем залына халык әкренләп җыела торды, ә шулай да Фирдия әле бер генә мәртәбә дә баш күтәреп карамады. Әгәр ул артка борыл-

са, бөтен кешенең карашы аңарда булачак. Бәлкй аны танучы, дөньяда бар дип тә белүче булмас, ләкин Фирдиягә, ул артына борылу белән, бөтенесенең күзе аңарда булыр һәм һәрберсе бармак белән төртеп күрсәтеп, аның яманатын сата башлар төсле тоела. Чынлыкта исә залдагыларның Фирдиядә гаме юк, хәтта әлегә монда аны танып белүче кеше дә юк иде. Сәлим килеп җитмәгән, туган-тумачалары да күренми. Ә үз туганнарына Фирдия килеп йөрергә кушмады. Нигә кирәк? Алар өчен бу аерылышуның бер әһәмияте дә юк бит. Дөрес, алар аның язмышына битараф кешеләр түгел. Ә шулай да Сәлим белән алар торасы мыни? Хәер, нинди тору ди, хәзер инде аерылышу турында сүз бара бит. Туйда гына туганнар кирәк. Мәҗлес уткәрергә, котларга...

Ә монда күңелсез, әйләндереп кибәргә элеп куйган кием кебек, тормышның бу минутлары кеше күзен иркәләми — аның бөтен җөйләре, килбәтсезлеге, кытыршылыгы күзгә ташлана. Әйе, монда гаилә җимерелә. Нинди татлы хыяллар, якты өметләр, изге ниятләр белән, мәңге бергә торырга дип корылган тагын бер куыш ишелә. Ярый ла ишелеп кенә калса, беркемгә дә зыян итмәсә. Ләкин тормышта алай булмый бит. Әгәр ни дә булса җимерелә икән, ул кемгәдер гомер җуелмаслык йөрәк ярасы калдыра, мәңге төзәлмәслек җәрәхәтләр ясый.

Фирдия башын күтәреп алга карый. Шыксыз зал, көрән өстәл, ә аның артында биек урындыклар. Өч урындык. Өчәү... Нигә икәү, яки дүртәү түгел? Табигать әйберләрне парлы итеп яраткан бит. Кешеләр дә парлы булырга тырыша. Фирдия дә парлы булырга тиеш иде. Нигә тиеш? Ул бит парлы иде. Ә нигә бүген хөкем залында соң ул? Хакимнәр утырасы урындыкларга сүзсез генә багынып, залга күтәрелеп карарга да читенсенеп утыра ул. Югыйсә, ул да Сәлим белән кушылуын мәңгегә булыр дип уйлаган иде бит. Нишләп болай килеп чыкты соң әле бу? Кем гаепле? Нәрсә җитмәде? Соңгы айларда бу уйлар Фирдияне, көзге яңгыр кебек бертөзлексез борчып, теңкәсенә тиеп торды һәм, ниһаять, хөкем бүлмәсенә китереп җиткерде. Бәлки бу турыда алданрак уйларга, ике чит кешене бер-беренә бәйләп торган гаилә җепләрен алданрак өзәргә кирәк булгандыр. Бу кадәр үкенечле дә, газаплы да булмас. Җир йөзендә тагын бер ятим артмас иде. Кем белә инде аны. Фирдия һаман нидер көтте, ниндидер могҗиза булуына өмет итте бит. Тукта, сабыр итим, бала хакына түзим, диде. Ә Сәлим? Бәлки ул да үзенчә хаклыдыр? Ул да үз-үзен әнә шулай аклый торгандыр. Аның да дәлилләре җитәрлек бит. Ул мал таба торган егет иде, гаиләсен ачялангач тотмады, хатынын да, баласын да ярата иде. Монысы хак. Бу җәһәттән Фирдия Сәлимне яманлый алмый. Алайса гаеп кемдә соң? Нигә бу куыш җимерелә?

Фирдия тагын алга карады. Каршыда тәрәзәсез ак стена. Ләкин ул анда аксыл стена түгел, ә театр сәхнәсендәге кызыл бәрхет пәрдә күргәндәй булды һәм Сәлим белән беренче тапкыр очрашуын, танышуларын, моннан сигез ел элек һәм соңгы елларда булган вакыйгаларны исенә төшерде.

## II

Беркөнне иптәш кызы Разия Фирдиянең эшенә — китапханәгә шалтыратты һәм аны театрга чакырды. Егете билетлар алган булган икән дә, кичә үзе командировкага китеп барган.

— Өч билет бар. Берәр кызыңны да иярт. Җиденче яртыга минем янга килеп җитегез.

Таксидан төшеп, Разия театр ишек төбенә җитәр-җитмәс:

— Кемгә билет? — дип авызын гына ачкан иде, аларны артык билет сорап торучы яшьләр сырып алды.

Куллар сузылган, өтешәләр, төртешәләр. Разия ник әйткәненә үкенеп, сумкасын ачуы булды, халыкны ерып, каршысына саргылт кашлы бер таза егет килеп басты. Җәенке йөзенә елмаю кыяфәте чыгарып, оялчанрак тавыш белән:

— Апасы, миңа бир әле,— диде,— гомер эчендә бер театр карарга килдем, анда да билет юк.

Разия йөзен чытып, аңа бер генә карап алды да, аю, авылдан килгәндер инде, бирим алайса, дип өч билетның берсен ертып, егеткә сузды.

— Бәлки аягыгызны алырсыз?

Егет бер мәл аңышмыйча торды, аннан түбәнгә карап, арткарак чиккәндәй итте.

— Ә, аягыңа бастыммыни? — диде ул алтын тешләрен күрсәтеп.— Авырттымы?

— Зыян юк, издегез генә. Акчасын кергәч бирерсез.

Кыңгырау өченче мәртәбә шалтырагач кына егет тамаша залына килеп керде һәм байтак эзләгәннән соң урынын табып, сәхнәгә карыйкарый кызлар янына килеп утырды.

— Буфетлары шәп икән,— дип Разияга бер уч конфет һәм акча сузды.— Монысы синңа, апасы.

Разия рәхмәт әйтеп алды да конфетын Фирдия белән бүлеште.

— Ә-ә, сез икәүмени? — дип егет Фирдиянең кара тутлы түгәрәк йөзенә, негр кызларыныкыдай вак бөдрә чәчләренә карап алды.— Мә, апасы, синңа да.

Ул Фирдиягә дә уч тутырып конфет сузды.

Спектакль барышында егет бөтен дикъкатен туплап, авызын ачып, сәхнәгә карап утырды. Көлкеле урыннарда рәхәтләнеп, бөтен тәне белән калтырап, күзләре яшьләнгәнче ихластан көлде. Андый вакытларда ул хәтта янындагы кызларның барлыгын да оныта иде, ахрысы.

Тәнәфес вакытында ул тагын буфетка чыгып йөгерде, тагын конфет алып керде. Эшләр болайга киткәч, Разия яхшысынмады, егет белән танышырга туры килде.

— Икегез дә сөбханалла күренәсез, кайсыгызны озатыйм икән,— диде Сәлим батыраеп.

— Әнә Фирдияне озатырсын, минем егетем бар,— диде Разия мыскыллы елмаеп һәм иптәш кызына күз сирпеп алды.

Фирдия җиңелчә генә аның кабыргасына төртеп: «Авызыңнан җил алсын»,— диде.

Спектакль тәмамлангач, алкышлардан тамаша залының түшәме дерелдәп торгандай булды. Ә Сәлим барыннан да уздырып, көрәктәй учларын шулкадәр нык шапылдата иде, кызларның колак барабаннары ярыла язды.

Кызлардан артта чыкса да, Сәлим киенеп, аларны урамда көтеп торган икән, бергәләшәп Куйбышев мәйданына кадәр җәяү төштеләр. «Апалары, таймагыз!» — дип егет алар арасына кереп, култыклап та алмакчы иде, тик кызлар кулларын аермадылар. Караңгы, тайгак урамнан көлешә-көлешә шуып диярлек түбән төшүе, спектакльдән алган тәэсирләр белән уртаклашуы бик күңелле булды. Күбрәк кызлар сөйләде, Сәлим, «әйе», «шулай», дип алар сүзенә пичәт басып кына барды.

### III

Восстание урамында, универмагны узып, бераз баргач, Разия, шоферның иңенә ике бармагы белән генә кагылып, туктарга кушты. Таксист белән янәшә утырган Сәлим каерылып артка карады.

— Кайтып җиттекмени, апасы?

Разия, әйе, дигәнне аңлатып, баш какты һәм кечкенә сумкасында актарынып шоферга ике берлек сузды. Сәлим аның акчаларын кулы белән этәреп:

— Акчаларыңны җыеп куй әле, апасы,— диде һәм түш кесәсеннән ялт кына кыштырдап торган бишлек чыгарып, шоферга бирде.— Сау бул, туган.

Фирдияне култыклап бераз баргач, Разия туктады. Әле саубуллашкач та аерылыша алмыйча, алар бик озак сөйләшеп тордылар. Сәлим, сүз\югында сүз булсын дигәндәй, хатын-кызның сөйләшер сүзе бетмәү хакында хәтта бер мәзәк тә сөйләп алды. Китеп бармасмы, дип, юри вакытны сузган Фирдия бер-ике тапкыр Сәлимгә, барыгыз, кайтыгыз, мин үзем дә юлны беләм дисә дә, егет елмаеп башын гына селкеде.

— Болай булгач, озатам инде. Вакыт та соң.

Кыз, җилкәсен сикертеп, авыз чите белән генә елмаеп, иренен җыерып куйды. Аның бу кыланышы, теләсәң нишлә, миңа барыбер дигәнне, әллә потың бер тиен, дигәнне аңлата идеме — егет төшенмәде. Ул үҗәтлек белән тыныч кына көтә бирде. Шулай да, Разиядан аерылгач, Фирдия яп-якты урам буйлап Сәлим белән янәшә атлап китте. Берздән алар яңа таш мәктәп яныннан үтеп, наратлыкка килеп җиттеләр. Колач җитмәс юан һәм шәмдәй төз агачлар урамның уң ягында, ә алар артында халык телендә «кинопленка» дип йөртелә торган химия заводы урнашкан. Бу урын Фирдия өчен бик күп истәлекләр белән бәйле, шуңа күрә ул һәркөн диярлек бу төштән үтеп китә, наратларга соклана-соклана барып Марат белән узган бәхетле көннәрен хәтерендә яңарта. Ул хәзер дә, үзенең кем белән икәнен онытып тандай:

— Беләсезме, монда тукраннар бар! — диде.

Сәлим башта сүзнең ни турында барганын аңламады булса кирәк, берникадәр паузадан соң гына:

— Китсәнә, бу бит урман түгел,— дип куйды.

Фирдия кар кунган наратларны сыйпарга теләгәндәй итеп:

— Үз күзләрем белән күрмәсәм, мин дә ышанмас идем,— диде.— Узган атнада гына менә бу агач башында күрдем. Ә көз көне, октябрь аенда, әнә тегесендә тукылдап утыра иде. Бичараны кызганып та куйдым. Бер юан ботакка утырган да томшыгы белән и бәрә, и бәрә... бөтен гәүдәсе селкенә. Әзрәк кенә туктап тора да тагын бәрергә тотына.

— Мескеннең ничек баш мие селкенми икән,— диде Сәлим көлеп.— Кеше урындыктан егылса да мие селкенә. Ә бу гомер буе...

— Юкка көләсез. Ул шундый матур! Ә сезнең тукран күргәнегез бармы соң?

— Нигә булмаска.

— Тукылдавын да ишеткәнегез бармы?

— Бар.

— Аның тукылдавы Морзе әлифбасындагы кебек: ти-та-та, ти-та-та...

— Ә сез аны каян беләсез?

— Егетем өйрәткән иде,— диде Фирдия һәм, бу турыда яңадан сүз куертмаска булып, сүзне икенчегә борды.— Тукраннарны минем ял паркында да күргәнем бар.

Сәлим, башын югары күтәреп, агачларны күздән кичергәч, әйтеп куйды:

— Наратлары чыннан да шәп. Менә шуларны егып, алты почмаклы бура бурарга! Өч буй чыгар иде. Каравайда бер дигән нарат өй салып куйсаң иде. Уклау кебек тигез бүрәнәләр бит! Бернинди буяу тидермичә җиткезеп керсәң, өеңдә нарат исе аңкып тора инде. Әчми исерер идең, ә!?

Фирдия бу чынлап әйтәме, әллә юри үчеклиме, дип, башта аптырады, аннан мыскыллы көлде.

— Аның әле чәере дә була. Диванда кырын ятып, нарат сагызы чәйнәр иде. Чегәннәрнең «жевачкасын» да сатып аласы булмый.

— Во-во, нәкъ өстенә бастың, апасы,— диде Сәлим шатланып һәм бармагы белән агач башларына төртеп күрсәтте.— Ә өске буйларыннан җыйнак кына итеп мунча салып куясың. Ак мунча. Мин чабынырга яратам. Каен себеркесе белән чабынып кайткач, бер стаканны гөплисең дә диванда гәҗит тотып ятасың, я телевизор карыйсың, аннан...

— ... әкрен генә йокыга китәсең.

— Тач дөрес әйттең, апасы.

— Хыялга бай икәнсез!

Фирдия Сәлимнең сүзләрен ул чакта чынга алмаган иде, юри шаярта, дип уйлады. Их, әгәр дә чынга алган булса! Юк шул, кайчагында кеше үзе әйтеп торса да ышанып бетмисең, үз каланчаңнан карап фикер йөртәсең. Бигрәк тә менә шундый кызлар күңелен сихерле торган кышкы төннәрдә... Хәтта керәсе дә килми. Йөрисе иде дә йөрисе иде шулай икәү генә тын урамнар буйлап, иңне иңгә куеп, кулга-кул тотынышып, чыр-чу килеп йөгерәсе, шаярасы иде. Их! Юк шул, кешесе ул түгел. Ә Фирдия белән йөрисе кеше, дөресрәге, кайчандыр шул рәвешле йөргән кеше кайда икән хәзер? Нигә алай итте икән ул?

Нигә Фирдиянең ялгызын калдырды икән? Нигә бүген, янәшәсендә ул түгел, ә бүтән?..

— Шушында хушлашыйк,— диде Фирдия урамның икенче ягына чыгып баскач.— Өй янына ук бармагыз.

Сәлим, бәлки, хушлашканда сузар, дип, кызның кулына да күз төшереп алды, ләкин андый уй Фирдиянең исендә дә юк иде. Аның бар теләге шул: тизрәк моннан китәргә, үзе генә калырга. Марат турындагы истәлекләрдән я тиз генә арынырга, яисә аны уйлап, аның белән булган рәхәт минутларны сагынудан тулыша башлаган күңеленә ирек биреп, туйганчы бер елап алырга. Ләкин эчпошыргыч, мәгънәсез сораулар, үтенечләр һаман аның колагына иңә.

— Тагын бер очрашасы иде бит.

— Белмим шул, минем вакытым юк.

— Эштән соң...

— Мин бит укыйм да.

— Кайда?

Я, хода, соң аңа — бүген күреп, иртәгә исемен дә онытасы, бүтән беркайчан да тормыш сукмагында очрашмаячак кешегә Фирдиянең кайда укуы барыбер түгелмени?! Ничек шуны аңламый ул? Кыз үзе шулай уйлый, ә теле белән икенче төрле әйтә.

— Культура институтында.

— Кешеләр һаман укып туймый. Аңарчы да укыган идегезме? Ул бая Разия белән сөйләшүләреннән кызның китапханәдә эшләвен аңлаган иде инде.

— Әйе. Унны бетергәч, Алабугада читтән торып техникум тәмамладым. Ярый, хушыгыз.

— Сау булыгыз.

Фирдия, мең бәладән котылгандай, сөенеченнән кызу-кызу атлап, китеп барды. Ә Сәлим, яңа теле ачылган бала хәлендә булса да, сөйләшәсе килүен тыярга мәҗбүр булып, нәүмизләнеп, әкрен генә кузгалды. Берничә адым атлагач, ул, артына борылып, Фирдиянең биек үкчәле итеге белән шыгырт-шыгырт басып, йөгерә-атлый барган җиңел адымнарына, кара тун кигән булса да буеның зифалыгы сизелеп торган сылу гәүдәсенә сокланып торды. Ә күз алдында кызның кара тутлы йөзе. Башында кәҗә мамыгыннан бәйләнгән челтәрле ак шәле булгангамы, аның болай да кара кыйгач кашлары тагын да ныграк

күзгә бәрелеп тора иде. Кечкенә түгәрәк йөзе, күпереп торган калынча иреннәре әйтерсең лә сөешер өчен генә яралган. Һәй, китте шул кызый... Сәлимнең күңел түрендә нидер сыкрап куйгандай булды. Фирдиянең күп сөйләшмәве дә күңеленә хуш килгән иде егетнең. Ә сөйләшкәндә сүзләрен кызу-кызу әйтүе, күлгәндә тавышының шөлдер авазыдай чыгуы, хәтта сирәк кенә каш сирпеп алуларына кадәр егетнең күңеленә сеңеп калды. Беләме икән ул шуны, юкмы икән? Юктыр. Әнә бит артына да карамыйча атлый бирә!

Сәлим урыныннан кузгалырга кыймыйча икеләнеп торганда кинәт чырр итеп хатын-кыз кычкырган тавыш ишетелде. Егет башта бу авазның кай яктан килгәнен абайламады. Урам буйлап яшьләр уйный-шаяра кайтадыр, юри кычкырышалардыр, дип уйлады. Ләкин тавыш яңадан кабатланды. Һәм Сәлим аның әле генә Фирдия киткән яктан икәнен шәйләде. Ул олы ботинкалары белән лап-лоп атлап, тавыш килгән якка таба йөгерде...

## IV

Икенче көнне Фирдия иртүк шифаханәгә китте. Чөнки ул Сәлимне ашыгыч ярдәм машинасы белән шунда озаткан иде. Көн салкынча, мамык кисәкләре кебек эре-эре кар ява. Табигать, күрәсең, кичә Сәлимнең бәлагә дучар булуын да, Фирдиянең төнне ничек газаплы уздыруын да — берни дә белми: ул тыныч, дөнья-хозур, җил дә исми, көзен коелмыйча калган сирәк, бөрешкән яфраклар да селкенми. Әйе, табигать берни гә карамыйча үзенең изге эшен — җиргә талгын гына йомшак кар коя.

Фирдиянең башында иртә таңнан, су суыра торган урынга эләккән яфрак шикелле һаман бөтерелүче бер уй: «Хәле ничек икән?» Кичә, ашыгыч ярдәм машинасы килгәч, врач та әйдәде, Фирдия үзе дә ияреп китмәкче иде, тик Сәлим генә: «Барып йөрмә, апасы,— дип каршы төште.— Ничава, курыкма». Ләкин егетнең әйткәненә карап кына Фирдия тынычланмады, әлбәттә, төне буе йокыга китә алмыйча борчылып, борганып ятты. Куркыныч төшләр күреп, аны сарайлар арасына сөйрәгән егетнең: «Әйдә, әйдә, чего ломаешься! Марат барыбер ярдәмгә килмәс хәзер»,— дигән сүзләрен ишетеп, сискәнеп уянды.

Челтәрле тимер рәшәткә белән әйләндерелгән, озын тупыллар, алардан шактый кайтыш карт өрәңгеләр моңаеп утырган бакчаны, шифаханәнең биек таш бинасын күргәч, Фирдия йөрәге ешрак тибүен абайлады. Яр читенә, упкынга якынлашкан кешедәй, аның адымнары акрынайды, җитмәсә Сәлимгә дип алган азык-төлек инен баса иде. Кызның болай да хафалы йөрәгенә шом салып, сиренасын яман улатып, шифаханә капкасыннан ашыгыч ярдәм машинасы җан фәрманга чабып кереп китте. Тагын кемнедер, бер бәхетсезен алып киләләр булса кирәк.

Фирдия килеп кергәндә Разия үзенең эш бүлмәсендә, өстәл янында кичә төшергән рәсемнәрне — рентген пленкаларын барлап аларга авыруларның исем-фамилияләрен язып утыра иде.

Ашыга-кабалана килеп кергән иптәш кызын күргәч, башта аның йөзенә балкыш инде, аннан аптырау чыкты, чөнки Фирдиянең төс-бите сулган, йокысызлыктан күз төпләре зәңгәрсуланып тора иде.

— Нәрсә булды?

Фирдия исәнләшергә дә онытты, ахирәте тәкъдим иткән урындыкка килеп утыргач, кичәге хәлне — элек йөргән егетенең бер иптәше аңа бәйләнүен, Сәлимнең йөгереп килеп арага керүен, ә теге егетнең аңа пычак белән кадавын — кабалана-кабалана сөйләп бирде. Аның дулкынлануын күреп, Разия стаканга су салып, өстәлгә куйды, бер-ике урында сорау биреп бүлдерде, чөнки Фирдиянең сөйләве өзек-өзек, бу-

талчык иде. Уен-көлке яратучан шаян Разияның хәзер нечкә кара кашлары җыерылган, ике каш арасында сызык хасил булган иде.

Фирдия сөйләп бетергәч, ул үзенә хас тәвәккәллек белән, эшне озакка сузмыйча:

— Син утырып тор,— диде.— Мин белешим әле, ул бездә микән?

Разия көзгегә карап чәченә кул тидереп алды да чыгып та йөгерде.

Фирдия үз-үзен кая куярга белмичә күптәннән таныш булган бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Ләкин карашы һичнәрсәгә тукталырга теләми, чөнки йөрәге урынында түгел иде. Радиоданниндидер моңсу музыка яңгырый, ул да эчне пошыра. Кыз урыныннан торып, аның тавышын әкренәйтте һәм шунда ишектәге пәрдәгә күзе төште. Кызыл төстәге ефәк пәрдә театр сәхнәсендәге шикелле авыр, тантаналы иде. Ләкин аның чит-читләрен кайгы төсе — кара белән әйләндергән кебек, чөнки кызыл пәрдә артында кара пәрдә дә бар икән. Фирдия, шомланып, процедура бүлмәсенә чыкты. Андагы ишек-тәрәзәләрдә дә кызыл һәм кара пәрдәләр иде. Кыз, як-ягына каранып, шомлана башлады, пошаманга төште.

Бераздан халат чабуын, коңгырт кара чәчләрен җилфердәтеп, бүлмәгә Разия килеп керде.

— Чурт булсынмыни аңа! — диде ул һәм лып итеп урындыкка килеп утырды.— Аңа операция ясаган хирург әле китмәгән иде, егетне мактап бетерә алмый. Гомерне кыскарта дип Сәлим башта наркоз иснәмәгән, шул килеш кенә тегәргә кушкан...

— Хәле ничек соң? — диде Фирдия аны сүзеннән бүлдереп.

— Әйбәт, әйбәт. Хирург шаккаткан, кеше түгелдер, ул, әзвирдер, эһ тә итмәде, ди.

— Аю кебек таза бит ул,— диде Фирдия һәм, күзеннән ихтыярсыз тәгәрәгән яшьләрен сөртеп, елмайды.

— Аю икәнен беләм инде. Театр ишек төбендә, беренче күрүдә үк, аягыма басты.

Кызлар күңеле — язгы кояш. Шунда ук бүлмә яңгыратып көлешеп тә алдылар. Разия җил-җил үз эшенә кереште, чөнки аның янына ак халатлы, түшенә фонендоскоп аскан бер врач хатын керде.

— Разия Хабибулловна,— диде ул өстәл янына ук килеп,— минем авыруыма снимок ясагыз әле, зинһар. Умыртканың муен бүлеге.

— Хәзер. Керен чишенә торсын.

Врач чыгып китте. Разия пульт янына килеп, аппаратларны тоташтырды һәм нидер гөжли, зырылдый башлады. Кыз кулына кассета тотып, теге якка чыкты.

Өстеннән тау төшкәндәй җиңеләеп, зиһенен җыя алмыйча утырган Фирдия бераздан исенә килеп, үзенең бу хәлендә ни кылырга тиеш икәненә төшенде.

Разия эшен бетереп, авыруны озаткач:

— Мине кертерләр микән? — дип сорады Фирдия, өмет тулы коңгырт күзләре белән ахирәтенә карап.

Ул әйтерсең ниндидер бер илаһи көчкә мөрәҗәгать итә иде. Моны сизгән Разия гаҗәпләнеп көлеп җибәрде.

— Кертмичә... Чишен, мә халат. Кыяфәтеңә кара әзрәк...

Разия Фирдияне палата ишегеннән төртеп җибәргәндәй җиңелчә генә этәрде дә, үз кабинетына төшеп китте.

Сак кына адымнар белән кергән Фирдия палатаның авыр исен дә тоймады, анда кемнәр ята икән, ниндирәк бүлмә икән бу, дип тә кызыксынмады, алан-йолан каранмады. Аның бөтен игътибарын бары Сәлим генә җәлеп итте, күз алдында аның кичәге агарган йөзе генә иде. Фирдия палатага килеп керү белән аны танып алды, дөресрәге, ни өчендер Сәлимнең караваты ишек янында булырга тиеш кебек иде

һәм кыз ялгышмады. Озын, тар караватта чалкан яткан егет гаепле кешедәй тартынып кына елмайды, кызга урын күрсәтте. Башта Сәлим үзенең бу хәлендә булуыннан оялды. Ул бил тиңентен генә ябынган одеялын аксыл куллары белән өскәрәк тартты һәм йонлач күкрәген каплады. Ләкин Фирдия бер дә тартынмыйча аякларын бер якка авыштырып халат чабуы белән тез башларын каплый төшеп, Сәлимнең баш очындагы урындыкка утырды. Егетнең хәлсезлеге йөзенә чыккан, күз төбе күгәргән — зәңгәрләнеп тора, тәне кызыша ахры, маңгаена тир бәреп чыккан. Шулай булса да аның аксыл йөзе кичәгегә караганда матуррак та, ягымлырак та сыман, борыны да ул кадәр котсыз җәенке дә түгел икән. Югыйсә, кичә Фирдия аны күргәч, бу егетнең борынын тугач та берәрсе кулы белән басып торды микән әллә, дип уйлаган иде. Аның саргылт бөдрә чәчләре колакларын ук каплаган, ә күзләре сыек зәңгәр икән. Кичә Фирдия аларны абайламаган, аларның нинди икәнлеге белән кызыксынмаган да иде.

— Хәлегез ничек?

— Ярыйсы,— диде егет кипкән иреннәрен чак кына кыймылдатып. Фирдия аның авыртудан газапланырга тиеш икәнен һәм моның чыннан да шулай икәнен дә сизеп тора, шулай булмыйча мөмкин түгел, ләкин, ни хикмәттер, Сәлимнең йөзендә елмаю. Бу — кичәге шикелле мәгънәсез елмаю түгел, бу — кешенең үзе генә белгән, бүтәннәргә әйтергә кыймаган һәм сиздерергә ярамаган шатлыклы-куанычлы елмаю иде. Менә шушы хәлендә, шифаханә караватында ятканда елмаю өчен кеше чыннан да я бик сөенечле хәбәр алырга, я ул кемнедер, үтә якын кешесен күрергә тиеш.

Фирдия озак утырмады. Хәл-әхвәл сорашкач, егетнең баш очындагы бәләкәй мендәрен, карават башындагы ак шадра сөлгесен рәтләп куйды, алып килгән күчтәнәчләрен җайлап кына тумбочкага тутырды.

— Кирәкмәс иде.

— Сезгә тазарырга кирәк, күп кан югалткансыз.

— Ничава, атна-ун көндә җыям мин аны, ял итәм бит.

Фирдия гаҗәпләнү катыш сокланулы күзләрен төбәп, егеткә карады. Аннары, читенсенеп, рөхсәт сорагандай, читкә карап әйтте.

— Озак торырга кушмадылар. Китим инде.

— Ярый, барыгыз,— диде Сәлим йомшак кына.

Ә күзләре моның киресен әйтә иде. Текәлебрәк караса, Фирдия аларда: «Китмә, утыр инде. Бераз гына, менә шулай дәшмичә, елмаеп, миңа карап кына утыр»,— дигән ялвару күрер һәм егетнең үтенечен кире кагарга батырчылык итмәс иде. Ләкин Фирдия Сәлимгә туры карамый, чөнки егетнең үз карашы аңа төбәлгән.

Сәлим кызны җылы карашы, рәхмәт тулы күзләре белән озатып калды һәм ул үзен ничектер җиңеләеп киткәндәй хис итте, тәненең сызлавы да басылды кебек. «Тагын килсә иде бу кызый! — дип уйлады ул эчтән генә.— Юк, килмәс шул инде. Бүген дә әдәп саклап кына сугылгандыр. Минем монда ятуда аның ни гаебе бар? Көн саен яныма килеп йөрергә мин кеме соң аның?»

## V

Ләкин Фирдия икенче төрлерәк уйлаган икән. Егет терелеп чыкканчы ул аның янына килүдән туктамады. Китаплар да кыстырып килә иде. Күптән кулына китап алмаган Сәлим өчен бу үзе бер могҗиза булды.

Авылда җиде классны бетергәч, Сәлим кабат укымады. Дөрес, берничә мәртәбә өстәл артына утырырга туры килгәләде, ләкин алар кыс-

ка сроклы һөнәр мәктәпләре генә иде. Башта егет тракторчылар курсын бетерде. Армия хезмәтенә киткәнче авылда механизатор булып эшләде. Хәрби хезмәттә чагында шоферлыкка укыды һәм аннан кайтканнан бирле һаман эш тә эш. Сәлим бер төзү идарәсендә автобус йөртә. Эше көн аралаш. Тиккә вакыт уздырганчы дип ул үзләре янындагы техник училищега да шофер булып урнашты. Менә шуңа күрә аның бөтен вакыты я руль артында, я машина астында уза. Бигрәк тә училище машинасы интектерә — искегә тисәң исең китәр, дип белми әйтмәгәннәр, бер көн эшләсә, ике көн ремонт сорый. Сәлимнең китап түгел, каләм тотуы да путевкага һәм хезмәт хакы алганда ведомостька кул куюдан узмый. Менә шулай уза көннәр. Көннәр генә түгел, атналар, айлар, еллар... Ә баксаң, дөньяда үтә кызыклы һәм бик гыйбрәтле хәлләр язылган китаплар бар икән. Кайберәүләр мәктәптә чагында укып кала, ичмаса. Сәлимнең анда да нужа куып көне үтте. Җәй житсә, урманда печән чапты, аны җыеп, богыл куйды, кышын бәләкәй арба тартып утын ташыды. Унике яшеннән көтү көтте, ат жигеп колхоз эшенә йөрде. И, кайсын санап бетерәсең инде аның, атасыз бала эшләмәгән эш буламыни авыл җирендә! Шуңа күрә уку бөтенләй онытылды. Сәлим китергән китапларны баштарак ижекләп диярлек укырга керешге. Соңыннан гына, кем әйтмешли, китапны «су кебек эчә» башлады. Фирдия килгәч, кызык урыннарын аңа да күрсәтә, эчтәлеген сөйли иде. Ул гаҗәеп яңа бер дөньяга чумды һәм кайвакыт моннан тиз генә чыгармауларын тели иде. Ләкин бу уй аңа вакытлыча гына килә һәм ул аны кемгә дә булса әйтергә дә ояла. Кызны көтеп алса да, китапларын бирелеп укыса да, Сәлимгә Фирдияне борчуы уңайсыз иде. Чөнки ул эшли, укый. Эше әле ярый, ә уку — энә белән кое казу. Сәлим бу турыда кызга әйтеп тә карады. Ләкин үзсүзлелектә хатын-кызны җиңеп буламыни?!

Фирдия башта тынларга да теләмәде һәм Сәлим бик аптыраткач:

— Мин барыбер Разия янына киләм бит,— диде.

Шулай итеп Сәлим җиңелде, бу турыда яңадан сүз кайтарып әйтмәде. Хәер, бу очракта ул җиңүче булып калырга теләми дә иде, ахры. Чөнки Фирдиянең килүе аның өчен тансык, ә ярасына — дәва.

Фирдия Сәлимне күрергә килгәндә иң әүвәл Разия янына керә, соңыннан да шуннан китә иде. Беркөнне Разия иптәш кызында ниндидер үзгәреш күргәндәй булды. Очынып йөрүе, бизәнү-ясануга әвәсләнеп китүе, затлы киемнәрен киюе, шифаханәгә еш килүе — болар берсе дә Разия кебек үткен күзнең игътибарыннан читтә калмаган иде. Ул Фирдиянең йөзен илтифатсыз гына ут яктысына таба борып, турыдан ярып әйтеп тә ташлады:

— Карале, кызый, син әллә гашыйк булдыңмы?!

— Абау, китсәнә...— дигән булды ахирәте, ә йөзе гаеп эш эшләп тотылгандай кып-кызыл иде.

Беренче карашка беркатлы, юаш булып күренсә дә, Сәлим үз кирәгенә кыю булып чыкты. Шифаханә белән араны өзеп, таксида өенә кайтканда ул Фирдиягә туп-туры әйтте дә салды.

— Апасы, бүген соңгы көн. Моннан соң син — мине, мин — сине белмәбез. Мин бик белергә теләр идем дә, син каршыдыр, дим. Шулай булгач, бүген хәл ит: я бу очрашуны бетерик, я миңа кияүгә чык. Кимхур булмассың.

Алар арткы урында янәшә утыралар иде. Кыз Сәлимгә күтәрелеп карады һәм шунда ук башын иде. Чөнки бу уен сүз түгел, егетнең йөзе житди. Фирдия читкә карады һәм тәрәзә аша берәм-берәм артта калучы биек йортларны, шәһәр ыгы-зыгысын күрде, шау-шуын ишетте. Ә биредә, машина эчендә, тыныч. Бары узган чакрымнарны һәм Сәлим әйткәннән соң үткән минутларны санаучы счетчик кына тыкелди. Янәшәсендә Сәлимне, аның җылы карашын тойган хәлдә Фирдия уйга калды, ни

әйтергә дә белмәде. Ялгыш ишетмәдеме ул? Юк, Сәлим ап-ачык әйтте бит. Нигә алай кисәк кенә әйтте дә туктады соң ул? Тагын нидер әйтсен иде. Дәшми. Ә машина чаба: әнә Фирдиянең эш урыны — китапханә артка чигә, моннан Сәлим яшәгән тулай торакка да ерак калмый. Егет, шуны сизгән кебек, телгә килде.

— Минем кызлар белән йөрергә вакыт та юк, ике җирдә эшлим. Давай, хәл ит. Бер атнадан эшеңә килермен, әгәр риза булсаң — әйтерсең.

Такси белән бергә Фирдиянең йөрәге дә туктагандай булды. Чөнки бик ачык һәм бик гади ясалды Сәлимнең тәкъдиме. Романтик җанлы, каядыр күккә ашкынучан рухлы кыз өчен артык гади иде бу. Ләкин әйтелде. Димәк, уйла, Фирдия, синнән җавап көтәчәкләр.

Тулай торак каршында кыз егет белән саубуллашты.

— Тизрәк терелегез.

— Сезнең хәер-фатиха белән.

Ишек шапылдап ябылды. Егет кереп киткәч, урам бушап калды сыман. Чөнки саргылт кашлы бу егет Фирдиянең йөрәгенә якын була башлаган икән. Кыз әкрен генә кузгалды, эшенә юнәлде.

Бүтән вакытта ул эшкә дип җыена башлау белән бүген кая барырга, кемнәрне күрергә, ниләр башкарырга тиеш икәнен уйлый һәм аларның мөһим булуларына карап, билгеле бер тәртипкә китерә иде. Һәм күңелендә туган шушы план нигезендә ул аларны эш сәгате дәвамында башкарып чыга торган иде. Шуңа күрә аның эше һәрвакыт төгәл барды. Соңгы көннәрне дә бу тәртип үзгәрмәсә дә, Фирдия йокыдан торгач та башына килгән беренче уе Сәлим янына бару, аның хәлен белү була иде. Эш вакытында да алдан корган планнарына кайбер төзәтмәләр кертергә туры килгәләде. Менә бүгеннән шифаханәгә баруның кирәге калмады. Хәзер эш планына бернинди үзгәреш кермәячәк. Хәзер аның бөтен күңеле эштә һәм укуда гына булачак. Ләкин әле бая гына Сәлим белән аерылышкан һәм, кышкы һаваны иркен сулап, салмак кына атлап барган Фирдия үзен моңарчы кысып-буып торган кирәкле адым ясарга ирек бирмәгән богаулардан азат кеше итеп түгел, ә нидер югалткан кеше төслерәк хис итте, бик мөһим мәҗбүри бер шөгыле юкка чыкты шикелле. Әйе, бу шулай. Чөнки шифаханәгә баруның хаҗәте бетте. Хәзер ул фәкать эшенә генә барыр, анда үзенә юаныч табар. Ләкин Фирдия әле күңеле белән эшкә бирелерлек, эш турында уйларлык хәлдә түгел иде. Ул әле Сәлим турындагы уйларыннан арына алмый, аның белән булган хәлне, ул шифаханәдә дәваланганда аның янына баруын, Разия белән булган сөйләшүләрне янә бер кат зиһененнән кичерә иде.

Башта ул Сәлимне үзен бер залим кулыннан тартып алган кеше итеп карый иде. Тора-бара ул аңа бары егет кеше итеп кенә карый башлады. Ә соңгарак ул Сәлимне үзенә гашыйк бер мәҗнүн итеп күрде. Фирдия сукыр түгел, егетнең уй-карашын чамалый иде. Палатага килеп керүгә Сәлимнең йөзе балкып китә, Фирдиядән күзен алмый, кызара, сөйләшкәндә тотлыга, бутала. Үз-үзен тотышы да, аның әйткән сүзләре дә хәзер кызның ачуын китерми, гомумән, егет хәзерге заманның гадәти бер кешесе булып күз алдына килә. Дөрес, ул эрудициясе ягыннан Фирдия күреп белгән, аңа очраган егетләр белән чагыштырганда бераз оттыра, гомуми белеме, укымышлылыгы аксый. Кешеләр алдында үз-үзен тотышын да үрнәк итеп куярлык түгел, ул иң гади кагыйдәләрне дә белеп җиткерми... Монда егетне гаепләп тә булмый. Чөнки вакытында аны өйрәтүче, колагына тукып торучы да, аларны тыңлап утырырга вакыты да булмагандыр. Ул — эш кешесе. Ул файдалы, кирәкле эшне башкара, шуннан үзенә ләззәт ала. Аның ихтыяҗлары да чикләнгән. Ләкин ныклап тотынганда аны әле укырга да мәҗбүр итәрмен, кешеләр кырыкка җиткәч тә техникум-институтларда укып

йөриләр бит. Сәлимнең үз-үзен тотышы да үзгәрер. Фирдия, хатын-кыз буларак, үзенең инстинктына таянгандыр, чөнки хатын-кыз үзеннән көчсезләрне карау-үстерүгә бөтен көчен сарыф итүче һәм моны үзенең бурычы дип санаучы асыл зат.

Икенче яктан караганда эш менә ничек тора: Фирдия быел егерме алтынчы белән китте, бу яшьтә инде кызлар җүләрлек чорын кичергән, акыл утырткан һәм ак белән караны аера торган булалар. Бу яшьтә кызларны егетнең буй-сыны, төс-бите генә кызыксындырмый. Чөнки егерме бишне тутырган кызлар хатын-кызларга хас алдан күрүчәнлек белән тормыш итү турында уйлана башлыйлар, аларны тышкы ялтыравык белән генә алдап булмый. Яшерен-батырын түгел, Фирдия дә Сәлим турында барысын да — егетнең аңа булган карашын да, егеткә карата үзенең мөнәсәбәтен дә һәм аннан башка бик күп нәрсәләрне дә һәр яклап уйлагандыр. Кыз бала — диңгездә йөзгән кораб, ул күпме генә айкалмасын, чайкалмасын, бер вакыт, ярга килеп якорь салган кораб кебек кемне дә булса сайларга, кемгә дә булса килеп сыенырга тиеш.

Тирән уйга чумган Фирдия китапханә турына җиткәнен сизми дә калды. Ишек төбендә туктап, керергәме, юкмы, дигәндәй, берничә секунд икеләнеп басып торды. Нигәдер хәзер үзе кереп эшкә чумачак дүрт стенаны күңеле тарсына иде. Моңа көннең искиткеч сихри булуымы — чөнки төнлә яуган кар бөтен нәрсәне акка төргән, ул кояш нурларында җем-җем итә, агачларга әйтерсең лә вак кына энҗе бөртекләре сибәли, чыпчыклар чөкердәшә, күгәрченнәр гөлдер-гөлдер серләшә, — әллә кызның үзенең йөрәге ашкынулы идеме, — нидер сәбәп булды. Ә урамда халык, машина — бәйрәм диярсең. Әйе, кемнәргәдер бәйрәм икән шул. Әнә түбәсенә ике зур балдак ясалган кара «Волга» үтеп бара. Ул тасмалар, шарлар белән бизәлгән, алдына ак күлмәкле курчак утыртылган. Ак киемле курчак, пакь кар... Машина эчендәге кызның да киеме ап-ак, йөзе бәхетле... Ә машина үзе кап-кара...

## VI

Озынча тар бүлмә. Монда ничә еллар гомер узган. Бүтәннәрендә Сәлим озак тоткарланмый иде, ә бередә ун ел яши. «Кичә типтергәннәр ахры,— дип уйлады Сәлим чишенгәндә. — Әлек, бер өйрәнгәч, ярыйсы кебек иде, бик котсыз икән бу бүлмә. Монда Фирдияне ничек чакырырсың». Хәер, әле кызый киләм дип тә тормас. Бер атнадан барырмын, диде дә диюен Сәлим, ай-һай, түзәр микән. Анысына гына чыдар, ә менә әгәренки, яңадан килеп йөрмә, егет, дисә. Тот та асылын. Әйе, эшләр хөртигә әйләнәчәк. Хәзер Сәлимнең һич кенә дә элекке сукмакларны таптыйсы килми иде. Кеше шулай бит ул: әгәр беркая чыкмыйча, үз тирәсендәге билгеле кешеләр белән генә аралашып яшәсә, тормыш гел шулайдыр һәм башкача яшәүче юктыр кебек тоела. Барысының да яшәү рәвеше аныкы шикелле, дип уйлый. Ул, гомумән, үзенең ничек яшәве, нигә алай яшәве турында уйланмый. Аңа барысы да шулай булырга тиеш кебек тоела. Әгәр дә кеше каядыр барып кайтса, үз тирәлегеннән читтәрәк булган кешеләр белән аралашса, ул инде уйлана башлый. Янәсе, нигә ул болай да, бүтәннәр икенчеләй. Аның сәбәпләрен эзли, тормышын, яшәү шартларын үзгәртү турында уйлана. Сәлим дә шифаханәдә ятып, анда төрле кешеләр белән аралашып кайткач, үзенең бүлмәсендә дә болай яшәвенә чит кеше күзе белән карап куйды. Һәм моннан соң тормышын үзгәртергә дигән карарга килде. Бу Фирдиягә бәйләнгән. Ай-һай риза булырмы? Ул бит әнә нинди — буй җитмәс. Ә Сәлим кем? Гап-гади бер шофер, яше дә (Сәлим моны күңеленнән дә әйтергә курка) дүртенче дистәгә китте. Ә Фирдиянең чын

яшен егет белми, шуңа күрә аны егерме-егерме берләрдә генә дип уйлый иде һәм шундый чибәр, яшь кызның язмышын үзе белән бәйләренә шикләнә иде. Хәер, җентеклəбрәк тикшерә, уйлана башласаң, Сәлим дә төшеп калганнардан түгел. Ул тартмый, эчүе бераз бар, лəкин хәзерге заманда, кем әйтмешли, тавык та эчә. Аңа карап кына үзеңне кимсетергә, түбәнсетергә кирәкмәстер, ахры. Тагын нинди уңай яклары бар соң аның? Әйе, тиздән фатирлы булачак. Акчасы-ние түләнгән, ордер көтә. Хатын-кыз өчен бу кечкенә нәрсә түгел. «Шулай булгач, егет,— диде Сәлим үз-үзенә һәм кулларын тез өстенә куеп, әкрен генә урыныннан торды,— әйткән сүзеңнән кайтма».

Сәлим Фирдиягә ясалган тәкъдимнең дөрес, вакытында ясалган икәненә тәмам ышанды һәм бу тәкъдимнең тормышка ашуына да өмет белән карый башлады. Ул билгеләнгән вакыттан алда ук барып, кызга үзенең уй-теләкләрен янә бер мәртәбә кабатларга булды...

## VII

Шау-шуы, сөенечле мәшәкатьләре белән туйлар да узды һәм тормыш, Сәлим йөргән асфальт юлдай, берөзлексез агыла торды. Әйе, нәкъ асфальттагы кебек, артык селкетми дә, борылмада читкә дә алып ташламый, машина кебек сазлыкта да батмый, бер уйлаганда бик рәхәт — барасың да барасың... Лəкин гади юл белән чагыштырганда асфальтның бер хәтәр ягы бар: йокыны китерә. Шуңа күрә авыл шоферлары аны өнәп бетерми. Ә Сәлим өйрәнгән. Хәзерге тормышыннан ул бик канәгать. Нәкъ ул теләгәнчә, нәкъ ул көткәнчә. Бер көйгә салынган тормыш бара да бара.

Шул көенчә берничә ел үтте. Бу вакыт эчендә ике ят кеше бер-берсен бөтенләй диярлек белеп бетерә һәм шуның аркасында я бер-беренә бик нык ияләнә, я — бизә. Чөнки кешеләрнең бәхетле буласы килә. Ә бәхетле булу өчен кешегә ни кирәк?

Фирдиянең кияүгә чыкканына әле алты гына ел булса да инде барысы да бар: ике бүлмәле кооператив квартира (аның ачкычын Сәлим иртәгә туй буласы көнне алып кайтты), чәтертән кебек тере биш яшьлек кызы, ике җирдә даими эшләп, тагын аннан-моннан да җаен чыгаручы һәм акчаны күрәп ала торган, типсә тимер өзәрдәй таза ире. Шулар өстенә, бүгенге шәһәр халкы өчен зарури һәм горурлык билгесе саналган дача. Ике катлы йорты әле төзелеп бетмәгән. Сәлимнең машина үз кулында — анысын да булдырыр, мотоциклын сатып, машина да алыр, Фирдия шикләнми, ул яктан аның күңеле тыныч.

Ә нәрсә борчый соң аны? Югыйсә, аңа бөтен кеше кызыга: әнисе, туган-тумачасы, авылда яшәүче яшьлек дуслары аның тормышына сөенеп-сокланып бетә алмыйлар. Авылдан килеп, шәһәрдә урнашкан кем баласына тәти ди шундый тормыш? Бик күпләргә түгел. Аңа ирешсәләр дә гаилә корып, ун-унбиш ел чиләнгәч кенә ирешәләр.

— Кызым, кияүнең кадерен белеп кенә тор, әйткән сүзеннән чыкма,— ди Фирдиянең әнисе, кызларына кунакка килгән саен.

Әйе, Фирдия иренең сүзен аяк астына салып таптамый, Сәлим дә аның әйткәннәренә саңгырау түгел, лəкин... И, әнкәй, аңласаң иде син кызыңның йөрәгендә ниләр барын?! Ниләр генә кыласы соң? Ничекләр түзәсе? Бер нәрсә күзенә күренми бит кызыңның, син аһ иткән, чит-ятның күзен яндырган, көнчеләрнең йокысын качырган бу байлыкларга исе китми бит аның. Фирдия үзе дә аптырый: нишләп ул гына һаман тормышыннан риза түгел соң, нишләп аңа гына һаман нидер җитми, күңеле түгәрәкләнми. Әллә ул бер дә бу турыда уйланмыймы? Башкаларның ничек яшәгәнен, кеше почмакларында интегүче, акча алганнан ал-

ганга тиенен санап тотучылар юк дип беләме? Алай да түгел. Тормышның бу якларын да аз-маз аңлый ул. Ә шулай да барыбер үз-үзеннән канәгать түгел. Әллә нинди тормыш бит бу — ул хыялланмаган, көтмәгән, теләмәгән...

Һәм Фирдиянең күз алдыннан өзек-өзек картиналар, алты ел дәверендә булып узган эреле-ваклы вакыйгалар уза. Берәү өчен алар гадәти булса, Фирдиянең исә бәгырен телгәли, җелегенә тоз салалар иде.

Сәлим мәҗлесләрне бик ярата. Бәйрәм саен я үзе кунак чакыра, я туган-тумачага, дусларына бара. Ләкин үзендә булсын, кешедә булсын — исерә, сүзенең тозы юк, җырының көе юк. Фирдия оятка калып бетә: һәрвакыт шул хәл кабатлана. Шифаханәдән чыккач ул атлыгып, укырга керергә хыялланып йөрде, Васильеводагы автотехникумга барып та кайтты. Ләкин эш шуннан ары узмады. Өйләнешкәннән бирле Фирдия иренә дип китап ташый, ә алар кул тимәгән килеш киштәдә тора. Ярар, инде ни кыласың, өлешеңә тигән көмешеңдер, дип Фирдия аларына гына да түзәр иде әле. Ләкин төрле вакыт була.

Сәлим эштән кайтты. Кызмача. Телевизор карарга утырдылар. «Аккош күле» балетын тапшыралар иде.

— Бу аккошларның сыйрак шәп, анасы, ә? — дип, тел шартлатып, үзенчә елмаеп, сөйләнә башлады Сәлим.

Фирдия телевизорга керердәй булып, карап утырган кызына ымлап:

— Ни сөйләнәсең, тик кенә утыр,— диде.

— Мактыйм бит. Кая, алайса, беренчене ачыйк әле, анда футбол.

— Ты чего, пап, без бит карыйбыз.

— Иртәгә икенче сериясе була, иртәгә карарсың, кызым,— диде Сәлим һәм, үзенең юморга тартым тапкырлыгына сокланып, хихылдап алды.

Фирдиянең дә карыйсы килә иде.

— Карыйк инде.

— Ха, синең дә шәрә ир-атны күрәсең киләмени? Фигуралары шәптер шул. Алар бит безнең кебек эшләп ватылмаган. Бездә андый гәүдә юк шул.

— Затсыз,— диде дә Фирдия кызы белән икенче бүлмәгә кереп китте: — Әйдә, сабыем, мин сиңа әкият укыйм.

— Минем балет карыйсым килә!

Кызы, еларга житешеп, әтисенә астан гына карап узды, телен күрсәтте.

— На тебе!

Фирдия аны орышып та алды.

— Кызым, алай ярамый. Әтигә тел күрсәтмиләр.

Фирдия кызын юындырып, йокыга әзерләп, караватына салды да аның янына урындыкка утырды, кулына китап алды.

— Ул нехороший, син аның белән ятма, әни.

— Алай әйтмә, кызым, ул синең әтиең бит. Ул сине ярата, бүләкләр алып кайта. Тыңла, мин сиңа әкият укыйм: «Борын-борын заманда булган, ди, дәү сакаллы бер кәҗә. Аның булган, ди, өч бәтие... Тагын булган, ди, бу кәҗәнең өй-куышы...»

— Белдем, белдем. Кәҗә әйтә: «Кырдан кырга йөримен, кыр җимеше җыямын...»

— Таудан тауга йөримен.

— Тау җимеше җыямын...

— Кызым, син моны беләсеңмени?

— Кичә укыдың бит.

— Ә, шулаймыни? — дигән булды Фирдия һәм икенчесен укырга керешә. — Булган, ди, бер әби белән бабай. Аларның бер дә маллары булмаган, тик...

Фирдия укыганда кызы күзен дә йоммыйча дикъкать белән тыңлады. Аңлашылмаган сүзләр очраса гына бүлдерде, кат-кат сорады. Ә әкият тәмам булгач, кулларын чәбәкләп, караватында талпынды.

— Так и надо, так и надо,— диде ул, очынып шатлана-шатлана, һәм, әнисе йокларга кушкач, ялына башлады.— Әнием тагын берне генә.

— Ярар. Аннан йокларсың, яме.

Ләкин соңгысы бала өчен кызыксыз булып чыкты. Күрәсең, ул аны аңламады. Хәер, бәхет эзләүче бер эшлексез турындагы бу әкият Фирдиянең үзенең дә кәефен кырды. Ул үзе дә һаман нидер көтә бит. Булган белән канәгатьләнергәдер, бәлки? Ләкин Фирдия тагын каршылыклы уйларга чума. Нигә соң әле ул Сәлим турында гел генә начар фикердә, үз-үзеннән дә риза түгел. Нигә аңа шушы тормышына куанып, шөкрана кылып яшәмәскә. Тамагы тук, өсте бөтен, ире янында, алма кебек бала... Бәлки Фирдиягә артык җиңел килгәндер бу бәхет? Нигә соң ул Сәлимнең начар якларын гына күрә? Аңа кара күзлек аша карый. Алай карасаң, кояшта да таплар табып була бит. Бәлки кыз баланың язмышы шулайдыр. Төшкән җиреңдә туфрак бул, дигәннәр түгелме соң борынгылар. Ә хәзер нишләргә?

Фирдия тыныч кына йоклап яткан кызын битеннән үпте дә, юрганын күтәрә төште, утны сүндерде һәм, авыр атлап, залга чыкты.

Чыкса, телевизор бөтен көченә эшли. Сәлим, диванга башын кыңгыр салып, йокыга киткән. Фирдия телевизорны сүндерде дә, ирен уятып, урын җәя башлады.

Йокларга яткач та баягы уйларын куып җибәрә алмады, июль челләсендә атка каныккан кигәвен кебек, алар аны бимазалап һаман килә тордылар. Мондый хәлләр елга бер генә булса, Фирдия ыһ та итмәс, түзәр иде. Ләкин алар көн саен диярлек кабатлана, алар бер-береннән әллә ни аерылмыйлар да. Өендә сөйләшер, эч сереңне бүлешер кешең булмагач, нишләргә соң? Бәлки артык вакланмаска, яши бирергә, Сәлимнең кыланышларына әһәмият бирмәскәдер.

## XIII

Октябрь башы. Җилле көн. Агачлардан яфрак коела.

Йокы бүлмәсеннән Фирдия бер тупыл агачыннан березлексез сары яфраклар коелганын карап тора. Алар күмәк коелмыйлар, ә берәм-берәм, теләр-теләмәс кенә агачтан аерылып, тирбәлә-тирбәлә төшәләр. Төшкәч, бер-ике тапкыр әйләнеп, чирәмдә мәтәлчек аткан малайлар кебек, тәгәрәп китәләр. Ул яфраклар мәңге шунда калыр. Кабат агач башына мenә алмаслар. Кеше гомере дә шулай: гомер агачыннан еллар берәм-берәм китә тора... кире кайтмаска.

Әйе, кире кайтмаска. Ләкин айлар, еллар үткән саен кеше үзгәрә. Сабый үсә, мәктәп баласының гыйлеме арта, яшь гаиләдә яңа сөенеч — бәби туа, кыскасы, кеше тормышында һаман ни дә булса үзгәрә, яңара.

Ләкин айлар, еллар буена үзгәрешсез калган кешеләр бер дә юкмыни соң бу дөньяда? Бар. Кайберәүләр моны белмиләр, ә сизгәннәре үз хәлләре белән килешмәсәләр дә, аны үзгәртергә көч-кодрәт таба алмыйча, тайгак юлда батып яткан машина кебек, һаман бер урында таптаналар, искечә яши бирәләр.

... Сәлим өенә тагын кызмача килеш кайтты. Ләкин ишектән башка вакыттагыча елмаеп кермәде. Аның саргылт кашлары салынып төшкән, болай да эчкә баткан күзләре күренми диярлек.

Фирдия аны ишек ачып кертте дә кухняга юнәлде. Аннан чыккач, иренә ни дә булса әйтмәүне килештермичәме, әллә чыннан да аның хәлен белү теләге беләнме — ул моны үзе дә анык кына әйтә алмас иде — сорап куйды:

— Бүтән чакта, әзрәк салсаң, авызың колагыңа житеп, жырлап кайта идең. Ни булды? Нигә сөмсерең коелган?

— Ә,— дип кул селтәде Сәлим аңа, майкасын салып, ачу белән ишек катындагы тартма өстенә тондырды.— Директор белән телгә килдек.

— Нишләп? — дип сорады Фирдия, бу юлы аның тавышы яңадан кухнядан ишетелде.

— Мебель кибете янында торганны күрде.

— Анда нишләдең соң?

— Берәрсенә әйбер илтеп булмасмы, дип килеп кенә туктаган идем. Гомер булмаганны, ул тирәгә ничек килеп чыккандыр.

— Йомышы төшкәндер.

Сәлим ванна бүлмәсендә юынып чыкты һәм, кухняга кереп, ашарга утырды.

— Кыз кая?

— Урамда. Күрмәдеңмени?

— Юк, күзгә чалынмады. Директорны әйтәм, йомышы төшеп килмәгәндер ул: берәрсе чаккандыр,— дип Сәлим үзенең баягы сүзен дәвам итте. Ул әле һаман тынычланып житә алмый иде. — Училище эшенә машина ватык, ә чумарага — тәзек, дип орыша башлады.

— Кеше көлдереп йөрмә инде,— диде Фирдия һәм ире алдыннан бушаган тәлинкәне алып өстәл читенә куйды, чәй агыза башлады.

— Алай димә, анасы. Мә, алып куй әле, истә чакта. Төп-төгәл утыз таңкә. Тәки үз сүземне иттем: директор китеп баруга яңадан килеп туктадым. Бик удачно булды. Кайтышлый бер стаканны гөпләдем, ачуланма, яме.

Сәлим залга чыгып телевизорны жибәрде һәм диванга кырын ятты. Кухняда эше беткәч, Фирдия дә ире янына килеп утырды.

— Сиңа тагын китаплар алып кайттым. Бәлки техникумга әзерләнерсең.

— Нигә кирәк ул?

— Бик арыйсың бит, механик булып күчәрсең.

— Аларның зарплат мәче ялаган. Әле минем монда чүтки начар түгел. Кулда машина. Ә механик булсаң, көн саен эшләргә кирәк, училищены ташларга туры килә.

— Житәр инде. Укырсың...

— Һәй, укыган кешеләр дә әллә ни майтара алмый. Әнә, абыйның малае КАИ бетерде, инженер. Күпме ала дисең? Йөз егерме таңкә. Премия буламы, юкмы — алла кулында. Әзмәвердәй егет, буйга миннән озын, унбиш ел ми черетте.

— Аның перспективасы бар.

— Һи, әле ул үскәнче. Хәзер инженерлар буа буарлык.

— Мәскәү дә тиз генә төзелмәгән.

— Беләм. Бәлки берзаман ул завод директоры да булыр. Ләкин кайчан?

— Ул интеллект буларак югары, карашы киң.

— Ә нәрсәгә ул интеллигентлык? Кесәңдә акчаң булмагач, ни пычагыма ул? Аягыңны ботинка кыскач, дөньяның киңлегеннән ни файда. Исеме генә инде, тикшереп карасаң, ул мин ашаганны ашый, мин кигәнне кия алмый торгандыр әле.

Сүз бүленде, чөнки урамнан кызлары кайтып керде һәм мыштым гына кухняга үтте. Фирдия кызның да ашарына бүлеп бирде.

— Опять пьяный? — дип сорады кызы, пышылдап кына олы бүлмәгә ишарәләп.

— Юк,— диде Фирдия ачу белән һәм ул ашаганда ире янына чыгып утырды.

Сәлимнең күп тапкырлар ишеткән сафсатасын тыңлыйсы килми иде аның, чөнки һаман бер балык башы. Шуңа күрә ул теләр-теләмәс кенә икенче темага күчте. Монысы да бер бүген генә кузгалмаган иде, шуңа күрә Фирдия ире сүзен ишетүдән бигрәк, үзенең буталчык уйларына ачыклык кертү өчен, үзен борчыган һәм экрен-экрен күңелендә бөреләнгән уйның ни кадәр дөрес икәне турында бер төпле фикергә килергә тели иде.

— Хәлимәне берәр түгәрәккә яздырасы иде бит.

— Ниндигә?

— Фигуралы шууга дигән идем бит. Әле һаман кереп белешмәдеңмени?

— Юк, пожалый сөйләшмәм дә. Кем йөртә аны? Икебез дә эштә.

— Җае чыгар иде әле. Кирәк бит. Кеше балалары...

— Ничава, беребезне дә беркая да йөртмәделәр. Аңа карап гарип җиребез юк. Быел укырга кирәсе елы, вакыты да булмас, авырга туры килер.

— Ул инде хәзер үк укый-яза белә. Математиканың яртысына життек.

Сәлим аптырап, кухнядан алар янына чыккан кызыннан сорады.

— Чынмы?

— Да, папа,— диде кызы горурланып.

— Өлгерермен диең, кызым, әйеме,— дип Фирдия Хәлимәнең башыннан сыйпады.

— Әйе, минем Ирина Роднина кебек кататься итәсем килә.

— Кирәкми, кызым, анда бөтен кешегә арт күрсәтеп йөрергә. Мин сиңа скрипка алып бирәм, пиликать итәрсең. Кил әле яныма.

Сәлим, кызын иркәләмәкче булып, сузылды, ләкин Хәлимә әтисенең йонлач юан беләген этеп җибәрде.

— Сам пиликай. Фу, опять пахнет.

— Лимонад ул кызым. Кил әле бер үчтеки итим.

— Мин кечкенә түгел.

— Ярар, тимә балага. Эчкәнсең икән, буеңа сеңдер,— диде Фирдия һәм яңадан кухняга чыкты.

Хәлимә йокы бүлмәсенә, уенчыклары янына юнәлде, ә Сәлим бераз вакыт телевизор карап утырды да, гадәтенчә гырлап йокыга китте.

## IX

Җәй айларында шәһәр урамнары ничектер бушап калган төсле, киңәеп киткәндәй булалар. Чөнки җәй айлары — ял, каникуллар чоры. Эш кешеләренең күбесе чираттагы ялга чыга, чират житмәгәннәре дә тик ятмый — справкасын юнәтә, хәйләсенә керешә, ничек итсә итә — барыбер ялын җәй көне алырга тырыша. Кайберәүләр ялгыз әти-әнисе янына авылга ашыга, берише Кырым, Кавказ төбәкләренә ләззәт, могҗиза эзләп сәфәргә юнәлә. Студентлар һәм мәктәп балалары да кайсы кая тарала. Кайбер кешеләрне бакча тотып тора, алар беркая китми, ләкин аларны да шәһәр урамнарында сирәк күрәсең.

Фирдия быел да беркая чыгып китә алмады. Беренчедән, Сәлим белән ялы бер вакытта туры килмәде, икенчедән, дача — аяк-кулга салынган богау.

Разия исә тагын үз кыйбласына — Сочига юл тотты. Барсын, бик яхшы, ахирәте өчен Фирдия шатлана гына. Ләкин җанны борчыганы шул: Разия көньяктан кайткач та аның янына килә. Болай гына, үз итеп, ә шулай да... Билгеле, кием — бүтән, төс-кыяфәт тә үзгә. Юк, ул ахирәте алдында мактанырга, аны кимсетергә дип килми. Андый уй Разияның башында булганы да юк, ә менә Фирдия — китек күңел өчен

аның килүе һәкъ менә шулай кабул итель. Фирдия бу юләр уен уйламаска, төбе-тамыры белән йолкып ташларга тели — булдыра алмый, күңеленнән куып җибәрергә тырыша — уй китми. Ә шулай да ахирәте белән очрашу — рәхәт бер мизгел. Разияның килүе Фирдиянең күңел кылларына кагыла, иң нечкә җепләрен зеңләтә, аның белән көрешү, карашын тою авыр, ә барыбер бу зарури һәм Фирдия аннан беркая да качып котыла алмый.

Ул, платформалы босоножкалары белән ялкау гына атлап, ишектән килеп керде. Чынаяк тәлинкәсе кадәр пыялалы кара күзлеген ялтыратып, Фирдиягә туп-туры килә. Ышкылып-таушалып бетеп, зәңгәрдән аксылга әйләнә башлаган джинси чалбарын зур аеллы киң саргылт каеш буган. Ә дустының тәненә сыланып торган юка кофтасын күргәч, Фирдиянең шатлыктан ачылган авызы шул килеш калды...

— Абау, синме соң бу?

— Мәгарәңдә ятып, кеше танымаска әйләнәсең инде.

Алар кочаклаштылар, битләрен чупылдатып алдылар. Эчке бүлмәгә керделәр.

— Туктале, тагын бер карыйм әле үзеңә.

— Кара-кара, сиңа тансыктыр мондый киемнәр.

Аннары алар кара-каршы утырдылар.

— Кайчан кайттың?

— Өченче көн. Кичә, бүген эшләдем инде.

Разия тезен-тезгә куеп утыра иде. Аякларын алыштырып, иңенә аскан сумкасыннан сигарет, шырпы алып, көйрәтеп җибәрде. Башын кыңгыр салып төтен өргәч, гамьсез генә сорап куйды.

— Ничек яшисең?

Сүз бүленде, чөнки ачык ишектә бер ир-атның житү чәчле башы күренде.

— Гафу итегез,— диде Фирдия урыныннан торып.

— Исәнмесез.

Керүче егерме дүрт-егерме биш яшьләрендәге житди кыяфәтле (хәтта кеше белән исәнләшкәндә дә аның кашлары җыерылган килеш кала иде) бер егет. Фирдия аның сәламен кабул итте һәм почмактагы шкафтан бер китап алып, егеткә бирде.

— Менә, көчкә таптым.

— Рәхмәт инде сезгә, Фирдия апа. Борчыдым. Бер атнадан китерәм, яме.

— Ярый. Мин ун көнгә дип сорап алдым.

Егет, кат-кат рәхмәт әйтеп, уку залына чыгып китте.

— Кем ул? — дип сорады егетне баштанаяк күздән кичереп, аңа уңай бәя биреп өлгергән Разия.

— Төзүче. Читтән торып институтта укый.

— Күптәнге танышыңмы, әллә шушы тирәдә торучымы?— дип сорады Разия күзләрен уйнатып, һәм ирен чите белән генә елмайды.

— Кит инде,— диде Фирдия ахирәтенең тел төбен аңлап. — Күршедә генә диярлек, элек Сәлим яшәгән тулай торакта яши ул. Җәй көне дә ял итми бичара, һаман укуда.

Ахирәтләр арасындагы сүз яңадан элекке сызага төште.

— Я, сөйлә үз хәлләреңне? Кайда булдың? Әйбәт ял иттеңме?

Разия лак белән буялган ялтыравык озын тырнаклы бармакларын өстәлгә бәргәләп алды.

— Шикарно.

Аның шулай икәнен Фирдия үзе дә күреп тора иде. Разияның тәне шоколад төсенә кергән, ябыккан да ахры, тагын да зифаланган. Бер никадәр вакыт ахирәте кайда, ничек ял итүе турында сөйләде.

Аннары:

— Менә, сиңа пластинкалар алып кайттым,— дип, Разия сумкасыннан бер китап тартып чыгарды. — Абба, Бони-м язмалары.

— Алары ни тагын? — диде Фирдия, ахирәте алып биргән пластинкаларны әйләндергәләп.

— Ансамбльләр. Аларны ишетүгә яшьләрнең күзе тона. Безнең янга Югославиядән АБС килгән иде, көчкә билет достать иттек. Ужас, что творилось! Пугачевага да бардык. Ярыйсы гына... Син ничек соң монда?

— Мин дә кичә эшкә чыктым. Беркая барып булмады. Виктория җыеп, варенье кайнатып, бакча белән өй арасында киләп сарып вакыт үтте.

Разия ахирәтенә текәлеп карады, аның әллә ни күзгә ташланырлыгы булмаган өс-башын, түгәрәк буй-сынын күздән кичерде.

— Әллә бүртә башладың инде.

— Юк, тазарганмындыр.

— Әллә икенчесенә җыенасыңмы дип торам.

— Белмим әле,— диде Фирдия сүлпән генә.

— Тиле булма. Яшә рәхәтләнеп, үзең өчен. Баладан кем рәхәт күргән хәзер. Ир бала булса — бандит, хулиган, кызлары — унбиштән себереләә башлый...

Фирдия ни ә, ни я димәде. Аның бу турыда сөйләшәсе килмәвен күреп, Разия теманы үзгәртте һәм сумкасыннан кәгазьгә төргән шешә чыгарды.

— Әйдә, очрашу хөрмәтенә сыйлыйм үзеңне.

— Рәхмәт, эчмим. Тегеннән алып кайттыңмыни?

— Юк, бу әле мондагы. Коньяк.

— Акча түгеп шул кандала суын алмасаң.

— Бушлай килгән ул.

— Ничек?

— Бер таныш калдырып киткән. Мин аның туганын үзебезгә больницага урнаштырган идем.

— Шуның өчен бүләк алып килгәнме? Ничек кулың бара...

— Бәй, алмасаң, кешене рәнҗетү була бит. Беркөн ательеда эшләүче... Ой, туктале, ательега шалтыратыйм. — Разия өстәлдәге телефонга үрелеп, номер җыйды һәм ягымлы тавыш белән сөйләшә башлады. — Зөләйха Шариповна, хәерле көн. Әйе, мин. Снимокларыгыз әзер. Әйе. Үзем килиммени? Ә, шулаймыни? Ярый, яхшы. Әйе, шулай диган идем шул. Яхшы, килермен.

Разия трубканы куеп, Фирдиягә бер-ике сүз белән генә кем белән һәм нәрсә сөйләшүен аңлатып бирде.

— Сизенгән кебек снимокларын үзем белән алган идем. Әйдә, барып килик, бәлки сиңа да өлеш чыгар. Бәрхет вәгъдә итә.

— Бик остардың син,— диде Фирдия ахирәтенең аны да үзе белән барырга димләвен ишетмәгәндәй.

— Шунсыз ярамый хәзер. Син генә җебеп йөрисең. Тап яхшы китаплар, подписка, әллә кемнәр белән дуслашырбыз.

— Соң бездә китап җитәрлек бит, укысыннар,— диде Фирдия, ачык ишектән күренеп торган киштәләргә һәм бу бүлмәне дә тутырган китапларга ымлап.

Разия, бала-чагага карагандай, мыскыллы елмайды.

— Һи, юләр, хәзер кем китапханәгә йөреп китап укый?! Үз кадерен үзе югалтмаган һәр кешенең өендә хәзер бөтен юньле китап. Менә шул турыда сүз бара. Кара базарда китап үз бәясеннән өч тапкыр артык йөри. «Сорочка»да чүпрәк-чапрак та ул кадәр түгел, иң күбе ике бәя. Ә китап... Әнә, ике йөз томлык всемирка өч мең ярым, ди? «Запорожец» бәясе...

— Кирәк кеше аладыр инде.

— Әле бер гинеколог сөйләп торды. Бер хатын шул базарда җеп

белән үлчәп йөри, ди, киштәдә менә шушының кадәр буш урын бар, күрән тышлы китаплар кирәк, дип әйтә, ди.

— Монысы инде көлке. Ә берәү кирәгеен таба алмыйча интегә...

— Алаймы, түгелме — белмим,— диде Разия, ахирәтен сүзеннән бүлдереп. — Ә менә китапның дефицит икәнен беләм. Үзегезгә яздырып ал да шәпләрен — озатырбыз.

— Ничек? — дип сорады Фирдия дусты әйткән сүзнең асылына төшенә алмыйча һәм аптырап, ахирәтенә, аның затлы крем сөрткән йөзенә текәлде. Разия алдында ул үзенең көлке хәлгә кала баруын да сизә, ләкин берни эшли алмый, чөнки алар икесе ике телдә сөйләшәләр иде.

— Таныш-белешкә бирербез,— диде Разия, шуңа да башың җитмимени дигән кыяфәт белән Фирдиягә карап. — Аннары югалды, урладылар диярсең дә, списать итәрсең.

— Җыен тузга язмаганны сөйләмә инде,— диде Фирдия, тавышын акрынайта төшеп.

— Һи, мондый карашың белән бик авырдыр сиңа яшәве, кызый. Ярар, әйдә киттек. Ательега соңга калмыйк.

Разия торып басты, шешәне кире сумкасына салды һәм өстәлдә яткан күзлеген алып киде дә көзгегә карады.

Фирдия уңайсызланып кына ахирәтенә иярде һәм, тиздән кайтырмын, дип кызларга әйтте дә, Разия белән чыгып китте.

Ательеда эшләре пеште: икесе дә костюмга заказ бирделәр. Ателье мөдире, Фирдиянең китаплар белән эш итүен белгәч, чат ябышты, кирәкле китапларның тулы бер исемлеген язып бирде. Көчкә-көчкә ычкандырып, берәр яхшы китап табарга вәгъдә итеп, Фирдия аннан котылды. Ательедан ул, Разия күпме кыстаса да, аңа ияреп китмәде. Ахирәтен иртәгә очрашырга күндереп, китапханәгә — эшенә кайтты.

## X

...Сәлим бүген дә лаякыл исереп кайтып керде.

— Тагын ни шатлыктан эчтең? — дип сорады Фирдия мыскыллы елмаеп.

— Бүген кайгыдан.

— Битең нишләде? — диде Фирдия, иренең тырналган, күз төбе яныш чыккан йөзенә карап.

— Ә, аны әйтәсеңме? Булды әзрәк, берәү белән чәкәләштек.

Сәлим хатынына карап елмайды һәм, сул кулы белән стенага таянып, ботинка бавын чишәргә маташты. Ләкин гәүдәсе я уңга, я сулга чайкалып китә иде. Ахырда ул, аякларын селкеп, бавын ычкындырмыйча гына ботинкаларын салды. Соңгысын салганда ботинка ычкынып китте һәм коридордан залга ук очты.

— Әкрен.

— Ярар, ярар,— диде Сәлим хатынына һәм кинәт аның кыяфәте үзгәреп, чырае кырысланды. — Тегенең кое-что исенә төшердем әле. Хәзер ул аптекага план тутырырга булышсын инде. Нигә кем дип сорамыйсың? Миңа кадаган бәндәне әйтәм.

— Әле син аны онытмадыңмыни?

— Ю-ук.

— Ничек таптың соң аны?

— Акча барысын да эшли.

Фирдия дәшмәде. Чөнки ире тагын үзенең фәлсәфәсенә бирелер, акча, яшәү турында сафсата сөйли башлар дип көтте. Ләкин Сәлим ул турыда сүз куертырга җыенмый, аның уйлары бүтәнчәрәк иде. Хатынының дәшмәвен дә ул үзенчә аңлады һәм бу тынлык аның ачуын кабартты. Маңгаена төшкән чәчләрен баш чөеп артка селкеп җибәрде дә,

кулларын йодрыклап, коридор уртасында тураеп басты. Фирдия аңа җылы су җибәрергә ваннага кереп бара иде. Сәлим аякларын аерып басты да, хатынының юлына аркылы төште. Күзләре зәһәр ялтырый, карашы куркыныч иде аның. Йонлач күкрәген кулы белән уып:

— Нигә дәшмисең? — дип сорады.— Сөяркәң җәлме әллә?

Сәлим тешләрен кысып, күзенең агы белән аңа карап тора иде. Кысылган иреннәрендә ачы елмаю. Җәенке борын тишекләреннән пар бөркеп, пошкырып торган атка охшаган иде ул бу минутта. Яңак мускуллары уйный.

Фирдия кисәк күтәрелеп, Сәлимгә күз атты.

— Ни сөйлисең син? Нишләп минем сөяркәм булсын ул? — диде.

— Хәзергесе димим, элеккесе. Әйт, алайса, кемең иде? Синең бит миңа чыкканда шулпаң гына калган иде, ә өресен кемгәдер бер бәхетлесенә эчерткәнсең.

Фирдия ни әйтергә белмичә, тораташ кебек катып, иренә текәлде. Шаккаткыч хәл, күпме гомер куенында елан асраган икән бит ул. Ничә ел торып искә төшергәне булмады, туйдан соң да тел тибрәтмәде. Ә хәзер менә казып чыгарган. Фирдия тыныч кына сорап куйды.

— Ә ул сиңа бик мөһим идеме?

— Үзең ничек уйлыйсың?

— Алайса нигә башта ук сорамадың соң?

— Әйткән булыр идеңме?

— Билгеле.

Сәлим мондый җавап көтмәгән иде булса кирәк, бер мәлгә аптырап калды. Ләкин бозлы таудан шуучы аска төшеп җитмичә туктый алмаган кебек, ул да үзенең Фирдияне мәсхәрә итүен, аны газапларга, аннан сүз белән генә булса да үч алырга тырышуын дәвам итте. Аның һич кенә дә әле генә хатыны әйткән белән килешәсе килми һәм бу сүз көрәштерүдә җиңүче булып калырга тырыша иде.

— Һы, әйтерсең, бар...

Шушы соңгы сүз, тулы стакан ташып аксын өчен бер тамчы су җиткән кебек, Фирдияне чыгырыннан чыгарды, пычак булып йөрәгенә кадалды. Аны мәсхәрәләү генә җитмәгән, ул әле аңа ышанмый да икән. Бәлки ул өйләнешкәннән бирле аңа ышанычсыз, бозык, ирен алдарга сәләтле бер хатын итеп карагандыр. Бәлки ул, теле белән әйтмәсә дә, үзен мөгезле ир дип санагандыр һәм менә бүген, теге егет белән очрашкач, ничә елдан соң аннан үчен алып, Фирдиядән дә үч алмакчыдыр. Я, хода, кем белән яшәгән ул. Кемне куенында җылыткан. Фирдия, гарьләнеп, үз-үзен белештермичә елый башлады һәм битен куллары белән каплады, иңбашлары дерелди иде. Аның күз яшьләрендә барысы да бар иде: Сәлимнең бүгенге рәнҗетүе дә, үзенең аның белән әрәм үткән еллары да һәм хәзер инде тиздән кабул ителәчәк карарның ахырын тою, алдан күрү дә — чөнки алар икәү генә түгел бит — араларында, аларны әзме-күпме бәйләп торчы өченче җан иясе дә бар бит. Һәм берничә секунд эчендә шуларның барысын да уйлау аның зиһенен томалады, ул үзен берни күрмичә томан эченнән баргандай тойды, ләкин бераздан барысы да ачылды. Үткән юл да, алдагысы да, барысы да үз урынына кайтты. Моңа Сәлимнең бәреп әйткән ачы сүзләре сәбәпче иде.

— Ела, ела, шайтанның күзе яшьле була, ди торган иде әби мәрхүмә.

Сәлим бу ачы сүзләрен эчке тантана белән, җиңүче сыйфатында әйтте. Хәзер сөйләшер сүз дә бетте шикелле. Ләкин Фирдия дә күңелендә җыелганны иренең алдына чыгарып түкмичә тыелып кала алмады.

— Оятсыз. Мин синең егет чакта йөргән хатыннарыңның барысын да беләм. Аның белән авыз чайкаганым булдымы?

— Безгә шулай положено.

— Нәрсә — положено?

— Хатыннар янына йөрү. Әгәр егетләр тол хатыннар янына йөрмәсә, бер саф кыз да калмас иде. Болай да инде...

— Шуның белән мактанасыңмы? Их син! Ә нигә синең белән ничек алай булды, дип сорамыйсың.

— Бәлки үзеңне гаепсез итеп күрсәтәсең киләдер?

Фирдиянең хәле бетте. Дөресрәге, бу мәгънәсез сөйләшүдән арды ул. Үз туксанын такылдаган бу мүкләк сыерга ничек итеп барысын да аңлатырга һәм, гомумән, аңлату кирәкме. Ул хатын-кызның, бигрәк тә кыз баланың уй-хисләрен, вакыты-вакыты белән ялкынланып, дөрләп янган йөрәген, күңелендә ташкын булып аккан хисләрен, бернинди киртәләргә дә карамыйча, үзенчә генә агарга теләгән хисләр ташкынын ничек аңлатырга! Юк, моны бит сүз белән генә әйтеп биреп булмый. Моны иң якын кешең генә, аның да әле йөрәге синекедәй бердәм булып типсә генә аңлар. Ә бөтен рухы, бөтен барлыгы чит булган бу тун күчәнгә табигать тарафыннан аны аңлау сәләте бирелмәгән. Шулай булгач, сүз, вакыт, исраф итеп торуның хаҗәте бармы? Калсын үз фикерендә. Фирдияне яманласын, үзе чиста булып калырга тырышсын. Моннан гына ни зыян соң күз яшьләрен түгеп, диванда утырган яшь хатынга. Тор, Фирдия, сөрт күзләреңне, җебеп төшмә. Кылган яхшылыкларыңа, аңа багышлаган көн-төннәрең бәрабәренә ишетәсеңмени син бу сүзләрне. Шушы җәберләрне күрер өчен чыктыңмыни син кияүгә?

Фирдия торып, кием элгече янына килде, күзләрен сөртте һәм кискен бер карарга килгән кеше кебек, әкрен, ләкин нык хәрәкәтләр белән киенә башлады.

— Син кая җыенасың?

— Кибеткә,— диде ул иренә карамыйча, чөнки күтәрелеп караса ул аның сытык чыраен, җәенке борынын күрүдән курка иде.— Әллә китә дип курыктыңмы?

— Китеп кая барасың? Кем сине колачын җәеп көтеп торсын. Шул теге булса гына инде.

— Син коточкыч кеше икәнсең! — диде Фирдия һәм тагын, яшенә буылып, чыгып китте.

## XI

Фирдиянең күңеле авыр минутларда һәрчак Разияга тартыла. Ахирәте аны юатмый, кызганмый, ә күбесенчә әрләп ташлый иде. Ә шулай да Разия гына бөтен тирәнлеге белән аңлый аның уй-хисләрен.

Менә хәзер дә башын кая куярга белмәгән Фирдия ахирәте янына китте.

... Фирдия икенче рюмкадан баш тарткач, Разия аны яңадан кыстап тормады һәм җиңелчә генә үзе эчеп җибәрде.

— Әйдә, мин сине бер терапевт белән таныштырам,— диде Разия, кәгазеннән арындырган шоколадлы конфетының яртысын кабып куйгач.— Чын мәгънәсендә интеллигент, кандидатский әзерли.

— Нигә ул миңа?

— Йөрерсез.

Фирдиянең чынаяк күтәргән кулы ярты юлда туктап калды. Пөзендә аптырау.

— Ничек? — диде ул аңышмыйча.

— Соң ничек йөриләр инде? Аның сөяркәсе булырсың. Ул шулкадәр күп белә, бик итагатьле.

Фирдия аптырап, күзләрен зур ачып ахирәтенә карады, чынаягын ирененә тидермичә өстәлгә кире куйды. Аның кашлары күтәрелеп китте.

— Ир өстеннән йөрергә кушасың бит син миңа!

Фирдиянең тавышын күтәреп, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп һәм ничектер чирканып әйткән бу сүзләренә каршы, Разия тыныч кына сөйли башлады.

— Нигә? Әллә синнән-миннән генә калырмы,— диде ул исе китмәгән кыяфәттә.— Элек тә йөргәннәр, хәзер дә кимен куймыйлар, бездән соңгылар барыбыздан да уздырачак әле. Әнә, кайсыдыр илдә ир өстеннән йөргән хатынны асып үтерәләр икән. Аңа карап, туктыйлар дип уйлыйсыңмы? Булмаганны. Ә бездә аны тыя торган бернинди закон юк. Киресенчә, бөтен закон хатын-кыз яклы хәзер. Әгәр берәрсе, ирем эчә, кыйный, дип жалоба белән барса, шундук унбиш тәүлек чәпиләр. Ә ир шулай дип барса — көләләр. Так что курыкма.

Бу кадәресен генә Фирдия белә иде, әлбәттә. Ул да бит айдан төшмәгән. Кеше йөргән сукмактан йөри, кеше яшәгән зур йортта тора. Нинди генә хәлләрнең шаһиты булмыйсың да, нинди генә могҗизалар ишетмисең. Хатын-кызга хокуклар артык күп бирелде, таләп кимеде шикелле. Анысы хак. Ләкин аңа карап бөтенесен бер калыптан сөреп булмый бит. Күпчелек хатын-кыз яхшы ана, тугрылыклы тормыш иптәше,囗 эштә — үрнәк. Ләкин, кызганычка каршы, Разияның сүзләрендә дә хаклык бар бит. Шулай да бу мәсьәлә үзенә килеп кагылгач, Фирдия аяк терәп бәхәсләшергә, үзен якларга әзер иде. Чөнки ул ахирәте әйткәнне башына сыйдыра алмый иде.

— Ә намус, оят?

— Фи...— диде Разия, бот чабып көлгән авыл хатыннары сыман кул селтәп.— Әнә минем Мәскәүдәге апа әйтә: иренә тугрылыклы хатынны хәзер бер мәхлуккә саныйлар, ди. Андыйлар бармак белән генә санарлык, ди.

— Белмим тагы,— диде Фирдия иңнәрен сикертеп.— Минем дә бергә үскән иптәш кызым Мәскәүдә тора. Кунакка кайткач, ел саен авылда очрашабыз, бер дә андый нәрсә сөйләгәне булмады.

— Аны теләсә кемгә әйтмиләр инде.

Фирдиянең уенча, Разия аның үзен дә бер мәхлуккә саный иде шикелле. Дөрес, ул аны теле белән әйтми, сиздермәскә тырыша, ләкин үзүзен өстен куярга тырышуда, кинаяле сүзләрендә, алар артында яшеренгән мәгънәләрдә, бүтәннәр турында сөйләгән булып, вакыт-вакыт суктырып куюында шул чагыла түгелме соң?

Фирдиянең күзәткәне бар: ир-атны татып караган уналты-унҗиде яшьлек кызлар үз яшьтәшләренә түбәнсетеп карыйлар, аларны бала-чагага саныйлар. Чөнки «иртә өлгергәннәр»гә иптәшләре белмәгән серләр, алар татымаган ләззәтләр билгеле. Һәм алар үзләрен зурга санап, бүтәннәргә кызганыч бер бәндәләр итеп карыйлар. Бу аларны иптәшләре каршында үстереп җибәргән кебек була. Ләкин бу беренче карашка, тыштан гына шулай, чөнки бу тышкы ялтыравык кабырчык кына. Эчтән исә алар һәр даим ут йотып, кара көеп йөриләр. Чөнки әти-әниләре сизүе, эшнең тирәнгә китүе һәм алар теләмәгән нәтиҗә килеп чыгуы бар. Барыбер ул кызларны алдагы билгесезлек куркыта. Алар хәтта ир-атны тиешлесеннән артык якын җибәрмәгән кызлардан көнләшәләр дә. Ләкин монысы беркайчан да тышка бәреп чыкмый.

Фирдиянең бу уйлары үзенә кагылмый, чөнки ул ир-атны соңрак, бөтен кылган гамәлләрен аңлы рәвештә эшләрлек һәм аларга үзе җавап бирерлек яшьтә белде. Марат аның беренче һәм мәңге онытылмас мәхәббәте иде. Моның өчен үкенү беркайчан да булмаячак. Шуңа күрә Фирдия үзен «кайберәүләр» белән бутамаска, аларга тиңләмәскә тырыша. Ә менә хәзер Разия Фирдиягә үз каланчасыннан торып карый шикелле, чөнки ул инде оят, намус дигән төшенчәләрдән ерак тора. Ул аларга карап кына эшлисе эшен ярты юлда калдыра торган җебегән хатын түгел. Аның өчен тормышны алып барырга, ләззәт алыр өчен,

яки тормышта кирәге чыгардай кем белән булса да бәйләнешкә керү кирәк икән — бернинди киртә юк. Әйе, Разия өчен шулай, ә Фирдиягә ничек?

— Юк, мин алай булдыра алмас идем,— диде ул өстәл янынннан кузгалып.

Разия да урыныннан торды. Бөтен савыт-сабаны раковинага ташлады да, ахирәтен култыклап, бүлмәгә чыкты.

— Утыр,— диде ул һәм тәкәллефсез генә элеп алып китте. — Алайса яшә инде шул гыйбадың белән, мукләнеп беткәнче... Кара инде бу күлмәгеңне. Каян алдың моны?

— Туган көнемә алып кайтып бирде,— диде Фирдия һәм, ни булган, дигәндәй өс-башына карап алды.

— Сал, ташла чүплеккә. Моның модасы әллә кайчан үтте бит инде.

Разия ахирәтенең хәтере калыр дип тә уйламады. Һәм дөрес эшли, чөнки Фирдия үз хәлен аз-маз аңлый иде.

— Яхшы түгел.

— Яхшы түгел, яхшы түгел, имеш,— диде Разия аны бала-чагадай үчекләп.— Оят, намус, имеш. Төкер барысына. Ә, беләсеңме нәрсә?

— Нәрсә?

— Аерыл.

Фирдия куркынып ахирәтенә карады. «Каян белә ул минем күңелемдә ни барын, минем шул чиккә җиткәнемне һәм бу турыда киңәш сорар өчен килүемне? Сизенде микәнни?»

— Аннары?

— Минем шикелле яшәрсең.

— Ничек?

— Берәр дәрәҗәле кешенең сөяркәсе булырсың. Әнә минем Василий Михайловичның бик якын дусты бар. Әле карт түгел, алар икесе бер чама — илле тирәсендә.

Фирдия ахирәтенең тормышын яхшы белә иде. Разия ире белән аерылышты, дөресрәге, ирен куып чыгарды. Бер бүлмәле фатирда баласы белән генә яши. Зур бер оешмада баш инженер булып эшләүче Василий Михайловичның сөяркәсе икәнен үзе дә яшерми, туган көненә, бәйрәмнәргә ул алып биргән әйберләрне Фирдиягә күрсәтә. Василий Михайлович аңа иң әүвәл танышу истәлеге итеп алтын чылбырлы гәрәбә кулон бүләк иткән, аннары асыл ташлы йөзек, әле күптән түгел генә тун-дубленка белән сөендергән. Фирдия: бу бүләкләргә акча каян юнәтә соң ул, дип сорагач, Разия анысын да яшереп тормады. Василий Михайлович квартал саен рационализаторлык тәкъдиме бирә, я кемнәр беләндер өлешкә керә икән. Ә аның өчен күпме акча алуын хатыны белми, ди. Премияләрен дә тулысынча өенә кайтармый, күрәсең. Менә шулай яши хәзер Разия. Исерек иренең көен көйләп тә чиләнми, иргә дә аптырамый. Фирдия кебек, оят, намус, дип тә борчылмый. Әле Василий Михайловичтан башка кешесе дә бар, анысы бер яшь врач. Әйе, әллә нишләбрәк киттек. Кем ничек булдыра ала, шулай тормышка яраклаша. Кыскасы, кемнең кулында — шуның авызында. Василий Михайлович кебекләр кул озайта, алдаша, кечерәкләре алардан калышмаска тырыша. Хөкүмәт кесәсе белән үз кесәсен бутаучылар күбәеп китте. Ул машиналарны үз йомышына чаптыруга гаҗәпкә калырлык. Хәтта трактор, экскаватор кебек нәрсәләрне дә бәләкәй арба урынына үз хуҗалыкларында йөртәләр. Үз күзләре белән күрмәсә, Фирдия моңа ышанмас та иде. Алар дачасыннан ерак түгел сазлык урын бар иде. Шунда ике атна буе экскаватор, трактор, үзбушаткыч машиналар китертеп, балчык ташыдылар, җир тигезләделәр һәм бер ай эчендә икешәр катлы ике йорт калкып чыкты. Андыйлар бернидән чирканмый, җан газабы дигән нәрсә — юк нәрсә. Алар беркемнән курыкмый. Кемнәр алар? Ерак йөрисе юк. Фирдия ахирәтенең концерт заллары кебек бөтен шартын китереп

бизәлгән бүлмәсенә күз салды. Разияның өенә ике көндә ремонт ясап чыктылар. Материалы да буш, осталарына да түләмәде, хәтта көндез кайтып төшке аш та ашатмады. Барысын да Василий Михайлович җайлаган, үзе оештырып та йөрмәгән, шалтыраткан гына. Ә Фирдия ике атна чиләнде ул ремонт дигәннәре белән. Сәлим көн-төн эштә, өйдә булса да аннан ни он, ни йон — исерек. Ашый да ята, тора да чыгып китә. Ярар инде, узган эшкә салават, ерып чыкты Фирдия. Анысына гына түзәргә була, кулы череп акмаган. Ике-өч елсыз кыл кыймылдатасы юк. Ә менә өйгә, Сәлим янына кайтып керүе бер әҗәлгә әйләнде бит. Менә анысына ничек түзәргә?

Элек Фирдия ире эштән кайтуын көтеп ала, пошкыра-пошкыра бил тиңентен юынганын, ухылдый-ухылдый йөнтәс сөлге белән сөртенгәнен елмаеп күзәтә, йөгерә-йөгерә ашарга әзерли һәм иренең шаптыр-шоптыр ашавын карап утыра иде. Туйгач, юрамалый гына бит сыпырып куюын, бөтен гәүдәсе белән сискәнеп кикерүен дә гаепкә санамый, киресенчә, авыр хезмәттән арып кайткан кешенең хак эше кебек кабул итә иде. Ә хәзер аның бу гадәтләре Фирдиянең җан ачуларын чыгара, ул иренең һәр кыланышыннан кимчелек таба. Юк, бу явыз хатынның юаш иренә ачуы килүдән, яисә гаеп эзләүдән килми, бу ничектер Фирдиянең үзенә дә аңлашылмаган халәт. Ире мышный-мышный янына килеп ятуга ук Фирдия табага ташлаган борчак кебек куырылып куя, иннәрен кабарткан керпегә әйләнә. Сәлим түшәм җимерердәй гырлый башласа дерт итеп уяна. Элеккеге үзара аңлашу, якынлыкның эзе дә калмады. Менә монысына ничек түзәргә? Бу хәлләр, кайры астында агач кимергән корт кебек, Фирдиягә тынгы бирми, аны һәр даим бимазалап тора.

— ...Җаның тыныч булыр,— диде Разия үзенең әңгәмәсен дәвам итәргә теләп.

Фирдия, уйларыннан арына алмыйча, башын күтәреп, сагыш тулы коңгырт күзләрен аңа төбәде.

— Нәрсә?

— Василий Михайловичның дусты турында сөйлим бит,— диде Разия һәм ахирәтенең мәрткә киткәндәй оешып утыруыннан көлде. — Вакытында килер, вакытында китәр. Көн-озын ирең кебек карачкыдай каршыңда басып тормас, туйдырып бетермәс. Аның сасы күлмәк-ыштанын, каткан оекбашларын юып та кул итең ашалмас. Ирек, хөррият, элеккеләр әйтмешли.

Фирдия Разияның авыз ерып көлүен хупламыйча, башы түнгән кешедәй сорап куйды.

— Ә бала? Аңа бит ата кирәк!

— Үсә ул, аптырама. Йөргәнеңне бик сиздермәссең. Балаң барында килмәс. Я үзенә бирәр фатир табарга кушарсың. Аена ун-унбиш сум түләп торса, любой карчык риза була. Атнага бер-ике көн фәлән сәгатькә, дип килешәсең. Шито-крыто.

Фирдия Разияга карап утыра башлады. Туктале, бу аның ахирәтеме соң? Каян килгән дөньяга мондый караш. Элек ул болай фикер йөртми иде бит. Ничек оялмый ул шулай эшләргә. Моны бит хәтта сөйләве дә уңайсыз, ә ул тып-тыныч. Кем баласы соң бу? Кайда туып, кайда үскән? Бу бит гади авыл кызы иде. Ә хәзер энә ничек үзгәрде, әллә нинди туз-га язмаган нәрсәләр сөйли. Үзе генә түгел, ахирәтен дә шуңа өнди. Ничек оялмый ул? Үзенең шул бозыклыкларын тәкъдим итәргә ничек җөрьәт итә. Ничек теле әйләнә шулай сөйләргә.

Туктале, Фирдия, алай шелтәләргә ашыкма, катгый хөкем чыгарма. Болай өстән-өстән генә уйлавы җиңел ул. Ә синең уйлаганың бармы: Разия ничек шул хәлгә төшкән? Кем, нәрсә аны мәҗбүр иткән? Шулары турында уйла. Исерек иренең көен көйләп ике ел интеккәнен дә исенә төшер. Ул аны тик торганнан түгел, ә үзәгенә үткәнгә куып чыгарды бит. Башка якларын да уйла. Ирсез хатын ничек дөнья көтсен. Ә, гому-

мән, түбәнлекме ул Разияның бүгенге хәле, әллә тормышка яраклашумы? Ә бәлки Разия үзе дә бу тормышыннан канәгать түгелдер. Бәлки ул тыштан гына шат күренәдер, эчтән кара көеп йөридер. Әллә аңа рәхәттерме ялгыз төннәр үткәрүе, бер ялгызы урамнарда йөрүе. Үз ире булса, ул аны култыклап кайларга бармас иде! Ә болай... кача-поса, кеше өлешенә кереп, ул боларны сизмиме әллә? Сизәдер. Ни әйтсәң дә шул бер сүз инде ул. Элек-электән, алты улың булганчы, аксак ирең булсачы дигәннәр түгелме соң? Разияның болай көр күңелле күренергә тырышуы көчсезлеген яшерү өчен сәбәп кенә түгелме? Ә нигә ул Фирдияне дә үз ызанына этәрмәкче була? Фирдияне үзе кебек яшәргә өндәве бәлки ялгызы гына алай яшәмәскә теләүдәндер, башкалар да шулай яшәсә, аңа үз-үзен аклавы җиңелрәктер...

Фирдия кыяр-кыймас сорап куйды.

— Син бүтән кияүгә чыкмыйсыңмы?

— Юк.

— Гомерең буе шулай Василий Михайловичның сөяркәсе булып яшәрсеңмени?

— Юләр, биш-алты елдан комы коелып бетә ич аның,— диде Разия һәм кычкырып көлеп җибәрде.— Курыкма, алыштырырбыз.

Һич тартынмыйча әйтелгән бу сүзләрне ишеткәч, Фирдия бөтенләй төшенкелеккә бирелде. Һәм кызганулы караш белән ахирәтенә карап утырды. «Ә син үзеңне озакка чыдармын дип уйлыйсыңмы? Ун-унбиш елдан таушалып, син үзең дә шул картлар хәлендә калмассыңмы? Ул чагында кемгә синең кирәгең калыр микән? Әллә шуны сизенеп, алда кое булмаячагын белгән юлчы кебек су эчеп калырга, хәзер яшәп калырга ашыгасыңмы?» Аннары Фирдия затлы өй җиһазларына: каршындагы ялтыравыклы «стенка»га, идәнгә җәелгән һәм софа турына элгән йомшак, күзне иркәләп торган эре чәчәкле келәмнәргә, төсле телевизорга, шарсыман түгәрәк хрусталь люстрага карап сокланды. Кем ул Разия? Министр да, академик та түгел — гади бер лаборантка. Ә аны на кемнәр генә килми. Азык-төлек кибетенә керсә, әтисе исемен дә кушып, зурлап дәшәләр, башка җирдә дә танышлары җитәрлек. Әшендә дә аңа исеме, атасының исеме белән мөрәҗәгать итәләр, ә Фирдиянең мөдир була торып та андый бәхеткә ирешә алганы юк. Дөресрәге, аның моны таләп иткәне дә, теләгәне дә юк. Хезмәттәшләре үзләре белеп дәшмәгәч, ул ни әйтсен инде. Ә нигә соң Разияга шулай дәшәләр? Хөрмәт ул сорап алына торган әйбер түгел бит.

Ә Разияның кигән киеме — зәңгәр джинси, кара күн куртка — һәммәсе импортный, берсе дә кибет киштәләрен сыгылдырып, дымланып күгәреп ята торган әйберләр түгел. Ә синең нәрсә? Акчаң юкмы әллә? Бар. Тик әйберен табып булмый. Теләмисең дә, чөнки зәвыгың үзгәрде, югалды... Менә шулай тора эшләр, Фирдия ханым, шулай. Кешегә тиз генә ярлык тагарга ашыкма. Ә бәлки синең үзеңә дә Разия кебек яшәргәдер. Син барыбер элеккечә яши алмыйсың бит инде. Монда искитәрлек берни дә юк шикелле... Юк, юк... Күңеле ятмый... намусы күтәрми. Ә ничек яшәргә соң? Туктале, ә нигә Сәлим белән яшәгән чордан хәтергә гел караңгы уйлар, ятышсыз вакыйгалар гына килә? Бер дә якты хатирәләр, сагынып искә алырдай минутлар юкмыни соң? Бар иде бит. Авылга сабантуйга кайтулар... Бер елны Сәлимнәргә булса, икенчесендә Фирдиянең туган авылына, Сарман якларына кайталар иде. Сабантуй карагач, елга буена төшәләр, шунда балык шулпасы пешерәләр, күңелле итеп җырлап утыралар, биилар иде. Әйе, барысы да истә. Көзлектә, сугым вакытында да ике якка да чакыралар иде. Анда да, сабантуй чорындагы шикелле туган-тумача җыела иде. Әйе, булды андый рәхәт чаклар да. Ләкин мичкәле балга бер кашык деготь салган шикелле тагын шул бер хәл кабатлана. Сәлим һәрвакыт эчеп исерә, теләсә ни

сөйләнеп, мәҗлеснең ямен җибәрә иде. Фирдияләрдә аңа сүз әйтүче юк, чөнки кияү — кадерле кеше. Ә үз ягында туганнары белән телгә килешкән чаклары да булгалады. Уйлана торгач, туристик путевка белән Севастопольгә баруы да Фирдиянең исенә төште. Әйе, Сәлим аны берсүзсез җибәрде. Ләкин кайткач, хатынының ике конвертка шыплап тутырылган карточкаларына, төрледән-төрле значок, открытка һәм сувенирларына карап мыскыллы елмайды, башын чайкады. «Бүтән хатыннар чүпрәк, йорт кирәге карагандыр әле, ә син...» Фирдиянең үзенә дә уңайсыз булып киткән иде ул минутларда. Менә шулай, ни генә исенә төшсә дә, кояшлы көнне артыннан калмаган күләгә кебек, һәр якты хәтирә кара буяулар белән каплана да куя. Әгәр бөтен гомер шулай узса? Искә алып сөйләрдәй якты көнең, бәйрәмең... тормышың булмасын инде. Һәм Фирдияне күптән борчыган, ләкин әле моңарчы куып җибәрелгән уй котылгысыз чарага әйләнде мени? Ничек очына чыгасы да, ничек төгәл җавап табасы бу моңлаган сорауларга.

Фирдия сәгатенә карап алды.

— И-и, озакладым, ахры.

— Кая ашыгасың, утыр.

— Кузгалыйм инде. Рәхмәт, эчләрем бушап китте,— диде Фирдия боек кына.

Чынында исә аның күңеле һаман төшенке, иңнәренә авырлык кына өстәлде кебек. Разия ахирәтен озата чыкты.

— Шалтырат.

— Ярар,— диде Фирдия баскычтан төшеп барышлый.

Ул урамга чыкты. Нигәдер бу йортта да юаныч таба алмады. Элек Разия яныннан канатланып чыгып китә, ахирәтенең күтәренке рухы аңа бик тиз күчә иде. Ә хәзер... Фирдия үзен күтәрәмгә калган ат хәлендә тойды. Ул авыр атлап, барысы да бер төстәге йортлар арасына кереп китте.

## XII

Хөкем залы.

Фирдия башын түбән иеп, нидер сөйләгәннәрен тыңлап утыра. Ләкин ул сүзләрне ишетми, чөнки күңел түрендәге сагыш, ризасызлык бертөзлексез аны борчып тора һәм ул ирексездән үз уйларына чума. «Нигә соң безнең гаилә тормышы барып чыкмады? Нәрсә җитмәде? Гаиләне ныгытучы бала, ул да бар, матди яктан да мохтаҗлык кичермәделәр, сабырсызлыкта да гаепләп булмый шикелле. Ә нигә соң без корган куыш ишелде? Нишләргә кирәк иде соң? Янгын вакытында кешеләр нишли? Утны сүндерәләр. Нигә? Мөлкәтне саклап калу өчен. Ә гаилә шул ук мөлкәт, ил байлыгы түгелмени? Мин генәме хәзер аерылышучы... Йөзләгән, меңләгән. Һәр яңа гаиләнең бик аз дигәндә өчтән бере таркала. Өч ай торганнарның холык туры килми. Өч ел бер түбә астында яшәгәннәр дә бер-береннән читләшә, унөч ел гаилә арбасын бергә тартканнарның да аты кәҗәләнә башлый, камыт баулары өзелә, аркалыклары чәбәләнә, дилбегәләр тәгәрмәчкә урала һәм арбаның асты өскә, бөтен нәрсә пыран-заран килә...

Алтынны, асылташны табуы бик авыр, ләкин аны кулда тотуы, саклавы тагын да кыенрак. Шулай да саклыйлар, бик кадерләп базларда, сейфларда тоталар. Ә гаилә шул ук асылташ түгелмени? Аның бәясе очсызракмыни? Бәлки алтыннан да кыйммәттер. Кайберәүләр судка да барып тормыйлар, хат аша гына аерылышалар...»

Фирдия үзе хөкем залында утырып, хакимнең соңгы карарны укуын тыңласа да, күңеле кемнәр беләндер бәхәсләшә, даулаша иде.

Менә бетте. Хакимнәр үз сүзен төгәлләде. Фирдиягә чыгып китсә дә була. Ә нигә соң аякларына гер таккан кебек, иңен көянтә-чиләк баскандай, урыныннан кузгала алмый. Шулай да Фирдия бөтен көчен җыйды һәм, торып, урамга чыкты.

Сәлим баскыч төбендә аны көтә икән, янәшә атлады. Бераздан туктадылар. Чит кешеләрдәй, ара калдырып, кара-каршы бастылар. Сөйләшер сүз дә юк кебек. Тирә-юньдә игътибарны җәлеп итәр нәрсә дә күренми, суд бинасы каршындагы бакчада тынлык хөкем сөрә. Тар эскәмиядә ике пенсионер карт бөкерәеп шахмат уйнап утыралар. Ком сибелгән аллеядан култыклашып карт белән карчык килә. Аларның киемнәре генә түгел, хәтта йөзләре дә бер-беренә охшаш: икесе дә эшләпә һәм озын җәйге пальтодан, җыерчыклы аксыл битләренә ямь өстәп күзлек пыялалары ялтырый. Картның сул кулында юка гына китап, ул әледән-әле аңа ишарәләп, әкрен генә нәрсәдер сөйли. Ә көрән пирчаткә кигән карчыгы уң кулына җайлап нәзек сары каеш ураган, алларыннан бәләкәй генә чандыр эт уйнаклап бара.

... Сүзне Сәлим башлады.

— Ярар, анасы, бигайбә. Төрле чак булгандыр, яманлык белән искә алма.

— Сау бул.

— Кызны обижать иттермә.

— Килгәлә.

— Бәлкем... Нишлисең бит шулай килеп чыккач... Әйткән иде аны абый, буең җитмәстәйгә кулыңны сузма, дигән иде. Хак булды.

— Кузгатмыйк инде.

— Әйе. Ни, анасы... дачаны синең исемгә яздырасы булыр инде,— диде Сәлим юаш кына. — Фатир да баш-аягы белән сезгә калыр.

— Бүлик.

— Кирәкми. Мин ир кеше бит, җае чыгар әле. Хәзергә училищеда кунам. Хәлимә белән сиңа калсын. Машинаны саткач, квартир хакын түләп бетерерлек акча да бирермен.

Фирдия аптырап калды. Ничек алай була соң инде бу? Ирә, дөресрәге, элеккеге ире (ә алай әйтергә Фирдиянең теле әйләнми иде әле) үзе бернисез кала түгелме соң? Фирдия үзен кеше талаучы сыйфатында хис итте. Җитмәсә Сәлим алимент та түләячәк. Фирдия судка гариза биргәч тә өйдән чыгып киткән иде ире. Фирдия аны үпкәләп, я ачу итеп берәр элек йөргән нәрсәсе янына киткән дип уйлаган иде, баксаң... Нигәдер күңеле әрнеп, елыйсы килеп китте. Ирен кызгануымы бу, әллә намусы тыныч түгелме?

— Алай булгач өй җиһазларын алып кит.

Сәлим кечкенә күзләрен зур итеп ачып, хатынына карады. «Ничә ел бергә торып, мине аңлый алмадыңмыни син? — дия иде аның күз карашы. — Мин бит сезнең өчен, сезгә рәхәт булсын өчен тырыштым. Сез булмагач, ул әйберләрнең миңа ни хаҗәте бар соң?»

Сәлим, башын түбән иеп, олы ботинкалары белән салмак атлап, китеп барды. Фирдия аның киң аркасына, сары чәчле зур башына карап, секунд эчендә каршылыклы бик күп уйлар кичерде һәм ире аңа бик кызганыч тоелды. Фирдия аны куып җитеп, я булмаса эндәшеп, барысы өчен гафу үтенүдән, ирен кичерүдән үзен чак кына тыеп калды. Ул көчкә урынында басып торган хәлдә иренең киң җилкәсе юл читендә торган машина артында югалгач кына бераз тынычланган төсле булды. Чөнки аны кире борудан, аннан гафу үтенүдән ни файда?.. Тагын шул ук хәлләр кабатланмас дип, аны кем ышандыра ала? Аерылды юллар... Аерылды... Сәлим монда да машинасы белән эш арасында гына килгән. Әнә китеп тә бара. Бүтән вакытта җилдәй оча торган иске машинасы бүген авыру кешедәй әкрен кыймылдый, тәгәрмәчләре теләр-теләмәс барган кешенең аяклары шикелле...

Фирдия дә, бик кадерле нәрсәсен югалткан кешедәй, нәүмизләнеп, башын иеп, әкрен генә өенә таба юл алды. Ул хөкем бинасыннан шактый ерак китте, ләкин каршында Сәлим торган кебек һәм уйлары һаман элекке иренә барып тоташа. «Нигә миң аңа кияүгә чыктым? Кай ягына кызыктым икән? Яше олы, аягында нык тора иде ул, фатир аласын да белдем. Ә нәрсәне белмәдем, уйламадым соң? Ике арада мәхәббәт югынмы? Анысын Разия әйтте: «Аптырама, тора башлагач килә ул. Ычкындырма, егете юаш күренә, муенчаклап алырсың да кулыңда биетеп тотарсың». Ә нигә алай булмады? Ярый, монысын калдырыйк... Сәлим көн-төн эшләде, йорт өчен, безнең өчен тырышты. Ә мин үзем нишләдем? Аны үземә тиң итәргә, рухын күтәрер өчен барысын да эшләдемме? Нигә аның өчен көрәшмәдем? Кайбер хатыннар, балалары музыка мәктәбенә йөри башлагач, хәтта ноталар өйрәнәләр. Ә мин? Нигә аны укырга мәҗбүр итмәдем, театр-концертларга йөртмәдем? Киресенчә, үзем дә ул якка сукмакны оныттым». Авыр иде Фирдиягә боларның барысын да уйлау. Ләкин уйлар дулкыны берөзлексез кага да кага.

...Фирдия автобустан төште дә бераз вакыт җәяү кайтты. Нигәдер авыр, ямансу. Ләкин кайта-кайта ул тынычлангандай булды. Иңеннән ниндидер авыр йөк төшкәндәй, бушанып, җиңеләеп калды. Ләкин бу җиңеләю аңа ләззәт бирми, киресенчә, нәрсәсендер югалткан кешедәй ул борчыла. Әллә каян күренеп торган биш катлы ак өйгә якынлашкан саен аның күңеле тынычсызлана барды. Әнә урам тулы бала-чага: уйныйлар, шаяралар, чыр-чу киләләр. Әти белән әни кеше, нәниләрен ике кулыннан тотып, тәпи йөрергә өйрәтәләр. Йорт янына килеп туктаган өр яңа машинадан башта бала-чагалары, аннан хатыны белән ире чыкты. Болар — бишенче катта торучылар. Бакчадан кайттылар булса кирәк. Кая карама, Фирдиянең йөрәгенә тоз салучы күренешләр.

Йорт буйлап бераз баргач, ул күтәрелеп, баеп баручы кояшка карады. Бакыр табак кебек кояш өйләр арасында тора. Агачларда, йортларда, болытларда кояш нуры, шәүләләр. Ләкин аларда сары төс — сагыш төсмерләрен дә шәйләп була иде. Әйе, кояшның нурлары бүген сагышлы иде. Бәлки бу алай да түгелдер, ләкин күңеле моң белән тулы яшь хатын бүген башкача уйлый алмый иде.

1979 ел.

Ризван Хәмид

# СИНЕҢ УРЫНЫҢА КАЙТТЫМ

Драма 2 бүлектә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Мәгънәви Хәбиров.
Зәйнәп — аның хатыны.
Рәхилә — өлкән кызлары, ялгыз хатын.
Наил — уллары, агроном, соңыннан колхоз председателе.
Нигъмәтҗан — Мәгънәвинең бертуган энесе, ат караучы.
Илдус — Мәгънәвинең уртанчы энесенең улы, агроном.
Зөһрә — Наилнең хатыны, агроном.
Гамилә — Илдусның хатыны.
Зәйтүн — Рәхиләнең асрамага алган улы, укучы.
Шофер.
Мәгънәви картның авылдашлары.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Елга буена урнашкан кечкенә авыл. Җәй. Мәгънәви карт йортының ишегалды. Ике якта ике өй, берсендә Мәгънәви карт белән карчыгы Зәйнәп тора, икенчесендә Рәхилә белән Зәйтүн. Түрдә — бакча капкасы, урам капкасы беръяк кырыйда.
Пәрдә ачылганда Зәйтүн болдыр түбәсе өстендә чүкеч белән кадак кага, Мәгънәви карт түбәннән аңа шиферлар бирен тора.

Зәйтүн *(кага-кага)*. Монысын да ябыштырдык, бабакай! Наил абый кайткач, бу йортта ирләр калмаган икән дип әйтә алмас инде хәзер.

Мәгънәви *(шифер бирә)*. Ашыкма, әйбәтләп как.

Зәйтүн *(шиферны үрелеп ала)*. Хәбировлар какса, үзәгенә үткәреп кага инде ул, бабакай! Читләп-кырыйлап тормый. *(Шуып китә.)* Тпру!

Мәгънәви. Иплән! Хәбиров булсаң, әүвәле аяк астының ныклыгын кара, аннары үрелерсең.

Зәйтүн. Тайгак, каһәр!

Мәгънәви. Түбәгә сылтама — аякларым тернәксез диген! Егет кеше шулай бассын — эзеннән танысыннар. Әнә — Наил абыең: баскан җиреннән ут чыгара. Шуңа күрә ышаналар да үзенә. Җиде егет китте институтка, бер үзен укырга алдылар.

---

[1] Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры репертуарында.

Зәйтүн. Синең аркададыр ул, бабакай! Анда бер танышым бар диган иден бит.

Мәгънәви. Төкерә ул андый танышларга! Берәү булса, атасының җилкәсен кимереп ятар иде, ә ул без салган акчаны да кире җибәрде.

Зәйтүн. Егетлек дигәннән, бабакай, син соңгы вакытта нишләптер бирешә башладың кебек әле — бер дә бүре тотарга бармыйсың. Әллә картаясың инде? Син тотмагач, бигрәк кыюланганнар, әнә бүген таң алдыннан берсе Кызыл-тау маңгаенда улап утыра иде. Ишетмәденме?

Мәгънәви җавап бирәп өлгерми, урам ягыннан кычкыралар.

Тавыш. Мәгънәви абый, кил әле!

Зәйтүн. Миңлехарис абый. Фәризәттәй малае.

Мәгънәви. Ни кирәк? Йомышны әйткәнче исәнләшә торганнарие!

Тавыш. Исәнме, Мәгънәви абзыкай. Уставыңны биреп торчы, Мәгънәви абзыкай?

Мәгънәви. Нинди устав? Юк миндә.

Тавыш. Биреп тор инде, Мәгънәви абзый. Колхоз уставы. Синдә дә булмагач, кемдә булсын? Гомергә персидәтел булган кеше ич син.

Мәгънәви. Пенсиягә чыккан кешедән устав сорап йөриләрмени, булмаган! Яңа председательдән сора, Шакировтан.

Тавыш. Бар бит инде ул синдә, Мәгънәви абзый. Ашамам. Биреп тор бер генә көнгә.

Мәгънәви. Ә нинди хаҗәте чыкты әле аның?

Тавыш. Эшкә чыкмый калган өчен штраф салырга дигән закон бармы икән, шуны карыйм. Тоталар да, штраф дип, теңкәгә тияләр.

Зәйтүн. Сиңа скидка тиеш бит, Миңлехарис агай!

Тавыш. Миңамы?

Зәйтүн. Әйе!

Тавыш. Нишләп миңа гына скиткә ясасыннар!

Зәйтүн. Әйтимме нигә?

Тавыш. Әйтеп кара?

Зәйтүн. Мыек җиткергәнең өчен.

Тавыш. Тфү, дурак! Чынлап сөйлисеңме дип торам... Бирмисеңмени инде, Мәгънәви абзый?

Мәгънәви. Бар әле, кеше көлдереп ахмак сүз сөйләп йөрмә. Тиле түгелсеңдер. Бар, бар, арбаң юлында булсын! Мә, Зәйтүн, тот. *(Шифер бирә.)* Һе, моңа да устав кирәк булган!

Зәйтүн. Ул әле партиягә керәм дә «начальник булам»,— дип әйтә ди. «Дуңгыз асты чистарту туйдырды»,— дип әйтә ди.

Мәгънәви. Синең кебекләрне генә көтеп торалар ди анда!..

Капкадан ашыгып Зәйнәп килеп керә.

Мәгънәви. Кайда йөрисең син? Тиздән малаең кайтып керәчәк!

Зәйнәп җавап бирмичә өйгә кереп китә.

Зәйтүн. Беттең, бабакай, бүген кысыр аштан башканы өмет итмә, әбекәй нигәдер бик ачулы.

Кызу-кызу Илдус керә.

Сәлам, Илдус абый! Фасоль үсәме?

Илдус *(ачулы)*. Дурәтәй! Нигъмәтҗан абыйны тыясыңмы инде,

юкмы? Ипекәй менә, атларын тагын бер мәртәбә басуда күрсәм, кардәш кеше дип тормыйм! Я атларының белән шушы тимер кулым белән сугып сындырам, я — үзенең ботын. Мин көне-төне басуда, ә ул минем эшне таратып йөри. Билләһи, бер аулакта тотып ярам үзен!

Мәгънәви *(тәрәзәгә)*. Анасы!

Зәйнәп *(тәрәзәне ача)*. Ни кирәк?

Мәгънәви. Су чыгар.

Зәйтүн. Фасольгә кергәннәрме әллә, Илдус абый?

Илдус. Антик! Атларын ташлый да шәһәргә чаба, ташлый да шәһәргә чаба. Каян килеп чыккан ул безнең Хәбировлар нәселендә?! Колхоз эшенә дисәң, анарда радикулит!

Зәйнәп тәрәзә аша су бирә.

Нихәл дүрәнәй!

Зәйнәп. Исәнме.

Мәгънәви. Мә эч. *(Суны алып Илдуска бирә.)*

Илдус. Су эчәргә дип кермәдем мин, дүрәтәй, рәхмәт.

Мәгънәви. Эч.

Илдус *(суны ала)*. Председательгә ничә әйттем! *(Эчә.)* Куймагыз шуны... *(Эчә.)* Конюх итеп дидем! Рәхмәт, Зәйнәп дүрәнәй, мең яшә!

Мәгънәви. Ярсуың басылдымы инде?

Илдус. Басылырлык кынамы монда!

Мәгънәви. Кычкырма. Болай да яхшы ишетәм.

Илдус. Соң, дүрәтәй...

Мәгънәви. Нәрсә ул?

Илдус. Нәрсә ул?

Илдус. Кайда?

Мәгънәви. Кулыңа нәрсә тактың?

Илдус. Ә-ә, моны әйтәсең икән. Кулым бау кебек файдасызга асылынып йөргәнче, ярдәме булыр дип, ыргак кебек бер нәмәрсә ясап куйган идем. Сыңар кул белән ни эш майтарасың! Ыштан төймәләргә дә кешегә ялынып торып булмый лабаса.

Зәйтүн. Ә син Гамилә җиңгидән молния замогы алып тактыр.

Мәгънәви. Китер әле монда.

Илдус. Чишеп торуы озак.

Мәгънәви. Ут чыкмагандыр, чиш.

Илдус *(костюм җиңен сызганып, протезын чишеп бирә)*. Әллә нәрсә түгел инде, күгәргән тимер кисәге...

Мәгънәви *(протезны әйләндергәләп карый һәм койма аша урамга ыргыта)*. Я, нигә бугаз ерта идең?

Илдус. Туктале, дүрәтәй, нигә ыргыттың аны?

Мәгънәви. Йөрмә кеше көлдереп!

Илдус. Соң, дүрәтәй, аптыраганнан азаплану.

Мәгънәви. Протезың бар, шуны так. Аны тагасың килмәсә — болай йөр. Кеше көлдермә...

Зәйтүн. Илдус абый! Хәтереңдәме, Наил абый каникулга кайткач әйткән иде? Хәзер ничек теләсәң, шулай хәрәкәтләнә торган протезлар ясыйлар икән. Мәскәүдән электрон протез ясатып кайт.

Илдус. Мәскәү кайгысы гына иде монда! Бер-ике атнадан уракка төшәсе. Туңга сөрү, көзге чәчү... Наил үзе кайтсын иде монда. Ду китереп бергә эшләр идек. Направлениене үзебезнең колхозга ал дип хат язгыз үзенә, дүрәтәй. Штат бар. Үземә ярдәмче итеп алам.

Зәйтүн. Бәй, ишетмәдеңмени әле, Илдус абый? Наил абый бүген кайта ич. Телеграммасы килде.

Илдус. Чынлапмы, дүрәтәй?!

Мәгънәви. Помышың ни иде?

Илдус. Нигъмәтҗан абзый атлары инде һаман да. Әпәйт басуга җибәргән. Зифа чокырындагы бодайны таптап эштән чыгарганнар. Яхшылыкны аңламагач, аңламый!

Мәгънәви. Син кем? Баш агрономмы, әллә бер малаймы?

Илдус. Соң, дүрәтәй! Баш агроном булып мин ни эш кыра алам?

Мәгънәви. Акт төзе.

Илдус. Төзедем. Берне түгел, бишне төзедем.

Мәгънәви. Тагын төзе.

Илдус. Төкереп бирә ул синең актыңа. Эшне эрегә җибәрмәгәнне беләә.

Мәгънәви. Ничек?

Илдус. Штраф салдырмам бит инде! Үз абзыем!

Мәгънәви. Алай булгач, шыңшып та йөрмә монда.

Илдус. Штраф салдыртыйммыни? Димәк, рөхсәтең бар, дүрәтәй! Ә мин аны, дүрәтәй, синең бертуган энең булганга җәлләп йөрим тагын! Ярар. Нигъмәтҗан абзый, күрмәгәненне күрсәтәм хәзер болай булгач. Дүрәнәй! Суың бик тәмле булды, тагын бир әле. Әйрән булса да ярый.

Зәйнәп тәрәзә аша әйрән бирә.

Молодец та инде үзең, дүрәнәй! *(Эчә.)* Рәхмәт, дүрәнәй, шәп булды әле бу. Ә син, Зәйтүн, чыпчык борын, фасоль дисең! Ә беләсеңме ул эшне кем башлады? Наил абыең! Их, дүрәтәй, председатель туганнарын да йөгәнләп булса! Алары үз малларын чыгарып теңкәгә тияләр.

Зәйтүн. Тот та аларга да штраф салдыр!

Илдус. Салдырырсың! Җилгә каршы пес итмә, өстеңә чәчрәр диләр.

Мәгънәви. Ә син югач чистартуны бел дә сиптерә бир!

Зәйнәп өйдән чыгып каралтылар ягына уза.

Илдус. Сиптереп кара! Ул сиңа дүрәнәй белән чәкәләшү түгел! Шулай бит, дүрәнәй!

Зәйнәп җавап бирми, өйгә кире кереп китә, кулында йомычкалар.

Бүген ни булган аңа? Сөйләшми.

Зәйтүн. Нигъмәтҗан абзыйлар бозавы сөзгән.

Илдус. Юньсезнең бозавы да үзенә ошый икән! Мин киттем, дүрәтәй!

Мәгънәви. Ашыкма, Зәйтүн! Бар әле, җәһәт кенә Нигъмәтҗан абзыеңны алып кил.

Зәйтүн *(болдыр түбәсеннән сикереп төшә)*. Була ул!

Бакчага кереп китә.

*(Кычкыра.)* Зәйтүнә! Атаң өйдәме? Бабакай аны экзекуциягә чакыра! Бар, чыксын!

Илдус. Нигъмәтҗан абзый белән үзең генә сөйләш инде, дүрәтәй. Бу агылый белән тагылыйның бәхәсе бик озын күренә. Киттем.

Чыгып китә. Мәгънәви ишегалдына караган тәрәзәләрнең капкачларын ябып куя. Билендәге каешын чишеп алып, бакча коймасы янындагы түмәргә барып утыра. Бакча ягыннан Зәйтүн белән Нигъмәтҗан килеп керәләр.

Нигъмәтҗан. Чынмы бу, олы абый? Зәйтүн әйтә, бабакай өч ай саклаган бал мичкәсен ачты ди, сине авыз итеп карарга чакырды ди.

Зәйтүн яшерен генә пырхылдап, болдыр түбәсенә менеп китә.

Зәйтүн *(югарыдан)*. Минем кайчан ялганлаганым бар соң, Нигъмәтҗан абзыкай? Башта бабакай сиңа экзекуция ясый, аннан соң...

Нигъмәтҗан. Анысы ни нәрсә тагын?

Мәгънәви. Якынрак кил.

Нигъмәтҗан килә. Шул вакыт Мәгънәви көтелмәгән житезлек белән сикереп торып, Нигъмәтҗанга каешы белән сугып җибәрә.

Менә сиңа бал! Мә тагын берне!

Зәйтүн. Менә шушы экзекуция дип атала инде, Нигъмәтҗан абзый!

Нигъмәтҗан *(тирән аптырашта)*. Ни өчен, олы абзый?! Ой! *(Каешын тартып алып, читкә ыргытмакчы була.)*

Мәгънәви. Бир монда!

Нигъмәтҗан *(каешны бирә)*. Әллә карт көнендә шөрефләрең тарала башладымы? Тиктомалга! Гаебем булса, телең белән әйт, кулыңа ирек бирмә!

Мәгънәви. Тиктомалга? Уйлабрак кара.

Нигъмәтҗан. Берәрсе килеп чактымы? Кеше сүзенә карасаң, олы абый! Миңа каршы тояклары белән җир тырнаучылар буа буарлык ул!

Зәйтүн. Ә син аларны тот та дагала, Нигъмәтҗан абзый!

Нигъмәтҗан. Синнән сорамыйлар, тик кенә утыр, малай актыгы!

Мәгънәви. Бежләмә!

Нигъмәтҗан. Әйтсәң әйт, әйтмәсәң...

Китәргә кузгала.

Мәгънәви. Яп капканы! Утыр! Вакыты житкәч, үзем дә куармын. *(Каешын биленә бәйләп куя.)*

Нигъмәтҗан утыра.

Кайчан акылга керәсең димим. Хәзер соң инде. Атларың кайда?

Нигъмәтҗан. Сорау алмале, олы абый! Илдусның теңкәне корытканы да бик житкән. Мин үз эшемне үзем беләм.

Мәгънәви. Мин исән чакта фамилиябезне рисвай итәргә ирек бирмәм, ишетсен колагың!

Нигъмәтҗан. Ат камчыларга кем дә оста! Менә минем урында булып карагыз!

Мәгънәви. Синең урынга ни булган?

Нигъмәтҗан. Ат артыннан чыбыркы сөйрәп чабарга кемгә кирәксә, Нигъмәтҗанны чакыралар. Әйбәтрәк эш сорасаң, калибрың килмәгән!

Мәгънәви. Шулай! Эшләмәгән эшең юк синең. Тик кинәндергән төшең юк.

Нигъмәтҗан. Тәртә кыска булганга карап, атны кыскартмыйлар, олы абый. Менә син: атларың кая дисең. Кайда йөртим соң мин аларны? Сазлыкны сөрдегез. Тау битләрен дә. Ә мин гаепле.

Мәгънәви. Эшләргә теләге булган кешегә урын житәрлек. Бүген дә атларыңны ташлап, күрше авылга кибеткә киткәнсең!

Нигъмәтҗан. Соң инде, олы абый, шул ундүрт корчаңгы тайны

кибеткә дә үзем белән ияртеп барыйммыни? Болай да көне-төне шулардан аерылып булмый.

Мәгънәви. Анысы миңа караңгы. Ә менә Нигъмәтҗан картның энесе эшлексез дигән сүзне еш ишетәм. Без — Хәбировлар. Шуны исеңдә тот.

Нигъмәтҗан. Хәбировлар, Хәбировлар! Гомергә фамилиягез белән мактандыгыз инде.

Мәгънәви. Фамилиябез!

Нигъмәтҗан. Бик эчегез пошса, тотармын да фамилиямне алыштырырмын. Котылырсыз.

Зәйтүн. Ниндигә, Нигъмәтҗан абзый?

Нигъмәтҗан. Табармын!

Зәйтүн. Бераз күтәргә туры килер дип уйлыйм мин, Нигъмәтҗан абзый!

Нигъмәтҗан. Анысы ни өчен тагын?

Зәйтүн. Соң, үзең уйлап кара: утырып гариза язарга кирәк бит. Ә синең арт ягың ниерәк бит әле... Бүгенге экзекуциядән соң — үзең беләсең!

Нигъмәтҗан. Эт кемгә өрә, мәче шуңа фырылдый! Син дә лыгырдап утырасың анда.

Мәгънәви. Акыл кермәгәч, керми икән кешегә.

Зәйнәп чыга.

Нигъмәтҗан. Исәнме, Зәйнәп җиңги? Әйрән ясап бирче, тамак кибәрлек иттеләр монда!

Мәгънәви. Өеңә кайтып эчәрсең!

Нигъмәтҗан ни әйтергә белми аптырап тора да чыгып китә.

Зәйнәп. Нәрсәгә урам кутәреп кычкырышасыз тагын?

Мәгънәви. Димәк, сәбәбе бар.

Зәйнәп. Күпме чәйнәсәң дә бер балык башы инде! Аны әрләп игә кертә алырмын дисеңме? *(Капка ягына карап.)* Әйтүләре дөрес икән, кайтып та җиттеләр. Әнә, яраткан малаең ирдән калган хатын алып кайтып килә.

Мәгънәви. Кем әйтә аны?

Зәйнәп. Чатан Гарифулла кызы кайткан. Шул әйтә.

Наил белән Зөһрә керә.

Зәйтүн. Наил абый! *(Сикереп төшә һәм егылып китә.)* Һоп! Чак кына егылмый калдым!

Наил. Нихәл? Очып буламы?

Зәйтүн *(каршы бара)*. Йөз яшисең икән, Наил абый. Әле генә Илдус белән сине искә алган идек. С приездом!

Күрешәләр.

Наил. Таныш бул: Зөһрә җиңгәң.

Зәйтүн. Җиңги? Шушы яшь кызмы?

Наил. Ишеттеңме, Зөһрә? Ә син картаям дисең!

Мәгънәви белән Зәйнәп янына үтәләр.

Менә, Зөһрә, минем картлар шушылар була инде...

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук кич.

Мәгънәви карт өендә кечкенә мәҗлес. Өстәл янында Мәгънәви, Наил, Зөһрә, Илдус, Гамилә, Рәхилә, Зәйтүн утыра. Зәйнәп табын карый.

Мәгънәви. Ярар, улларым, кызларым, хәзер сүземне тыңлагыз.

Илдус. Тс-с! Дүрәтәй тост әйтә!

Мәгънәви. Тост әйтмим мин, Илдус улым. Сүз әйтәм. Зөһрә килен син дә тыңла, Наил улым, сүзем сезгә кагыла. Без, Зөһрә килен, син нинди нәселдән дип сорамыйбыз.

Зәйнәп. Бәй, нигә сорамаска? Безнең гаиләбезгә кирәсе кеше лә ул!

Мәгънәви. Мин «сорамыйбыз» дидем! Наил улыбыз сине сайлап алган икән, димәк, үзенә тиң күргән. Ә менә нинди йортка киләсең — шуны күңелеңә тирән салып куй. Нык беркет. Без — Хәбировлар. Колхозга нигез салучылар. Теләсә кемнән сорый аласың: Хәбировларны нәрсәдә булса гаепләп буламы? Юк! Һәм киләчәктә дә шулай барыр дип ышанам. Синең каршыңда, килен, өлкән кызыбыз Рәхилә утыра. Авылда аның турында җырлар җырлыйлар. Чөнки лаеклы ул моңа. Ире, Әхмәтҗан киявебез, утыз ел элек сугышта хәбәрсез югалды. Ә кызыбыз аны бүгенге көнгә кадәр тугрылыклы көтә. Рәхилә турында бер яман сүз дә ишетмәссең. Кызарма, кызым, мин хак сүз әйтәм. Асрамага алып, менә дигән малай үстердең. Кеше иттең. Тавык фермасын үз җилкәң белән күтәрдең. Наил улыбызны, Зөһрә килен, безгә караганда үзең яхшырак беләсеңдер. Соңгы елларда ул безнең белән яшәмәде. Сынатмагандыр, шәт. Бераз кызурак. Зыянлы түгел. Үтәр... Бианаң белән дә, Зөһрә килен, уртак тел табарсыз дип уйлыйм. Аңарда да Хәбировлар оеткысы.

Илдус. Бәй, дүрәтәй, сүз генә булмады бу, речь килеп чыкты!

Мәгънәви. Чәбәләнмә. Мин әйтеп бетермәдем. Хәзер синең турында сүзем. Йөрәгеңдә Хәбировлар каны булса да, әниең ягынарак тарткансың син. Кыз бала булып туарга калган да... Артык йомшаксың. Эшеңдә зыян китергәли... Бер нәрсә шатландыра — вөҗданың пакь синең. Бу да аз түгел. Атаң мәрхүмгә охшаган булсаң, әйбәтрәк булыр иде дә...

Зәйтүн. Бабакай, ә бабакай! Нигъмәтҗан абзый турында бер сүз дә әйтмисеңмени?

Мәгънәви. Тик кенә утыр! Зөһрә үзе күрер. Ә хәзер, Зөһрә килен, иң мөһимен тыңла. Мин, килен, синең бер нәрсәне истә калдыруыңны телим. Без, Хәбировлар, бер кайчан да кеше артына яшеренеп яшәмәдек. Киресенчә, башкалар безгә тиңләшергә тырышты. Үткәнендә ни булган — үз хәтереңдә калсын. Бүгенгең һәм киләчәгең безнең күз алдында булачак. Ялгыш абынгансың икән, күтәреп торгызырбыз. Үзең егылсаң — бездән гафу көтмә. Ышанам, килен, безнең йөзгә кызыллык китермәссең. Наилгә дә зур ышанычыбыз бар.

Илдус. Наил сынатамы соң! Үзебезнең егет! Наилме? Һи! Зөһрә, син белмисеңдер әле, ул мине үлемнән алып калды бит.

Наил. Ташла!

Гамилә. Башлады инде. Ашыңны кабып кына утыр әле, суына.

Илдус. Ә нигә аны яшерергә? Юк, Хәбировлар яшерерлек эш эшләми! Сиңа Наил әйттеме, Зөһрә?

Зөһрә. Беренче тапкыр ишетәм.

Илдус. Молодец, Наил! Шулай кирәк. Менә бу — безнеңчә. *(Хатынына.)* Син, Гамилә бичәкәй, аякка басмый гына утыр әле.

Наил. Ярар инде, Илдус, башка вакытта әйтерсең.

Илдус. Юк, хәзер сөйлим.

Наил. Аның нәрсәсен сөйлисең? Трактор аугач, сине тартып алдым. Шул гына.

Илдус. Шул гына? Баш бетә иде лабаса! Ә син — «шул гына!» Үзең дә аздан гына трактор астына эләкми калдың.

Рәхилә. Эшкә кая җибәрәләр, Наил? Икегез дә бер җиргәдер?

Наил. Әйе. Бергә.

Илдус. Кая?

Наил. Үзебезнең колхозга.

Зәйтүн. Чынмы, Наил абый?

Наил. Чын.

Зәйтүн. У-у!

Илдус *(торып баса)*. Тукта... Шаяртмыйсыңмы, Наил?

Наил. Әллә охшаганмы?

Илдус. Билләһи диген!

Наил. Үзең «авылга кайт» дип чакырдың ич.

Илдус. Наил! Менә бу — минемчә! Дүрәтәй! Ишеттеңме, нәрсә ди? Мә, тот бишне, Наил! Их, туганкай, шатландырдың! Күрдеңме, Гамилә? Эшләп күрсәтәбез болай булгач! Мин теге син әйткәнне башладым инде, Наил.

Наил. Нәрсәне?

Илдус. Оныттың дамыни? Фасоль.

Наил. Ә-ә! Ничек соң?

Илдус. Менә! Киләсе елга тагын да арттырабыз. Тукта, ә Зөһрә? Аны кая куябыз? Бездә ике генә штат ич.

Наил. Зөһрә дә минем белән.

Илдус. Ничек?

Наил. Эшләр болай, Илдус. Мин... синең урыныңа кайттым. Район карары иртәгә килер.

Тынып калалар. Илдус тирән аптырашта кала, әкрен утыра.

Илдус. Минем урыныма?

Гамилә. Чынлап әйтүеңме бу, Наил?

Наил. Ә нәрсә?

Рәхилә. Бәй, ничек килеп чыга соң әле бу, Наил? Үз абыеңның эшен тартып аласың түгелме соң?

Наил. Тартып алам?! Сез нәрсә? Ул вакытлыча гына куелган иде. Барыбер кем дә булса алыштырыр иде.

Гамилә *(әкрен генә)*. Мондый ягың да бар икән әле, Наил... Үч ала торган гадәтең дә.

Наил. Үч? Шаштыңмы әллә?

Гамилә *(Илдуска)*. Нигә авызыңны ачып каттың? Әйт берәр сүз. Рәхмәт диген!

Мәгънәви. Тавышланмый торыгыз! Улым Наил, мин аңлап бетермәдем. Ничек диден?

Наил. Иртәгәдән башлап мин — баш агроном, мин әйтәм. Илдус урынына.

Мәгънәви. Син үзең сорадыңмы, әллә җибәрделәрме?

Наил. Үзем сорадым. Дөресрәге, райүзәктә башта Илдуска ярдәмче итеп җибәрмәкчеләр иде. Колхоз председателе Шакиров та шунда чак туры килде. Мин риза булмагач, Илдус урынын тәкъдим иттеләр. Каршы килмәдем.

Мәгънәви. Менә хәзер аңладым. Максатың ни?

Н а и л. Сөйләве озак.

М ә г ъ н ә в и. Тартынма. Сөйлә.

И л д у с. Кирәкми, дүрәтәй.

М ә г ъ н ә в и. Утыр урыныңа! Без тыңлыйбыз.

Н а и л. Ярар. Әйтәм. *(Кулын Илдусның җилкәсенә куя.)* Илдус, кулыңны күкрәгеңә куеп әйт әле: син булдыклы агрономмы, түгелме? Дәшмисең. Чөнки синең әйтер сүзең юк. Начар агроном син! Пешмәгән агроном! Ә хәзер, эткәй, син үзең әйт: колхозда әйбәт җитәкче идеңме син?

М ә г ъ н ә в и. Ул турыда сөйләшергә сиңа иртә әле, улым.

Н а и л. Юк! Нәкъ вакыты! Мин аңлыйм, еллары икенче иде. Әмма бу сезне акламый. Син, эткәй, син дә, Илдус — әйе, сез колхозны бөлгенлеккә төшерүчеләр! Сез аның җирен таладыгыз, чөнки юньләп эшли белмисез. Бездә кара туфрак. Ә сез нәрсәгә риза булып ятасыз? Унбиш центнерга! Адәм көлкесе! Анысы да алла биргәндә генә. Бу хәлендә җир артыгын бирә дә алмый. Менә ул сезнең мирасыгыз! Мин сезне тырышмагансыз дип гаепләмим. Башкача эшли белмисез сез.

М ә г ъ н ә в и *(тыныч)*. Ә син эшли аласыңмы?

Н а и л. Әйе! Эшли алам! Эшләргә дип кайттым да. Әзгә риза булып ятар чормыни хәзер? Техника заманы. Фәнне җигеп эшли торган заман. Безнең җирдән кырык центнер ашлык алу да аз. Алтмыш-алтмыш биш центнер — менә норма!

З ә й т ү н. Гектар башынамы?

Н а и л. Гектар башына.

З ә й т ү н. У-у! Ул чагында... мин — риза!

М ә г ъ н ә в и. Улым, Зәйтүн, бар, сиңа йокларга вакыт.

З ә й т ү н. Бераз гына утырыйм инде, бабакай?

Р ә х и л ә. Бар, бар. Мин дә тиздән чыгам.

З ә й т ү н. Наил абый, син берәр сүз әйт әле шуларга?

Н а и л. Берни эшли алмыйм, егет.

З ә й т ү н. Менә унынчыны гына бетерим.

Чыгып китә.

И л д у с *(эчә)*. Шәп! Ярар, эшеңне күрсәт, егет! Бәй, үзем генә эчеп утырам түгелме соң? Нигә барыгыз да тынып калдыгыз әле? Дүрәтәй, сузып җибәр әле яраткан җырыңны! *(Зөһрәгә.)* Сез белмисез әле. Наилгә икенче кулымны кисәргә бирәм — дүрәтәй кебек оста җырчыны таба алмыйсыз! Дүрәтәй, әйдәле! Сузып җибәр «Карурман»ыңны. *(Гамилә аның кулыннан тарта.)* Нәрсә? Ә? Кунаклардан узып кычкырып утырам икән! Шундый бер начар гадәтем бар инде, минем, Зөһрә...

М ә г ъ н ә в и. Чәбәләнмә, утыр. *(Наилгә.)* Чебешләрне көз көне саныйлар, улым.

Н а и л. Санарбыз. Анысы өчен курыкмагыз. *(Илдуска.)* Кайгырма Илдус, эшсез утырмассың.

И л д у с *(үз-үзенә әйткән кебек)*. Дилбегәне үз кулыңа алырга булдым, дисең инде?

Н а и л. Алыргамы, түгелме, сез таптанган сукмакны ташлап олы юлга чыгарга кирәк.

Г а м и л ә. Нәрсә, ирем, башыңны ашадыларм?

И л д у с. Ашыкмый тор! *(Наилгә.)* Ә син минем хакта, менә минем хакта уйладыңмы?!

Н а и л. Уйладым.

И л д у с. Синме?! Молодец! Ерак китәрсең. Тик бер киңәшем бар: атлаганда аяк астыңа карап бар — ялгыш бервәрсенең баш сөягенә бәрелеп абына күрмә! Их, син! Әйдә, хатын!

М ә г ъ н ә в и. Кайнама! Самавыр түгелсеңдер. Сез икегез дә миңа үз балам урынына якын. Кем күбрәк баш агроном булып калырга хаклы икәнен үзем әйтермен.

Н а и л *(мыскыллы)*. Синме? Бездән башкамы?

М ә г ъ н ә в и *(аның сүзенә игътибар итмичә)*. Бүгенгә җитте. Йокларга вакыт.

Г а м и л ә *(кузгала)*. Сыегыз өчен рәхмәт, Зәйнәп җиңги. Киттек, Илдус. Рәхилә апа, сиңа бер-ике авыз сүзем барие, озата гына чыкчы?

Чыгалар. Илдус алар артыннан нәрә, ләкин кире борылып килә.

И л д у с. Менә нәрсә, Наил! Курыкма: өстеңнән жалоба белән йөрмәм. Уйлама: үлемнән коткарып калуың өчен түгел, характерым шундый! *(Китә.)*

Ишегалды.
Тәрәзәдән лампа яктысы төшә.

Г а м и л ә. Рәхилә апа, Зөһрәгә белдермәгез, яме?

Р а х и л ә. Нәрсәне?

Г а м и л ә. Теге чактагы... Наил белән минем арада булган хәлләрне.

Р ә х и л ә. Ишетсә ни булган? Яшь чагында кем кем белән очрашмый да, кем кем белән үбешми!

Г а м и л ә. Шулай да. Минем аркада аралары бозылып куймасын, җәл ул миңа...

Р ә х и л ә. Кем?

Г а м и л ә. Зөһрә. Сиңа бәлки гаҗәеп тоеладыр... Теге вакытта Наил белән кушылмавыбызга бүген тагын бер тапкыр шатланып куйдым әле...

Р ә х и л ә. Ай-һай! Шулаймы икән? Ә кем аңардан күзен дә алмый карап утырды? Әһә, кызарасыңмы?

Г а м и л ә. Чынлапмы, Рәхилә апа? Шаяртасыңдыр!

Р ә х и л ә. Сак бул, кызый.

Г а м и л ә. Юк инде, Рәхилә апа. Бер киселгән кире ябышмый. Илдусым яшәсен.

Илдус чыга.

Шулай бит картым! *(Кинәт Илдуска сыена.)*

И л д у с. Син нишләп тиктомалга мәче кебек сырпаланасың әле. Берәр гаебеңне юарга телисең ахры! *(Елмая.)* Кара син!

Г а м и л ә. Күзләремне тутырып карыйм, картым! *(Үбә.)*

И л д у с. Кара, кара, нишли! Башка вакытта кул тидереп булмый, сырт йонын кабарта!

Г а м и л ә *(җитди)*. Башка вакытта бит ул. Ярый, хушыгыз, Рәхилә апа! Әйдә!

Китәләр.

Р ә х и л ә. Хушыгыз. *(Кереп китә.)*

Илдус капка төбенә җитәрәк Гамиләне култыклап ала.

Гамилә. Я, артыгын кыланма! *(Кулын ычкындыра.)*

Чыгып китәләр.

Өйдә.

Рәхилә кергәндә Наил ишекле-түрле йөри. Зәйнәп савыт-саба жыештыра. Мәгъназн карт белән Зөһрә өстәл янында утыралар.

Зөһрә. Ярдәм, кирәкмиме, әнкәй?

Зәйнәп эндәшми.

Наил. Менә син, әткәй, ник алдан хәбәр итмәдең, дисең. Ә нәрсәгә? Төрле гайбәтләр тарала торсын өченме?

Зөһрә. Әллә Илдус абый берни дә белми иде?

Зәйнәп. Аптырадыгыз инде барыгыз да! Шулай кирәк тапкандыр. Һәр адымын очраган бер кешегә әйтеп эшләсенмени!

Рәхилә. Нигә алай дисең, әнкәй! Хатыны ич ул аның. Гаилә булгач, бары да бергә киңәшләшеп эшләнә инде.

Зәйнәп. Гаилә булгач шул.

Рәхилә. Кызык. Алар кемнәр соң?

Мәгъназн. Җитәр сезгә! Уйламыйча эшләгәнсең, улым! Эш Илдус абыеңда гына түгел. Мир бар. Мир нәрсә әйтер... Шунысы мөһим. Сиңа мир белән яшисе.

Наил. «Мир, мир». Мир кеше турында фикерне эшенә карап йөртә. Ана Илдус ни, мин ни!

Рәхилә. Безгә бер түгел. Кеше-кара ишеткәнче, баш тарт. Бу эшеңне хупламыйм, Наил!

Зәйнәп. Ягез, житәр! Икесенә дә эш табылыр. Рәхилә, кунак кызны йокларга үзеңә алып керерсең. Наил, сиңа урынны чоланга җәям.

Рәхилә. Бәй, ни сөйләвең бу, әнкәй!

Зәйнәп. Кушканны эшлә.

Барысы да гаҗәпкә кала.

Наил. Ни булды, әнкәй?

Зәйнәп. Ни булганын үзеңнән сора. Ата-анага әйтү юк. Киңәш сорау. Кыз тапмам дип курыктыңмы?

Мәгъназн. Житте!

Зөһрә *(тыныч)*. Гафу итегез, әти. Әни үз сүзен әйтеп бетерсен. Наилне ирдән калган хатын өчен үстермәдек димәкче буласыз, шулаймы, әни? Гаҗәпләнмәгез, капкадан кергәндә ишетеп калдым.

Зәйнәп. Шулай түгелмени?

Наил. Бу Зөһрә белән икебезнең эш.

Зөһрә. Кызма, Наил. Алдан ук әйтеп куям — Наил белән икебезнең арага керергә беркемгә дә рөхсәт юк. Беркемгә дә. Мине күрәсегез килми икән, башка квартирага күчәрбез. Безне эшкә монда җибәрделәр. Квартир табарлар. Наил белән арагызны бозарга тырышмам, аннан курыкмагыз. Үзебезнең араны да боздырмам.

Наил. Ниткән ара бозу ул?! Сез нәрсә? Хан заманындамыни! Рәхмәт, әнкәй, малаеңны әйбәт каршы алдың!

Зәйнәп. И бала, бала! Тәмам үзенә каратып бетергән икән...

Гамилә керә.

Г а м и л э *(сулышы капкан)*. Илдус... кире әйләнеп килмәдеме?
М ә г ъ н ә в и. Ни булды, Гамилә килен?
Г а м и л ә. Әллә кая югалды! Эзләмәгән җирем калмады!

Чыгып йөгерә. Наил аның артыннан иярә.

Р ә х и л ә. Алла сакласын!..
М ә г ъ н ә в и. Каркылдама!

Күренешара

Айлы кич. Ындыр арты киртәсе буенда бер ялгызы гына Илдус уйланып тора. Кайдадыр ерак та эт шыңшый. Гармун тавышы ишетелеп куя.
Бакча ягыннан абына-сөртенә Нигъмәтҗан килә. Ул шактый исерек. Җырлый.

Алсаң — кыйбат, җиксәң — тузмый
Мәскәуский ызбурый.

Н и г ъ м ә т җ а н *(туктап кала)*. Әй! Син! Карачкы! Нишләп торасың анда?

Илдус эндәшми.

Сиңа әйтәм, мажик!

Илдус эндәшми.

*(Иелеп нидер күтәрә.)* Кем бар анда?

Илдус эндәшми.

Выж койма ягыннан. Башыңны таш белән ярганчы!

Илдус китә.

Тукта!

И л д у с. Бакчаңа алтын күмдеңме әллә, Нигъмәтҗан абзый?

Н и г ъ м ә т җ а н *(якын килә)*. Илдус? Син? Нишләп торасың монда?

И л д у с. Сине көтәм.

Н и г ъ м ә т җ а н. Мине? Ә-Ә! Пунятне. Наил энең артыңа типтеме?

И л д у с. Эчне пошырып йөрмә әле, Нигъмәтҗан абзый.

Н и г ъ м ә т җ а н. Тәк... Калибрың килмәдеме? Ә ни өчен? Мин синнән сорыйм! Ни өчен димен? Эндәшмисеңме? Эндәшмә шул! Мәгънәви абзыең ишетмәсен! Тс-с! Ул!.. Ул — без түгел... Юк! Менә син! Сине алыйк. Физанумиең килгән! Агранумиене беләсең... Яшермә, беләсең ич? Ә — тфү! — алдылар да ыргыттылар.

И л д у с. Бар әле, Нигъмәтҗан абзый, кереп йокла.

Н и г ъ м ә т җ а н. Юк, энем! Син абзаңа алай димә. Абзаң... Үзе белә ул! Юкса — үзең ычкын моннан! Менә шулай... Их, ширмәнкә син, Илдус энем! Бәхәсләшмә, ширмәнкә! Мин кем? Мин дә ширмәнкә! Бөтенесе черный дубка кара тун кия. Халык баеды!.. Ә миндә нәрсә? Нигъмәтҗанның аты кирәкми хәзер. Элек ничек иде? «Нигъмәтҗан абзыкай! Наныем!» Тегесен китер, монысын! Ә нигә алай? Ат кирәк! Ә хәзер! Ә хәзер... Тфү! Авызларына ат типкере!.. Нигъмәтҗанның кадерс китте!..

И л д у с. Нишләп тиктомалга салып йөрисең, Нигъмәтҗан абзый?

Н и г ъ м ә т җ а н. Сәбәбе бар! Беләсеңме син — минем йөрәк ни өчен яна? Ни өчен җан сызлый?.. Аргамакларымны искә төшерәм дә... *(Елый.)* Ундүрт корчаңгы тай калды!.. Нәрсә эшлим мин алар белән!.. Менә, менә! *(Күрсәтә),* шундый чагымнан алып ат тирәсендә бит!.. Ат койрыгына буем җитми иде, тай чаптыра идем инде!.. Үтте!.. Юк хәзер минем тулпарларым!.. Алардан башка нишлим мин?! Эх! Бер чакрым читтә тай чаба, ә мин аның нинди нәселдән икәнен әйтеп бирәм!.. Урамнан барасың — күңелдә аргамак кешни!.. Нәрсәгә миңа трактор? Йөрәгемдәгене аңа сөйләп буламыни?! Кем әйтмешли, соңгы җырым җырланган инде минем...

И л д у с. Ә ник соң пләмә хуҗалык оештырмыйсың? Пләмә атлар звеносы?

Н и г ъ м ә т җ а н. Бездәме?

И л д у с. Нигә? Председатель белән килеш тә...

Н и г ъ м ә т җ а н. Кем дип саныйсың син аны?! Шакировны белмисезмени! Төкереп бирә ул синең корчаңгы тайларыңа. И-их! *(Елый.)* Син беләсеңме, Мәҗит Гафури нәрсә дип әйткән? *(Елый.)* Энем! Беләсеңме, Мәҗит Гафури... *(Елый.)* Мәҗит Гафури нәрсә дигән... *(Елый.)*

И л д у с. Нәрсә дигән?

Н и г ъ м ә т җ а н. Беләсеңме, ул... ул... «Сарыкны кем ашаган», дигән...

И л д у с. Дисә — ни булган?

Н и г ъ м ә т җ а н *(елый).* «Куян ашаган», дигән ул. Менә ничек ул энем!.. Әнә шул куян мин булам инде!..

И л д у с. Ай-һай, Нигъмәтҗан абзый, куянмы икән?

Н и г ъ м ә т җ а н. Куян, энем, Илдус... Куян! Их! Син генә аңлыйсың мине. Йөрәгең алтын синең. Хәбировлар йөрәге түгел! Наиле кайтып эшли башламаган — миңа штраф салдырып өлгергән! За патрау өчен, имеш! Төкерәм мин! Ашлыкка юри җибәрмим мин ул тайларны.

И л д у с. Сиңа мин салдырдым ул штрафны. Наилнең катнашы юк.

Н и г ъ м ә т җ а н. Син?! Туган абыеңамы?!

И л д у с. Колхоз эшендә эне-абзый юк. Белеп тор. *(Китә.)*

Ашыга-ашыга Гамилә килә һәм, Илдусны күргәч, койма буендагы агач артына яшеренеп кала. Илдус аны күрми үтеп китә. Наил килә.

Н а и л. Илдус! Син нишләп йөрисең монда?

И л д у с. Йөрү тыелмыйдыр ич!

Н а и л. Тукта, аңлашыйк әле.

И л д у с. Төн уртасындамы? *(Китә.)*

Н а и л. Үпкәләргә урын калмасын дим!

Илдус эндәшми. Наил әкрен генә аның артыннан атлый.

Г а м и л ә *(яшеренгән урыннан чыгып).* Наил!

Н а и л *(туктый).* Илдусны очратмадыңмы? Әле генә кайтып китте.

Г а м и л ә. Күрдем.

Н а и л. М-да... Мондый хәлләрне көтмәгән идем.

Г а м и л ә. Нәрсә көткән идең?

Н а и л. Элеккечә үк усал син, Гамилә.

Г а м и л ә. Син бик юаш.

Н а и л. Беләсеңме, Гамилә, мин ник өйләнеп кайттым?

Г а м и л ә. Миңа үч итеп диген. Китаптагыча булыр.

Н а и л. Юк. Үч итеп түгел. Үземне сыныйсым килде.

Г а м и л ә. Ничек?

Н а и л. Сиңа карата булган хисләрем... чынмы, түгелме — шуны беләсем килде.

Г а м и л ә *(ирония белән)*. Белдеңме соң?

Н а и л. Белдем.

Г а м и л ә. Соң?

Н а и л. Чын булган.

Г а м и л ә. Аны бүген аңладыңмы?

Н а и л. Әйе.

Г а м и л ә. Шуннан?

Н а и л. Үзгәрмәгәнсең син, Гамилә. Кыяфәтең белән түгел... Менә кайттым да хәзер... үкенерлек төсле...

Г а м и л ә. Оятыңа көч килә башладымы әллә?

Н а и л *(туры җавап бирми)*. Мин үз-үземне белеп бетермәгәнмен икән.

Г а м и л ә. Мин дә сине — шулай ук.

Н а и л. Без икебез ике нәрсә сөйлибез ахры.

Г а м и л ә. Сөйләшәсе калмады инде. Әйтәсеңне әйттең. Ятып йоклыйсы гына калды.

Н а и л. Төрттермичә генә сөйләшик әле, Гамилә, мин сине Илдустан тартып алам. Телисеңме?

Гамилә кинәт читкә тайпыла һәм кычкырып көлеп җибәрә.

Нигә көләсең?

Г а м и л ә. Карагыз әле шушы юләргә!

Көлә-көлә кайтып китә. Наил аптырап кала: чөнки Гамиләнең көлүендә шатлык та, үкенү дә һәм тагын әллә нинди хисләр дә бар сыман, тик мыскыллау белән ачулану гына юк кебек. Гамилә күздән югалгач, Наил әкрен генә аның артыннан кузгала.

Н и г ъ м ә т җ а н *(бакчадан)*. Ала-ай!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### КҮРЕНЕШАРА

Көн кичкә авышкан вакыт. Урман буенда кулына зур күсәк тоткан Наил басып тора. Аягында пычранып беткән кирза итекләр.

Н а и л *(читкә карап)*. Җитте, бүтән көчәнмибез! Машинабыз көпчәгенә кадәр кереп чумган — икебез генә чыгарырлык түгел. Төш, әйдә җәяү кайтып киттек!

Машина якынлашканы ишетелә.

Бәхетебез бар икән! Төшмә — машина килә. Ә-әй! *(Күсәген болгый.)* Тукта!

Машина туктаган тавыш.

Ш о ф е р *(килә)*. Ни булды?

Н а и л. Исәнмесез! Мин — «Бүләк» колхозының баш агрономы. Безнең «газик»ны чыгарышыгызчы?

Ш о ф е р. Агроном түгел, миңа син хет министр бул! Ничек чыгарыйм мин сине? Трактор түгел ич миндә — машина! Үзем дә көчкә үрмәләп кайтып килем. Бензиным да песи яларлык кына калды.

Н а и л. Миндә бар. Агызып алырсың.

Ш о ф е р. Күзең чыккан идемени, сазлыкка барып кергәнсең! Әнә таш кебек такыр юл!

Н а и л. Ашыктык.

Ш о ф е р. Ашыксаң, утыр инде кукыраеп!

Зәйтүн килә, кулында кечкенә чемодан.

З ә й т ү н. Наил абый! Син нишлисең монда?

Н а и л. Районнан кайтып киләм. Ә син каян килеп чыктың? Слет бетте дәмени?

З ә й т ү н *(бераз көттереп)*. Әйе. Мин — менә бу абыйның машинасы белән. Ул Турай авылыннан. Бабакайның танышы икән.

Ш о ф е р. Син — Мәгънәви абзый малае мыни?

З ә й т ү н. Әйе, әйе. Мин сезгә әйткән идем.

Ш о ф е р. Баштук шулай диләр аны! Юкса — баш агроном! Фәлән! *(Дусларча Наилнең җилкәсенә суга.)* Мировой мужик синең атаң! Ул булмаса, мин һаман да биләнкә белән аунап ятасы идем. Бүре тиресе бирде ул миңа. Шуны бәйләгән идем — сыпырып алдымыни! Атаң йөз яшәсен! Миннән кайнар сәлам тапшыр. Турай авылы шоферы Әкрамнан диген. Әйдә, алайса, тросыңны китер. Синдә булмаса, үземнекен алырмын.

Н а и л. Бар. Әйдәгез.

Китәләр.

З ә й т ү н. Наил абый!

Н а и л *(туктый)*. Нәрсә?

З ә й т ү н. Синең очравың бик әйбәт булды әле.

Н а и л. Соңыннан, юлда сөйләшербез.

З ә й т ү н. Тукта, Наил абый. Үзеңә генә әйтәсе сүзем бар иде.

Н а и л. Ни булды? *(Кычкыра.)* Фәрит! Әкрам абыйга тросны алып бир әле! *(Зәйтүнгә.)* Я, нәрсә бар?

З ә й т ү н. Наил абый! Мин Әхмәтҗан абыйны күрдем.

Н а и л. Умартачы Әхмәтҗанныммы? Ул авылда калды ич!

З ә й т ү н. Түгел. Үзебезнең Әхмәтҗан абыйны.

Н а и л *(аптырап)*. Кем ул тагын? Безнең туганнар арасында Әхмәтҗан исемлесе дә бармыни шулай?

З ә й т ү н. Сугышка китеп югалган булган ич? Әнкәйнең... ире.

Н а и л. Әхмәтҗан җизнине күрдеңме? Юкны сөйләмә.

З ә й т ү н. Чын. Заводта эшли. Токарь булып. Малае да шунда. Сергей исемле.

Н а и л. Туктале, бутама! Әллә кайчан үлгән ич ул!

З ә й т ү н. Әнкәйнең карточкасын күргәнче, мин дә ышанмаган идем. Менә кара. *(Түш кесәсеннән фоторәсем алып бирә.)* Яшь чагы.

Н а и л. Бу карточканың монда ни катнашы бар?

З ә й т ү н. Альбомнарыннан алдым.

Н а и л. Рәтләп генә сөйлә әле: нинди альбом? Кайда ул?

З ә й т ү н. Новосибирск шәһәрендә. Гоголь урамында. Дүртенче йорт, илле дүртенче квартир. Өйләнгән.

Н а и л. Соң?

З ә й т ү н. Тегесен-монысын сорашты. Рәхилә ничек яши ди.

Н а и л. Туктале. Син анда ничек барып чыктың? Слетка анда бардыгызмыни?

З ә й т ү н. Юк, мин слетка бармадым бит.

Н а и л. Ә Новосибирскига нигә бардың?

Зәйтүн. Әхмәтҗан абыйны эзләп. Миңа бер җавап килде дә... Оборона министрлыгыннан. Менә... *(Кәгазь бирә.)*

Наил *(кәгазьне ала)*. Берни аңламыйм! Каян алдың моны?

Зәйтүн. Үзем сорап язган идем. Новосибирскида булырга тиеш дип җавап бирделәр... Тулы адресын әйтмәгәннәр. Сорашып белдем. Мин аны шундук таныдым.

Наил. Синме?! Син туганчы унбиш ел элек сугышка киткән кеше бит ул! Их, Шерлок Холмс!

Зәйтүн. Бездә карточкасы бар ич аның!

Наил. Ташла! Утыз ел элек төшкән рәсем белән чагыштыра башласаң!

Зәйтүн. Әхмәтҗан абзый инде. Битендәге миңе дә исән. Ә каян белә соң ул бабакайларны! Әнкәйнең рәсемен каян алган?

Наил. Син аңарга кем икәнлегеңне әйттеңме?

Зәйтүн. Юк, нишләп әйтим. Әнкәй турында әллә ниләр уйлап бетерер иде бугай...

Наил. Карточканы үзе бирдеме?

Зәйтүн. Юк, үзем алдым. Альбомда иде. Урлап алып киттем.

Наил. Нигә кирәк ул сиңа?

Зәйтүн. Нишләп калдырыйм ди мин аны? Кеше гомер буе көтеп ята. Ә ул!..

Наил. Һәм!.. Ситуация... Ә нишләп моңынчы кайтмаган?

Зәйтүн. Әсир булдым ди. Аннан соң — Себердә. Шунда өйләнгән. Нигә кайтмадыгыз дип сораган идем: «Мәгънәви судынамы?» ди. Миңа бер суд җиткән инде, ди... Әнкәй жәл!

Наил. Жәл! Юләр ул! Көтеп ятма, кияүгә чык дип ничә әйттеләр! Кая! Изге җан, имеш.

Машина тавышы.

Әйдә киттек! Машинаны чыгардылар...

Зәйтүн. Наил абый! Әллә... әнкәйгә әйтмибезме?

Наил. Тагын нәрсә? Ир бул!

Китәләр.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рәхиләнең өе. Стенада Әхмәтҗанның зурайтылган фоторәсеме. Пәрдә ачылганда Рәхилә ялгызы авыз эченнән генә көйләп, өстәлгә табын әзерли. Репродуктордан: «Без баш агроном Наил Хәбировның көзге агрочаралар турындагы әңгәмәсен тапшырдык. Хәзер концерт тыңлагыз»,— дигән сүзләр ишетелә.

Гамилә керә.

Гамилә. Исәнме, Рәхилә апа!

Рәхилә. Бик әйбәт әле, Әйдүк, үт, Гамилә.

Гамилә. Квартирантларың өйдәме?

Рәхилә. Наилләрме? Нишләп квартирантлар булсын алар?

Гамилә. Шаярып кына әйтүем, Рәхилә апа! Өйдә юклармы?

Рәхилә. Юклар. Наил районга китте диделәр. Зөһрәсе күренми әле... Уз, утыр.

Гамилә. Вакытсыз килдем ахры... Табын әзерлисең бугай.

Рәхилә. Мактап йөрим диген. Әйдә, син дә сыярсың.

Гамилә. Кая ул, Рәхилә апа! Әле генә табыннан торып килдем... Рәхмәт!

Урындыкка утыра.

Р ә х и л ә. Наилгә бирәр йомышың бар идеме?

Г а м и л ә. Юк... Йомыш дип... Юк эшне бар итеп йөрү генә.

Р ә х и л ә *(урындык алып Гамилә янына утыра)*. Син кызый, турысын гына әйт: нигә килдең?

Г а м и л ә. Туктале, Рәхилә апа, нигә алай кисәк бәреләсең?

Р ә х и л ә. Бәрелерлек булганга.

Г а м и л ә. Берни аңламыйм, Рәхилә апа!

Р ә х и л ә. Аңлыйсың. Бик аңлыйсың!

Г а м и л ә. Ни сөйләвең бу?

Р ә х и л ә. Син, Гамилә, Наил тирәсендә чуалма инде. Син хәзер ялгыз кыз түгел. Ул да башлы-күзле. Әйбәт түгел...

Г а м и л ә. Әнекәем!.. Каян алдың аны? Тузга язмаганны!

Р ә х и л ә. Каян алуым сиңа кирәкми. Ә Наилне тынычлыкта калдыр. Ул халык күзе алдындагы кеше. Ярамый.

Г а м и л ә. Карале, үтерсәң дә, берни аңламыйм!

Р ә х и л ә. Белмәгәнгә салышма. Кешеләр берничә мәртәбә бергә булуыгызны күргәннәр. Ярамый алай. Ир-ат бик алдын-артын уйлап бетерми ул. Син үзең уйларга тиеш. Бер даның чыкса... Я, ни житми сиңа? Илдусың менә дигән. Тормышыгыз бөтен. Яратмагач, нигә чыктың соң?

Г а м и л ә *(кинәт өстәлгә каплана)*. И, белсәң иде хәлләремне!.. Нигә чыктым?.. Йөрәге алтын дип уйлаган идем. Наилнеке кеше түгел дип... Ә ул! *(Яшь аралаш көлә.)* Ышанма, Рәхилә апа. Мин юри генә кыланам. *(Торып йөри.)*

Р ә х и л ә. Белмәссең сине, кызый!

Г а м и л ә *(кинәт Рәхиләнең иңеннән кочаклап ала)*. Онытa алмыйм мин аны! Нишлим соң?! Үз-үземне бәкегә ташлый алмыйм бит!

Р ә х и л ә. Туктале, Гамилә... Ни сөйлисең син?!

Г а м и л ә. Сиңа әйткәч, җиңел булып китте әле. Ачулансаң-ачуланмасаң да — яратам мин Наил чукынганны... Кеше гомерендә мәхәббәт бирәү генә була икән... Я, ни әйтерсең?

Р ә х и л ә. Ни әйтим... Киңәш бирүдән узгансың күрәмсең.

Г а м и л ә. Киңәш? Нәрсәгә миңа киңәш? Үз башым юкмыни! Юк инде, кеше киңәшенә калудан аллам сакласын! Әйтер кешем булмаганга гына әйттем мин, Рәхилә апа. Сине якын итеп кенә. Үз эчемә бикләнеп йөрүдән туйдым!

Р ә х и л ә. Наил... Нәрсә ди?

Г а м и л ә. Наил?.. Наил-Наил инде ул... Кайчак, шуның йөрәк турын ярып карыйсым килеп китә. Нәрсә икән аның йөрәге урынында!

Р ә х и л ә. Нигә укып кайтканын көтмәдең?

Г а м и л ә. Нигә көтмәдемме?.. Беләсеңме, миңа Наил нәрсә дигән иде? Мәңге онытасым юк! Ул мине үзе белән бергә укырга китәргә үгетләп йөргән иде. Ничек китим — әнкәй авырып ята... Минем читтән торып укырга керүемне белгәч, котлау урынына: «Нәрсә, Илдус авылда калгач, аңа якынрак булырга теләдеңмени?!» — диде. Мин юләр, яратуымны исбатларга теләп: «Әйдә алайса, синең булмәнә киттек»,— дигән идем, «Йоклар өчен генә мин Казанда да кызлар табам!» — дип китеп барды. *(Торып йөри.)*

Р ә х и л ә. Син шулай... Наилне күрергә дип килдең инде болай булгач...

Г а м и л ә *(горур)*. Килсәм?!

Р ә х и л ә. Ә Зөһрә?

Г а м и л ә. Булса ни!

Зөһрә керә

З ө һ р ә. Хәерле көн! Исәнмесез, Гамилә апа!

Г а м и л ә. Ярыйсы. Их, чибәр дә соң үзең, Зөһрә! Хуш иттек әлегә! Рәхилә апа, ни-ни!

Чыгып китә.

Р ә х и л ә. Наил кая?

З ө һ р ә. Район үзәгеннән кайтмады әле. «Сельхозтехника»га РМГ-4 кайткан икән.

Р ә х и л ә. Нәрсә ул?

З ө һ р ә. Ашлама тараткыч.

Р ә х и л ә. Ә-ә... Председатель Шакировның хәле ничек? Эшеннән, алалар, имеш, дигәннәр иде.

З ө һ р ә. Шабашникларга тиешеннән артыгын түләгән икән. Тикшерү бара.

Р ә х и л ә. Мескен... Кешеләр өчен әйбәт иде. Аның урынында кем калды?

З ө һ р ә. Әлегә Наил.

Зәйнәп керә, кулында таба белән бәлеш.

Исәнмесез, әнкәй?

З ә й н ә п *(сәламләмичә, баш кына кага)*. Бәлеш керттем, кызым Рәхилә. Әхмәтҗаныңа. Наил кайтмадымы?

З ө һ р ә. Ул район үзәгенә китте.

З ә й н ә п *(Рәхиләгә)*. Мин ачу сакламыйм... аңа. Бездә иркенрәк. Сезне кысрыклап ятмасыннар. Безнең өйгә күчсеннәр.

З ө һ р ә. Рәхмәт, әнкәй!

Р ә х и л ә. Наил кайткач, әйтербез. Әйдә, әнкәй, үзең дә безнең белән утыр.

З ә й н ә п. Мин ашадым.

Китә. Зөһрә, нидер әйтергә теләгәндәй, аңа таба омтыла, ләкин Зәйнәп тукталмый.

Р ә х и л ә *(өстәлгә ашамлыклар куя)*. Әйдә, Зөһрә, утыр.

З ө һ р ә. Рәхмәт. *(Утыра.)* Тагын кемне дә булса көтәсезме, Рәхилә апа? Дүрт савыт куйгансыз.

Р ә х и л ә *(сандыктан ипи телеме алып, бер тәлинкә янына куя)*. Кайтып җитсә, берсе Наилгә. Икенчесе — Әхмәтҗаныма. *(Утыра.)*

З ө һ р ә. Кемгә дидегез?

Р ә х и л ә. Әнә бит — стенада. Күзен дә алмый карап тора.

З ө һ р ә. Хәбәре бармы әллә?

Р ә х и л ә. Кая булсын?.. Бүген Әхмәтҗанымның туган көне. Әнкәйне әйтәм — һаман үз сүзендә тора: бүген дә киявенә дип бәлеш пешереп керткән. Бервакыт шаяртып үзенә, ел да туган көнендә бәлеш белән сыйлармын дип әйткән иде. Киявеннән башка утызынчы бәлеш инде...

З ө һ р ә. Яхшы кешеләр сез, Рәхилә апа!

Р ә х и л ә. Бик мактап бетермә әле. Төрле чакларыбыз бар безнең. Әнә бит, Наилең дә үз туганын җәлләп тормады, эшеннән кудыртып, үзе менеп утырды! Ярар, әйдә, җылы чакта аша.

З ө һ р ә *(Рәхилә куйган телемне ала)*. Бу нинди каткан ипи?

Р ә х и л ә. Урынына куй, Зөһрә, Әхмәтҗанның ашап бетермәгән телеме ул.

З ө һ р ә. Утыз ел сакладыгызмы?

Р ә х и л ә. Ашап бетермәгән ризык кайтканыңны көтеп ала диләр...

З ө һ р ә. Ачуланмагыз, бер нәрсә сорыйм дигән идем. Сез... аны һаман көтәсезме?

Р ә х и л ә *(тиз генә җавап бирми)*. Кем белсен инде...

З ө һ р ә. Менә мин сезгә карыйм да уйлап куям: мин беркайчан да сезнең кебек була алмас идем.

Рәхилә. Тапкансың үзең белән чагыштырырлык кеше!
Зөһрә. Чын! Утыз ел көтәргә! Уйлап карарга да куркыныч!
Рәхилә. Еллар... Аларга нәрсә? Үтә бирәләр. Көтсәң дә, көтмәсәң дә...
Зөһрә. Наил белән очрашканчы минем бер егетем бар иде. Өйләнешәбез дип йөри идек инде.
Рәхилә. Арагызны Наил бозмагандыр бит?
Зөһрә. Әллә ничек кенә килеп чыкты инде шунда. Авырлы чагым иде.
Рәхилә. Әнекәем! Өйләнешмәс борынмы?!
Зөһрә. Яраткач була икән ул.
Рәхилә. Әй, башсыз! Наил беләме соң?
Зөһрә. Больницага барырга ул киңәш итте инде.
Рәхилә. Әстәгъфирулла! Шул хәлне белә торып өйләнгән!
Зөһрә. Кызык кеше сез, Рәхилә апа! Аның нәрсәсе гаҗәп?
Рәхилә *(торып Әхмәтҗанның рәсемен ала һәм өстәл янына килеп утыра)*. Әй, ходаем! Ике генә ай бергә торып калдык лабаса без синең белән! Ике генә ай! Заяларга гына көтәм микән әллә мин сине?!
Зөһрә. Тынычланыгыз, зинһар. Хәзер су бирәм.
Рәхилә. Әй, Зөһрә, Зөһрә... Газапларны су гына баса торган булса иде... Ачуланма миңа, Зөһрә. Кара, бәлеш турында бөтенләй исемнән чыгарганмын.

Наил белән Зәйтүн керәләр.

Менә бит әйбәт кайтып җиттегез әле!
Зәйтүн. Исәнме, әнкәй! Исәнмесез, Зөһрә апа!
Зөһрә. Саумы, дөнья гизүче егет!
Рәхилә. Озакладың, Зәйтүн, улым. Бик озакладың.
Зәйтүн. Шулай килеп чыкты, әнкәй.
Рәхилә. Я, ярар. Тиз генә кулларыгызны юыгыз да — өстәл янына. Бәлеш суынып бетә инде. Зөһрә, кыен булмаса, торып тагын бер тәлинкә, кашык алып килче.
Зөһрә. Хәзер.

Эчке бүлмәгә кереп китә. Зәйтүн белән Наил кул юалар. Рәхилә су салып тора.

Зөһрә *(эчтән)*. Наил! РМГ-4 ала алдыңмы?
Наил. Ничәне алдың дип сора.
Зөһрә *(чыга)*. Без сораганчамы?
Наил. Өмете! Икене әлактерганга сөен. Анда минем кебек теләнеп йөрүчеләр буа буарлык! *(Өстәл янына утыра.)* Әйдә, Зәйтүн, утыр. Үзләре генә сыйланып ятмасыннар әле! Бәлешме?!
Зөһрә. Әнкәй пешереп кертте. Торырга үзебезнең өйгә күчсеннәр диде. Безнең турыда әйтте. Тик миңа әйтмәде, Рәхилә апага. Мин үзем шунда торсам да.
Наил. Әнкәйдән булыр!
Рәхилә. Юкка бәйләнмә. Карт әнкәң белән көрәшәләр димени...

Утыралар.

Наил *(Әхмәтҗанның рәсемен күреп)*. Һаман көтәсеңме?
Рәхилә *(рәсемне ала)*. Мә улым, Зәйтүн, урынына элеп куй.

Зәйтүн рәсемне ала һәм нишләргә белмәгәндәй карап тора.

Наил. Көт, көт! Бәлки кайчан да булса кунакка килеп китәр. Икенче хатынын җитәкләп.

Р ә х и л ә. Юләр сүзләр сөйләп утырма әле!

Н а и л. Ә юләр сүзләр булмаса? Ул чагында ни әйтерсең? Ә?

З ө һ р ә. Нигә алай дисең?

Н а и л. Кысылмый тор. Юләр син, Рәхилә апа! Ничә мәртәбә сиңа кияүгә чык диделәр! Баласыз күке сыман утырасың. Кемең бар синең?

Р ә х и л ә. Кагылма!

Н а и л *(тора)*. Юк инде! Әйтеп бетергәнне көт! Изге җан килгән имеш! Кемгә кирәге бар синең көтүеңнең? Әхмәтҗангамы? Төкерә ул сиңа! Әнә, икенче хатын белән рәхәтләнеп типтереп ята! Зәйтүннән сора!

З ө һ р ә. Ни сөйлисең син?!

Н а и л. Сөйлә, Зәйтүн! Нигә авызыңа су каптың?!

Зәйтүн тора һәм рәсемне кая куярга белмичә карана. Рәсемне утка ыргыта.

З ө һ р ә. Ой!

Рәхилә бер мәлгә ни булганын аңламагандай катып тора да мичкә ташлана. Зәйтүн аны мичкә якын җибәрми.

З ә й т ү н. Якын килмә, әнкәй! Янсын! Син берни белмисең! Көле күккә очсын! Юньсез кеше ул!

Р ә х и л ә *(Зәйтүннең яңагына суга)*. Кит!!!

З ә й т ү н. Әнкәй! Син берни белмисең ләбаса!

З ө һ р ә *(Наилгә)*. Ни карап торасың?! *(Мичкә ташлана, ләкин Зәйтүн аны да якын китерми.)*

З ә й т ү н. Кагылмагыз, Зөһрә апа! Сез берни дә белмисез! Ул исән! Ул Новосибирскида тора! Гаиләсе бар! Әнкәй аны көтеп ята! Үзем күреп кайттым!

Рәхилә сугарга әзерләнгәндәй күтәргән кулларын әкрен генә түбән төшерә.

Р ә х и л ә. Исән?!

З ә й т ү н. Исән дим бит инде! Ул әсирлектә булган! Менә кара. Үзеңнең яшь чагыңда төшкән карточкаң. Аның альбомыннан алдым.

Рәхилә ихтыярсыз карточканы ала.

Син аны көтеп ятасың. Ул икенче хатынга өйләнгән. Ике баласы бар. Берсе — Сергей, икенчесе — Николай.

Р ә х и л ә *(карточкасын күрсәтә)*. Каян алдың моны? Әхмәтҗаным алып киткән иде бит аны!

З ә й т ү н. Әйтеп торам ич! Әхмәтҗан абыйдан алдым!

Рәхилә аптырап Наилгә карый.

Н а и л. Я, ничек Рәхилә апа! Көтеп алдыңмы инде?

Рәхилә Зөһрәгә табан борыла — анысы тирән аптыраушта. Рәхилә Әхмәтҗанның рәсеме эленеп торган стена янына бара һәм киселгән агач кебек идәнгә ава.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Колхоз идарәсе. Ике карт утыра.

Б е р е н ч е с е *(өстәлдән газеталар ала)*. Нинди уйга калдың, Дәүләт кода? Әнә, гәҗит укы.

И к е н ч е с е. Идарәгә тиккә генә килмәдек микән дип уйлыйм мин, Хәбибулла кода... Ике тиле картның бакча ясыйбыз дип йөрүе кемгә хаҗәт димсең...

Б е р е н ч е с е. Вакытсыз каушама! Шакировка киракми иде ул! Ул — перестрахувщик. Районнан әйтмәсәләр, хатынын да кочакламас. Шалтыратып рөхсәт сорыйм дип безне ничә алдады. Шалтырата, пычагым! Телефон шалтыраганга дер калтырап тора. Районнан начальствосы шалтыратадыр дип куркып! Наил — үзебезнең авыл малае. Азаулы егет. Атасы Мәгънәвигә тарткан. «Кировец» тракторын башка кайсы колхоз ала алды! Туты! Ә Наил бер атнада кайтартты. Тезтүбән Мөкәрәмнең бакчасы артындагы күлне генә кара. Наил кайтмаса, мәңге саз булып ятар иде әле — ә хәзер балык фермасына әйләнеп килә! Кемнең башына килгәне бар иде? Башкасын әйткән дә юк. Чая егет, әмма эшнең мөгезеннән эләктереп тота белә.

И к е н ч е с е. Ә мин әйтәм — юкка килдек... Нәрәт тә үтмәгән әле.

Б е р е н ч е с е. Бар кайт ла соң! Сине йөрткән мин юләр!

Нигъмәтҗан керә.

Н и г ъ м ә т җ а н. Картларга сәлам! Колхоз идарәсендә иртә таңнан нишләп утырасыз.

И к е н ч е к а р т. Син кайчаннан алып картлар эше белән кызыксына башладың әле? Эчүгә сабышкачмы?

Н и г ъ м ә т җ а н. Мин кешенекен эчмим, Хәбибулла абый.

Б е р е н ч е к а р т. Кешенекен булмаса? Җисем иден — хәзер исемең генә калган!

И к е н ч е к а р т. Башладылар!.. Кайтам әле мин, Хәбибулла кода. Күңелем сизә— юкны бушка уздырып утырабыз. Юл уңмавы иртүк билгеле иде инде — иртән иң элек хатын-кыз очрады.

Н и г ъ м ә т җ а н. Миңа ни өчен минем бер генә дә юньле көнем юк икән!

И к е н ч е к а р т. Аңламадым.

Н и г ъ м ә т җ а н. Соң бит мин көн дә иртән уянгач, иң элек үз хатынымны күрәм! *(Көлә.)* Наил энекәш күренмәдеме, абзыйлар? *(Зал ишеген ачып карый.)*

Б е р е н ч е к а р т. Үзебез дә аны көтәбез.

Н и г ъ м ә т җ а н. Начальство! Ярар, көтегез, көт... *(Китә.)*

Б е р е н ч е к а р т. Әрәм була бу егет! Хәбировлар ыруыннан димәссең.

И к е н ч е к а р т. Атларыннан язды— шуңа юләр сата. Атлары янында хан иде...

Наил керә.

Н а и л. Исәнмесез, агайлар!

Б е р е н ч е к а р т. Исәнме, егет. Сиңа йомышыбыз бар иде.

Н а и л. Хәзер. Анда берәрсе бармы?

Б е р е н ч е к а р т. Барлар, нәрәткә җыелдылар. Сине көтәләр.

Н а и л. Һаман — элеккечә?

Эчкә үтә, ачык ишек аша күренә.

Алай... Исәнмесез! Мине көтәсезме? Сез нәрсә: бүген нишләргә кирәген белмисезмени? Белгәч, нигә монда чалбар төбе ышкып утырасыз? Менә нәрсә: бүгеннән башлап иртәнге нарядка җыелуны тыям. Үз эшләрегезгә барыгыз. Атна азагында нәтиҗә ясарбыз. Бетте.

Залдан чыгып китүчеләрнең аяк тавышлары ишетелә.

Картлар гаҗәпләнеп бер-берсенә карашып куя. Наил чыга.

Я, йомышыгыз ни, Хәбибулла абзый?

Беренче карт. Менә без Дәүләт кода белән... Атаң белән сөйләшкән идек инде...

Икенче карт. Сүзебез парк ясау турында иде.

Наил. Нинди парк?

Беренче карт. Менә безгә, картларга... Балаларга да бик кирәк...

Наил. Аңлый алмыйм әле мин сезне.

Беренче карт. Әә син бүлдермә. Шунда аңларсың. Без пенсионерларга кайда да булса ял итәргә кирәкме-юкмы?

Наил. Сыйган кадәр ял итегез. Кем тыя сезне?

Икенче карт. Әйттем мин сиңа, Хәбибулла кода! Киттек әйдә!

Беренче карт. Вакытсыз каушама дидем мин сиңа! Син, егет, аңламаган булып кыланма. Без сиңа бакча турында әйтәбез. Үзеңнең туган авылыңда мәрхүм Фәтхинең — туфрагы җиңел булсын — бакчасы әрем астында ята. Нәкъ агач утырта торган вакыт. Шакировка ничә тапкыр тукыдык. Аңа нәрсә? Аның йорты монда түгел.

Наил. Әә миннән сезгә ни кирәк?

Икенче карт. Җимеш үсентеләре. Һәм синең рөхсәтең. Барыбер бакча тик ята.

Наил. Үсенте? Колхозның бурычы күпме икәнен беләсезме? Үсенте өчен акча юк. Бик кулыгыз кычыта икән — әнә, борын төбендә урман, агач алып кайтыгыз да утыртыгыз.

Беренче карт. Дөрес сүз сөйлисеңме син, егет? Бер дә дөрес түгел! Иң элек, егет, атаң белән киңәш! Киттек, Дәүләт кода!

Икенче карт. Әйттем ләбаса юкка йөрибез дидем... Яшьләр аңлыймы соң безне!

Киталәр.

Наил *(телефон трубкасын ала)*. Алло!.. Мәктәп директорын бирегез әле, кызыкай... Йосыф Шәйхиевич? Исәнмесез. Бу мин әле — Наил Хәбиров... Сиңа утынга машина кирәкме?.. Шулай булгач, унунбиш пәһлеван егетеңне миңа җибәр әле. Тиз генә бер вагон ашлама бушатасы бар... Дәрес икәнен беләм... Кирәк, Йосыф Шәйхиевич! Юкса, вагонны озак тоткан өчен штраф түләргә туры киләчәк. Килештек алайса. *(Трубканы куя. Уйланып тора. Кабат ала.)* Алло, чибәр кыз!.. Райсекретарь белән тоташтырыгыз... Җавап бирми? Авыл хуҗалыгы идарәсен бир... Җир упканмы әллә аларны! *(Трубканы ташлый.)*

Нигъмәтҗан керә.

Нигъмәтҗан. Сәлам энекәшкә! Яңа урының белән котлыйм! Күтәрәләр үзеңне!

Наил. Сәлам. Йомышың бармы?

Нигъмәтҗан *(утыра)*. Кечтеки генә.

Наил. Әйт. Тик озак сузма, Нигъмәтҗан абзый. Ашыгам.

Нигъмәтҗан. Хәзер сиңа нигә ашыгырга? Баш агроном чакта ашыксаң да ярый иде. Хәзер син үзең хуҗа, үзең баш!

Наил. Мин әле дә баш агроном. Шуңа ашыгам да.

Нигъмәтҗан. Үзең беләсең инде. Ашык. Үз эшең... Мин менә нинди киңәш белән килгән идем...

Наил. Бүген дә эчәргә өлгердең мени?

Нигъмәтҗан. Әә син миңа салдыңмы соң? Кичә бераз гына булды. Яшермим. Бүген — бер грамм да! Төн йокламый чыктым әле Шуңа күрә синең янга килдем дә... Син ат яратасыңмы?

Наил. Моның белән ни әйтмәкче буласың?

Нигъмәтҗан. Ни әйтмәкчеме? Мин сине менә — мондый чагыңнан ат сыртына утырта идем. Миннән бер адым да калмыйча ияреп йөри торган идең.

Наил. Шуннан?

Нигъмәтҗан. Тыңлап бетер. Башка бик шәп бер уй килде әле: әйдә колхозда ат пләмәлеге оештырабыз? Ә?

Наил *(кычкырып көлеп җибәрә)*. Кара син аны! Кем белән оештырмакчы буласың соң син аны? Әллә үзең генәме?

Нигъмәтҗан. Ә нигә? Оештырам! Син миңа әз генә ярдәм ит. Калганына — комачаулама. Я, кул сугыштыкмы?

Наил. Ул атларың белән нишләмәкче буласың?

Нигъмәтҗан. Ничек — нишләмәкче? Яхшы нәселле юртаклар кирәкме? Кирәк! Нәсел айгырлар кирәкме? Кирәк! Аягын-кулың белән тартып алачаклар! Үстереп кенә житкер! Бөтен Европага шаулаячакбыз!

Наил. Синнән башка да шаулыйлар инде.

Нигъмәтҗан. Син туктале. Кырт кисмә!

Наил. Эшсез ятып саташа башлагансыз, ахры. Андый хуҗалык турында сиңа кадәр биш былтыр элек уйлаганнар инде. Ат заводлары житәрлек. Нәсел атлары совхозлары бар. Әле мин синдә калган тайларны да ит комбинатына озатырга кирәк дип уйлап торам. Ике тиенлек тә файдалары юк! Азык бетерүдән башка...

Нигъмәтҗан *(кинәт кызып)*. Кагылып кына кара! Мин сине... Мин сине менә шушы кулларым белән өзгәләп ташлармын! Ишеттеңме?!

Ишекне тибеп ачып чыгып китә. Наил аптырап кала.

Илдус керә.

Илдус. Ни булган аңа?

Наил. Безне, Хәбировларны, бер бүген генә күрәсеңмени?! Бер нәрсә булса, тәртәгә тибәләр! Син дә минем янымамы?

Илдус. Синең яныңа... Я, ничек? Мономах бүреге авыр түгелме?

Наил. Гафу ит, мине келәтләр янында көтәләр.

Илдус. Шуңа килдем дә. Үзең беләсең: Шакиров үз эшенә кире кайта алмаячак. Сиңа озакка җигелергә туры киләчәк. Ярдәм кирәкмиме?

Наил. Нинди ярдәм?

Илдус. Үз эшемә кире кайтсам ничек булыр икән?

Наил *(кинәт кызып)*. Сез нәрсә — сөйләшеп килдегезме әллә?! Берәүләр парк корабыз дип юләр сатып йөриләр, икенчесе нәселле ат хуҗалыгы оештырам дип килгән! Әгәр син агроном булып эшли алсаң, мин тавыш күтәреп йөрер идеммени! Син миңа якын туган кеше, әмма бу эштә потың бер тиен! Мин аңламыйммыни? Яратасың син ул эшне. Тик син булдырырдай түгел ул, аңлыйсыңмы? Егәрең житми! Әнә, гаражга механик кирәк. Барасыңмы?

Илдус. Юк.

Наил. Үз ихтыярың. Ләкин барыбер сиңа кайда булса да эшләргә туры килер. Сыңар куллы булсаң да. Хатының Гамилә җилкәсендә ятарга җыенмыйсыңдыр ич?

Илдус *(әкрен)*. Син Гамиләгә тимә... Ишетәсеңме?

Наил. Җәһәннәмгә олакмассызмы!

Чыгып китә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рәхиләләр өендә.
Зөһрә ялгызы язып утыра.

Гамилә керә.

Г а м и л ә. Исәннәрмесез? Нихәл, Зөһрә!

З ө һ р ә. Саумысыз, Гамилә апа. Түргә үтегез. Утырыгыз.

Г а м и л ә. Рәхмәт. Мин тиз. Рәхилә апаның хәле начар дип ишеттем. Бик авыр түгелме?

З ө һ р ә. Вакыты-вакыты белән әйбәтләнгән дә кебек.

Г а м и л ә. Саташамы?

З ө һ р ә. Төрлечә.

Г а м и л ә. Кешене таныймы соң?

З ө һ р ә. Кем белсен. Кайчак исемнәребезне әйтеп сөйләшә.

Г а м и л ә. Мескен! Алайса, Әхмәтҗан абзыйның табылуы чын булды инде?

З ө һ р ә. Әйе. Әткәй белән Наил тикшерткәннәр иде, раслап җавап килде.

Г а м и л ә. Нинди генә хәлләр булмый дөньяда! Рәхилә апа терелсә генә ярый инде. Айтан абыйга хәбәр итмәдегезме?

З ө һ р ә. Кем ул?

Г а м и л ә. Белмисең икән. Әйтмәгәннәрдер. Ишеткән булыр идең. Күреп чыгыйм әле үзен. Йоклыймы?

З ө һ р ә. Врач әле генә дару биреп китте. Йоклый.

Г а м и л ә. Мин иплəп кенә...

Аяк очларына гына басып, эчке бүлмәгә үтә. Зөһрә өстәл яныннан торып, ишек янына килә. Бераздан Гамилә кире чыга да ишекне ябып куя.

Лимон кисәге китергән идем. Аппетиты ачылмасмы. Янына куйдым, чәйгә салып биреп карагыз.

З ө һ р ә. Рәхмәт. Утырыгыз, Гамилә апа.

Г а м и л ә. Кая ул! Утырып тора алмыйм!

Чыгарга бара һәм туктап кала.

Карале, Зөһрә, Наил ничек соң? Бик борчылмыймы?

З ө һ р ә. Нәрсәгә?

Г а м и л ә. Рәхилә апага әйткәненә. Әхмәтҗан абзый турында дим. Шулай дип уйлаган идем аны. Бигрәк каты бәгырьле кеше инде. Шундый булмаса, ул Илдус абыйсының кулын да чабып өзмәс иде.

З ө һ р ә. Кулын? Наилме?!

Г а м и л ә. Бәрәч, ишетмәдеңмени? Алар икесе бергә бер трактор да урман чыгаралар иде. Кырын җиргә эләгеп ауганнар да, Илдусның кулы аста кысылып калган. Үзен бөтенләй сыта дигәндә, Наил балта ала да...

З ө һ р ә. Ой!

Г а м и л ә. Терсәктән диярлек. Үзен тартып алып өлгерә... Әнә шундый ул синең Наилең.

З ө һ р ә. Ул миңа бер нәрсә дә әйтмәде.

Г а м и л ә. Шулай итмәсә, Хәбиров буламыни ул!.. Син... яратасыңмы аны?

З ө һ р ә *(бераз көттереп)*. Белмим.

Г а м и л ә. Ә менә мин... Илдусымны...

Наил керә.

Әй, сөйләшә торгач, эшемне онытканмын! Киттем. Исәнме, Наил!

Н а и л. Саумы. Мәктәптә эшләр ничек, барамы?

Г а м и л ә. Бара. Ярыйсы. Хушыгыз.

Чыга.

Н а и л. Нигә килгән?

З ө һ р ә. Рәхилә апа янына... дөресме ул, син... Илдус абыйның кулын балта белән чабып өзгәнсең икән?

Н а и л. Кем әйтә аны?

З ө һ р ә. Дөресме?

Н а и л. Шуннан? Дөрес булса?

Зөһрә артка чигенә.

*(Тирән газаҗәпсенеп...)* Аңламыйм мин сине!.. Нәрсә, синеңчә, тракторның сытканын көтеп, карап торырга тиеш идеммени?! Кайсы яхшырак соң?.. Ник миңа җәлладка караган кебек карап каттың? *(Зөһрә янына килә.)*

З ө һ р ә *(чигенеп)*. Мин... берни дә әйтмим бит сиңа...

Зәйтүн керә, портфелен урындыкка ташлый.

З ә й т ү н. Сәлам! Наил абый, сине бабакай чакыра.

Н а и л. Ни булган?

З ә й т ү н. Белмим. Нигәдер бик ачулы.

Наил чыга.

Наил абый бүген келәттә эшләүче абзыйны эшеннән куган икән. Анысы бабакайга килеп зарланган ди. Шуңа бугай... Ни булды, Зөһрә апа?

З ө һ р ә *(уз-үзен кулга алып)*. Берни булмады... Зәйтүн акыллым, син Наил абыеңны... яратасыңмы?

З ә й т ү н. Менә сиңа иске авыздан яңа сүз! Абый бит ул миңа! Нигә сорыйсыз аны?

З ө һ р ә *(бераздан)*. Наил абыең кебек булырга теләр идеңме соң?

З ә й т ү н *(аңлап бетермичә)*. Агрономмы? Белмим әле. Бабакай әйтмешли, куеныңа кермәс борын, кызны мактамыйлар... Әнкәй йоклыймы?

З ө һ р ә. Әйе.

З ә й т ү н. Уянып мине сораса, хәзер кайта диярсез, Зөһрә апа. Бүрегә ауга барып карыйм әле. Бик әрсезләнә башлаганнар. Бабакай да нишләптер ауга йөрүен ташлады.

З ө һ р ә. Ул аучымыни?

З ә й т ү н. Ниндие генә әле! Бүрене мылтыксыз тота. Пычак белән. Яшьрәк чагында тирә-юньдәге бөтен бүреләрне кырып бетереп тора иде диләр. Теленнән сөйрәп алып кайткан чаклары да булган. Аның үзе теккән бияләе бар. Үч төбе сумалалы. Шул бияләйле кулын, бүре авызын ачкач, тыгып җибәрә дә икән, теленнән бөтереп алып,— әйдә, кодагый! Хәзер картаеп бара шул.

З ө һ р ә *(ышаныр-ышанмас)*. Әллә шаяртасың инде?

З ә й т ү н *(җитди)*. Хәбировлар беркайчан да буш сүз сөйләми, Зөһрә апа!

Чыга.

Бераздан Зәйнәп керә.

З ө һ р ә *(тора)*. Исәнмесез, әнкәй?

З ә й н ә п. Саумы?

Эчкә үтә. Зөһрә дулкынлануын басарга теләп йөри. Бераздан Зәйнәп эчке бүлмәдән чыга.

Зөһрә. Әнкәй...
Зәйнәп. Нәрсә?
Зөһрә. Мин сездән китәрмен ахры...
Зәйнәп. Китәсең? Һе.

Кузгала.

Зөһрә. Әнкәй!
Зәйнәп. Тагын нәрсә?
Зөһрә. Нинди кешеләр сез, әнкәй?!
Зәйнәп. Кемнәр?
Зөһрә. Сез, Хәбировлар...
Зәйнәп. Белмәгәч... Ник килдең соң безгә?

Чыга.

Мәгънәви карт өендә.

Мәгънәви *(ишекле-түрле йөри)*. Фәтхетдинне нигә эштән кудың? Егерме ел эшләгән кеше сиңа ярамадымыни?

Наил *(тыныч)*. Эш вакытында өенә кайтып киткән.

Мәгънәви. Аның улы чирләгән! Өендә калыр кешесе юк. Шуны беләсеңме?

Наил. Беләм.

Мәгънәви. Белгәч?

Наил. Аның аркасында дүрт машина ике сәгатькә якын бушатылмый торды. Бер вагон ашлама ташып бетерә идек. Киләчәккә акыл булыр. Мин аны иртүк кисәтеп куйдым. Складтан бер адым да читкә китмә дидем. Тыңламаган! Бер мәртәбә ышанычны акламады, икенче тапкыр да күп уйлап тормас.

Мәгънәви. Мин аны эшенә кабат җибәргән идем. Атаңның сүзен дә халык алдында егасың!

Наил *(көлемсерәп)*. Кайчаннан алып пенсионерларга председатель кушканны үзгәртергә хокук бирделәр әле?

Мәгънәви. Атаң белән бәхәсләшергә сиңа иртә әле! Башта эшләргә өйрән!

Наил. Минем эшем өчен борчылма. Бик әйбәт эшләрмен. Аяк астында син буталмасаң!

Мәгънәви. Минме?

Наил. Абруең белән! Колхозда әллә Шакиров председатель иде дисеңме? Түгел, син! Бөтен нәрсә синең сүзгә карап эшләнә. Сазлыкны сөрү турында кем беренче сүз кузгатты? Син! Колхоз өчен тырышам, дип уйлыйсыңдыр. Халык шул сазлык аркылы салам урламасын! Синең максатың шул иде!

Мәгънәви. Салам урлатмау колхозга файда түгелмени?

Наил. Зур файда эшләдең инде! Бер тиенлек куян, өч тиенлек зыян! Хәзер, әнә, сазлык урынында пычрак баткаклык. Үләне дә, шомыртлыгы да калмады. Сөрерлек тә түгел! Урлатмауга башка чара бетмәгән.

Мәгънәви. Синең үзеңә минем абруем ние белән зыян итә?

Наил. Мин кушканны үтисе урынга, сиңа йөгерәләр. Имеш, ялгыш кушмадыммы?

Мәгънәви. Куша белмисең. Шуңа йөгерәләр. Фәрбизәгә ник бодай бирмәдең?

Наил. Һәм бирмим дә.

Мәгънәви. Ул — ялгыз карчык! Ире сугышта үлгән!

Наил. Үлсә? Бер аныкы гына үлгәнмени? Колхозчыларга өләшми

торып, аңа бер бөртек тә юк. Ачтан үлмәс. Малае ярдәм итәр. Сандыгын ачсын, гомер буена спекуляция белән шөгыльләнде!

Мәгъңәви. Анысы синең эш түгел! Иртәгә үк яздырып бир. Кеше белән кешечә эш итәргә өйрән.

Наил. Үзеңне кешечә эшли идем дип саныйсыңмы? Ни кыланганнарыңны онытгың дамыни? Бервакыт Нигъмәтҗан абзыйның атына бер сәнәк солы саламы салып кайтуын күргәч, бөтен халык алдында тукмап ташладың! Исеңә төшер әле!

Мәгъңәви. Ул — минем бертуган энем! Үзен генә түгел, ул мине дә бөтен мир алдында хурлыкка төшерде!

Наил. Ә Гарифулла абзыйның хатынын нишләттең? Сугыштан соң. Ачлык еллар иде. Кесәсендә бер уч бодай алып кайтканы өчен колхоз җыелышы ясап карак дип сүккәнсең! Тагын кирәкме? Әллә җитәрме?

Мәгъңәви. Син үткән еллар белән чагыштырма. Ул чакта бер уч ашлык өчен утырталар иде. Ә мин аны яклап алып калдым.

Наил. Харап инде! «Яклап алып калган!» Бүгенгә кадәр туган авылына кайтып күренергә гарьләнә. Бөтен нәселенә «карак» кушаматы тагылды.

Мәгъңәви. Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетми синең?

Наил. Ишетә. Нәрсә, ошамыймы? Юк инде, эткәй, минем эшкә тыгылма. Син эшли белгәнеңчә эшләгәнсең, мин үз белгәнемчә эшләрмен. Анысын миңа калдыр. Минә кайда утыра ул синең абруең! *(Җилкәсенә күрсәтә.)*

Мәгъңәви. Мин исән чакта, минемчә булыр! Синең өчен мин җавап бирәм. Илдус урынына кайткач, малаем булганга каршы килмәгән дип уйлагансыңдыр. Синнән рәт чыгар дип уйладым. Шуңа эндәшмәдем.

Наил. Эткәй! Син мине әллә чынлап та бу мәсьәләдә синең теләгең белән санашыр иде дип уйлыйсыңмы? Ялгышасың. Ярар, калсын. Сүз көрәштереп утырырга вакытым юк.

Чыгып китәргә кузгала.

Мәгъңәви. Тукта! Мин әйтеп бетермәдем. Рәхилә апаң үлем түшәгендә ята. Синең аркада!

Наил. Минем аркада?! Ю-ук! Ул синең аркада шундый хәлгә калды! Гаилә горурлыгы, имеш! Хәбировлар кызы! Хәбировларныкы кешечә генә буламыни? Әгәр дә синең шапырынуың булмаса, ул күптән яңа гаилә корып, рәхәтләнеп яшәр иде!

Мәгъңәви *(ачуы чиктән ашып)*. Җитте дим!

Наилгә ташлана, ләкин аны улының үз-үзенә нык ышанган тыныч тавышы туктатып калдыра.

Наил. Мин Илдус түгел, эткәй. Нигъмәтҗан абзый да түгел!

Чыгып китә.

Мәгъңәви. Тукта!.. Борын асты кипмәгән! Карт атасын өйрәтергә! Анасы! Зәйнәп! Җен алгыры нәрсә! Кая олактың!
*(Аяк астында яткан киез итекләрне тибеп җибәрә.)*

Зәйнәп керә.

Кайда йөрисең син? Итекләрем кая?!

Зәйнәп *(ире тибеп җибәргән итекләрне алып бирә)*. Нинди чебен тешләде?

Мәгъңәви. Ә-әй! «Чебен!» Син үзең чебен!

Зәйнәп. Ни булды? Нигә кычкырасың?

Мәгънази. «Ни булды, ни булды!» *(Итекләрен кия, сыймыйлар.)* Нәрсә бирдең миңа?! Аяк астына ташлама дип ничә әйттем! Киптермәгәнсең! *(Киенә.)* Малай үстермәгәнсең син! Бүре баласы үстергәнсең!

Зәйнәп *(кинәт усал)*. Ул — син үзең! Син шундый итеп үстердең аны!

Мәгънази тынып кала.

Дөрес түгелмени?! Исеңә төшер! Гомеремә синнән бер җылы сүз ишетмәдем! Балалар бар дип тормадың! Бер нәрсә барып чыкмаса, миңа җикерендең! Хәзер — «мин бүре үстергәнмен!» Җитте! Күп түздем!

Мәгънази. Ә-әй! Син дә монда!..

Зәйнәп. Төнгә каршы кая барасың?

Мәгънази. Синең эшең түгел!.. *(Муенына шарф бәйли, бутала.)* Тфү!

Шарфын идәнгә атып чыгып китә, бакча ягына уза.
Бераздан шул ук яктан Зәйтүн тиз генә өйгә кереп, мылтык белән патронташ алып чыга. Бакча коймасына сөялгән чаңгыларын алып, бакчага йөгерә.

Урамда, капка төбендә.

Илдус *(куып җитеп)*. Гамилә! Туктале.

Гамилә. Ни булды?

Илдус. Барма аларга.

Гамилә. Рәхилә апа янынамы?

Илдус. Мин беләм... Син аның янына дип кермисең бит.

Гамилә. Синеңчә кем янына соң?

Илдус. Әйдә кайтыйк, Гамилә.

Гамилә. Минем арттан шуны әйтер өчен килдеңмени?

Илдус. Нишләп синең арттан йөрим ди мин? Эштән кайтып килүем. Синең монда кереп баруыңны күрдем дә...

Гамилә. Бар кайт. Мин озак булмам.

Илдус. Чынлап әйтәм, Гамилә. Йөрмә. Бәлки болай да...

Гамилә *(бүлдерә)*. Нәрсә — болай да?

Илдус. Үзең беләсең. Наил янына дип килсәң, ул өйдә юк.

Гамилә. Кайда калды ул?

Илдус. Алачык янында калды.

Гамилә. Күптәнме?

Илдус. Гамилә! Мин сизәм бит!

Гамилә. Күптән күрдеңме дим?

Илдус. Биш-ун минут элек. Әйт әле, сиңа ни булды?

Гамилә дәшми.

Үзгәрдең... Бәлки минем Наилгә каршы чыкмавым сиңа сәер тоеладыр. Ул мине үлемнән коткарды... Бәлки ул хаклыдыр да. Мине эштән алдыруын әйтәм...

Гамилә китәргә кузгала.

Гамилә! Барма анда, үтенәм. Ичмасам, кеше күрмәсен. Бик күрәсең килсә, монда көт. Ул озакламый кайта.

Китә.

Гамилә *(бераз карап торганнан соң)*. Илдус!

Илдус туктый.

Илдус, минем синнән яшерен серләрем юк. Син тыныч бул. Шикләнмә. Безнең арада берни дә булганы юк. Тик... Мин үземне-үзем дә аңлап бетермим әле. Син үпкәләмә инде миңа. Зинһар. Бәлки юләрлек кенәдер... Белмим... Белмим. Син бар. Кайткач сөйләшербез. Кайткач. Яме?

Илдус. Соң булмасмы, Гамилә?

Гамилә. Белмим. Бар дим бит инде!

Илдус китә.

Каршысына Наил килә.

Илдус. Наил, синең белән сөйләшәсем бар иде.

Наил *(гаҗәпләнеп)*. Кая җыендыгыз болай? *(Гамиләгә.)* Сиңа ни булды?

Илдус *(ашыгып)*. Гамилә! Бар, син кайта тор.

Гамилә дәшми.

*(Житди.)* Ишеттеңме! Безнең Наил белән җитди сөйләшәсе бар. Курыкма, син уйлаган темага түгел. Бар. Анысын син үзең хәл итәрсең. Тик бүтән вакытта.

Наил *(шаярып)*. Мәнә ничек? Илдус, синме бу?

Илдус. Шаяртырга вакытым юк. Бар, Гамилә!

Гамилә әкрен генә китә.

Наил *(аның артыннан карап кала)*. Я? Ни әйтмәкче идең?

Илдус. Берсекөнгә, үзең беләсең, ачык партҗыелыш була. Шунда мин синең турыда сүз кузгатачакмын.

Наил *(мыскыллап)*. Тормышыңны бозуым турында түгелдер ич?

Илдус *(тыныч)*. Түгел.

Наил. Ә ни турында?

Илдус. Гомумән... Синең турыда. Эш методың. Кешеләр белән мөнәсәбәтең... Гомумән, синең хакта. Минемчә, син күп нәрсәне аңламыйсың...

Наил. Я?

Илдус. Я аңлап та шулай эшлисең.

Наил. Ничек?

Илдус. Син минем ни әйтергә теләгәнемне яхшы аңлыйсың, Наил. Эштән алдыртуың өчен үч ала дип уйлама. Мине яхшы беләсең — андый түбәнлеккә төшә торганнардан түгел мин.

Наил. Алай... *(Катгый.)* Карарбыз, карарбыз.

Илдус. Әйе, карарбыз. Күп нәрсә ишетергә туры килер сиңа. Туганнарча кисәтеп куям: усаллашып түгел, аңлап тыңларга тырыш. Ачу саклый торган кеше булсам, мин моны сиңа әйтми эшләгән булыр идем.

Китә.

Рәхиләләр өендә.

Кич.

Наил *(ишекле-түрле йөри)*. Сентиментальләшеп тора торган вакытым хәзер! Өйрәнгәннәр бар да күз яше күрсәтеп үзләрен жәлләтергә. Һәр елакның көен көйләп тора башласаң! Достоевский бик дөрес әйткән: артыңда шыңшыган һәр этне туктап юата башласаң, ерак китә алмыйсың!

Зөһрә. Шыңшыган түгел, һәр өргән эткә таяк ыргытсаң, дигән.

Н а и л. Барыбер түгелмени!

З ө һ р ә. Каты бәгырьле кеше син, Наил. Гамилә әпа дөрес әйтә...

Н а и л. Нәрсә ди?

З ө һ р ә. Үзеннән сора. Бер рәттән яшьлегегезне дә искә алырсыз.

Н а и л. Моның белән ни әйтмәкче буласың? Бәлки... безнең дә синеке кебек балабыз булгандыр?! Я, нигә туктап калдың?

Зөһрә торып читкә китә.

Н а и л *(аның янына килә)*. Я, ярар, бетте. Үзең гаепле. Әллә ниләр чокып чыгармассың.

З ө һ р ә *(тыныч)*. Мин иртәгә китәм, Наил. Анда... күз күрер.

Н а и л. Нәрсә?!

З ө һ р ә. Моны мин бер бүген генә уйламадым. Күптән әйтергә йөри идем инде... Ә бүген... бергә яши алмавыбызны аңладым.

Н а и л. Акылдан шаштыңмы әллә?

З ө һ р ә. Хәтта монда да йомшаграк сүз таба алмадың... Юк, миңа синең зыяның тигәне булмады. Мин сине моның өчен гаепләмим.

Н а и л. Ә нәрсәдә гаеплисең?

З ө һ р ә. Гаеплим!.. Наил! Син нинди кеше! Нигә шундый син?

Н а и л. Нинди?

З ө һ р ә. Үзең сизмисеңме?

Н а и л. Табышмаклар белән сөйләшүеңне ташлачы!

З ө һ р ә. Табышмак... Син үзең табышмак, Наил! Тик бер нәрсәне яхшы беләм мин, Наил! Җитәкче булырга хакың юк синең.

Н а и л. Кызык!

З ө һ р ә. Киресенчә, кызганыч! Аңламавың кызганыч! Кит син бу эшеңнән, Наил. Үзең өчен түгел, башкалар өчен әйбәтрәк булыр. Авылдашларың өчен. Син сәләтле кеше. Фәнни эшкә күч. Кешеләр өчен куркыныч кеше син, Наил. Йөрәге урынына роботныкы кебек мотор булган кешенең язмышлар белән эш итәргә хакы юк! Күзеңне ачыбрак, бер генә минутка булса да йөрәгең җылысы белән тоярлык итеп кара: шушы ярты ел эчендә никадәр кешенең язмышын җимереп ташладың син! Рәхилә апа! Нигъмәтҗан абый! Илдус абый! Завсклад! Тагын әллә кемнәр! Әгәр дә син кешеләргә бәхет урынына күз яше китерәсең икән, синең яхшы агроном булуыңнан ни файда?! Алай гына да түгел! Зәйтүн сиңа карап үсә. Синнән өйрәнеп үсә. Әлегә ул саф, самими бала. Ләкин аңарда да синең характер сизелә башлады инде! Димәк, син авыл өчен икеләтә-өчләтә куркыныч кеше! Шул турыда уйла, Наил!

Н а и л. Беттеме?

З ө һ р ә. Ничек кенә аңлатыйм соң мин сиңа?!

Т а в ы ш *(тыштан)*. Наил абый!

Н а и л *(тәрәзә аша)*. Ни булды?

Т а в ы ш. Мәгънәви абзыйны бүре талаган!

Н а и л. Кайда ул?

Тиз генә пальтосын алып чыгып китә.

З ө һ р ә. Ни булган?!

Урам чатында.

Баганадан төшкән яктылыкта халык. Уртада Мәгънәви карт ята. Кырыйда кулына мылтык тоткан Зәйтүн. Наил, Зәйнәп киләләр. Халык шаулаудан туктап юл бирә.

З ә й н әп. Әй, ходаем! Үлгән түгелме соң?! *(Мәгънәви янына килә.)* Йөрмә дидем! Күңелем нидер сизенгән иде!.. *(Елый. Аны Гамилә юата.)*

Н а и л. Их, эткәй, эткәй... *(Пальтосын салып, әтисенә яба.)* Кем алып кайтты?

Т а в ы ш л а р. Зәйтүн. Ул алып кайткан.

Н а и л. Кайда иде?

З ә й т ү н. Мин бабакайга сиздерми генә артыннан карап барган идем.

Н а и л. Соң?

З ә й т ү н. Бүре чокырлыгына җиткәндә караңгы төшкән иде инде. Ай калыкмаса, кире кайтып китәрмен дип бара идем, бабакай басып тора! Якынрак барсам — аланлыкта бүре утыра. Бозау чаклы бар.

Т а в ы ш л а р. Шул чакта атарга кирәк иде!

З ә й т ү н. Атсам, бабакай ачуланыр дип курыктым. Бабакай каршы бара башлагач, бүре бер-ике ырлап куйды да читкә сикерде. Шунда бабакай нишләптер сөрлеккән кебек булды да егылды.

Т а в ы ш л а р. Әйтәм бит, йөрәге тоткан!

З ә й т ү н. Бабакай егылгач, бүре аңа таба килә башлады да шунда мин атып җибәрдем.

Т а в ы ш л а р. Тидеме соң?

З ә й т ү н. Башына. Бабакайны торгызыйм дисәм, селкенми.

Т а в ы ш л а р. Йөрәген тыңлап карарга иде... Әллә соң, бүрегә атам дип, ялгыш бабаңа тидерденме?

З ә й т ү н. Нишләп тидерим ди!

Т а в ы ш л а р. Ә бүрең кайда соң?

З ә й т ү н. Шунда, аланлыкта калды.

Н и г ъ м ә т җ а н *(Мәгънәвине капшап)*. Үз башыңа кылангансың икән, олы абый! Бүре кебек усал яшәдең, әҗәлеңне дә бүредән тапкансың.

И л д у с *(алга утә)*. Нәрсә дидең?! Кит дурәтәй яныннан! Син үзең бүре! Мәгънәви карт кебек яшәргә кирәк әле! Тор, дурәнәй! Дурәтәй мескен түгел иде, син дә елама! Авылыбызның маягы булды ул — башыңны югары тот! *(Илдусның сүзләрен игътибар белән тыңлаган Гамилә аның янына килеп баса.)*

Т а в ы ш л а р. Дөрес әйтәсең, Илдус!.. Әйе. Бик дөрес!.. Кырыс иде, әмма яхшы кеше булды!

И л д у с. Күтәрешегез әйдә. Тоттык...

З ө һ р ә *(Наилгә)*. Синең аркада үлде ул!.. Син генә гаепле! Атаңны шушындый хәлгә син җиткердең!

Китә.

Н а и л *(югалып)*. Ни сөйлисең син, Зөһрә?!

Мәгънәви картның гәүдәсен күтәрәләр. Наил, Илдус янына килеп, күтәрешмәкче була, ләкин аңа тотынырга урын калмаган. Ул икенче яктан килә — әллә очраклы, әллә махсус шулай иткәннәр — әтисенең гәүдәсе янында аңа урын калдырмаганнар! Мәгънәви картны саклык белән алып китәләр. Наил тирән аптырашта бер мизгелгә катып кала.

П ә р д ә.

## Мәхмүт Хөсәен

### Ике сонет

●

Урап кайтсам колхоз болынын,
Нигәдер син искә төшәсең.
Тезләреңә тигән толымың
Хәтерләтә авыл чишмәсен.

Йөзең күрәм кичке күкләрнең
Офыкларга иңгән төшендә.
Ялкын белән тулы күкрәгең,
Кояш бар күк аның эчендә.

Сөймәвеңне ачык белсәм дә,
Әйтә алмыйм каршы сүз сиңа.
И юләр дип, миннән көлсәң дә,
Нишләптер син һаман үз миңа.

Күлмәгеңнең кисәң яшелен,
Алга баса янар яшьлегем.

●

Син җырласаң, кайта уйларым
Саф мәхәббәт тулы таңнарга,
Җырла, җаным! Синең моңнарың
Дәрман өсти дөрләп янарга.

Җырда шаулый яшьлек еллары,
Тәүге гыйшкым җырда елмая.
Күзләреңнең сүнмәс нурлары
Йолдыз булып ява дөньяга.

Йөрәгемне гыйшык кылычы
Гомер буе килә телгәләп...
Җырла, бәгырем! Җырның моңлысы
Җанга иңсә — дөнья түгәрәк.

Йөзләремдә — еллар юшкыны,
Күзләремдә — сөю очкыны!..

## Кави Латыйп

### Дүрт җыр

Дүрт җыр белә иде минем авылдашым, полкташым,
Җиңел булсын кабер ташы!..

Беренчесен ул җырлады
туган җирендә, авылыннан чыгып киткәндә.

Икенчесен — көнбатыш Украинада,
Стрый елгасын кичкәндә.

Өченчесен Яссы янында, атакага кергәндә.
Дүртенчесен Болгария җирендә, җан биргәндә...

Хәтеремдә тик шул җыр — юк аның үләсе,
Чөнки аңарда калды фашистның миңа дигән пулясы...

Дүрт җыр белә иде минем авылдашым, полкташым,
Җиңел булсын кабер ташы!..

### Тетрәп киттем...

Тетрәп киттем...
Әтием авазын ишеттем.
Ул кычкырды: «Коммунистлар, алга!»— дип,
окоп аша сикергәндә,
бер взвод солдат ияртеп
атакага кергәндә.
Ә бит ул ятып калган иде
июль таңында
Ржев янында...

Утыз сигез елдан соң
әтиемнең тере авазын ишеттем
Тетрәп киттем, тетрәп киттем...

## Сталинградымны бирмәдем

Мин уңышлардан, җиңүләрдән башламадым...
Ләкин булмый, беттем дип кул күтәрмәдем,—
каләмемне ташламадым.
Чигендем, әмма өметемне өзмәдем,—
эзләдем!

Кәттем — минем өчен дә килер дип
сөенечле хәбәр:
«Ул — солдат, җиңәр!»

Чигендем, ә җиңелмәдем.

Мин беркайчан Сталинградымны бирмәдем!

## Тел өчен

Мин тел өчен разведкага йөрдем,
атакага кердем, үлем күрдем,
сазлыкларда яттым, пулеметтан аттым,
«Фердинанд»лар, «Тигр»ларны ваттым,
бер йотым суга тилмереп,
шәрә таш өстендә аунап яттым —
тел өчен!
Фашистны әсир — «тел» итәр өчен генә түгел,
туган илемне җирдә балкытыр өчен,
туган телемне кояштай калдырыр өчен!

Мин тел өчен, туган ил өчен разведкага йөрдем,
атакага кердем, үлем күрдем...

## Боз өстендә өч песи баласы

Боз өстендә өч песи баласы...
Каттан катка чабып йөри анасы —
балаларын югалткан.
Күзләре дә ачылмаган балаларын йорт хуҗасы
шәһәр күпереннән боз өстенә аткан.

Инде барысы да бушка, юкка,
Ана йөрәге утта.
Нидер сизгәндәй йорт хуҗасына карый
«өзелә» дип үзәгем.
Ә тегесе — яшерә күзләрен...

Төн. Язгы ташу.
Йөрәк ярсый, кинә ачу.

Боз өстендә өч песи баласы.
Йоклый боз йөрәкле йорт хуҗасы.
Ничек аның җанын уятасы?

## Габдрахман Минский

# КАНӘФЕР ЧӘЧӘГЕ

*хикәя*



Тыны кысыла-кысыла күтәрелде ул баскычтан. Кулында канәфер чәчәкләре, башында мең төрле уйшик, күңелендә дулкынлануга да, сабырсызлануга да охшаш хис. Күтәрелә барган саен сулышы ешаеп, адымнары әкренәйде аның. Туфан шигырен үзгәртебрәк әйтсәң — әллә шатлык авыргамы, әкренәйде бу адымнар...

Ә кайчандыр... кайчандыр очып менгәндәй менә иде бит ул бу баскычтан!.. Шул «кайчандыр» артында калган яшьлеге хәтер күгендә уянгандай булды...

...Баскыч басмаларының биш атлыйсын бер атлап өченче катка ашыга, ашыга гына да түгел, ашкына егет. Менә ярым караңгы коридор. Әнә, түшәмдә тәүлек буена янган электр лампасы. Таныш ишек. Ишек янагында таныш төймә. Басарга-басмаска кыймыйча икеләнеп тора егет. Тапшырдык. Баса. Эчтә кыңгырау зыңлый. Җәһәт атлап килгән аяк тавышы якынлаша. Егет сагая. Ул түгел бу! Әйе, әйе, аның аяк тавышы түгел. Егет шуны уйларга да өлгерми, ишек ачыла. Олы яшьтәге мөлаем апа. «Ни йомыш?» дигән сыман карап тора. Егет каушый. Гаепле кеше төсле кызара:

— Исәнмесез! Ни... Гафу итәсез... Ни... Разия кирәк иде...

Разия өйдә юк икән. Дус кызына дәрес әзерләшергә киткән. Егеткә ямансу, тик ул моны сиздермәскә тырыша.

— Калдырып кына китим, алайса,— ди ул һәм, кулындагы чәчәкләрне сузган арада, апаның ирен кырыйларында чагылган кинаяле елмаюны шәйләп ала.

Уйлар... уйлар... Хикмәтле бер тизлектә яшьлегенә алып кайттыгыз, дәртләндереп җибәрдегез кешене! Һәм кеше, баскыч басмаларын җиңел атлап, югары катка менеп җитә...

Таныш коридор. Бик тә таныш ишек. Барысы да якын, барысы да үз аңа монда, тик ишек янагындагы төймә алмашынган да, түшәмнән асылынып торган электр бавы лампасыз калган.

Кеше, сузыла төшеп, бармак очын төймәгә тидерә. Күр инде, эчтәге кыңгырау тавышы да үзгәргән, теге еллардагы кебек зыңгылдамый хәзер, саесканны хәтерләтеп чырылдый. Кинәт туган шик өшетеп җибәрә аны... Әгәр ул булмыйча, башка берәү булып чыкса?! Чү, кемдер йомшак басып килә түгелме соң? Кеше, колагын ишеккә таба суза төшеп, тыңлый. Әйе, килә. Улмы соң бу?

Менә теге йомшак басып килүче ишеккә үк килеп җитә. Гаҗәп!

Житә һәм тынып та кала. Ни дип ачмый соң әле ул? Һич югында «Кем бар?» дип сорарга тиештер бит инде. Кеше тагы бармак очын төймәгә тидерә. Эчтә тагы «саескан чырылдый».

— Кем син??!

Аның тавышы! Кешенең чырае ачылып, яктырып китә.

— Ач, күрерсең.

— Кем син?!

— Мин...

Ишекнең эчке келәсе алынуы ишетелә, аннары чылбыр бавы ычкындырылмыйча гына ачылган ишек ярыгыннан түгәрәк йөзле, киндер сүседәй чәчле, кара кашлы хатын күренә. Бу озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән, хәзер исә пенсиядәге мәгариф ветераны Разия Асылбаева.

Иске танышлар, бер-берсен таный алмыйча сүзсез килеш карап торгач, икесе дә берьюлы телгә килә:

— Исәнме, Разия!

— Зариф!..

— Ялгышмадың.

Ишекнең чылбыр бавы бушатыла. Зариф эчкә уза һәм узышлый:

— Бер күрүгә таныдың тагын,— ди.

Дәшми генә уздырып җибәрергә теләп, Разия Зарифка плащын эләргә урын күрсәтте. Бүлмәгә керделәр.

Разия мондый көтелмәгән очрашу тәэсиреннән әле дә булса арына алмый иде булса кирәк.

— Кая, тагы бер карыйм әле үзегезгә. Сезме соң бу?! Я, хода, булса да булыр икән! Сез шул! Зариф! Нинди язмышлар белән?! Нинди җилләр китерде? Ничек килеп чыгасы иттегез?

— Килдем менә. Юлны яшьтән үк белә идем бит. Әле хәзер дә, баскычтан менешли...

Кинәт сүзе бүленде аның һәм утырган җиреннән, корт чаккандай, атылып торды:

— Һәй... Оныта язганмын бит...

Ашыгып барып, бая плащын элгән җирдә онытып калдырган чәчәкләрне алып килде һәм Разияга сузды:

— Менә бу юлы үз кулыңа тапшырдым дип әйтә алам...

— Оныта язуың гына әйбәт булмаган,— диде Разия һәм өстәп тә куйды,— склерозың көчле, күрәсең...

— Гафу ит, дускай, никадәр генә көчле булмасын, сүзләр безне барыбер шушы канәфер чәчәкләренә китереп җиткерергә тиеш иде. Аннары, онытылырлык булсам, бүген, кырык ел вакыт узуга да карамастан, мин аларны китерә алыр идем мени?

— Кырык ел? Нинди кырык ел?

— Склероз үзеңдә икән әнә. Онытучысы да үзең икәнсең...

— Берни аңламыйм...

— Аңлатырга теләп, мин бу өйгә бер килгән идем инде... Бүгенгедәй канәфер чәчәкләрен тотып. Туры китерә алмадым. Язмаган, күрәсең. Хәтерлисең микән?

— Мин бер нәрсәне яхшы хәтерлим, Зариф. Артыгынча кыюсыз идең син ул елларда.

Зарифны үртәп алды бу сүзләр. Ул җавапсыз калырга теләмәде:

— Безнең буын Мусалар, Матросовлар буыны. Ул елларда, әйе, бүгенге джинс чалбарлылар кыюлыгы җитми иде шул безгә...

Киная иде бу, усал киная. Зарифтагы эчке ярсуны Разия аның тавышыннан ук тотып алды. Әмма сүз көрәштерергә теләмәде. Ләкин бу килешү дигән сүз дә түгел иде әле. Югыйсә, Разия үзе дә игәүләп кыршылган, ялган ямаулар белән «бизәлеп», балаклары кайтарылган чалбарлар кигән, ат ялыдай чәч үстереп йөрүчеләрне «бүгенге яшь-

ләр» дип гомумиләштерүгә баш-аягы белән каршы иде. Шуңадыр да Зарифның авырткан җиренә орынмас өчен, беррәттән үзен дә кушып:

— Картаябыз, Зариф! — диде.

Зарифны тагы үртәделәр, хәтта чәнчеп тә алды бу сүзләр. Кашлары җимерелде аның.

— Картлык куркыныч түгел. Ялгызлык! Менә нәрсә куркыныч! Әнә шул ялгызлык үзе картлыкны китерә дә инде. Мин, Разия, әйтим инде алайса... Шундый ялгызлыкка дучар булудан куркып юлга чыктым. Юлчыга юлдаш кирәк. Ялгызлыктан ялгыз гына котылып булмый. Юлдаш кирәк, ә юлдашка кем эләкте шуны алып булмый. Юлдашның якын күргән кеше булуы шарт. Иске дус булса, тагы да ышанычлырак. Иске дус яңаның икесенә тора диләр бит... Хәзер белдеңме инде бу канәфер чәчәкләренең мәгънәсен...

Мин әйтәсемне әйттем, хәзер сүз синеке дигәнне аңлаткан сыман, Зариф урыныннан торып, балкон ишеге каршысына килеп басты. Шәһәр күренешен күзәткән булып Разияның җавабын көтте. Разия исә көтмәгәндә-уйламаганда борылыш ясаган сүзләрнең очына чыга алмыйча газаплана иде.

«Нигә дәшми ул? Бу юлы да аңлата алмадыммыни? Әллә...» Зариф, артык түзеп тормаска булып, күңелендәгесен ачты да салды:

— Сине эзләп килдем мин бу йортка, Разия.

Разия мондый хәбәрдән башын җуйган кеше төсле аптырап калды һәм нинди җавап бирергә дә белмичә торды.

— Сине эзләп! — дип кабатлады Зариф.

— Соңга калынмаганмы соң, Зариф?! — диде аптыраган Разия.

— Изге эшкә беркайчан да соң түгел.

— Изге эшнең үз вакыты да булгандыр бит...

— Яшьлегебез ут эчендә узды шул безнең...

Ярсый төшеп, әмма горурлык белән әйтелгән бу сүзләр Разияның күңел ярасын кузгаттылар. Ул күтәрелеп стенадагы фотога карады. Фотодан сугыш кырында ятып калган газиз әтисе — гвардия капитаны Асылбаев карап тора иде.

Бүлмәдә шыксыз тынлык урнашты. Зарифка сүзен дәвам итү кирәк иде.

— Бүгенгедәй исемдә, безнең группа студентлары алдагы якшәмбедә Маркиз утравына[1] пикниккә чыгарга сүз куешканнар. Пикниктә син дә катнаша дигәч, шуны ачыклау сылтавы белән, сезгә кереп чыгарга булдым. Дөресен әйткәндә, ул елларда гел сине күрәсе, бергә буласы килеп кенә тора иде. Нишлисең, үзең әйткән кыюлык җитмәгән, күрәсең. Беренче сылтау икенчесен тудырды. Черек күл бакчасы чатындагы чәчәкләр магазинына кердем дә кесә төбендәге барлыюклы көмешләрне җыештырып, өч сабак канәфер чәчәге сатып алдым. Канәфер чәчәге — мәхәббәт билгесе дигәнне ишеткәнем бар иде... Өйдә булмадың... Ул көнне ил өстенә коточкыч хәбәр ябырылды...

Баягы тынлык яңадан өшетеп җибәрде. Мондый тынлыкта үзенә урын таба алмаган Зариф, балкон ишеген ачып, тышка атлады.

Җәйге челләнең алсу-зәңгәр рәшәсенә уралган шәһәр өсте — таш йортлар, Сөембикә манарасы, арырак, көмеш тасмадай сузылып аккан Идел һәм Идел аръягы яшеллекләре җәелеп ята иде.

Разия да, бүлмәдәге ялгызлыктан качкан сыман, кухня ягына узды. Газ кабызды, су тутырып чәйнек куйды, сервант-комодтан, пенсиягә озатканда мәктәп коллективы бүләк иткән һәм моңарчы бер дә тотылмыйча яткан затлы фарфор сервиз чынаякларның бер парын өстәлгә куйды. Шушы атнада гына кайнаткан карлыган вареньесы исенә төш-

[1] Ул елларда Идел уртасындагы комлык.

те һәм... шунда ук онытылды да. Ни дип бу күңел дигәнең балкон ягына тарта соң әле? Балконга чыкты. Берни булмагандй, Зарифка сүз катты:

— Шуннан?

— Шуннан... Алты елдан соң гына кайттым мин сугыштан... Хәер, кайттым, дисәм бигүк туры килмәс... алып кайттылар. Госпитальдән озата килгән берәү бүлмәдә ничек җайлашырга, кирәк нәрсәне ничек табарга, утны ничек кабызырга, суны ничек агызырга, кыскасы, ничек итеп бәрелми-сугылмый хәрәкәт итәргә өйрәтте дә кайтып китте. Рәхмәт яугыры, күршеләр ярдәмендә кара ялгызлык газабын ул хәтле авыр кичермичә яшәп ятканда, көннәрдән бер көнне Одессага мәшһүр Филатов клиникасына чакырып алдылар. Дәвалаучы күз врачы— Филатов шәкертләренең берсе — Борис Петрович Сокол, бер-ике ай дәвалап операциягә әзерләгәч, бер иртәне җайлап кына янымa утырды да, операциягә ризалыгымны сорап, сүз башлады. Яшермим, диде, операция шактый тәвәккәллек сорый, тик, диде ул, бер шарты бар. Әгәр дә шул шартны үти алсагыз, сез йөз проценты белән бәхетле! Йөрәк түзми, беләсе, ишетәсе килә — нинди шарт? Бер түгел, мең шарт дисәләр дә үтәргә әзер мин хәзер! Менә нинди шарт, ди: бүгеннән, хәтта менә шушы, без сөйләшеп утырган минутлардан башлап бары тик бер өмет, бер генә уй-теләк белән янып, бар нәрсәдән кадерле (сөйгәнең булса бик тә әйбәт) кешеңне кабат күрү хыялы белән яшисең, аның рәсемен гел күңелдә саклыйсың. Менә шундый хикмәтле шарт иде бу... Нәкъ шул минутларда, берни күрмәс күзләрем алдында, синең төсең кабынып балкый башлады... Операциянең ничек узуын, ничек урыныма китереп салуларын, тәүлекләр буе уянмастан йоклавым, кыскасы, бернәрсә белмәвем-сизмәвемне сөйләп тормастан, күңелгә кереп калган бер минут турында әйтеп узасым килә. Ничәнче көн булгандыр, хәтерләмим. Колак төбемдә йомшак та, назлы да яңгырап әйтелгән «Хәерле иртә!»не ишетеп уянып китсәм, янымда син утырасың. Әйе, әйе, син. Ышанмыйча, кулларым белән битемне, күземне карасам, күзләрем кат-кат урап бәйләнгән бинт астында... «Хәерле иртәне» әйтүче дежур медсестра икән... Тагы да ике атнадан соң күзләремнең бәйләвен алдылар. Ах, ул минутлар! Ничек кенә сөйләп аңлатырга да сүз тапмам төсле... Дүрт елга сузылган кара төннән соң кояшлы көн яктысын күрү бәхетенә ирештем. Әмма бу «бәхет» күңелем күгендә кабынган зур бәхетнең яртысы гына иде әле...

Шулай итеп, бу юлы инде клиника ишеген бернинди ярдәмсез, үзем, үз кулым белән ачып чыктым. Палата халкы, сестралар, Борис Петрович капкага хәтле озата килеп, мең теләк теләп, мең киңәш биреп саубуллашып калдылар. Баш врач машинасын тәкъдим иткән иде, риза булмадым. Портка кадәрле озын юлны рәхәтләнеп җәяүләп килдем. Әйтергә онытканмын: клиника месткомы миңа Кырым ял йортларының берсенә путевка бирде. Одессадан, «Россия» теплоходына утырып, Ялтага килдем.

Ялтаның коры-йомшак һавасы, «кара» дисәләр дә зәп-зәңгәр диңгезе, каштан, инжир, бадам тирәкләре, кызыну-коенучылар тулы пляжлары, даны дөньяга билгеле Массандра подвалында дистәләрчә ел яткан шараблары, әфлисун, шафталу җимешләре, төрле милләт телләрендә яңгыраган авазлары, музыкалары, якты күрми интеккән фәкыйрьнең күңелен ачып җибәрде.

Күтәренке күңел белән тирә-якны тамаша кылып йөргәндә, күңелле генә бер ялгышу ычкындыра язып калдым. Күңелле дисәм дә, азагы шактый үкенечле булып чыкты.

Ялтаның мәшһүр үсемлекләр дөньясы — Никитский бакчасында экскурсия белән йөргәндә булды бу хәл. Охшаса да охшар икән кеше кешегә! Әйтәм ич, күзләремә ышанмыйча, телсез калдым. Син! Коеп

куйган син. Исемеңне әйтеп кычкырыр идем, телем тибрәнми. Аннары ул группа икенче аллеяга кереп китте...

Разия йөзендә җәелә барган елмаюны күреп, Зариф кисәткән сыман әйтеп куйды:

— Елмаерга ашыкмагызчы әле. Тыңлап бетерегез башта. Шул. Кайттым Ялтадан. Бу юлы инде чәчәкләр тотып түгел, ә Кырым җимешләрен алып сезгә барып чыктым. Тагы өйдә булмадың. Сораша торгач, күршеләрегездән берсе «Алар Ялтада» диде.

Кухня ягыннан ташып кайнаган чәйнек капкачының шыкылдап калтыравы ишетелде. Разия кухняга ашыкты. Зариф аңа иярде.

— Миңа нинди эш кушарсыз икән?

— Хикәяне дәвам итәргә!

— Әллә, мин әйтәм, ноктаны шушында куябызмы? — диде Зариф.— дәвамы, Такташча әйтсәк, шактый күңелсез аның.

Күңелсез узды аларның яшьлекләре. Зарифның да, Разияның да берсенең яшьлеген сугыш йотты, икенчесе гаилә бәхетен күрә алмыйча интекте. Эчкегә сабышкан һәм шуның аркасында һәлак булган ир белән узган еллар нечкә, саф күңеленә тирән яра салды. Яра тора-бара нәфрәткә әйләнгәч, иргә чыкмаска карар итеп, үзен бердәнбер шатлыгы булып калган кызын тәрбияләргә багышлады. Ә инде кызы үсеп җитеп әнисенә онык та табып биргәч, Разияның күңел ярасы бөтенләй онытылды, көннәре шатлыкта узды...

Әлбәттә, шатлыкның да чиге бар. Кеше бөтен гомерен шатлыкта гына кичерә алмый... Шатлыкны көтеп алу, аңа омтылу, яшәвең, хезмәтең, иҗатың белән шуңа ирешү үзе ни тора!

Әнә шундый, көтеп алына торган шатлык белән яши бүген Разия. Дәү әнисенә хат язарлык булган оныгыннан берсе ай башында, икенчесе — ай азагында ике хат көтеп алу шатлыгы белән яши. Бая Зариф звонок биргәндә ишекне ачмый торуы да шуңа бәйләнгән, чөнки почтальон хат китерә торган көн түгел иде әле...

Онытын исенә төшереп алу Разияның кәефен күтәрде.

— Ярый, алайса,— диде ул,— узганнар узганда калсын дибез икән, әйдә, рәхәтләнеп бер сөйләшә-сөйләшә чәй эчик әле...

Зариф ап-ак эскәтер ябылган өстәл янына килде. Тагы нинди ризык куярга белмичә, әле сервант, әле суыткыч тирәсендә әвәрә килгән Разияның җитезлегенә хәйран калып күзәтеп торды Зариф:

— Кайдан алдың әле син ул сүзне, Разия?!

— Нинди сүзне?

— «Картаябыз» дигәнне...

— Ә...,— Разия чак тотылып калды, аннары,— паспорттан алганмындыр... — диде.

Зариф елмайды.

— Кешенең, дускай, йөрәк «паспорты» да бар әле.

— Килешәм... Килешәм...

— Монысы беренче килешү булсын, ди. Әйдә, үзең әйтмешли, рәхәтләнеп бер чәй эчик әле.

Чәйгә утырдылар.

Разия Зарифны кыстый-кыстый сыйларга тотынды. Әле тегесен, әле монысын китереп тезә торды. Табында аңа тагы нәрсәдер җитми төсле күренде.

— Нәрсә белән генә сыйлыйм икән үзеңне, Зариф. Әйт, тагы нәрсә теләр идең?

— Бер генә нәрсә теләр идем мин, Разия. Яшьлегебездә арага кергән сугыш золымы бәхетле картлыгыбызга кагылмасын иде...

Алар озак утырып, сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр. Киңәштеләр, аңлаштылар, килештеләр, табыштылар да шикелле...

.................

## Асия Минһаҗева

# БОЛГАРДА УЙЛАНУЛАР

1

## Катламнар

Катлам-катлам тарих ята
Гасырларга бүленеп...
Халыклар аһ-зары кайта
Күз яшенә эленеп.

Җир үзәгенә җиткәнче
Туфрак өч төстә генә.
Эзләре ерак китмәгән
Яталар өстә генә...

Әйтерсең, шулай тиеш дип,
Табигать үзе бүлгән.
Яңадан хисап алырга
Кемнәр киләсен белгән.

..Дөнья яралган көннәрдә
Тарих ак төстә булган.
Ак көннәр, төннәргә кереп
Ак балчыкка уелган...

Кешелек барлыкка килгәч,
Кызарган дошманлыктан.
Калын катлам булып ауган
Яшәеш кушканлыктан...

Җанга иң якын туфракның
Өстә ятканы кара...
Кинокадрлар шикелле,
Гасырлар үтеп бара.

..Катлам-катлам тарих ята
Бары өч төскә кереп.
Уйландыра. Ак көннәргә
Китәрсең күк йөгереп.

2

## Археологик күзәтү

...Прессланган илләр ята,
Прессланган кешелек.
Кыя булып алларыңа
Төшәр кебек ишелеп.

Өскә калкып чыгалмаган
Шәһәрләр уйга талган.
Җиргә кабат кайтыр өчен,
Музейлар өчен калган.

Юктан бар булып дөньяга
Килгән сөякләр ята.
Кешелек бөртекләп җыйган,
Янган теләкләр кайта.

Яшел бөреләр чыгарган
Табигать җиргә иңгән.
Бу туфракка үзәк өзгеч
Кыска гомерләр сеңгән.

Егерме гасырлык халык —
Мәңгелек башы гына.
Баш идерә баш очына
Куелган ташы гына.

3

## Кайчандыр

Шул ук туфрак, шул ук һава,
Шул кебек урманнары.
Булгандыр булат уракның
Учмалар урганнары.

Шул Идел һаман тынгысыз
Балык күк бәргәләнә.
Шул саллар һаман ага күк
Тезелеп әрдәнәгә.

Шулдыр — һаман «Җитәм!»— диеп
Йөгерешкән кылганнар...
...Шушы җирдә шул кешеләр
Әлләниләр кылганнар.

Бары һәйкәл булып калган
Мәчет һәм тирбәләре...
Әле дә ярый калмаган
Кирәксез тирмәләре!..

...Моңландыра әллә нигә
Күзгә калган гөл исе.
Килә никтер шул аланда
Үкси-үкси елыйсы.

4

## Мәхәббәт

Күптән төсен җуйган инде,
Күптән беткән үзгәреп.
Асыл болгар егетенең
Назлап әйткән сүзләре.

Офыкларга кадәр китеп
Җәелер моңсу томан;
Болгар кызы Айбикәнең
Алсу күлмәге сыман.

Карагайлар арасыннан,
Җитәкләшеп йөгереп,
Тиен баласыдай җитез,
Болан кебек йөгерек.

Бер пар төшеп бара кебек
Иделдәге каекка.
Алар өчен безнең Идел
Күптән инде саеккан.

Чыклы үләндә калган күк
Болгар читек эзләре.
Кай гасырдан төшеп калып,
Яшьлекләрен эзләвем.

...Мең елдан соң килермен күк,
Бетмәс әле үзгәреп
Назлы болгар иркәсенең
Пышылдаган сүзләре.

5

## Иделдә, таң вакытында

Әле алланып Иделдә
Таң гына атып килә.
Мул үләндә ауный-ауный
Бахбайлар гүя көлә!..

Елан-чыбыркы сөйрәгән
Тиен бүрекле малай,
Йөгереп чыгып тирмәдән
«Бик узынмагыз алай!»—
дип куяр кебек сызгырып.

Буй тарткан үсмер кызларның
Йөрәкләрен сыздырып.
Әйләнер тирмә тирәләп,
Атыннан төшми юри,
Әле дә булса сабыем
Моң көйләр көйләп йөри.

Ил-ананың сак карашы
Тартылган җәя кебек.
Кунакчылланып алдыңа
Ашъяулык җәя кебек.

Ничә гасыр үзгәрмәгән
Урман — хәйран, тамаша!
Ауга барырга җыенган
Ирләр кебек шаулаша.

●

Җан яна, кайнап җан яна!..
Сизәм аның талпынганын.
Ташкын лава, кайнар магма кебек
Сүзләр ташар ялкынланып!

Бу — хакыйкать: вакыт җиткәч,
Һәр көч шаша, уза чикне!
...Вулканнарның бар дөньяга
Җан атарлык чагы җитте!

●

Мин үземнең тарихымда
Шундый чорга кереп барам:
Кемнеңдер ачы теленнән
Түгел инде күңел ярам.

Кешеләргә барыр юлны
Инде йөрәк белән ярам —
Шуңа бәлки үз-үземә
Якыная бара арам.

Гомер уртасына туктап,
Хәл алам бер — гүя арам.
...Үзем бер ил, дәүләт булып,
Тарихыма кереп барам.

●

Көннәр үтми, оча гына!
Әллә синең кочагыңа,
Әллә минем кочакка.
Сүрелмәсен, сүрелмәсен,
Утлар өстә учакка син,
Утлар өстә учакка.

Көннәр үтми, йөгерәләр,
Кай арада өлгерәләр,
Кай арада өлгерә?!
Мәхәббәттер, мәхәббәттер
Безнең башны идерә шул,
Күзләр генә тидерә...

Көннәр үтми, кире кайта,
Үткәннәр күңелгә ята,
Һәрберсенең туган җире,
Һәрберсенең иле бар...
Ятка бирмә сөюләрне,
Сатма мине, хәләл яр!
Сөюнең дә иле бар бит,
Сөюнең дә иле бар.

## Булат Сөләйманов

# СЕБЕР УРМАНЫ

### Козоклыкда

Йөрим тайга ханлыгында,
Кояш белән бергәләп.
Йөри яз да безнең белән
Агачларны иркәләп.

Маҗаралар иле бит бу,
Балачак һаман исән.
Аю булып акырыр күк
Ешлыктан аю Хәсән.

Керпе сырты кебек шыткан
Җир сыртында үләннәр.
Алар ләкин йомшак, атлыйм
Гүя яшел keләмнән.

Агачларда яз бүләге —
Киемнәрнең яңасы.
Чүлдә суга сусагандай
Эчәм урман һавасын.

Монда дөнья оҗмахыдыр,
Мең төрле ямь бар монда.
Әкияттәге сыман кошлар,
Исерә җаным моңга.

Шаулый урман. Мәңге шаула!
Карашымны иркәләп...
Козокларны[1] барлап йөрим
Кояш белән бергәләп.

---

[1] Козоклар — чикләвекләр (Себер).

## Җәйге таң

Таң.
Томан.
Мунча кәрә авыл,
Болын. Урман.

Пар диңгезе,
Ун адымнан
Күреп булмый бер-береңне.
Хәтта күрше өйне,
Тик тавышлар гына
Йөзеп килә,
Ишетелә.
Әнә әтәч әйтә азан;
Уян, и җан!
Кырда, ара-тирә
Үгез гудок бирә.
Кешни атлар,
Кыңгыраулар:
чың-чың.
Башка бер аваз юк,
Тып-тын.
Тынлык...
Таң.
Томан.
Җир-чабыштан
Кайткан сыман.

●

Кара төннәргә күңел күнекми —
Күңелгә мәңге яктылык кирәк.
Яңа шигырьләр җиткәнче туып
Яна тик бер ут,— ул минем йөрәк.

Таң аткач алар сәфәр чыгарлар,
Юллары авыр, юллары ерак.
Шигырьләремә бердәнбер терәк,
Әлеге дә шул,— ул минем йөрәк.

●

Һәрбер агач — яшел болыт,
Болытлап куйган урман.
Яшел болытлар астында
Яшьлегем — чая юргам.

Һәрбер яфрак — тере бер җан
Яшьлегем урманында.
Ул да, мин дә — бөтен дөнья
Мәхәббәт буранында.

И. Бабель

# МОПАССАН

*Хикәя*

*Исаак Эммануилович Бабель — рус совет әдәбиятында чагыштырмача кыска гына вакытта күренеп киткән язучы, ләкин бу үзенчә күренеп китү булды. Эзләп карыйк әдәбияттан, аныңча дип әйтмик, аңарга якынрак торган берәр стильне. Юк, таба алмыйбыз. Калдырган мирасы да күп түгел, югыйсә. Үзе үлгәннән соң, «Конармия», «Одесса хикәяләре» циклларын да кертеп, «Шәфәкъ», «Мария» исемле пьесаларын, истәлекләрен һәм хатларын да шунда туплап чыгарылган бер томлык — бөтенесе менә шул. Шунда Бабельның осталыгы, шунда көлә һәм яхшы кешеләрне яклап елый белүе.*

*И. Бабель — минем әдәби кумирларымның берсе. Кай яклары, нәрсәсе өчен яратам мин аны? Стенага терәп сорагыз, тулы һәм әтрафлы җавап бирә алмамдыр. Тыгыз сюжетлы кыска хикәяләре һәм гомумән, кыска яза белүе өчен дәдер, сүзнең кадерен һәм урынын белеп әйтә белү дә бар анда, ир белән хатын арасындагы җенси мөнәсәбәтләрне артык шәрәләндермичә, ләкин җелегеңә үткәрә торган итеп ачып бирү дә, очкын чәчеп торучы юмор һәм кешелек трагедиясе дә...*

*Мин аның хикәяләрен татарчага тәрҗемә итмәкче булып, беренче мәртәбә «тешләп» карадым, юк, тешем үтмәде. Әлбәттә, «аударырга» булыр иде, ләкин без көләч Бабельне түгел, имгәнеп, кәгазьдән укучы күңеленә күчә алмыйча, сыкранып ятучы Бабельны гына күрер идек. Мин үз кумирыма хыянәт итәргә теләмәдем.*

*Ниһаять... дөнья классигы Мопассан белән икесе бергә кочаклашып дөнья гизгән чакларында мин аларны тоттым. Әлбәттә, Мопассан да, Бабель да бөтен тулылыкларында миңа бирелгәннәрдер дип уйламыйм. Мин Мопассанны да, Бабельны да яратам, ләкин алардан да элегрәк мин үземнең туган телемне яратам. Бу зур художникларның үзенчәлекләрен саклыйм дип, мин туган телемне рәнҗетүгә шулай ук бармадым. Шунлыктан, кай урыннарда француз Мопассан, һәм совет язучысы И. Бабель татарчарак та сөйләп җибәрәләр икән, укучылар гаеп итмәсеннәр, алар татар язучысы Фатих Хөсни кулы астыннан үткән мопассаннар, бабельләр.*

Тәрҗемәчедән

Уналтынчы елның кышында мин ялган паспорт һәм бер тиен акчасыз килеш Петербургта кысылып калдым. Рус әдәбияты укытучысы Алексей Казанцев мине үзе янына сыендырды. Ул Пескида, утәли каткан, сасы истән сөрсегән, соры бер урамда тора иде. Юк кына жалованиесына азмы-күпме өстәмә булсын өченгә ул тагын испанчадан тәрҗемәләр ясау белән дә шөгыльләнә — ул чагында Балеско Ибаньес дигән испан язучысы шөһрәт казана башлаган иде.

Казанцевның үзенең Испаниядә булганы да, хәтта үтеп тә киткәне юк, әмма ул илгә аның мәхәббәте ташып тора — ул Испаниядагы барлык замокларны, бакчаларны һәм елгаларны белә иде. Миңа иш буларак, Казанцевка дөрес юлдан кысрыклап чыгарылган күп кенә бүтән кешеләр дә сыйганнар иде. Без ярым ач яшибез, чыкса, әллә нидә бер бульварный газеталарда вак кына хәрефләр белән безнең хәбәрләребез басылып чыга — тамса, шулар өчен азмы-күпме тамгандыр.

Иртәләрен мин моргларда һәм полиция участокларында кайнашам. Казанцев үзе безнең барыбызга караганда да бәхетлерәк иде, чөнки аның туган иле — Испаниясы бар.

Ноябрь аенда миңа да бәхет чак кына елмая язды — Обухов заводында конторщиклык вазифасы барлыгы беленде — ярамаслык эш түгел, өстәвенә хәрби хезмәттән коткара торган. Мин бу конторщиклык эшеннән баш тарттым. Мин ул чагында — егерме генә яшьтә булсам да — үземә-үзем ант биреп өлгергән идем инде: ач торсам торырмын, төрмә икән төрмә, читтә-чатта кагылып-сугылып йөрергә риза, әмма да ләкин конторка өстәле артында көнгә унар сәгать какланып утырасым юк. Бу антны мин әллә ни егетлек дип уйламыйм, ләкин мин ул антымны бозмадым һәм һәм бозмаячакмында. Ата-бабаларыбыздан калган зирәклек утыра иде минем башта: без хезмәт белән ләззәтләнергә, туры килсә сугышырга һәм сөю-сәгадәт өченгә дөньяга туганбыз, әйе без шуның өченгә туганбыз, башка берни өченгә дә түгел.

Минем бу яңгыравык сүзләрне ишетеп, Казанцевның чәч дип аталуы да мөмкин булган кыска сары төкләре үрә басты, аның күз карашындагы куркыну соклану белән аралашкан иде.

Рождество бәйрәме көннәрендә безнең өскә дә бәхет ишелә язып калды. Присяжный поверенный Бендерский, бер үк вакытта «Альциона» нәшрияты хуҗасы, Мопассанның әсәрләр җыентыгын чыгарырга булган. Мопассанны тәрҗемә итү эшенә присяжныйның хатыны Раиса ханым керешкән. Аның эч пошканнан тотынган бу эшеннән, әлбәттә, берни дә чыкмаган. Испанчадан тәрҗемәләре белән мәгълүм булган Казанцевтан, Раиса Михайловнага ярдәмгә килердәй берәр кешене белмисезме, дип сораганнар. Казанцев минем исемне атаган.

Икенче көнне, өстемә кеше пиджагы киеп, мин Бендерскийларга киттем. Алар Невский урамы белән Мойка чатында, Финляндия гранитыннан, фасадына ал колонналар чыгарып, бойницалар һәм таш герблар калдырып төзелгән йортта яшиләр иде. Нәсел-ырусыз банкирлар, муеннарындагы тәреләрен югалткан имансызлар, аның каравы, хәрби поставкаларда баеп тәннәрен май баскан комсыз бәндәләр сугыш алды елларында Петербургта шөкәтсез зур, ялган галибанәлек дәгъва кылучы күп кенә шундый замоклар салдырырга өлгергәннәр иде.

Баскычтан ук хәтфә палас-юл салынган, баскыч чатларындагы мәйданчыкларда тырпаешып баскан плющ аюлар, аларның киерелгән авызларындагы хрусталь колбаларда утлар янып тора.

Бендерскийлар өченче катта торалар икән. Башына күпертмәле калфак кигән, түше дә яхшы ук күперенке горничная ишек ачты. Ул мине борынгы славян стилендә бизәлгән кунак бүлмәсенә үткәрде — стеналарда художник Рерих иҗаты — зәңгәр картиналар, хан заманындагы ташлар, әкәмәт җанварлар. Почмаклардагы махсус мөешләрдә — иконалар, алары да борынгы, затлы итеп эшләнгән. Түшле горничная бүлмәдә тантаналы гына атлап йөри — төз гәүдәле, күзләре ерактан аерып бетерми, тәкәбберлеге йөзенә чыккан. Әллә кайдан сизелеп тора — теге якка бик хирыс нәрсә булса кирәк. Кызый болай әкрен генә атлап йөри, ләкин мин шулай да уйларга өлгердем; ятканда ул өлгер кыланадыр.

Ишеккә эленгән эре бизәкле чаршау-пәрдә искәрмәстән генә калтыранып куйды, кунак бүлмәсенә — бусы да шулай ук бик түшле нәмәстә — күз кабакларын ал төскә буяган кара чәчле ханым килеп керде. Бу Бендерская үзе иде, һәм аның йөреше-торышыннан безнең бу якларга Киев, Полтава шәһәрләреннән — каштаннарга һәм акацияләргә күмелеп утырган тук шәһәрләрдән килеп чыккан симез еврейкалар токымыннан икәнлеген шәйләү әллә ни зирәклек сорамый иде. Эш йөртә белүче ирләре ансат тапкан акчаны бу ханымнар шундый ук ансатлык белән корсакларындагы, җилкәләрендәге һәм иңбашларындагы алсу майга әвереддерергә остарып беткәннәр. Аларның йокымсырау катнаш нәфислек белән өртелгән көлемсерәүләре шул тирәдә чуалучы гарнизон офицерларын акылдан шаштыра, имеш.

— Мопассан — минем тормышымның бердәнбер куанычы,— диде ханым, минем алда беренче буларак сүз башлап. Һәм тыгыз балтырларының дерелдәвен ничек тә сиздермәскә тырышып, бүлмәдән чыгып китте дә «Мисс Гарриэт» хикәясенең үзе ясаган тәрҗемәсен күтәреп әйләнеп керде. Аның тәрҗемәсендә Мопассанның иркен, дәртле сулышының, ичмасам, эзе дә калмаган — Бендерская ялыктыргыч дөрес язган,

дөрес һәм жансыз, дөрес һәм саксыз — элек тә еврейлар рус телендә шулай язалар иде.

Мин кульязманы үзем белән өйгә алып киттем һәм Казанцевның мансардасына — йоклап ятучы кешеләр арасында — төннең төн буена икенче берәү тәрҗемәсендәге чытырманлыкларны кырып-кисеп үземә юл салдым. Бер караганда, бу алай күңелсез эш тә түгел икән. Җөмлә дөньяга бер ук вакытта яхшы да, яман да булып туа, сер — аны кирәгенчә бора белүдә, сизелер-сизелмәс кенә бора белүдә. Бора торган ачкыч һәр вакыт синең учыңда булсын һәм синең жылыныңнан жылынып торсын. Аны тик бер генә кат борырга кирәк, ике кат түгел.

Төзәтелгән кульязманы иртәгесен мин Бендерскийларга үзем алып киттем. Раиса Мопассанга булган мәхәббәте турында әйткәндә ялганламаган икән. Безнең бергәләп төзәткән кульязманы укыганда, кулларын ике якка төшереп утырган хәлдә, ул шөйлә дә хәрәкәтсез калды. Ханымның атластай куллары һавада асылынып тора, маңгае агарынган, күкрәкләре арасындагы серле бушлыкта левчигының нәфис челтәре сизелер-сизелмәс кенә кузгалып-калтыранып куйгалый.

— Ходавәндә, сез моны ничек болай эшли алдыгыз? — диде ул, гажәпләнүеннән әле һаман арына алмыйча.

Шунда мин аңарга стиль турында, аерым сүзләрдән торган армия турында, гаскәрләрнең барлык төрләре дә хәрәкәткә китерелгән сүзләр армиясе турында сөйләдем. Кеше жанына үз вакытында һәм үз урынына куелган ноктадан да нык үтеп керә алучы бернинди тимер дә юк, дидем мин. Ул мине, башын бер якка сала биребрәк, буялган иреннәренең ачылып калганлыгын сизәргә дә өлгермичә тыңлап торды. Ике якка ачылган чәч юлы лакланып катырылган, чем-кара чәчләрендә кояш нурлары уйный, тыгыз балтырлы аяклары хәтфә паласлар өстенә ташланган иде.

Җенси комсызлыгы күзенә бәреп чыккан карашын читкәрәк алырга тырышып, хадимә хатын безгә поднос белән иртәнге аш кертте. Петербург кояшының салкын пыяладай шыксыз нурлары идәнгә төшәлгән палас жыерчыкларында тын гына качыш-качыш уйный, ә үзләре тамчы да жылытмый иде. Безнең артыбыздагы киштәләрдә Мопассанның егерме тугыз томы тезелгән, ул китапларның сафиян төпләрендә әлеге шул сүнми дә, жылытмый да торган Петербург кояшы уйнапмы уйный.

Аннары безгә зәңгәр чынаякларда кофе китерделәр һәм без «Идиллия»не тәрҗемәләргә тотындык. Сөтен кая куярга белмәгән юан хатынны имеп тамагын туйдыручы плотник егет турындагы хикәяне күпләр беләләр булыр. Бу хәл Ниццадан Марсельгә баручы поездда, эссе чиллә көнендә, розалар илендә, розалар пайтәхетендә, чәчәк плантацияләре сузылып, диңгез ярына хәтле төшеп үсә торган жирдә була.

Мин ул көнне Бендерскийлардан егерме биш сум аванс алып киттем. Безнең Пескидагы коммунябыз ул кичне дөм исерек хәлдә калды. Без ярмаланып торган кыйммәтле кара икраны кашыклап ашадык һәм аны ливерный колбаса белән кудырдык. Тәмам исергәннән соң мин Толстойны сүгә башладым.

— Коты чыкты аның, сезнең ул графыгызның, картлыктан калтырап төште. Аның иманы — курку. Картаюдан, суыктан куркып, сезнең ул графыгыз иманыннан үзенә фуфайка тектереп киде.

— Ә шуннан нәрсә? — дип, үзенең кош борнына охшаган борнын миңа таба сузып, бәйләнергә тотынды Казанцев.

Бәхәсләшеп аргач, без үзебезгә атап әзерләнгән урын-жирләребезне бер читтә калдырып, ялангач идәнгә ятып йоклап киткәнбез. Мин төшемдә Катяны күрдем — кырык яшендәге прачка, безнең аста тора, иртәләрен без аның кухнясыннан кайнаган су төшеп ала торган идек. Мин ул Катяның йөзенә дә рәтләп караганым юк, ә төнлә — йокы аралаш — хода белсен, нишләп кенә бетмәдек. Без үбешә-үбешә бер-беребезне соңгы чиккә җиткереп җәфаладык.

Иртәгесен барыбер, мин аның кухнясына кайнаган суга дип төшмичә булдыра

алмадым. Мине шыңгән-шәлперәйгән, башына аркылы да торкылы итеп шәл ураган, шәл астыннан аксыл-көрән чәч учмалары тырпаешкан һәм, куллары ябыгып, асылынып төшкән хатын каршылады.

Шул вакыттан бирле мин һәр көнне иртәнге ашны Бендерскаяларда ашый башладым. Безнең Казанцевлардагы чарлагыбызда тимер мич пәйда булды, селедка һәм шоколад күренгәли башлады. Ике көнгә бер мине Раиса ханым, җиңел фаэтонга утыртып, күңел ача торган урыннарга — атауларга алып китә. Чыдамлыгым җитмәде, хәтта бер көнне мин аңарга үземнең балачагым турында да сөйләп ташладым. Хикәям күңелсез чыкты, бу яктан хәтта үземне дә гаҗәпләндерде.

Мин Раисаның ире белән дә таныштым — чәче коелган, яланбаш, соргылт йөзле, очып китәргә торган кебек өскә очланып килгән яһүд иде бер. Аның Распутин белән әшнәлеге турында да сүзләр йөри иде. Хәрби поставкалардан яуган табышлары аңарга үтә дә тәвәккәл кеше кыяфәте бирә, күзләрендә ут уйный, әйләнә-тирәдәге чынбарлык аның өчен чүп кенәдер кебек. Ирен икенче бераүләр белән таныштырганда Раиса ханымның уңайсызлануы төсенә чыга иде. Яшьлегем аркасында мин моны бер атна соңга калыбрак шәйләдем, әлбәттә, элегрәк ачык авыз булмаска кирәк булгандыр.

Яңа елдан соң Раиса янына Киевтан ике кыз туганы килеп төште. Мин Раисага «Мәхәббәттә аңлашу» хикәясенең тәрҗемәсен китергән идем. Ләкин бу килүемдә аның ялгызын гына туры китерә алмадым, көн кичкә авышып, инде чыгып барганда, кунак бүлмәсеннән кичке аш өстәле янында утыручы кыз-хатыннарның бияләрчә кешнәшеп көлешүләре, ир-атның кирәгеннән артык кычкырып гөрләшүе ишетелеп калды. Шулай инде ул — үз традицияләре булмаган бай йортларда һәр вакыт шулай шау-гөр килеп ашыйлар.

Соңыннанрак — белепме, белмичәме — Раиса да күренде, ул шәрә аркалы бию күлмәгеннән, ялтыравык туфлиләрдә — аңарга ничектер — җайсыз — авыш-түеш атлый иде.

— Мин исерекмен, күгәрченем,— дип сөйләнә-сөйләнә ул миңа күрешергә кулын сузды, куллары, түшләре ак алтыннан коелган беләзек-йөзек һәм зәбәрҗәт брошкалардан күмелгән иде. Тәне, музыка астында түшәмгә таба сузыла барган елан тәне кебек, тибрәлә иде. Ясап көдрәләткән башын бер чайкап куйды һәм шундук борынгы рус резьбасы белән бизәлгән креслога авып төште, пудраланган шәрә аркасында хөҗерләнеп үпкән теш эзләре беленә иде.

Стенаның теге ягыннан тагын шулай шаулашып көлешкән хатын-кыз тавышлары ишетелде. Ул да түгел, ашханә бүлмәсеннән Раисаның беленер-беленмәс кенә мыеклы сеңелләре килеп чыкты — алары да, Раиса кебек үк, озын буйлы, ярау ханымнар иде. Әлбәттә, түшләре алга ук бүлтәйгән, куе кара чәчләре күперенеп тора иде. Икесе дә узләренең хәләл җефетләре Бендерскийларда кияүдәләр икән. Алгы бүлмә бәйләнешсез яңгыраган хатын-кыз шау-шуыннан, уен-көлкедән, тәмам тулышып җиткән өлгер хатыннар бәхетеннән бер ара күмелеп калды. Ирләре хатыннарын шундук котиковый монтолар, мамык Оренбург шәлләре белән төреп алдылар, аякларына җылы ботинкаларын кидерделәр, чыгуга кар бөртекләре куныл та өлгергән шәлләре астыннан бары тик яныл торган алсу битләре, сөйкемле күзләре генә күренә иде. Шулай бер шаулашып алдылар да, артлы чаналарга төялешеп, театрга киттеләр, театрда ул кичне Шаляпин катнашында «Юдифь»ны уйныйсылар икән.

— Минем эшлисем килә башлады,— дигән булды Раиса, ялангач кулларын миңа таба сузып,— без болай да бер атна вакытыбызны әрәм уздырдык.

Ул ашханә бүлмәсеннән бер шешә мускат һәм ике бокал алып килде. Күкрәкләре ефәк күлмәгенең бушлыгында хәр генә дерелдәп, ефәк аларны йомшак кына иркәли кебек иде.

— Искә алып үтик,— дип шаярткан булды ханым, мускатны бокалларга агызганда,— мең сигез йөз сиксән өченче елгы. Белеп алса, моның өчен ирем мине үтерәчәк.

Мең сигез йөз сиксән өченче елгы мускат моңарчы минем авызга да тигән нәрсә

түгел, бер тәмен татыгач, бер-бер артлы өч бокал эчтем. Ул өч бокал мине шундук, зәңгәр нурлар уйный, музыка яңгырый торган тыкрыкларга алып китте.

— Мин исердем, күгәрченем... нәрсә әле анда безнең бүген?

— Безнең бүген «Франция кояшы»

— Франция кояшы икән — Франция кояшы. Хикәянең төп герое да шул ич. Франция кояшының эрегән нурлары җирән Селестаның битендәге вак-вак сипкелләргә әверелгән. Кояш үтәли кисеп төшә торган нурлары белән, шундук хәмерен һәм алма согын да кушып, кучер Политның табактай битен шомартып ташлаган. Атнага ике тапкыр Селеста Политның дилижансына утырып, шәһәр базарында сату өчен каймак, күкәй һәм тавык алып бара. Утыртып алып барганы өчен Селеста ундүрт су акча түли — ун су үзе өчен, дүрт су товарлары тутырылган кәрзиннәре өчен. Һәм барганы саен кучер Полит, күзләрен мутларча кыскалап, җирән Селестадан: «Кайчан соң без синең белән бер шаярып алырбыз икән, гүзәлкәем», дип сорап куя. «Бу нәрсә дигән сүз, Полит әфәнде?» дип кайтарып сорый тегесе. Утырган җиреннән сикергәләп, Полит аңлатып бирә: «Шаярып алу дигән сүз — шаярып алу дигән сүз ул, шайтан алгыры... егет белән кыз — икәүдән икәү генә, музыкан да кирәк түгел», «Мин андый шаяруларны бер дә яратмыйм шул, Полит әфәнде», ди тегесе һәм, Политның астында кысылып калган юбка итәген үзенә табарак тартып, чак кына күченебрәк утыра.

Ә Полит, шайтан коткысы, үзенең шаркылдап көлүен һәм ара-тирә мәгънәле йөткергәләвен белә — ягъни мәсәлән, «кайчан соң без синең белән бер шаярып карарбыз икән?». Ә үзенең битеннән кирпеч һәм хәмер кызыллыгындагы эре-эре тир тамчылары тәгәри.

Мин теге борыннан сакланган мускатны тагын бер бокал салдырып эчтем. Раиса минем белән чәкәштергән булды. Ул арада бүлмә аша теге мәгълүмебез — женси азгынлыгы күзләренә бәреп чыккан горничная узып китте.

Инде килеп теге ач күзле Политны алып карыйк. Бергә йөргән шул ике ел дәвамында Селеста, бичара, кучер Политка кырык сигез франк артык түли. Бу бит иллегә ике генә франк тулмаган дигән сүз.

Икенче елның азагына таба, дилижанста икәү генә барганда, юлга чыгу алдыннан чак кына хәмер дә тоткан нахал Полит, үзенең гадәттәге йөгәнсезлеген яшерә алмыйча сорый: «Әгәр бүген бер шаярып карасак, Селеста туташ?». Тегесе, күзләрен аскарак яшерә төшеп, әйтә: «Мин тулысынча сезнең карамакта, Полит әфәнде».

Раиса хахылдап өстәлгә йөзе белән каплана... Дилижанска ак ат жигелгән. Картаң барудан иреннәре аллана башлаган ат, ашыктыручы булмаганлыктан файдаланып, әкрен генә атлый бирә. Франция җиренең шаян кояшы, козырегы төшерелгән дилижансны дөньядан аерып, үз кочагына төреп ала...

Егет белән кыз икәүдән икәү генә, музыканың аларга хәзер пычагыма да кирәге юк.

Раиса миңа бокал сузды — бу алтынчысы.

— Картлач Мопассан өчен бусы.

— Үзебез өчен дә бер тырышып карамаскамы икән, гүзәлкәем?

Мин Раисага сузылдым һәм аның иреннәреннән үбеп алдым. Иреннәре дерелдәп калды, чак кына күпереп киткәндәй булды.

— Сез шук кына икәнсез,— диде Раиса һәм арткарак чигенде. Ялангач беләкләрен икесен ике якка җәеп, стенага барып сөялде. Беләкләрендә һәм иңбашларында алсу таплар пәйда булган иде. Кулларын җәйдереп тәрегә кадакланган аллалар арасыннан иң кызыклы тәре, бусы, ихтимал, иң котырткычы булгандыр.

— Сез утырып торыгыз, Полит әфәнде,— диде ул миңа, яшел плюш белән тышланып, чак кына авышрак итеп куелган кәнәфигә күрсәтеп. Кәнәфи бизәп һәм челтәрләп ясалган йомшак такталардан гына торса да, ул якка таба аякларым тартмый иде. Ханым әйткәч, әвеш-тәвешрәк атлап булса да бармый булдыра алмадым. Төн минем сусаган яшьлегем каршысына мең сигез йөз сиксән өченче елгы бер шешә мускат һәм Мопассанның даһилык, мәрхәмәт, дәрт белән сугарылган егерме тугыз томын китереп куйган иде. Мин аңышыр-аңышмас сикереп кузгалганмын, аяк астындагы утыргычны аударганмын, шул уңайдан китап киштәләренең берничә шүрлеген дә коеп төшергәнмен. Идәндәге келәмгә Мопассанның егерме тугыз томы да бер-

бер артлы коелып төште, китапларның кайберләре ачылып-ачылып калган иде... Һәм минем язмышымның арык тулпары шулар өстеннән әкрен-әкрен генә атлап китеп тә барды.

— Сез кызык кына кеше икәнсез болай,— дип тыны кысылган хәлдә, инрәп куйды Раиса.

Мойкадагы ул гранит кысалы йорттан мин төнге сәгать уникенчедә — Раисаның кыз туганнары һәм ире театрдан кайтып җиткәнче тизрәк киту ягын карадым. Мин инде айный төшкән һәм, әгәр теләсәм, гел бер генә тактага басып та рәхәтләнеп атлый алган булыр идем, ләкин миңа әле бер, әле икенче якка авышкалап һәм үзем уйлап чыгарган ниндидер билгесез телдә җыр мыгырданып, чайкала-чайкала кайту, әйтеп бетергесез күңеллерәк иде...

Мин өйгә кайтып кергәндә Казанцев, ябык сыйракларын киез итеккә тутырып, утырган җиреннән рәхәтләнеп йокыга киткән иде. Башында ничек кирәк алай саклаunion калган сирәк төкләре үрә торып баскан, ул мич буенда, җылыда, башын 1624 елда басылган «Дон-Кихот» өстенә куеп йоклаган, китапның титул битендә герцог де Браглиога багышлануы турында язылган юлларны да укырга мөмкин иде. Мин Казанцевны ничек тә уятмаска тырышып, бер кырыйдагы урынга килеп яттым, лампаны үземә табарак китердем һәм Эдуард де Мениальның «Гюи де Мопассанның тормышы һәм иҗаты» дигән китабын укый башладым. Казанцевның иреннәре йокы аралаш чапылдап куйды, башы аскарак шуышты.

Эдуард де Мениальны укып, мин ул төнне Мопассанның 1850 нче елда Нормандия морзасы һәм Лаура де Пуатевен — язучы Флоберның туганнан туган кыз кардәше токымыннан икәнлеген белдем. Егерме биш яшендә ул нәселдән килгән сифилис авыруының беренче һөҗүмен татый. Тормыш яратуы һәм шат күңеллелеге әлеге авыруга нык каршылык күрсәтә. Элек ул баш авыртуы һәм вакыт-вакыт килеп бәрә торган эч пошу бәлаләре кичерә, соңрак аның алдына сукырая башлау куркынычы килеп баса. Күрүе начарая. Тагын да соңрак аңарда юктан гына да шикләнү, кешеләр белән аралашмаска тырышу, хәтта кешеләргә урынлы-урынсыз бөһтан бәләләр ягу өянәге башлана. Боларга каршы ул ярсып көрәшә, яхтага утырып Урта диңгездә сәяхәтләрдә йөреп карый. Туниска чаба, Мароккода була, Урта Африка илләренә барып чыга һәм шул ук вакытта бер туктаусыз язуын белә. Даңга тәмам ирешкәннән соң, кырыгынчы яшендә ул үзенә-үзе пычак сала, күп кенә канын коя, ләкин исән кала. Ниһаять, аны акылсызлар йортына ябалар, ул анда дүрт аякланып йөри. Аның хәсрәт белән тулы язмаларының соңгы битендә мондый юллар бар: «Мопассан әфәндегез хайванга әверелде». Кырык ике яшендә әдип дөнья куя, бу вакытта әле аның әнисе дә исән була.

Мин Мопассан турындагы ул китапны төн йокламыйча ахырынача укып чыктым. Томан тәрәзәм каршына ук килеп тыгылган һәм мине галәмнән яшергән иде. Кинәт йөрәгем сулкылдап сызлап куйды, киләчәкнең хакыйкатен тою, ниһаять, миңа да килеп кагылды.

**Фатих ХӨСНИ** тәрҗемәсе.

Мәгъсүм Гәрәев

# ГОРУРЛЫК

ОЧЕРК



...Бодай кыры. Кичә иртән монда көзге җил уйный иде. Ул бодай башакларының алтын дулкынын ярларыннан чыгып китәрдәй диңгез шикелле ярсыта. Гүя башаклар яңгыр һөҗүменә чыдый алмыйча, механизаторларга зарлана. Минсалихның колагына аларның ялварулы тавышы ишетелә сыман: «Безне бу миһербансыз яңгырдан йолып калырга ашыгыгыз сана...»

Механизаторлар игенне кишәрлекләргә салып бетерергә өлгермиләр, чиләкләп яңгыр коярга тотына. Бер сәгать үтә, аннары бер тәүлек... Офыкта кояш балкый. Быел ул — басуларда сирәк кунак. Кырларны җылы нурлары белән күп иркәләми. Аның шулай күренгәләп алуы да комбайнчылар күңелендә алтын бөртекләрне яңгыр әсирлегеннән алып бетерүгә өмет чаткылары кабыза. Җир бераз кипши төшүгә, йөзләрчә ат көчен үзенә туплаган моторлар, бөтен кырны шаулатып эш башлый. Кыр кораблары алтын диңгездә йөзә. Көндәгечә, звено җитәкчесе Минсалих Хуҗиев комбайны беренче булып кузгала. Аның артыннан Николай Батманов, Виктор Муравцев, Иван Есипов агрегатлары китә. Кичкә кадәр әлеге алтын диңгездә салам кибәннәре генә өелеп кала.

Кырлар бушагач, игенче күңелен моңсулык биләп алгандай була. Ул беренче карашка гына шулай. Табигать көйсезлеге белән көрәштә җиңеп чыккан Кешенең йөзе моңсу түгел, горур була ул. Механизаторлар чиксез шат. Бу кырның соңга калып җыелган гектарлары аларның ел буе түккән хезмәтен 24—25 центнер гөрәбәдәй бөртек белән бүләкли. Яңгырлы ел шартларында чын мәгънәсендәге зур хезмәт батырлыгы.

Мәшәкатьле дә иде соң ул яңгырлы урып-җыю. Аны тәмамлап, кыр кораблары машина-трактор утарына алып кайткач та игенчеләр шул киеренке көннәрне һәм төннәрне кат-кат хәтер йомгагыннан сүтәләр. Уракка төшәр алдыннан «Ленинский путь» колхозы механизаторлары бөтен Лениногорск районы игенчеләренә мөрәҗәгать итәләр: урып-җыюны 17-18 көндә тәмамларга! Мул булырга вәгъдә итеп, яңа уңыш өлгерә. Колхозның барлык 15 урып-җыю транспорт агрегаты ашлык язмышы өчен көрәшкә чыга. Идарәгә беренче көннәрдә сөенечле хәбәрләр агыла. Танылган комбайнчылар Минсалих Хуҗиев, Александр Лобанов, Николай Фадин, Николай Батманов бункердан тәүлегенә 500-600 центнер ашлык бушаталар. Эш фронты киң җәелергә өлгерми, басуларны кара-кучкыл болытлар күләгәсе каплый. Колхоз механизаторларының чиктән тыш тырышлыклары белән ашлык җыеп алына. Елына күрә уңышы да начар булмый — һәр гектардан 19 центнерга якын. Хуҗалык унынчы бишьеллыкта дәүләткә ашлык сату планын арттырып үти.

Соңгы кишәрлекләрне суктырган көнне бераү дә өенә кайтып китәргә ашыкмый. Кыр корабларын басу читенә чыгарып куялар. Колхоз председателе СССР Верховный Советы депутаты Вениамин Георгиевич Арютин комбайнчыларны котлап, кулларын кыса. Минсалих председательгә пөхтәләп бәйләнгән зур бер көлтә суза.

— Быелгы авыр елда җинүебез истәлеге булсын...

Вениамин Георгиевич көлтәне күкрәгенә кыса. Алтын бөртекләрнең йөрәк тибешен, сулышын тыңлый сыман. Сак кына итеп көлтәдән озын кәүсәсе белән берәр башакны суырып ала, комбайнчыларга тоттыра.

— Тук һәм авыр башакны тотып торучы кәүсә нинди нечкә генә, — ди председатель.—Шулай да ул — бөтен кешелек дөньясының терәге. Кайдан килә соң аңа шундый илаһи көч-куәт?

Урак батырлары уйга кала. Минсалихның күз алдына туган ягы Зәй районы басулары килеп баса. 1941 елның июнь башында әтисе Хуҗиәхмәт, ике улы Гаяз белән Минсалихны ияртеп, Аксар авылы кырларына алып чыккан иде. Нәкъ менә бүген Вениамин Георгиевич биргән кәүсәне кулына алган кебек, әтисе тоттырган яшел башакларны чәчәк бәйләме төсле, зур бер учма итеп җыйган иде Минсалих. Ата-бабалары кебек, Хуҗиәхмәт абый да кендеге туган туфрагына, туган җиренә береккән кеше иде. Кулларында игенче һөнәренә мәхәббәт тәрбияләү өчен басулар буйлап йөрергә, аларга икмәк турында матур-матур хикәятләр сөйләргә ярата иде.

— Менә шундый тук башаклар үстерү өчен Кеше, киң күңелле, олы җанлы Кеше, бөртекләрне учларында иркәләп, йомшак туфракка сала. Эшләгән кешегә икмәк юмарт ул. Кеше җирнең җелектәй тәмле суын, кояш нурларының җылысын һәм көмеш яңгыр тамчыларының саф дымы белән тупланып җыйган баһадир көчен аннан ала.

Сталинград җирендә мәңге йокыга талган әтисенең сүзләре әле бүген дә булса Минсалихның колагында яңгырап тора.

Мин Хуҗиевның беренче зур бүләк алган тантаналы көнен хәтерлим. Аңа III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены тапшырдылар. Бүләкне кабул иткәндә Минсалих күп нәрсә турында уйланды. Хезмәттә дә, сугыштагы төсле, батырлык өчен такыр юллар юк. Хезмәт Даны орденын фронтта солдат алган сугышчан бүләк — Дан ордены белән очраклы рәвештә генә чагыштырмыйлар. Яңа орденның өч дәрәҗәсе эш кешесенең хезмәт даны биеклекләренә күтәрелү юлында яулаган җинүләрен чагылдыруын яхшы аңлый иде ул.

Күкрәгенә орден таккан көнне кич без аның өендә сөйләшеп утырдык. Хатыны Мөгаллимә өстәлгә шаулап торган самовар китереп куйды. Чәй янына мәктәптән кызлары Сания белән Венера һәм уллары Айрат та кайтып җитте. Балалар әтиләре муенына сырылдылар. Гаилә башлыгы сүзгә җор, тирән мәгънәле итеп сөйли:

— Бу бүләк минем шәхси тырышлыгым нәтиҗәсе генә түгел. Аның нигезенә мәктәптәге беренче дәрес, укытучының беренче сүзләре, авыл профессиональ-техник училищесында алган белем, остазым Рәкыйп Якуповның тормышчан киңәшләре салынган. Бу бүлектә әти-әни өлеше дә зур. Алар мине эш сөяргә өйрәтеп үстерделәр.

Венераның беренче класска кергән чагы гына иде әле.

— Әти, беренче класста укыган көннәрне хәтерлисеңме син?

— Хәтерлим, бүгенгедәй исемдә. Икмәк дәресе бик тә истә калган.

Укытучыларының класс белән сөйләшүен мин Минсалих авызыннан куен дәфтәренә язып алган идем. Анда мондый юллар сакланган.

— Балалар, хәзер нинди ай?

— Май ае.

— Бу айда нинди бәйрәмнәрне беләсез?

— Беренче Май, Җиңү көне!

— Тагын нинди бәйрәмнәр?

Класс тынып кала. «Майда тагын Икмәк бәйрәме. Язгы чәчү бәйрәме бар, — дип дәвам итә укытучы. — Бу көннәрдә авыл кешеләренең бәйрәме кырда, язгы чәчүдә». Анда эш авыр: җир юеш, әле яңгыр бимазалый, әле коры язгы җилләр

исә. Шулай да анда игенченең хезмәт бәйрәме. Ни өчен? Әлифбадагы халык мәкален укып карыйк: «Язның бер көне ел туйдыра»... Бу сөйләшү Айрат өчен әтисеннән алган Икмәк дәресе була.

Минсалих орден белән бүләкләнгән 1978 елда алтынчы классны тәмамлаган улы әтисенең ярдәмчесе булып эшләде.

... «Уңыш-78» штабының иртәнге утырышы бара. Көн тәртибе: район комбайнчыларының соңгы биш көнлек социалистик нәтиҗәләрен чыгаралар. Хуҗиев ун көн дәвамында беренчелекне үз кулында тоткан. Аның «Колос»ы иген дингезендә күчмә вымпел җилфердәтеп йөзеп йөрде. Бу юлы да дүрт көн алда барган. Әмма ахыргы мизгелдә дип әйтерлек аталы-уллы Хуҗиевларның корабы «комга терәлә». Минсалих, штурвалны улына тоттырып, звенодагы хезмәттәшләренең эшен күзәтергә киткән иде. Куәтле машина унөч яшьлек Айратка буйсынырга теләми. Малай «Колос»ны үз ирегенә куярга мәҗбүр. Кишәрлекләр өстеннән аркылыга-буйга китә. Ярты сәгать чамасы шулай йөргәч, машина чокырга төшеп туктый. Валикларга салам чорнала, илгәге ватыла. Машинаны төзәтергә өч сәгатьләп вакыт китә. Күршеләре йоклап ятмаган икән. «Дружба» колхозыннан Минсалих үкчәсенә басып килгән Хуҗиәхмәтов аларны узып киткән. Шулай итеп, улы белән эшли башлаган елда беренче мәртәбә вымпел алар кулыннан ычкынып тора. Хәер, звено башлыгы үзе моңа артык борчылмый.

— Ярышның көче бер-береңне уздырып эшләүдә. Шундый оста көндәшләр булганда, штурвалга ныграк ябышасың, күңелгә өстәмә дәрт, беләкләргә көч өстәлгәндәй була, — ди ул председательгә.

Алгы сафтан чигенүнең сәбәбе бер: Айрат гаепле. Комбайн тыгылгач, туктап кына торасы иде. Аны төзәтергә сарыф ителгән өч сәгатьтә темпны төшермәскә була иде ич.

Минсалихның кызып китә торган гадәте юк. Улын туздырып ташламый. Шулай да үзе белән булган гыйбрәтле вакыйганы тәфсилләп сөйләп бирә. «Новосибирскидан авыл профессиональ-техник училищесын тәмамлап кайткан чагым. Белем җитәрлек, тик комбайнда мөстәкыйль эшләп караганым юк иде әле. Рәкыйп Якуповның ярдәмчесе итеп куйдылар. Ул бу басуларны мең кат иңләгән тәҗрибәле кеше. «Я, егет, нәрсәгә өйрәнеп кайттың? Осталыгыңны кырда сынап карыйк»,— ди. Минем йөрәк түзми. Штурвалга ыргылам. Рәкыйп абыйның бригадир янына китеп барганын сагалап тордым да комбайнга менеп утырдым. Тезелмәләр өстеннән элдереп китеп тә бардым. Теге башка барып җитә алмадым, машина туктап калды. Тизлек не дөрес куймаганмын икән. Кабаланып Рәкыйп абый килеп җитте. Комбайннан сикереп төшкәнемне сизми дә калдым. «Әй, егет, шулай ярыймы инде? Комбайныңның эзләрен кара! Тезелмәләрдәге игеннең яртысы җирдә ләбаса. Камыл өстенә салынган башакларны ялатып алып барырга кирәк. Бер бөртек тә әрәм булмасын»,— дип орыша. Минем өчен ачы сабак булды бу. Эшкә җавапсыз карарга ярамавын аңладым». Әтисе сүзләрен улы күңел дәфтәренә теркәп куя.

Минсалих ул елны «Урак батыры» дигән мактаулы исемне үзендә саклап калу җиңел булмасын яхшы белә иде. Үткән сезонда 9400 центнер суктырды һәм район күләмендә беренчелекне алды. Быел башкалар да шул дәрәҗәгә күтәрелү максаты куялар. «Дружба» колхозыннан Хуҗиәхмәтов, Миңнеголовлар, һичшиксез, бу биеклеккә күтәреләчәк. Беренче булу өчен иң киме ун меңне бирергә кирәк. Моны яулау җиңел түгел, әлбәттә. Председатель Арютин дөрес әйтә: «Уракта көчле рухлы, нык холыклы, максатына кыю бара белгән механизатор җиңә».

Урак сентябрь уртасында бетә. Финишка җиткәнче Хуҗиевларның төп көндәшләре дә сөртенгәләп куялар. Минсалих улы белән булган теге күңелсез хәлнең бөтен кабатлануына юл куймый. Рульне Айратка биргән очракта да комбайннан төшми. Август ахырына комбайн бункерына тугызынчы йолдызны ясыйлар—тугыз мең центнер бар! Калган көннәрдә эш тизлеге бик үк әллә ни булмый. Чөнки соңгы кишәрлекләрне җыеп алу өчен басудан-басуга күчеп йөрергә туры килә. Башка басуларга барганда машинага Айрат хуҗа була. Ул комбайнны буш кырда йөртергә оста.

Аталы-уллы Хуҗиевларның гаилә агрегаты Лениногорск якларында моңа кадәр күрелмәгән биеклеккә күтәрелә. Алар «Колос» бункерыннан 13 мең ярым

центнер бөртек бушатып ала. Унөч йолдыз ясалган машина хуҗасы Мәскәүнең Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашу хокукына лаек була. «Урак батыры» башкаладан күкрәгенә күргәзмәнең көмеш медален тагып кайта.

Былтыргы уракның катлаулы шартларда баруы турында әйтелгән иде инде. Шундый авыр елда да «Ленинский путь» колхозында урып-җыю фронтында зур җиңү яулана. Ә менә күршедәге Тукай исемендәге колхозда игенне алып бетерә алмыйлар. Бу Минсалихка тынгылык бирми. Менә-менә кар яварга тора. Игеннең харап булуы бар. Хуҗиев моңа битараф була алмый, билгеле.

— Вениамин Георгиевич, булышып кайтыйк. Звено комбайнчыларының да теләге бар, — ди ул.

Тәвәккәлләп чыгып китәләр. Эшлисе эш җитәрлек икән әле. Дүрт агрегат белән күршеләрендә 10 мең центнердан күбрәк арыш суктыралар. Аның 3 мең ярым центнерын Хуҗиев комбайны бирә. Яңгырлы елның көзге төнендә дә машиналарын туктатмыйлар. Тукай исемендәге колхоз басуларында күп көч һәм тир түгеп үстерелгән ашлык амбарларга салына. Минсалих, ике колхоз кырында эшләп, үткән рекордын кабатлый.

Хуҗиев звеносында тагын өч комбайн бар. Аларны Николай Батманов, Виктор Муравцев һәм Иван Есипов йөртә. Механизаторлар звено башлыгыннан яшьрәк, тәҗрибәләре аныкы кебек түгел. Минсалих үз кулы астындагы кешеләрдән югары эш күрсәткечләре һәм сыйфатлы эш таләп итү белән генә чикләнми, шәхси үрнәге, көндәлек ярдәме, файдалы киңәшләре белән аларны нинди генә кырыс шартларда да басуның оста хуҗасы булып калырга өйрәтә..

Игенчегә урак өстенең берсендә дә җиңелгә туры килми. Икмәк күп көч, осталык куеп җыела. Шундый уттай кызу эш өстендә Минсалих көнен-төнен белми, ялы-йокысы белән исәпләшми. Игенче һөнәренә бөтен йөрәге белән бирелгән кеше генә шулай эшли ала. Ул үз хезмәтенә бөтен куәтен, осталыгын бирә, йөрәк җылысын сала. Бу сыйфатлар бала чагыннан ук аның канына сеңгән. Хуҗиевлар гаиләсендә игенче осталыгы нәселдән килә. Хәзер районның танылган комбайнчысы Минсалих мәктәбен Хуҗиевлар династиясенең киләчәк буын вәкиле Айрат дәвам итә.

Вениамин Георгиевич Арютин белән сөйләшеп утырабыз. «Унынчы бишьеллыкның соңгы өч урагында районда Хуҗиевларга тиңләшерлек осталар табылмады, — ди председатель горурланып. — Авылдашларыбыз аталы-уллы Хуҗиевларга зирәклекләре, инициатива күрсәтүләре, игенчегә хас осталыклары өчен чын күңелдән рәхмәт хисләрен белдерәләр. Икесе дә җир уллары алар».

Үткән ел «Ленинский путь» кырларында унбиш агрегат эшли. Алар 60 мең центнерга якын ашлык суктыралар. Шуның яртысын диярлек Хуҗиев звеносы җыя. Тагын бер үзенчәлекле нәрсә: унынчы бишьеллыкта Минсалих 50 мең центнер бөртек җыя. Биш елда — җиде еллык норма! Районда «Колос» комбайны белән суктырылган уртача ашлык алты мең центнер чамасы, ә аныкы — ун мең!

Хуҗиев шул ук шартларда, шундый ук машина белән хезмәт җитештерүчәнлеген ике тапкырга күтәрә. Хәзер ул барлык комбайнчылар өчен якты маяк һәм гыйбрәтле үрнәк.

... Башкалага КПССның XXVI съездына киткәндә делегатларны бер төркем журналистлар озатып кала. Аларның берсе Минсалихтан съездга нинди уйлар белән баруын сорый. «Миңа калса, съезд бездән күпне көтә. Аның тарихи карарларын авылда, әлбәттә, без тормышка ашырырга тиешбез», — дип җавап бирә ул кыска гына.

Съездан кайткач, районадашлары белән очрашулардагы чыгышларында да ул шушы ук фикерен куәтли.

Минсалих әледән-әле үзенә иң кадерле документ — съезд делегаты мандатын кулына ала. Куе кызыл төстәге кәгазьнең сул ягындагы Ленин рәсеме, янәшәсендә таныш сүзләр: «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!», «Советлар Союзы Коммунистлар партиясе». Шушы мандат белән съезд делегатлары, илебезнең барлык коммунистлары, бөтен халкыбызның ихтыярын үтәп, Ленин партиясе, аның Үзәк Комитеты политикасын яклап тавыш бирделәр.

Мандатына күз салган саен, Минсалих Хуҗиев уй-фикерләре, күңеле белән съездлар сараена әйләнеп кайта кебек. Башкалада ул туган колхозы, аның киләчәге турында күп уйлый иде. Съездда КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежневның: «Әгәр авыл хуҗалыгы турында тулаем сөйләсәк, аның алдында халык хуҗалыгының башка тармакларындагы кебек шул ук төп проблема тора, ул да булса — нәтиҗәлелек һәм сыйфатны күтәрү», — дигән сүзләреннән чыгып, эшләнәсе эшләрне күзаллый. Бурычлар зур. Аларны тормышка ашыру тырышлык һәм күп көч сорый.

«Ленинский путь» колхозы игенчеләре унберенче бишьеллыкта бөртеклеләрнең тулай җыемын 20 процентка арттыру, ягъни елына 61-62 мең центнерга җиткерү, терлекчеләр сөт җитештерүне 5 процентка күтәрү бурычын куйдылар. Колхозчыларның кулыннан килерлек эшләр. Моңа үткән бишьеллыкта ышанычлы нигез салынды. Колхозның игенчелек культурасын күтәрү, терлекчелек продуктлары җитештерүне арттыруда ирешкән уңышлары өчен 1979 елда КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының, былтыр РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байракларына лаек булуы — шуның ачык дәлиле. Монда коммунист Хуҗиевның да өлеше бар..

Минсалих Хуҗиев илебез авыл хуҗалыгы алдында съезд куйган программаны тормышка ашыру өчен аерата тырышып эшли. Ленин партиясенең гади бер члены буларак, съезд карарларын тормышка ашыруда катнашу — коммунист Хуҗиев өчен зур бәхет һәм горурлык ул.

# Флера Гыйззәтуллина

*Шагыйрә әдәбиятка чын мәгънәсендә тормыштан килде. Әйе, Азнакай районының Әсәй авылында туып үскән кыз бик яшьли хезмәт сафларына баса: унбиш яшендә авылда терлек карый, ә уналты яшеннән Кемерово якларына китеп шахталарда эшли. Аннан соң Омск — Томск тимер юлын салуда катнашу, Донбассның «Калиновка» шахтасында мотористка... Тормыш иптәше белән туган якка кайткач, Карабаш эшчеләр поселогында дистәдән артык ел тегүче булып хезмәт итү, берүк вакытта кичке мәктәптә белем алу... 1963 елдан бирле Флера Гыйззәтуллина Әлмәт, Лениногорск һәм Казан язучылары белән аралаша башлый, әдәби берләшмәләргә йөри, беренче шигырьләрен бастыра. «Кешеләр һәм чәчәкләр», «Беренче карлыгачлар», «Юл башы», «Кызлар җыры» кебек күмәк җыентыкларда күләмле шигырь бәйләмнәре белән катнаша.*



*Соңгы елларда шагыйрә Тольятти шәһәрендә яшәде. Казан белән ныклап әдәби бәйләнештә булып, «Чишмә юлы», «Сәлам хаты» исемле ике мөстәкыйль китабын бастырып чыгарды. Ә инде Казанга күчеп килгәч шагыйрә СССР Язучылар Союзына әгъза итеп кабул ителде.*

*Шигырьгә тормыштан килү... Флера Гыйззәтуллинаның үзе язганча, ул «тормышның кайсы почмагына барып чакса да үзен чит, мескен кеше итеп» сизми, чөнки: «кайнап торган хезмәт тормышы күкрәп торган куәт таләп итә». Ә хезмәт халкы белән аралашу — язылачасы җырларның ныклы нигезе. Шуңа да «Иделдән күтәрелеп тә тормыштан күтәрелеп» шигырьгә килгән шагыйрәнең адымнары ныклы, шигырьләре самими, табигый һәм ышандыру көченә ия. Бер сүз белән әйткәндә, алар — тормышчан.*

*Ә алда — яңа юллар, яңа җырлар. Барасы да барасы, язасы да язасы әле аңа!*

## Рәхмәт сүзе

**...Ватан-анам,**
**Минем уй-тойгымның**
**Бәләп тор син барын!**
**Синнән генә отам тормышның мин**
**Шигъри тылсымнарын.**

Тылсым телен ачам:
Ачыла зыңлап
Гыйлем ишекләрең...
Бу азатлык өчен кемнән генә
Рәхмәт ишетмәдең.

Үткән гомер безнең дәрья-судай:
Шигырь — көлтә-көлтә...
Тал-тирәкле борма юллар безне
Олылыкка илтә.

Олы язмышларны хәл иткәндә
Үткен акыл кирәк!
Акыл хезмәтемдә,
Ватан-анам,
Ялгышмаска өйрәт!

## Күршеләр

Яраткан күршеңә хәл-әхвәл сорарга
Кереп чык кимендә көнгә бер...
Күршедә бәби бар: бишектән төшкәнче
Ул әле биш төргә төрләнер.

Күршедә әби бар: орчыгын тутырып
Ул сиңа, шәлгә дип, җеп эрләр...
Кулдагы орчыклар зырылдап торганда
Озая яшисе гомерләр.
Җепләрнең мамыгы орчыктан йомгакка
Ураган арада кабара...
Ирешер морадым — тәгәрәр йомгагым —
Тулышып өлгергән кай ара?!

...Йомгаклар тәгәрәп югалып калучан,—
Күршеләр сукмактан табучан...
Күршеләр күз-колак, күршеләр хәбәрдәш,
Күршеләр уйларга талучан.

Күршенең күңеле
Күршегә береккән,
Баланың үсәре ал да гөл...
Иңемдә мамык шәл — Оренбур шәлләре!
Күршемнең хәлләре ал да гөл!

## Әсәйдә туй

### 1

Яз көне өй бурап күтәргән осталар
Кыз сорап килгәннәр күз кергәч...
Килер шул, сорар шул — кызыңа тиң булыр
Имәндәй ир-егет үстергәч!

Останың-остазның урыны иң түрдә,
Иң түрдә — ярәшкән яшь парлар.
...Бездә туй узганда — үзара туй ясап
Һавада тибрәлә яшь карлар.

Энҗедәй яшь карның эрисе билгеле
Олы юл өстенә төшүгә...
Туйларның хикмәтен,
Олыдан кубарын
Сөйләве күңелле кешегә.

Чын остаз теленнән ишетелгән тулы тост
Туйдагы һәркемгә җан азык!
Сүздәге чаткыдан
Җемелдәп балкыган
Иң якты йолдызлар — яңалык!

Без дә бит үзара туйлашып, сыйлашып
Яңардык, көн кебек яктырдык...
Төн безгә җилпучлап йолдызлар җилгәрде.
Төс җуймый йолдызлы матурлык.

Һәр эштә бергәләп без исбат итәрбез
Йолдызның күплеген күктәге! —
Меңләгән йолдызга тиңләшер гомернең
Минуты әрәмгә үтмәде.
Хезмәттән иңгән көч гел җиргә тартылыр,
Дан булып талпыныр югары.
Тик сугыш купмасын
Сынмасын халкымның
Кадерле чүкече-урагы.
Без салган калалар,
Без тапкын балалар
Булмасын тоткынлык корбаны.
Истә бит: сугышның буеннан-буена
Туйларның тукталып торганы.

2

Йолдызга менүләр,
Туйлап кыз бирүләр
Саналыр йөзгәчә, меңгәчә...
Җиткән һәр улына, киткән һәр кызына
Әсәем бәхиллек өләшә.

Осталар яңа өй салырга сүз ала,
Зур өйне түр өйгә беркеткәч...
Әнә шул өйләрдән
Бәрәкәт качмасын.
Кыз бала кайтмасын бер киткәч!

Зур бакча-түр бакча чәчәккә күмелсен
Төпчекләр бишектән төшүгә...
Бәхетнең алмадай кызарып пешкәнен
Күзәтү күңелле кешегә.

●

— Парлыдыр,— дияләр кешеләр,
Кыекта күгәрчен гөрләсә.
Мин карыйм түтәлгә, гөлләргә...
Гөлләр дә парлашып серләшә.

...Бәхетле ромашка — ак чәчәк.
Парланды, таҗларын өзмәдем! —
Чөнки мин теләмим кемнең дә
Хәсрәтле хыялда йөзгәнен.

— Парлыдыр,— дисеннәр һәрвакыт
Сандугач килгәндә язларын.
Синә да һичкайчан хатымда
Кәккүкләр хакында язмамын.

## Әнкәм назы

Иңбашымда ике нәни толым,
Юл башымда балкый ал таңым.
Чәчләремне әнкәй тарап үргән,
Яшәр хокук биргән Ватаным.

Җырга төргән халкым, нурга төргән
Ана назын, илем мирасын.
Әллә минем йөрәк түрем тармы?
Әллә бармы наздан туясым?

Үз баламны әллә аз назлыйммы
Гөлләр язлаганда илемдә?
Мин илемә мәңге кайгы салмам,
Өзмәм илнең сыңар гөлен дә!

Өзелсәм дә, үзем кайгырсам да,
Кайгыларга илне салмамын!
Үзем бала биләр вакыт җиткәч,—
Әнкәемнең хәлен аңладым...

Газиз әнкәм «түз!» дип сыйпагандай,
Сабырлыгым сыйпый башымнан.
Бу дөньяда минем телем дә бит
«Әт-тә! Ән-нә!» диеп ачылган.

Һәм бикләнгән шул сүз сабый килеш
Күбәләктәй күңелләремә...
Мин гаеплемени гомерләрнең
Шулай иртә сүрелгәненә.

Мин гаеплемени назланырга
Җитмәгәнгә миңа чиратлар?
Әнкәм җанын «ак күбәләк» диләр —
Илгә кайтса, гөлгә кунаклар.

...Әнкәемне эзләп тапмаганда
Күбәләкле түгәрәкләрдән.
Әнкәм назы чишелмәслек булып
Чәч тасмамда күбәләкләнгән.

Әткәм-әнкәм бәхиллеге булып
Юл башыма иңгән ал таңым.
Чәчләремне әнкәй тарап үргән,
Яшәр хокук биргән Ватаным.

## Акчарлак аваз сала

Пароход ярдырып бара
Суның нәкъ урталыгын.
Су буе — уйсу болында —
Безнең дә туктар урын.

Безнең дә хәзер дуслар бар
Уртадан үткәрерлек.
Килдек бит чөнки шигырьгә
Тормыштан күтәрелеп.

Булсын дип маяк дус-ишнең
Еракка барасына,
Адреслар язып калдырдык
Чакрымнар арасына.

Күзәттек, күздән кичердек
Чакрымнар чигенешен...
Акчарлак очыра Идел —
Ул да бит илем өчен!

Ышанып акчарлакларның
Уйнаклап очарына,
Сикерәм мин дә буй салып
Дулкыннар кочагына.

Кычкырам: — И-и-де-ел, кил-де-ем! — дип, —
Очышлы ярышларга!
Кавышуга куаныч кушып
Акчарлак аваз сала.

Тормышка ашасы тавыш
Үзәктән үтә элек...
Иделдән күтәрелеп тә,
Йөрәктән күтәрелеп.

## Күзләреңә әллә күз тидеме?

Күзләреңдә чулпан нуры иде,
Юлым юнәлгәндә йолдызга.
Күзләреңә әллә күз тидеме?
Күз тидеме дуслыгыбызга?

Чулпан йолдыз күздән җуйды мәллә
Зәңгәр төннең челтәр кашларын?..
Мин барыбер йолдыз-челтәремне
Синнән башка бәйли башламыйм.

Мин барыбер бүген киләм сиңа
Төн күгемнән йолдыз балкытып...
Учларыңда йолдыз биетер булсаң,
Үрнәкләрен күктән ал отып.

## Шахтер егеткә сәлам хаты

Араларны тоташтырыр өчен
Бар бит безнең Донбасс, Себерләр...
Киләчәгең алда якты булса,
Үкендерми үткән гомерләр.

...Горурланып искә алам сине,
Искә алам һәрбер сүзеңне.
— Аппагым!— дип, сыйпый идең минем
Кара тузан кунган йөземне.

Һәм сакланды синең ихлас сүзең,
Күтәрелеп лава түреннән,
Без баш идек җиргә сәлам биреп
Терриконнар биеклегеннән.

Стволдан кайтып лаваларга
Кәйлә, борау белән «ход» ачтык.
Дәверләрне кат-кат урадык та
Катламнарга янә тоташтык.

Муллыкларны, әйе, чагыштырсак,
Донбасстан ким түгел Себер дә...
Күмер кәрваннары дәвамында
Тармаклана безнең гомерләр!

Бизәк булып күлмәкләргә күчә
Күмердәге төрле төсмерләр...
Син дә шахтер — ачкан тауларың бар,
Минем дә бар алтын көшелләр.

Һаман тоям синең сулышыңны!
Сулышларың җырлы учакмы?
Гомерем забойларын иңләп киләм,
Җыр иркенә куеп кочакны.

Миргазиян Юныс

# ЕЛЛАР, ГАСЫРЛАР, СУЛАР АГЫШЫНА КАРАП

*Илдар Юзеевның иҗат портретына штрихлар*

*Нишләр идем әгәр:*
*Халкым бәла-каза кичергәндә,*
*Үз рәхәтем белән чикләнсәм,*
*Илем йөзен бәйрәм бизәгәндә*
*Үз кайгыма кереп бикләнсәм...*

Илдар Юзеевны беренче тапкыр күрүем. 1964 ел. Аның «Ялкын» журналында җаваплы секретарь булып эшләгән чагы. Өстендә кыйммәтле тукымадан тегелгән соргылт костюм. Килеш-килбәте кайсы ягы беләндер Дәрдмәнднең киенү рәвешен хәтерләтә. Студентлык чорыннан чыгып, бераз акчага тиенгән яшьләр шулай киенергә ярата. Илдарның да шундый көннәре иде булса кирәк.



Беренче күрешү беренче мәхәббәт шикелле көчле һәм тирән тәэсир калдыра. Тәүге күрүдә кешенең бар сыйфатларын бер юлы гомумиләштереп әлктерергә өлгерәсең. Якыннан танышу дәверендә шушы гомумилек аерым сыйфатларга таркала да, аларны икенче мәртәбә җыеп синтезлау өчен шактый вакыт һәм көч түгәргә туры килә.

Беренче күрүдә, ни сәбәпледер, Илдарның кимчелекләре күземә бәрелде: үзен кыюсыз дип әйтерлек дәрәҗәдә тыйнак тота, шагыйрьлеге чәчрәп тормый. Сәхнәгә күтәрелеп шигырь сөйләгәндә, залда утыручылардан оялган кебек каушый, газапланып бетә.

Без, кызганычка каршы, кыюлыкны, үткерлекне, соңгы чиктә, беркадәр шомалыкны да яратырга өйрәнгәнбез һәм шундый кешеләрнең күбрәк уңышка ирешәсенә өмет баглыйбыз.

Илдар Юзеевның артык тыйнаклыгын, әлеге тыйнаклыкның сәбәпләрен, шагыйрь белән якыннан танышып, тормыш ситуацияләрендә, үз-үзен тотуын күзәткәннән соң гына аңлыйсың икән. Шагыйрьнең бар көче, гайрәте, мөмкинлекләре аның рухи яшәвенә — намус көченә, вазифа тугрылыгына, вөҗдан эшенә тотылып бетә бара. Аның шәхси тормышы рухи батырлык, әхлакый сафлык өчен көрәш белән сугарылган, шуңа күрә, эффектлы кыланышларга, үзен отышлы яктан күрсәтүгә әһәмият биреп тормый ул. «Күңелем минем чиксез кара урман: шаулый, тына, үрли, сына, сайрый, көлә, туа, үлә... әзли, таба, күккә аша, сөя, шаша, ыңгыраша... Күңелем минем чиксез кара урман: өмет өзәр, түзәр, чыдар... Тик кояшлы юлга чыгар». Илдар Юзеевның йөрәк, иман, вөҗдан белән язган биографиясе шушы.

Илленче еллар. Илдарның педагогия институтында укыган, укуын тәмамлап, эшкә яңа гына керешкән чоры. «Без барабыз яшьлек юлларыннан, корчагиннар үткән юллардан. Без яшьлекне мирас итеп алдык мусалардан, муллануллардан». Бу — риторик сүзләр генә түгел. Шагыйрь нәкъ Мусаларча, Муллануларча яшәргә тырыша. Бу елларда язылган шигырьләрдә романтик пафос, чикләнмәгән өметләр, кайнар оптимизм, Такташ чоры сулышы һәм шул чорга хас идеаллар самимилеге. Илленче еллар азагында без әлеге шигырьләрдә гражданлык хисе ныгуын, җитдиләнүен күрәбез. Юзеевның лирик герое җаваплы хезмәткә, хәлиткеч көрәшкә ашкына:

**Соңгы яңалыклар тыңлыйм дисәң,**
**Чык урамга. Ишет...ниләр бар!**
**Ил шатлыгын, дөнья кайгыларын**
**Башлап сиңа шунда сөйләрләр.**

Алтмышынчы елларда илдә һәм җир шарының төрле почмакларында булып узган һәр вакыйга шагыйрь күңелендә дә урын таба һәм аның һәр шигырендә вакыйгаларның кайнар сулышы сизелеп тора. Шул чорда язылган шигырьләр аша илнең тарихын өйрәнеп булыр сыман. Мәскәүдә үткәрелгән Чайковский конкурсында Ван Клибернның беренче урынны яулавы; Әсгать Җиһаншиннарның 49 көн стихия кочагында йөрүе; физиклар белән лириклар арасындагы нәтиҗәсез бәхәсләр; чирәм җир үзләштерү; космос яулау; атом бомбасын куллануга каршы тынычлык өчен көрәш; илебездәге бөек коммунистик төзелешләр... Фатих Кәримгә, Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннарга багышланган шигырьләр. Шагыйрьнең вакыйгалар хәрәкәтен күрүе, аларны бәяли белүе, шул вакыйгалар аша укучының хисләрен уята алу осталыгы камилләшә. Илленче елларда язылган шигырьләр белән чагыштырганда фикер йөртүе тирәнәя, профессиональ осталыгы арта. Лирик герой күтәренке пафоска гына таянмый, аның кичерешләре җитди, ул чор куйган җаваплылыкны тоеп яши. Шуңа карамастан, шагыйрь әле үзенең бер кимчелегеннән арына алмый: ул һаман вакыйгаларга ияреп баруын дәвам итә.

Ниһаять, җитмешенче еллар. «Юк, мин яши алмыйм алай: әзер утлар табып, җил кай якка иссә, шунда таба авып. Юк, мин яши алмыйм алай: мичкә арка терәп; кеше яккан утта кызынырга теләп. Үзем утлар ягам, үзем дөрлим, янам... Үзем булып яшим, үзем булып калам... Юк, мин яши алмыйм алай: көчлегә баш орып, язмыш колы булып. Кеше — кодрәтле көч, кеше — алла тиңдер».

Философия фәненең мәгълүм бер кодрәтле кануны күләмнең сыйфатка әйләнү процессын исбатлый. Илдарның «Юк, мин яши алмыйм алай...» дигән шигырен укыганда аның егерме бер ел (бәлки бу процесс гомер буе дәвам иткәндер?) Прометей, Сизиф түземлеге белән дөньяны күзәтүе, эзләнү, фикер йөртү, тойгы газапларын кичерүе күз алдына килә. Шул озак елларга сузылган ачы һәм татлы иҗат газапларының бер ноктасында шагыйрьнең үз тавышын табып, үз юлына чыгуы күренә. «Юк, мин яши алмыйм алай...» — шигырь буларак, Илдар Юзеев өчен уңышлы этап һәм аның уңышы татар шигърияте өчен дә шактый зур әһәмияткә ия. Шушы шигырьдән соң язылган юллар шагыйрьнең иҗатында күзгә ташланып аерылып торалар. Юзеевның җитмешенче еллардагы иҗаты әдәбиятыбызда лаеклы урын били.

«Карурман» җыентыгы. Бу китапка 1971—1973 елда язылган шигырьләр кергән. Җыентыкка кергән шигырьләрнең исемнәрен генә укып карыйк: «Әйтегез, җан нидән яралган?», «Табыну», «Юк, мин яши алмыйм алай...», «Борчылу», «Офтану», «Шом», «Мәхәббәт, нишләттең син мине?» Шекспир һәм Толстой әсәрләрендәге төшенчәләр, сораулар болар. Кешелек дөньясында гасырдан гасырга күчеп килә торган, беркайчан да әһәмиятләре вакланмаячак гомуми гуманистик мәсьәләләр. Нәкъ шушы проблемалар бөек Гомерның «Илиада» һәм «Одиссея» әсәрләрендә куелган. Алар без яшәгән чордан соң тагын дүрт мең ел үткәч тә актуальлекләрен югалтмаячаклар.

«Карурман» җыентыгына кергән «Таш диварлар авазы» шикелле әсәр безнең татар әдәбиятында бар идеме икән? Поэманы укыганда мин инквизиция судының архивын укыгандагы кебек тетрәндем. Вакытында шушы әсәр тирәсендә җитди сөйләшүләр булыр дип көткән идем. Әллә инде тәнкыйтьчеләрнең теше үтмәде бу поэмага, әллә без, укучылар, шушы әсәрне аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмадык.

«Таш диварлар авазы» кайсы ягы беләндер Габриэль Гарсиа Маркесның «Йөз ел ялгызлыкта» дигән романын хәтерләтә. Гарсиа Маркесның роман-эпопеясына Колумбиянең бер гасырлык тарихы һәм шул тарих тәгәрмәче астындагы язмышлар сыйган. Автор әлеге язмышлар аша буржуаз тәрәккыятьнең йөзен, тормыштагы ялгышлыкларны, изүчеләр сыйныфы эшләгән җинаятьләрне тетрәндергеч итеп күрсәтә алган. «Йөз ел ялгызлыкта» — егерменче гасыр әдәбиятының иң зур казанышы дигән бәягә лаек булды. Ә без Илдар Юзеев поэмасының татар әдәбиятындагы урынын да билгели алмадык. Рус теленә һәм башка телләргә яхшы тәрҗемә итүне дә көтә әле ул әсәр.

Шагыйрь унынчы гасырлардан башлап бүгенге көнгә кадәр тоткынлыкта һәлак булган бөек шәхесләрнең язмышларын өйрәнеп, шуларга анализ ясаган.

**Мин гүя өнсез-авазсыз,**
**Җилкәнсез-юлсыз кораб —**
**Тын тордым еллар, гасырлар,**
**Сулар агышына карап.**
**Шомлы куркыныч зиндан мин,**

— дип башлана поэма һәм кереш сүз тәмамлануга җир астыннан коллар тавышы яңгырый башлый:

**Без коллар — без төрмә төзибез,**
**һай авыр...**
**Мәңгегә үзгәрмәс кануннар,**
**Без коллар: чыдамнар, сабырлар**
**Дүрт дивар эчендә калырлар,**
**һай авыр.**
**Камчылар үзәкне өзәләр,**
**һай авыр...**
**Ташларны башларга төзиләр,**
**Нигезгә салынып гәүдәбез...**

Тираннар коллардан төрмә салдырттаннар. Төрмә керешчеләрне ябып тотарга кирәк булган. Шагыйрь коллык һәм тиранлык тарихларына анализ ясый да: тиранлык та, коллык та битарафлык мохитында гына яши ала диган нәтиҗәгә килә. Коллыкның массалар битарафлыгыннан тууы тарихи документлар белән дәлилләнгән. Поэманы укып чыкканнан соң коллыкның күптәрлә булуына күзең ачыла һәм аның әсир төшеп, колбиләүче кулына эләгү генә түгел икәнлеген аңлыйсың. Коллык — тиран өмерен тормышка ашыру, коллык — югарыдан килгән фәрманнарны түбәнгә җибәреп, түрәләктә утыру, коллык — азатлык һәм хакыйкать өчен көрәшүдән баш тарту, ниһаять, коллык — халкың изелгәндә үз рәхәтлегең өчен яшәү. «Таш диварлар авазы» шушы турыда сөйли.

Поэмада ташлар, диварлар, агымсулар, җир үзе телгә килеп, тарихтагы язмышлар турында сөйли. Коллар төзегән таш диварлар тетрәндергеч серләр ача:

**Мин төрмә. Шашкын акылга,**
**Ирек-хыялга төрмә...**
**Мәңге салкын ташларымда**
**Уй-хисләр, серләр саклыйм.**
**Диварларымда: Хыял. Каргыш.**
**Васыятьләр. Сатылу.**
**Нәфрәт. Сөю. Шашу. Качу.**
**Хыянәт. Үч. Атылу.**

Поэмада берсеннән-берсе аянычлы, тапталып сытылган, тар-мар килгән кеше язмышлары. Әсәрне укыганда туктаусыз тоткыннар ыңгырашуы, аларның нәфрәте, ләгънәте ишетелеп тора. Шушы авазлар бәгырьгә — салкын җил, канга тоз булып үтә, тетрәндерә, җанны сыкрандыра.

Берничә эпизод. Билгесез болгар чәчәне: «Идел—туган өем, кыйссам, сүзем: көем каен тузларына язылды. Акчәеннар яфрак ярдылар, сүзләремне көйгә салдылар... Кызыктырып данга китерделәр ханга, — Нә боерсам — булыр шул, — диер. Сән кол, — диер, былбыл чәчән, бәнем сараемда бул», — диер. «Тәхетеңне мактап сайрамам... Мин хурлыклы юлны сайламам. Моңлы сазны тартып алдылар, кулларыма богау салдылар».

1600 ел. Рим. Тординон төрмәсе. Джордано Бруноның тарих битендә мәңгегә язылып калган әхлакый батырлыгы: «Чиксез ул галәм, җир ялгыз түгел!.. Әйләнеп йөри кояш тирәли. Шушы иманга тугры булганга ябып куйдылар кысын зинданга». (Пәнҗешәмбе көнне иртә белән җинаятьче дәһри Джордано Бруно Чәчәкләр мәйданында тере килеш утта яндырылды).

1774 ел. Казан төрмәсе. Пугачев полковнигы Мәсәгүт Гомәров. «Битемдә өч тамга, тәнемә сугалар, сугалар вөҗданга... Аркамнан — кан тама... Тән чыдар, җан чыдар, чыжылдый камчылар. Йөз илле мәртәбә, йөз илле мәртәбә чәчри ал тамчылар. Җан чыгар, җәлладлар гәүдәмне яшерер, йөз илле яз булыр, йөз илле көз булыр, онытма, нәселем».

Поэмада язмышлары күрсәтелгән тоткыннарның исемнәрен генә искә төшерик: «Җир һәм азатлык» хәрәкәтенең мәшһүр җитәкчесе, үлем җәзасы көткәндә реактив космик аппарат проектын төзеп калдырган Николай Кибальчич, протест йөзеннән башын таш диварга бәреп ярган декабрист Булатов, Петропавел равелинында үз-үзен яндырган революционерка Мария Ветрова, Владимир Ильич Ленин, Заксхаузен тоткыннары, Юлиус Фучик, Анна Франк, Фелисьен Жоли, Муса Җәлил, Хулиан Нримау һәм башкалар.

Поэманы укый башлау белән Бетховенныкына тиң көчле музыка яңгыравын ишетеп аласың. Укып чыкканнан соң да әле шул көй бик озак яңгырап тора. Сулышы һәм

шигъри интонациясе белән «Таш диварлар авазы»— опера либреттосы. Шушы кадәр аның музыкага салынмаган булуы бер гаҗәп хәл булып тоела. Әсәрнең тирән оптимизм белән сугарылган финалы сокландыра. Зиндан газапларын зар-ыңгырашуларны азатлыкка омтылучыларның ышаныч көче, фидакарьлекләре җиңә. Әсәр безгә бигрәк тә шушы ягы белән кыйммәтле.

**Берчак кеше вәхшилеккә,**
**Явызлыкка чик куяр...**
**Ул көн килер, — бер-береңә**
**Ышанмау-шикләр бетәр,**
**Илләр, телләр арасында**
**Таш дивар-чикләр бетәр.**

«Карурман» җыентыгын Илдар Юзеев Башкаладагы ике еллык Югары әдәби курсларда укыганда язды. Мин әле Илдарның Мәскәүгә укырга килүен ишетмәгән дә идем. Бер көнне без аның белән вокзалда очраштык.

Йөздән артык поезд Көнчыгыш юнәлешеннән килгән һәм шул якка китүче пассажирларны Казан вокзалына бушата һәм төяп алып китеп тора. Монда көне-төне гүктәлып тормый торган катлаулы хәрәкәт. Куанычлы кавышулар, сагышлы аерылышулар, шатлыклар, хәсрәтләр, күз яшьләре. Нәрсә генә юк монда! Вокзал ыгы-зыгысында ярты сәгатьләп торганнан соң халыкны бу урынга нинди мохтаҗлык китерүе, аларның башкалага нәрсә белән килүләре һәм моннан нәрсә алып китүләре ачыклана башлый. Вокзал безнең бөтен тормышыбызны хәтерләтә. Вокзал ыгы-зыгысы — кыскартып күрсәтелгән яшәеш моделе.

Илдар Юзеев билет залы фойесындагы һәйкәл каршында басып тора иде. Чырае сытылган. Күзләре бер ноктага текәлгән. Йөзенә куркыныч тетрәнү чыккан. Шулчак аның карашы төшкән урынны күреп алдым: һәйкәл янында кешелек сыйфатын югалткан бер исерек аунап ята иде. Пассажирларның үз мәшәкатьләре көчле. Алар әрлебирле узып йөриләр. Милиция башка эш белән мәшгуль. Шагыйрь һәйкәлгә әверелгән кешенең истәлеген пычратуны кабул итә алмыйча, газап чигә. Исерекне тиешле урынга күчергәч, Илдарның тулай торагына юл тоттык. Без вокзалдан чыкканда төнге сәгать уннар иде. Добролюбов урамына җәяү барып җиткәнче таң да беленә башлады. Шул төнне мин тыштан юаш-күндәм күренгән кешегә табигать компромисс белми торган батыр намус биргәнен аңладым.

Югары әдәби курсларда күп кенә татар әдипләре укыды. Мәскәүдә яшәүче әдәбият яратучылар Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Роберт Батулла, Гәрәй Рәхимнәрнең изге эшләрен онытмаячаклар. Башкалада укыганда Илдар Юзеев та укучылар өчен күп кенә файдалы эшләр башкарып китте. Уку программасы тыгыз булса да, Илдар башкаланың утыздан артык театрында барган спектакльләрне, дистәләгән музейлардагы күргәзмәләрне карап барырга өлгерә иде. Шагыйрь гигант шәһәрнең кайсы гына урыннарында булмагандыр? Нәфес, комсызлык тышка бәреп чыга торган җирдә — базарларда, дөнья малы бәясен югалткан, җан кайгысы гына кала торган урында — зиратларда...— мөнәсәбәтләр дөньясын нинди генә ноктalardан күзәтеп йөрмәде ул.

Кичләрен тулай торакның 412 бүлмәсенә еш кына башкаланың иҗат интеллигенциясе җыела иде. Бүлмә хуҗасы Илдар кунакларын сыйлау өчен ит пешереп йөри. Белмим, борынгыларның ит пешерү рецептын ул каян чокып чыгаргандыр?— Илдар пешергән иттән табигать кочагындагы учакларда кыздырылган калҗа тәме килә. Кәеф күтәренке. Әңгәмә тау чишмәләре тавышы чыгарып челтерап ага тора. Мондый чакларда Илдар гади сүзләр белән генә сөйләшә алмый башлый. Аның теленнән экспромт белән генә юмористик куплетлар чәчрәп чыга. Юмор иң четрекле сорауларны, иң катлаулы мәсьәләләрне аңларга ярдәм итә. Табигый юмор — гаҗәп зур тылсымлы көч, ул фикернең асылына үтеп кереп, мәгънәне әчке яктан яктыртып күрсәтә. Әңгәмәдә юмор чаткылары барлыкка килгәч, Илдар халтура җимеше булган шаблон шигырьләрне яттан укый башлый. Андый шигырьләр, аллага шөкер, тукталмый чыгып торалар. Бәлки, тән булмаган җирдә якты көн, минус булмаган очракта плюс булмаган шикелле, халтура катнашмаган әдәбиятта талантлы әсәрләр дә тумый торгандыр? Имитация юлы белән эшләнгән шигырьләрне Илдар искиткеч үзенчәлекле итеп укый белә. Аның укуын тыңлаганда, шигъри хакыйкатьнең рәнҗеп елавын, дәреслекнең, сынарга теләмичә, ярсып көрәшүен тоеп торасың. Юзеев интерпритациясендә шигырь эченә яшеренгән ясалмалык, аңгыравыклы пафоска төренгән эрзац тойгылар, калай даһилекләр, шәрә калып, чын йөзләрен ачалар. Шушы минутта хакыйкать тәмен, тугры яшәүнең чын бәһасен, шигъриятнең пакьләндергеч дәвасын сизәсең. Тойгыларны чистарта торган шигърияткә мохтаҗлык безнең күкрәктә даими яшәп килә.

Мәскәүдә яшәгәндә Илдар укучылар арасында татар әдәбиятына карата җылы хисләр уятып, Муса Җәлилләр чорындагы традицияне яңартып китте. Бәлки шуңа күрә шушы чорда иҗат ителгән «Карурман» җыентыгы безгә, башкала укучыларына, бигрәк тә кадерледер.

Илдар Юзеев драматургия өлкәсендә дә зур уңышлыкларга ирешә. Бу турыда сүз кузгатсак, озаккарак китәр иде.

Илдар язган җырларның күбесе халык моңына әйләнде. «Яшьлек дустыма», «Тәнбоек», «Сине уйлап янам», «Янар чәчәк», «Бишек җыры», «Хыяллар», «Яшьлегемнең язы»... Юзеев халык җырларының нечкәлеген, тылсымын белә.

**«Яшь наратлар» көен җырлап киттең**
**Көмеш кыңгыраулы пар атта.**
**Озатып кайтам сине, карый-карый**
**Бәдрәләнеп үскән наратка.**
**Басылмады йөрәк ярсулары,**
**Басылса да юллар тузаны...**

Бу җыр Тукай «Пар ат»ының дәвамы булып ишетелә.

Татар халык җырларында читкә китүгә, аерылышуга аеручы зур урын бирелгән. Революциягә кадәр җирсезлек күпләрне бәхет эзләп читкә китәргә мәҗбүр иткән. Бүгенге көндә урбанизация, армия, укырга китү яшь егетләрне туктаусыз авылдан суырып алып тора. Аерылышу һәр кешенең башыннан үткән хәл. Бәлки шуңа күрә дә «Яшь наратлар» җыры безне дулкынландыра торгандыр? «Бәдрәләнеп үскән яшь нарат» безне озатып калган беренче ярны хәтерләтә, сәф, нечкә тойгылар уятып, йөрәкне ешрак тибәргә мәҗбүр итә. «Яшь наратлар» безнең шигъриятә Хәсән Туфан «Ак каен»ының гүзәл сеңелесе булып керде.

Илдар Юзеев — Тукай, Кандалый, Дәрдмәнд әсәрләрен өйрәнеп, Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрдән турыдан-туры сабак алып тәрбияләнгән шагыйрь. Безнең шигъриятебез әдәплелек, тыйнаклык белән көчле. Шушы кыйммәтле сыйфатны Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек ил агалары белән бергә урта буын вәкиле Илдар Юзеев та саклап килә.

Илдар Юзеев — шигъриятебезнең офыкларын киңәйткән, зур гуманистик проблемалар күтәргән, фикер тирәнлеге белән танылган шагыйрь. Аның иҗаты һаман ныгый бара. Ул язган шигырьләрнең вакыт үткән саен бәясе күтәрелә.

Флера Яркимбаева

# ЙОМШАК ҖИЛЛӘР БУЛЫП ИСӘРМЕН...

Европа китапханәләрендә, борынгы фәлсәфи трактатлар, әле һаман сере ачылмаган манускриптлар белән бергә, саргаеп беткән кәгазьләргә язып калдырылган татар җырлары саклана. Европаның тимер шкафларындагы вакытлар тузаны кунган иске фонограммаларда татар моңнары бикләнеп ята. Төне әсирлектә булса да, җаны туган илдән аерылмаган якташларыбызның сагышлы авазы җиде дистә елдан соң да чит-ят туфрак аша яңгырап ишетелә... Чыннан да, җыр язмышы — кош язмышы сыман. Җырчы-шагыйрь күңелендә канат чыгара да, ерак юлларга чыга, еллар, илләр аша урап кайта ул.

**Сагындырды Агыйделнең камышы,**
**Челтерәп аккан чишмә тавышы.**

**Сагындырды сызылып таңнар атуы,**
**Әнкәемнең иркәләп уятуы...**

Әлеге шигырен язганда, үзенең туып-үскән төбәген, «алтын балачагы узган» болыннарны сагынып искә алгандыр шагыйрь. Аңа көй язган композитор С. Садыйкова да ихтимал, бу сүзләрдә чылтырап аккан чишмә кебек яшьлек елларының кайтавазын ишеткәндер. Ләкин ул чакта әле шушы җыр илләр гизәр, фин татарларының моңы белән әретелеп, кабат Идел ярларына кайтыр дип беркем дә күз алдына китерә алмагандыр.

Хәер, Илдар Юзеевның гаҗәеп язмышка тап булган башка әсәрләре дә аз түгел. «Ике малай китә армиягә» дигән көю һәм шашкын җырның тарихын гына искә төшерик. Аңа шагыйрь үзе үк «Яшьләр тарафыннан көй чыгарылган. Авторы билгесез» дип искәрмә ясый. Күрәсең, җырның халыклашып китүе, шагыйрьнең халыкчанлыгы шулай башланадыр инде. Илдар Юзеевның поэмаларында да җыр булып канат чыгарган юллар аз түгел. «Таныш моңнар» поэмасының заманында радиопостановка итеп эшләнүенә үзләре үк көй сорап торган җырлар сәбәпче булгандыр. Композитор Шакир Мәҗитовны да, ул чакта әле яңа гына сәхнәдә күренә башлаган консерватория студенты Илһам Шакировны да көе-моңы саркылып торган бу әсәр тикмәгә генә җәлеп итмәгәндер.

**Йомшак җилләр булып исәрмен дә,**
**Тәрәзәңне килеп кагармын,**
**Мин кагармын, син качарсың, —**
**Йөрәгемә утлар ягармын...**

Поэманың язылуына инде егерме биш ел, ләкин ул һаман телдән төшми, күңелдән китми, фольклор экспедицияләрендә булган студентлардан сорагыз: төрле төбәкләрдәге халык аның бөтенләй кителмәгән урыннарын көйгә салып җырлап йөри. Ничә буын яшьләр «Таныш моңнар»ның төрле өзекләрен махсус җыр тексты язганын да көтеп тормый, шигъри сүзнең асылын үзе сайлап ала, җыр итә, мәңгеләштерә. «Миләүшә» поэмасыннан бер өзекнең «Сине уйлап янам» (Сафьян Ибраһимов музыкасы) исемле җырга әйләнеп бик тиз таралуы да — шуның бер мисалы.

Кайдан килә мондый популярлык? Хикмәт шагыйрьнең яшьлеккә хас күтәренке рухлы һәм кайнар йөрәкле булуында да, яңа ачылган чишмә кебек табигый һәм саф тавышында да. Җыр юлы — катлаулы юл. Тулысынча халык җырына әверелгән хәлдә үзенең авторына — Сибгат Хәкимгә әйләнеп кайткан «Юксыну»ны, Әхмәт Фәйзинең вафатыннан соң җыр булып уянган «Умырзая»ны искә төшерик. Барыбызга да мәгълүм булган Илдар Юзеев сүзләренә җырлана торган «Яшь наратлар» көе дә әнә шуңа охшаш катлаулы вакыйгалар аша уза. «Юзеев сүзләренә» дип басым ясау һич тә очраклы түгел. Шагыйрь бу җырның текстын өзер көйгә яза. Ә аның тарихы җырчы репертуарыннан башлана. Илһам Шакиров халыктан яңа бер көй отып кайткан, тик сүзләрен ничектер ошатып бетерми, шагыйрь дусларыннан ярдәм сорый... Шулай итеп, әлеге көй Мирсәет Яруллин эшкәртүендә, И. Юзеев сүзләре белән җырчылар репертуарына керә, халыкка кире кайта. Аны Җәүдәт Фәйзи дә ишетә һәм: «Бу бит минем сугышка кадәр үк иҗат иткән көем. Сүзләре генә Фатих Кәрим язганча түгел!» — дип гаҗәпкә кала. Төрле сәбәпләр белән җырның Фатих Кәрим язган сүзләре төшеп калган да, көен югалтасы килмәгән һәвәскәрләр аны үзләренчә җырлап йөри башлаганнар икән... Үз агышына гаҗәп тиң килеп торган яңа сүзләр — Илдар Юзеев сүзләре кушылмаган булса, бу көй бәлки бөтенләй онытылып калган булыр иде. Шагыйрьнең «Яшь наратлар» шигырен ни өчен Фатих Кәрим истәлегенә багышлавы да менә шул тарих белән бәйле.

**Әле дә булса минем хыялымда**
**Көмеш кыңгыраулар чыңлыйлар.**
**Урман буендагы яшь наратлар**
**Син калдырган көйне җырлыйлар.**

И. Юзеев шигырьләренә, гомумән музыкальлек хас, аның «Өчәү чыктык ерак юлга», «Таныш моңнар» кебек әсәрләрен турыдан-туры музыкаль поэмалар дип әйтергә мөмкин.

Юзеев җырлары турында сүз чыкканда, башта көйме, әллә сүзләрме язылган дигән сорауга җавап әллә кайчан әзер шикелле: күпчелек очракта аның шигыре алдан ук көй сорап, композиторга илһам бирүчән язылачак көйне үз артыннан ияртеп китүчән. Әмма шул ук вакытта композиторларның әзер көйләренә иҗат ителгән сүзләре дә җырга әверелә бара. «Яшь наратлар» хакында искә алып узган идек инде.

Шагыйрьнең яңа җырларыннан берсе — «Каршы ал, туган калам!» да әнә шулай яшь композитор Луиза Хәйретдинова тәкъдим иткән көй рухын кабул итү нәтиҗәсендә язылган.

Илдар Юзеевның композиторлар белән иҗади дуслыгы күптәннән килә. Аның шигырьләре Мирсәет Яруллин, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Фасил Әхмәтов һ. б.-лар иҗат иткән үзенчәлекле көйләргә җырлана. «Кайтам инде», «Серле чәчәк», «Мәтрүшкәләр» кебек җырлар әнә шундый көйләр канатында еракларга таралды, халыкның күңел байлыгына әверелде. Әле «Таныш моңнар» язылганчы ук, педагогия институты студентлары Илдар Юзеев белән Ләбиб Айтугановның «Төнбоек» һәм «Карлыганым, бөрлегәнем» исемле ике җыры яшьләр арасында популярлык казанып өлгергән иде. Шуннан бирле, гәрчә көй өчен текстлар язу белән махсус шөгыльләнмәсә дә, кабатланмас үзенчәлеккә ия булган җырлары шагыйрьне бөтен иҗаты буена озата килә. Илдар Юзеевның поэзиясенә хас сыйфатлар — халык иҗаты мотивларын яңа яктан ачу, фикер һәм хис ачыклыгы аның җырларында аеруча тирән чагылды. Шунлыктан алар күңелне сафландыралар, тыңлаучыларны чын мәгънәсендә дулкынландыралар.

Юзеевның сәхнә әсәрләрендәге җырлары да бик үзенчәлекле. Бер яктан, алар драматургия материалының лиризмын, шигъри аһәңен көчәйтәләр, шул ук вакытта мөстәкыйль яшәеш алып спектакльләргә караганда озынрак гомерле булып чыгалар, димәк, замандашыбыз зәвыгын тәрбияләүне дәвам итәләр. «Янар чәчәк» пьесасыннан берничә җыр (М. Яруллин музыкасы), «Бөркетләр кыяга оялый» водевиленнән «Бөркет турында баллада» (С. Садыйкова музыкасы), әнә шундый язмышлы булып чыктылар. Биш ел буе сәхнәдән төшмичә уйналып килгән «Кыр казлары артыннан» драмасындагы мәгълүм җыр да (М. Имашев музыкасы) хис-моң тирәнлеге белән безне җәлеп итә, конкретлыгы һәм зур гомумиләштерү көченә ия булуы белән уйландыра.

Шагыйрь бәйрәм көннәрендә дә, моңайган-сагышланган чакларда да җырлана торган киң эмоциональ диапазонлы җырлар иҗат итә. Аның һәр җыры диярлек яңа моң чишмәсе булып туа һәм халык күңеленә юл таба. Чөнки аларда заман рухы, замандашларыбызның бай һәм катлаулы эчке дөньясы ачыла. Шагыйрь тормышның үзе кебек үк гади да, катлаулы да булган табигыйлегенә ирешә. Шуңа күрә аның җырлары назга сусаган җанга йомшак җил булып кагыла, яңа офыкларга ашкынган күңелләрне көрәш байрагы булып алга әйди.

Рәфыйк Нәфиков

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ АНЫҢ ДАИРӘСЕ

Соңгы елларда алып барылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә Г. Тукай һәм Ф. Әмирханның социал-демократлар белән элемтәләре, алар белән бергә патша самодержавиесенә һәм буржуаз милләтчеләргә каршы алып барган көрәше хакында сөйли торган мәгълүматлар туплана килә. Аларның кайберләре хакында үткән ел «Казан утлары» журналында (11 сан) урнаштырылган бер мәкаләдә бәян ителгән иде. Әлеге мәкаләдә, мәсәлән, Г. Тукай һәм Ф. Әмирханның әдәби кичәләр һәм концертлар оештыруда катнашулары, ә җыем акчасы большевикларның Казан шәһәр комитеты кассасына тапшырылуы хакында да телгә алына. Архив документларыннан күренгәнчә, әлеге акчаның бер өлешенә үзәк большевистик матбугаты, шул исәптән ленинчыл «Правда» газетасы алдырылган. Прагада үткән партия конференциясенә делегат итеп А. Н. Догадовны җибәргәндә дә шул акча тотылган[1].

Шул рәвешчә, Г. Тукай һәм аның дусларының ленинчы большевикларга теләктәш булуы һәм аларга ярдәм күрсәтеп тору кебек тарихи мәгънәгә ия булган фактлар ачыклана, жандарм һәм полицейскийлар да үз вакытында күреп бетермәгән, эзенә төшәргә өлгермәгән серләр күзаллана...

Г. Тукай һәм аның даирәсенең тоткан юлы, алдынгы рус культурасы һәм әдәби хәрәкәте, шәрык дөньясы белән элемтәләре аларның тәрҗемә эшчәнлегендә дә ачык чагыла. Мәгълүм булганча, Г. Тукай әле «Әлгасрелҗәдид» журналын чыгарган чорда ук Бахның «Ачлык падишаһ» исемле брошюрасын татар теленә тәрҗемә итә. Бу хәл, әлбәттә, жандармерия күзеннән читтә калмый. Охранка өчен русчага тәрҗемә ителгән материаллар арасында шагыйрьнең «Тавыш» хакында, «Милләтчеләргә», «Китмибез» һәм башка шигырьләре белән бергә «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган әлеге мәкаләдән дә өзек китерелә[2].

Кара реакция чорында Г. Тукайның дуслары, нәкъ менә аның йогынтысында һәм якыннан катнашуында рус һәм чит ил классиклары әсәрләрен тәрҗемә итеп бастыру белән шөгыльләнүче түгәрәк оештырып җибәрәләр. Бу эшнең үзәгендә Ф. Әмирхан, С. Рахманкулов, И. Богданов, Г. Кәрам, Г. Сәйфелмөлеков, С. Сүнчәләй, К. Бәкер, В. Апанаевлар тора. Тәрҗемә әсәрләрен нәшер итүчеләр дә шул ук кешеләрнең фикердәш дуслары Г. Камал, бертуган Хөсәеновлар, Шәрәфләр, Г. Саинов була. Бу даирә шул чорда ук А. М. Горький, Л. Н. Толстой, В. Г. Короленко кебек атаклы рус язучылары белән үзара җылы элемтәләр урнаштыра.

Шул ук вакытта социал-демократлар белән булган хезмәттәшлек җепләре дә өзелми. Әле 1906 елда ук Казанда чыга торган «Азат» газетасында большевистик «Социал-демократ» газетасыннан алынган кайбер мәкаләләр тәрҗемә итеп басыла. 1905 елның 1 декабренда ук А. Камалов (Г. Камал турында сүз барса кирәк — Р. Н.)

---

[1] ТАССР дәүләт архивы, 199 фонд, 2322 эш, 233, 250, 251 кәгазь.
[2] Татарстан дәүләт архивы, 41 фонд, 11 тасвирлама, 2 эш, 139 кәгазь.

«Таң» җәмгыятендә «Донская речь»тән эшчеләр турындагы бер мәкаләне тәрҗемә итеп бастырып чыгара [1].

Шушы чорда татар укучыларына рус әдәбияты классиклары А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, Н. В. Гоголь, М. Ю. Лермонтовның аерым әсәрләре җиткерелә, бөек пролетар язучысы А. М. Горькийның кайбер әсәрләре татар телендә дөнья күрә. Мәсәлән, С. Рахманкулов тәрҗемәсендә 1909 елда А. М. Горькийның «Ике сукбай» хикәясе басыла [2], 1910 елда шул ук әдип В. Гюгоның «Вөҗдан газабы» тәрҗемәсен чыгара [3].

Татар әдипләре игътибарын аеруча Л. Н. Толстой җәлеп итә. Г. Тукай һәм аның иптәшләре бу олуг каләм иясенең әсәрләрен тирәнтен өйрәнәләр, аның мирасын татар укучысына җиткерергә тырышалар. 1908 елда Х. Әбүзаров әдипнең «Сурат каһүәханәсе» әсәрен тәрҗемә итеп бастыра [4]. Шул ук елны татар укучылары әдипнең кайбер башка әсәрләре белән дә таныша.

Тәрҗемәләр арасында прогрессив төрек әдипләре (Намикъ Камал һ. б.), шәрык шагыйрьләре һәм философлары (Әбү Насир әл-Фараби, Әбү-галә әл-Мәгарри) әсәрләре дә күренекле урын алып тора [5].

Олы галим И. Ю. Крачковский үле дип саналган борынгы гарәп теле һәм язуының Төньяк Кавказда берничә гасыр дәвамында бердәнбер фән теле һәм әдәби тел, эш язулары теле, кабилә-ара культура бәйләнешләре чарасы булып хезмәт иткәнлеген, ул телдә әдәби әсәрләр иҗат ителүен дәлилләп күрсәтте. «XIX йөздә яшәгән гарәп әдәбияты белгечләре әлеге оригиналь һәм үзенчә бөек күренешне һичбер урында җитди рәвештә телгә алмадылар: ихтимал, әгәр кулъязмалар шундый уйга килергә мәҗбүр итмәгән булса,— дип нәтиҗә ясый академик,— минем үземә дә ул күренеш билгесез калган булыр иде» [6].

Галим, әлеге күренешне гарәп телендәге әдәбиятлар үсешендә үзенчәлекле юнәлеш, кырый тармак, дип бәяли дә, Төньяк Кавказ халыкларының гарәп телле әдәбияты бер вакыт гарәп әдәбияты тарихында үз урынын алыр дигән ышаныч белдерә.

Гарәп һәм фарсы телле әдәбиятларның Төньяк Кавказда гына түгел, Урта Азиядә, Кырымда, Идел буенда да билгеле бер күләмдә яшәгәнлеген расларга тулы нигез бар.

Әбү Насир әл-Фарабиның биографиясен Идел буе татарлары гарәп телендә укып беләләр [7]. Шул ук бертуган Борһан һәм Гыйльметдин Шәрәфләр М. Хаккиның Ш. Мәрҗани мирасын яклап, гарәп телендә язган брошюрасын 1908 елда Казанда бастырып чыгаралар. Б. Шәрәф 1909 елда фарсы телендә газета чыгарырга җыена [8]. Ул ук «Сада», «Гүнәш», «Каспий»да языша. Дөнья мәдәниятындагы борынгы традицияләрдән бик мөһим бер тармак Россиядә, шул рәвешчә, рәсми фән үсеше ызаныннан бер читтәрәк торган килеш, электән үк яшәп килгән. Кешелек культурасының уртак хәзинәсен баетуда һәм иң югары казанышлар традициясен дәвам итүдә Россиянең төрки халыклары, аерым алганда, татарларның да роле шактый ачык күзаллана.

Мәдәни бәйләнешләр хакында сөйләгәндә әзербайҗан телендә чыккан «Дебистан» журналының кайбер саннарына тукталмый мөмкин түгел. Журналның 1908 елгы 9 нчы саны тулысынча күренекле әзербайҗан мәгърифәтчесе Гасан-бәк Меликов-Зардаби истәлегенә багышлана. Бу галим, шул ук «Дебистан» журналының 1906 ел 8 санында хәбәр ителгәнчә, кавказлы укучылар өчен ана теле дәреслеге программасын төзүдә якыннан катнашкан. Программа төзү комиссиясе эшенә исә Нариман Нариманов җитәкчелек иткән. Әлеге программа журналның 1906 елгы 5 нче санына кушымта рәвешендә басылып чыккан. Мәгърифәтче Зардаби һәм большевик Наримановның уртак иҗат җимеше булган бу хезмәт — азатлык хәрәкәтенең төрле агымнары арасындагы дәвамлылыкның бик матур үрнәге һәм ул илдәге башка төр-

---

[1] Шунда ук, 41 фонд, 11 тасвирлама, 2 эш, 104 кәгазь.
[2] ТАССР дәүләт архивы, 41 фонд, 11 тасвирлама, 5 эш, 91 кәгазь.
[3] Шунда ук, 4 эш, 16 кәгазь.
[4] Шунда ук, 29 кәгазь.
[5] Шунда ук, 3 эш, 15 кәгазь, 4 эш, 30 кәгазь, 5 эш, 102 кәгазь, 1908 елда Оренбург шәһәрендә басылган. Әл-Мәгарри хакында шул чорда ук Г. Тукай да язган.
[6] Крачковский И. Ю. Над арабскими рукописями, 4 басма. «Наука» нәшрияты, Мәскәү, 1965 ел, 62, 65, 184 битләр.
[7] ТАССР дәүләт архивы, 41 фонд, 11 тасвирлама, 3 эш, 15 кәгазь.
[8] Шунда ук, 4 эш, 30 кәгазь; 9 эш, 125—126 кәгазь.

ки халыкларның да уртак байлыгына әверелә. Шул ук елны бу хезмәт Уфада басылып та чыга [1].

Халык рухын тирәнтен тойган Г. Тукай, әдәбият дәреслеге төзү эшенә керешкәч, әлеге программаның төп положениеләренә таяна. Программаның «Халык тарихы», «Туган тел укыту», «Милли әдәбият» (проза әсәрләре һәм шигырьләр, дөнья классикасы үрнәкләре) кебек бүлекләре Г. Тукай әзерләп дөньяга чыгарган «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле хезмәттә үзәк урынны ала. Шагыйрь әдәби үрнәк сыйфатында дәреслеккә Г. Х. Андерсен әкиятен һәм «Кодатгу билик» әсәреннән бер өзек ала. Укыту программасына «Вакыт» газетасының тәкъдиме белән Г. Тукай шигырьләре дә кертелә [2].

Татар демократлары дәреслекләр бастыру эшенә киңрәк колач бирергә тырышалар. Казан университеты ярдәме белән басма хәрефләр алдырмакчы, кредитка булса да типография ялламакчы булалар. Уку китапларының исемлеген төзү, әзерләп бастыру эшенә җитәкчелек итү өчен даими комиссия дә төзелә. Аңа М. Корбангалиев кебек педагоглар белән бергә Г. Тукай, Ф. Әмирхан кертелә [3].

Яңа идеяләр уңдырышлы туфракка төшә, тормышка үтеп керә башлый. Әмма төп фаҗига — бөек илнең бөек халкы өстеннән хакимлек итеп, һәр яктылык әсәрен яралгы хәлендә үк юк итәргә әзер торучы түбән җанлы явыз затлар утыруында иде. Тормышны революцион үзгәртеп кору, өлгергән мәсьәләләрне хәл итү көннәре алда иде әле.

Башкалада патша ялчыларының тимер шкафларында Г. Тукай тарафыннан әле 1904 елда ук әзерләнгән «Әлгасрелҗәдид» журналы ята. Санкт-Петербург цензура комитеты аңы бастыруга рөхсәт бирми. Журналның Җаек каласыннан Р. Фәхретдиновка җибәрелгән караламасы 1911 елда тенту вакытында алынып, охранка кәгазьләре арасында эзсез югала. Тарихчылар һәм әдәбият галимнәреннән кем дә булса аны бәлки табар әле.

Гомумән, бу елларда хөкемдарлар биге астында, охранка досьеларында дистәләрчә китап кульязмалары һәм йөзләрчә әсәрләр хәрәкәтсез ятып кала, туган җиргә мәхәббәт хисләре белән янган күпме яшь каләм ияләре билгесезлеккә корбан була.

Татар шагыйрьләреннән Г. Тукай аеруча нык күзәтү астына алына. Аның барлык шигъри җыентыклары диярлек охранка досьеларына эләгә. Охранка «Уклар», «Әлгасрелҗәдид», «Ялт-йолт» журналларыннан күчермәләр, шигырьләрдән сүзгә-сүз тәрҗемәләр туплап килә [4]. Кара исемлеккә теркәлгән татар әдипләр арасында Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Н. Думави, Г. Колахметов, Ш. Камал исемнәре аеруча күзгә ташлана.

Шомарып беткән агентлар күпме генә тырышып карасалар да, Г. Тукайны панисламизм идеяләре таратуда гаепли алмыйлар. Аның шигъряте нигезендә яткан социаль мотивлар гаять ачык һәм көчле яңгырый.

Патша жандармериясе татар шагыйрьләре иҗатын даими рәвештә игътибар үзәгендә тота, рус теленә сүзгә-сүз тәрҗемә иттереп күзәтеп бара. Мәсәлән, С. Сүнчәләйнең 1911 ел, 3 февраль көнне «Вакыт» газетасы редакторына җибәргән бер шигырен жандарм ялчылары менә болай «укыйлар»:

Обратил я свои взоры по окрестностям,  
Мрак и дикость одолевают государство;  
Годящихся людей берут, продают и ребят,  
Добрую правду привлекает тюрьма [5].

Самодержавие идеологлары, әлбәттә, татарларның тарих гыйлеме белән шөгыльләнүенә катгый каршы була. Мәсәлән, Н. Надиевнең тарих буенча дәреслегендә

---

[1] ТАССР дәүләт архивы, 41 фонд, 11 тасвирлама, 8 эш, 118 кәгазь.

[2] ТАССР дәүләт архивы, 41 фонд, 11 тасвирлана, 8 эш, 136 кәгазь. Соңгы факт Таврический губернасы Перекоп өязе халык училищелары инспекторы, бер үк вакытта мөселман эшләре буенча белгеч сыйфатында Казан губерна жандарм идарәсенә дә хезмәт итүче А. Горячкин дигән бәрәүнең аеруча кәефен җибәрә.

[3] ТАССР дәүләт архивы. 41 фонд, 11 тасвирлама, 9 эш, 121 кәгазь.

[4] ТАССР дәүләт архивы, шунда ук, 1 эш, 124, 222 кәгазь; 2 эш, 34; 100 кәгазь; 3 эш, 190 кәгазь; 4 эш, 23, 50 кәгазь; 5 эш, 88, 102 кәгазь; 6 эш, 43, 284 кәгазь, 7 эш, 33, 34 кәгазь, 8 эш, 133, 135 кәгазь; 9 эш, 120, 150, 151, 152 кәгазь, фонд 199, 1 тасвирлама, 2086 эш, 96 кәгазь, 3458 эш, 44, 46 кәгазь; 2121 эш, 12, 22 эш.

[5] Шунда ук 41 фонд, 1 тасвирлама, 9 эш, 226 кәгазь.

власть әһелләренә татарлар башка халыклардан ким түгел дигән фикер ошамый. Шәрыкнең бөек фикер ияләре Әбүгалисина, әл-Бируни, әл-Фараби, борынгы грек философлары, дөньяның төрле халыклары яшәеше турындагы материаллар бастыруы белән «Шура» журналы да хөкемдарларның ризасызлыгын тудыра. Журналның редакторы һәм нәшире Р. Фәхретдинов укучыларны тарихи мәсьәләләр белән кызыксындырырга омтыла, тарихны өйрәнергә өнди, тарих гыйлеменнән хәбәрдар булмаган кешене диңгездә идарәсез калган корабка тиңли [1].

Илдәге башка халыкларның да алдынгы вәкилләре хәрәкәткә килә, социаль һәм милли азатлык өчен көрәшкә күтәрелә. Шымчылар үзбәк телендә язылган шундый бер кульязма табып алалар: «Падишабыз дөянең нәкъ үзе кебек: кая таба тартсаң, шунда бара», — диелә анда [2]. Үсәргән волосте Чиянчур авылында яшәүче башкорт кешесе Мөхәммәт-Гариф Татлыбаевтан башкорт халкын йокысыннан уянып, үз хокуклары өчен көрәшкә башларга чакырган шигырь табып алына [3]. Ю. Кюфаяев фамилияле автор 1907 елда бертуган Шәрәфләр типографиясендә казакъ телендә «Казакъның хәзерге хәле. Сары-Аркага кем хуҗа» дигән брошюра бастырып чыгара. Автор анда казакъ җырләрен талаучыларны фаш итә, патша самодержавиесенә каршы көрәштә казакъ, үзбәк һәм башка халыкларның бердәмлеген яклый [4].

Патша цензурасы тарафыннан эзәрлекләнгән демократик матбугат белән рәттән рәсми власть органнары чыгарып килгән китапларга күз төшерү дә гыйбрәтле нәтиҗәләргә китерә. «Православный Собеседник» журналының «Инородческое обозрение» дигән кушымтасында «Агымдагы кыргыз әдәбиятына күзәтү» дигән язма урнаштырылган [5]. Биредә бер ел эчендә Казанда басылган кулланмалар хакында мәгълүматлар тупланган.

Арада «Окуу куралы» дип исемләнгән җыентык игътибарны җәлеп итә. Дәреслектә казакъ авторларының шигырь, хикәяләре, шулай ук русчадан кайбер тәрҗемәләр бирелә. Оригинал әсәрләр арасында И. Алтынсарин, Ә. Галиев, М. Жумабаев, И. Кунанбаев әсәрләре бар. Мондый китапларны төзүчеләрнең казакъ әдәбиятына Г. Тукай йогынтысын аңлап эш итүләре дә күренә. К. А. Абдуллинның 1914 елда Казанда басылып чыккан «Уран» исемле җыентыгында Тукай шигырьләреннән казакъ теленә тәрҗемәләрне һәм аңа иярәп язылган үрнәкләрне очратабыз.

«Инородческое обозрение» кушымтасының ахырында «Мөселман татарлар» исемле мәкалә урнаштырылган. Билгесез автор анда «яңа татар милләте башында» торучылар исемлегенә Г. Тукайны («инде теге дөньяда» дип әйтергә онытмыйча), Ф. Әмирхан һәм Г. Камалны да кертә. Мәкаләдә казакълар арасында да азатлык хәрәкәте башында торучылар күтәрелеп килүе күрсәтелә.

Менә шундый басмаларны, гәрчә аларда кайбер этнографик элементлар, фольклор үрнәкләре булуга да карамастан, прогрессив күренеш дип санап булмый иде. Чөнки алар асылда, Бөек Октябрьгә кадәрге рәсми тарих гыйлемендәгечә, азчылык халыкларның ил тарихында тоткан урынын һәм ролен, рухи үсешләрен кечерәйтеп, гарипләндереп күрсәтәләр. Тарих белеме белән махсус шөгыльләнми торган кешеләр алдында бу халыклар арттә калган, түбән кавемнәр булып күзалландырыла.

Әлеге характердагы материаллар Россия империясенең караңгы бер чорында халык шагыйре Г. Тукайның нинди олы оптимизмга ия булуын тулырак, ачыграк күз алдына китерергә ярдәм итә. Ул царизм һәм аның кара көчләренә каршы тигезсез көрәш алып барган бөтенроссия шагыйре сыйфатында күз алдына баса.

Кырыс тарихи шартларда котылгысыз булган югалтуларны күздә тоткан хәлдә, шагыйрьнең биографиясе, иҗаты тагын да тулырак, ачыграк аңлашыла. Охранканың тупас эшләнгән юлга-юл тәрҗемәләре, шымчыларның яшертен мәгълүматлары, Тукай даирәсендәге кешеләрнең хатлары да тикшеренүчегә шактый мәгълүмат бирә.

Үзәк матбугатта күренгән «Тукай һәм «Мәгариф» исемле мәкалә кызыксыну уятты [6]. Анда педагогия фәннәре кандидаты Ә. Сәгыйдова укучыларны шагыйрьнең моңарчы басылмаган бер хаты белән таныштыра. Бу мәкаләсендә Ә. Сәгыйдова

---

[1] Шунда ук, 11 тасвирлама, 8 эш, 122, 123, 141 кәгазь.
[2] Шунда ук, 91 кәгазь.
[3] Шунда ук, 7 эш, 31, 92 кәгазь.
[4] Шунда ук, 1 эш, 222 кәгазь; 7 эш, 34 кәгазь; 9 эш, 153 кәгазь.
[5] 1915 елның март санына кушымта, 10 нчы китап, Казан, 798—802 битләр.
[6] «Дружба народов» журналы, 1967 ел, 8 сан, 245—246 битләр.

Г. Тукай белән агале-энеле Шәрәфләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне өйрәнү мәсьәләсен куя һәм Г. Тукайның 1907 елда Уральскидан язган бер хатын китерә. Автор Г. Тукайның Г. Шәрәфкә язган хатлары бишәү дип раслый. Әлбәттә, төп нөхсәләре сакланып калган тәкъдирдә, бу хатлар Г. Тукай биографиясен өйрәнүдә өстәмә һәм кыйммәтле чыганак булыр иде.

Хәзергә исә бертуган Шәрәфләрнең бер-берсенә язган хатларыннан алынган һәм Тукайга кагылышлы кайбер мәгълүматлар белән танышып үтик. Сүз Шәрәфләрдә тентү вакытында алынган хатларның төп нөхсәләреннән Казан губернасы жандарм идарәсе өчен тәрҗемә иттерелгән өзекләр турында бара. Г. Шәрәф 1908 елның 31 августында Б. Шәрәфкә язган хатында: «Тукай Мәкәрҗә ярминкәсеннән кайтып, Болгар номерларында урнашты. Анда Солтан, Тукай, Г. Камал утырышлар үткәрәләр. Членлык акчасы мәсьәләсендә «кытай бомбалары» күбрәк фикер каршылыклары килеп чыкты. Мин карап кына утырдым», — дип хәбәр итә[1]. Хатларның берсендә (1909 ел, 29 август) «Гасыр» нәшрияты бастырып чыгарган бер китапка кагылышлы мәкаләне басмау турында Г. Тукай үтенече бәян ителә[2]. Г. Тукай турындагы мондый мәгълүматлар кайбер нәрсәләрне ачыклау, аңлатуны сорый. Бу эшкә әдәбият галимнәре дә алынса, яхшы булыр иде.

Г. Тукай ялгыз герой булмаган, ул һәрчак халыкның йөрәк тибешен тоеп яшәгән, аңа тугрылыклы дуслары һәм иптәшләре ярдәм иткән. Шагыйрьгә якын торган кешеләрнең берсе, Х. Ямашевның дусты А. Мостафин, Г. Шәрәфнең 1911 ел, 19 январьда язган хатыннан күренгәнчә, сайлау компаниясе якынлашкан көннәрдә сул группа исеменнән газета чыгара башларга ниятләнә. Г. Гобәйдуллин тирәсенә туплангган бүтән студентлар, Г. Шәрәф әйтүенчә, аларга каршы бармакчылар, «әгәр алар чыгара икән, без дә чыгарачакбыз, — диләр. — Яшьләрнең икегә бүленеп куюы да ихтимал»[3].

Г. Тукай һәм аның фикердәшләре һәр адымда калын кисәле байларга, карагрүһчы Сәйдәшләргә каршы торганнар. А. Мостафин 1910 елның 9 мартында язган бер хатында, мәсәлән, Мөхәммәтҗан Сәйдәшевның Котлыбаев турында мәкалә басылып чыгуына бик ачуы кабарган ди[4].

Мәгълүм булганча, И. М. Котлыбаев — демократ карашлы врач, алдынгы матбугат һәм театр үсешенә билгеле бер өлеш керткән кеше.

Кайбер фактлар жандармнар һәм полицейскийларга күп еллар үткәннән соң гына мәгълүм була. Әйтик, Ф. Әмирханның әтисе — мулла З. Әмирхан 1906 елда шәкертләр һәм зыялы яшьләр алдында кадимчеләргә кискен рәвештә каршы чыгып сөйләгән, бу эшен ул 1910 елда да дәвам иттергән[5]. Беренче рус революциясе елларында яшьләр җыелышларында Борһан Шәрәф тә кискен чыгышлар ясаган. Мәсәлән, бер җыелышта ул «мөселманнарга хөкүмәттән хокук таләп итәргә, автономия алырга кирәк», дип сөйләгән; ә бирмиләр икән, «моның өчен кан коярга кирәк», чөнки властьны үз кулыбызга алырга вакыт җитте», дип «котны тараткан»[6]. Жандармерия шымчысы Ф. М. Мөхетдинов 1909 елның 3 июнендә жандарм идарәсенә Б. Шәрәфне «чиктән тыш революцион юнәлешле кеше», язган мәкаләләрендә хөкүмәткә кул күтәрә һәм «мөселманнарны революцион чыгышларга котырта», дип күрсәтә[7].

1906 елның апрелендә Казан полицмейстеры губерна жандарм идарәсе башлыгына Болгар номерларында торучы Борһан һәм Гыйльметдин Шәрәфовлар (Борһан «Казан мөхбире» газетасы секретаре булып эшли) «гектограф белән татарча прокламацияләр басалар», дип хәбәр итә[8].

Документлардан күренгәнчә, Б. Шәрәф үзенең укучылары белән элемтәдә тора, алар кулыннан янсә Ф. Кәримидән 1906 елны «Марсельеза»ның татарчага тәрҗемәсен һәм «Шәкертләр җыры»н соратып ала[9].

---

[1] ТАССР дәүләт архивы 41 фонд, 11 тасвирлама, 9 эш, 132 кәгазь.
[2] Шунда ук, 129 кәгазь.
[3] Шунда ук, 132 кәгазь.
[4] Шунда ук, 129 кәгазь.
[5] ТАССР дәүләт архивы. 41 фонд, 11 тасвирлама, 6 эш, 209, 246, 262 кәгазь.
[6] Шунда ук, 210, 211, 241 кәгазь.
[7] Шунда ук, 199 фонд, 1 тасвирлама, 1729 эш. 42 кәгазь.
[8] ТАССР дәүләт архивы, 199 фонд, 1 тасвирлама, 1212 эш, 66 кәгазь.
[9] Шунда ук, 41 фонд, 11 тасвирлама, 9 эш, 130 кәгазь; 199 фонд, 1 тасвирлама, 1025 эш, 289 кәгазь.

Петербург татар яшьләре дә шул ук чорда татарча журнал чыгару нияте белән яналар, шәһәр яшьләре вәкилләре журналга «каләмнәре белән булышлык күрсәтергә вәгъдә итәләр»; шул ук яшьләр русча-татарча газета булдыру юлында башлап йөриләр[1]. Алдынгы татар студентлары илдәге иҗтимагый вакыйгалар белән якыннан кызыксыналар, матбугат битләрендә һәм җыелышларда халыкларны бер-беренә каршы куярга маташучыларны фаш итәләр. «Россия» газетасы редакторы ярдәмчесе Янчевецкий дигән берәү Петербург славян җәмгыяте утырышларының берсендә татарларга яла яга торган чыгыш ясый. Утырышта катнашкан ике яшь кеше аның уйдырмасын кире кагып, татарларның милли уяну һәм цивилизация казанышларын үзләштерүгә омтылышын исбатлыйлар. Яла ягучыларга фәнни нигезләнгән җавап бирү өчен яшьләр профессор В. В. Бартольд һәм приват-доцент А. Н. Самойлович кебек галимнәрне татар матбугаты битләрендә әлеге мәсьәлә буенча чыгыш ясарга чакыралар[2].

*
* *

Яшь татар революцион-демократларының көрәш эзләре безне Киев шәһәренә дә алып килә. 1913 елның 17 апреле көнне бирердә студентлар җыенында жандармнар язучы Галимҗан Ибраһимовны кулга алалар. Моңарчы чыккан хезмәтләрдә бу хакта язылган булса да, архив документларыннан яңа фактлар өстәлеп тора. Тентү вакытында Г. Ибраһимовтан бөтен бер китапханә тартып алынган: Казанның «Мәгариф», «Гасыр», «Үрнәк» һ. б. нәшриятларында басылып чыккан иң яхшы басмалар, Г. Ибраһимовның үз кульязмалары, Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Н. Думави, М. Укмаси әсәрләре, «Аң», «Ялт-йолт», «Мәктәп», «Акмолла» һ. б. журналлар, русча һәм татарча газеталар, А. М. Горькийның «Ана» романы, Гасан-бәк Зардабиның «Җир, су, һава», Г. Бичер-Стоу, Намикъ Камал әсәрләренең тәрҗемәләре һ. б. Г. Ибраһимовтан алынган әдәбиятның шактый өлеше 1912 елны РСДРПның Казан комитеты китапханәсендә дә булган.

Татар әдәбиятына хас интернационализм рухы бөек рус халкына гына түгел, рәсми властьлар тарафыннан халыкка да саналмаган азчылык милләтләргә карата да тирән хөрмәт хисендә, үзара якын мөнәсәбәтләрдә ачык чагылды. Якыннан аралашу, уртак рухи мирасны үзләштерү, төрле халыкларның милли традицияләрен өйрәнү татар әдипләренең иҗади үсешенә дә нык ярдәм итте. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар Россиянең мәгърифәтле кешеләренә билгеле әдипләр иде. Интернациональ бердәмлек рухы бу күренекле каләм ияләренең социаль аңы, гражданлык активлыгы үсүгә этәргеч бирде.

Г. Ибраһимовны һәм аның иптәшләрен менә бу прокламация, әлбәттә, дулкынландырмый кала алмый: «Иптәшләр,— диелә прокламациядә,— рәсми Россия, канлы тәхет тирәсенә җыелып... Романовлар йортының 300 еллыгын бәйрәм итә... Романовлар өере бөтенхалык тантанасы иллюзиясен тудырырга тырышып көчәнә бирсен. «Саф тән» вәкилләре ашыга-кабалана үзләренең ялган белән тулы йомгакларын ясый бирсеннәр. Тарих аларга гадел хөкемен чыгарыр... Бу халык бәйрәме түгел, рус гражданы кол итүчеләр шатлыгын уртаклашмас». Киев университеты советы исеменнән язылган бу мөрәҗәгатьтә патша династиясенең 300 еллыгы кайгы көне буларак бәяләнә: «Самодержавие белән көрәштә 300 ел буе Россиянең иң алдынгы көчләре һәлак була килде»[3].

Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан кебек көрәшчеләрне милләтчелектә яисә панисламизмда гаепләү мөмкин түгел иде. Төрле милләт вәкилләре, студентлар Украина туфрагында бер-берсенә дуслык кулын суздылар. Алар Мәскәү, Петербургта гына түгел, Казан, Томск, Тамбов, Троицк, Оса һәм башка шәһәрләрдә яшәгән фикердәшләре белән дә элемтәдә иделәр.

Г. Ибраһимовның танышлары арасында аның карашларын уртаклашмаган кеше-

---

[1] Шунда ук, 199 фонд, 2329 эш, 37 кәгазь.
[2] Шунда ук 199 фонд, 2329 эш, 224 кәгазь.
[3] Шунда ук, 1919 фонд, 2427 эш, 196 кәгазь.

ләр дә булмады түгел. Соңрак охранка агенты булып чыккан Х. Кайбышев 1912 елның 28 декабрендә Казан яшьләре хакында болай дип яза: «Сизелә ки, яшьләрне бер ноктага туплауга караганда комнан аркан ишү җиңелрәк булыр. Башка шәһәрләрдә дә яшьләр шул бер үк. Кавказ егетләрен мин ярата алмыйм. Карашлары үзләре яшәгән тау араларындагы упкыннар кебек үк тар... фикерләре канатсыз... Хәлиуллла студентларны бергә берләштерү максаты белән килгән иде: без каршы төштек»[1]. Охранка башында торучыларга нәкъ шул кирәк булган да, хезмәтчеләрен алар менә шундый гамәлгә өйрәткәннәр дә.

Г. Ибраһимовның тоткан юлы исә бөтенләй башка. Х. Кайбышевның хыянәте турында белмәгән килеш тә, әдип аның кыйблалсыз бәндә, өметсез эгоист икәнен аңлый. Г. Ибраһимов әзербайҗан, казакъ, украин егетләре Ф. Ордубатский, Ш. Рөстәмбеков, Г. Ахундов, Д. Вәзиров, Сона-ханым Ахундова, Мир-Якуб Мехтиев, А. Имамбаевлар белән дуслаша.

Ә Казанда шушы ук чорда Х. Ямашев, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Колахметов, Г. Камаллар нигезен салган «Шәрык» клубы актив эшләп килә һәм халыклар дуслыгының нигез ташларын ныгытуга үз өлешен кертә. Клубның эшли башлавын РСДРПның Казан комитеты газетасы «Волжский листок» үз вакытында хуплап каршы ала һәм яшьләрне демократик рухта тәрбияләү эшендә аңа уңыш тели[2].

Патша охранкасы да «Шәрык» клубының эшли башлавын күрми калмый һәм 90 нчы номер белән аңа махсус эш торгыза. Жандармерия агентлары 1911 елдан башлап клуб әгъзалары артыннан махсус күзәтү оештыра, алынган мәгълүматлар, урындагы жандарм идарәсеннән тыш, Саратов шәһәрендә урнашкан Идел буе Охранное отделениесенә җиткерелә бара[3].

Жандармерия Х. Ямашев, И. Әхтәмов исемнәре белән бергә шагыйрь Г. Тукайга зур игътибар бирә[3], һәм ул әлеге клубны оештыручылар, җитәкләүчеләр «Шәрык» клубын үзләренең үзәк пунктына, мөселман халык университетына әверелдерү максатын куеп эш итәләр, дип бик урынлы шикләнә[5].

Казан шәһәренең буржуаз рус матбугаты мөселман шагыйрьләре арасында беренче урында — Габдулла Тукаев, ул «хәзерге вакытта бик авыру — чахотканың соңгы стадиясендә», шулай ук М. Гафури, прозаиклардан Г. Камал, Ф. Әмирхан әеруча популяр, дип яза[6]. Рус авторларыннан татарларның бигрәк тә Л. Н. Толстой, И. С. Тургенев, А. С. Пушкин, Н. В. Гоголь, М. Ю. Лермонтов, А. М. Горький, чит ил әдипләреннән Байрон һәм Шекспир әсәрләрен яратып укулары әйтелә.

Г. Тукайга 1913 елның 16 гыйнварында бу мәкаләне укуы никадәр авыр булуын аңлавы кыен түгел. Халык тарафыннан тулысынча танылу, чынлыкта халык шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелү һәм үзенә кешә буларак үлем карары...

Татар халкының йолдызы сүнү алдында торганда да, Ф. Әмирхан теркәп калдырганча, золымга каршы, халкының якты киләчәген яклап көрәшүен туктатмый. Ул киләчәккә ышанып үлә.

Г. Тукай мирасы, әлбәттә, аның әдәби иҗаты белән чикләнми. Аның иҗтимагый эшчәнлеге йогынтысында барлыкка килгән яисә оештыруда шагыйрь турыдан-туры үзе катнашкан демократик җәмгыять оешмаларры озак еллар буе эшчәнлекләрен дәвам иттерделәр һәм халыкны, бигрәк тә яшь буынны революцион көрәшләргә, тормышны тамырыннан үзгәртеп кору өчен фидакарь хезмәткә әзерләүдә гаять зур эш күрсәттеләр. Тукайлар тәрбияләгән буын, аларның шәкертләре Совет власте өчен батыр көрәшчеләр булып үсте, Кызыл Армия сафларында алар Колчакны, Деникин һәм Врангельне, алаш-урдачыларны һәм басмачыларны тар-мар итүдә катнашты, илгә һәм халыкка ирек яулап алды.

---

[1] ТАССР дәүләт архивы, 199 фонд, 2427 эш, 197 кәгазь.
[2] «Волжский листок», 1907 ел, 8 декабрь, 552 сан.
[3] ТАССР дәүләт архивы. 199 фонд, 1 тасвирлама, 2065 эш, 17, 18, 20, 22 кәгазь.
[4] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 тасвирлама, 44 эш, 98 кәгазь, 25 эш, 63, 64 кәгазь.
[5] Саратов өлкәсе дәүләт архивы. 51 фонд, 1 тасвирлама, 26 эш, 363, 490 кәгазь; 44 эш, 71 кәгазь.
[6] «Камско-Волжская речь», 1913 ел, 16 гыйнвар саны. «Что читают мусульмане» исемле мәкалә.

Афзал Шамов

# ХАТИРӘЛӘРДӘН БЕРСЕ

Була шундый иптәшләр,— үзләренең эшләре, кешеләргә булган мөнәсәбәтләре, тормышка карашлары, уйлары, фикерләре, югары әхлак сыйфатлары белән алар күңелеңә шулчаклы кереп кала, еллар үткәч тә аларны онытa алмыйсың, әледән-әле яхшы сүзләр белән искә аласың, кемнәргәдер үрнәк итеп куясың, кыскасы, алар турындагы матур хатирәләр безнең белән бергә киләчәк елларга бара.

Тәнкыйтьче Гомәр Гали дә күңелдә шундый яхшы тәэсир калдырган кешеләрнең берсе.

Ул миңа әле дә исәндер кебек тоела. Әйтерсең, ул кайдадыр, бездән еракта яши, йөри, гадәтенчә, һаман ашыга, ашкына, матур хыяллар белән яна, якыннарын, иптәшләрен, танышларын очраткач, алар белән елмаеп исәнләшә, үтеп барышлый гына булса да, хәлләрен, исәнлекләрен сораша, аларга бер-ике җылы сүз әйтә, я булмаса оста, мавыктыргыч итеп берәр кызыклы вакыйга сөйләп ала...

Г. Гали бик үзенчәлекле холык-фигыльгә ия иде. 1931—1935 елларда миңа аның белән бергә Татарстан китап нәшриятында эшләргә туры килде. Ул матур әдәбият секторы мөдире, ә мин — шул секторның редакторы, эшем белән аңа буйсына идем.

Баштарак китап нәшрияты хәзерге Ленин урамындагы «Пассаж»га, аның аскы катындагы бүлмәләргә урнашкан иде. Бүлмәләр зур, биек, озынча. Берсе дә редакция өчен җайланмаган. Тәрәзәләре көнбатышка караганлыктан, иртә белән дә, көндез дә кояш керми, һәрвакыт диярлек караңгылык, күңелсезлек хөкем сөрә. Тик җәй көннәрендә генә, анда да кичкә таба, бүлмәләребезгә кояш нурларының койрыклары гына чагылгалап китә.

Бүлмәбез зур булганга, утырып эшләүчеләр дә күп иде. Матур әдәбияттан тыш, анда тагын ике сектор урнашкан: дәреслекләр һәм авыл хуҗалыгы әдәбияты секторы, аларның редакторлары. Кыскасы, кеше җитәрлек. Шуның өстенә эш белән килүчеләр янсә узганда-барганда болай гына, сәлам бирергә генә кереп чыгучылар да аз түгел. Кай сәгатьләрдә бүлмәбез эш белән шөгыльләнә алмаслык дәрәҗәдә шаулап тора. Тик бу — әйбәт шау-шу, әдәби шау-шу, иҗат яки берәр кулъязма турындагы бәхәс шау-шуы.

Г. Гали эшкә иртәнге сәгать тугызда түгел, ә бераз соңгарак калып килә иде. Аңа шулай рөхсәт ителгән. Чөнки ул Казан медицина институты аспирантурасында татар әдәбияты тарихы укыта, шуның өстенә берничә урында җәмәгать эше дә алып бара: ТАПП (Татар пролетариат язучылары асоциациясе) бюросы һәм әдәби журнал редколлегиясе члены...

Гомәр редакциягә кайчан гына килмәсен, аның бүлмәгә керүен сизми калмыйсың. Ул, пальто җапыйларын чишеп җибәреп, һәрвакыттагыча бөселеп торган калын кара портфелен култыгына кыстырган килеш, ашыгып, бераз алпан-тилпән атлабрак килеп керә, исәнләшә, өс киемен сала һәм шундук, хәтта ишектән кергәндә үк, урамда үзе тап булган берәр кызык хәлне сөйләргә керешә. (Күпләрнең күзенә чалынмый торган кызыклы вакыйгаларны, аерым кешеләрнең кайбер гадәтләрен, холыкларын, күз карашларын һәм башка үзенчәлекле якларын тиз тотып алучан иде ул). Булмаса, яңа берәр анекдот сөйләп ала. Ничектер, аның белән бергә безнең караңгы бүлмәбезгә яктылык кергән, нур кергән, саф һава кергән сыман булып китә. Шундый күтәренке рух алып килә белә иде ул кешеләргә. Хәер, бүлмәгә килеп кергәнче үк инде аның нәшриятка килгәнен сизәсең, чөнки кайдадыр, коридордамы, әллә күрше бүлмәләрнең берсендәме аның тавышы ишетелә, кемгәдер нәрсәдер сөйли, кемдер кычкырып көлә...

Ашыгып килеп кергән кебек, берәр эш белән ашыгып чыгып китә дә белә иде

ул. Ничектер, мин аның ашыкмаган чагын хәтерләмим кебек. Ашыкмаган чаклары да күп булган билгеле, ләкин минем өчен ул һаман каядыр ашкына кебек хәтердә калган.

Калын-калын кулъязмаларны да ул бик тиз карап чыга. Күбесен башыннан ахырына чаклы укымый, актара, аерым юлларын күздән кичерә, әсәр турында башлангыч бер фикергә килә. Әгәр әсәр өметле, игътибарны җәлеп итәрлек булса, аны әлеге бүселгән портфеленә дыңгычлап тутырып яисә икесен бергә кочаклап тотып, өенә алып кайтып китә, тынычта укый. Өметсез булып тоелган кулъязмаларны миңа бирә. Мин аларны я үзем укып чыгам, я берәр иптәшкә рецензиягә тапшырам.

Ул кайчак кулъязмаларның эчтәлеген укып түгел хәтта иснәп тә беләдер иде кебек. Чөнки ул өстән-өстән генә карап чыккан кулъязмалар турында да авторларны канәгатьләндерерлек, ышандырырлык дәрәҗәдә сөйләшә ала. Шулай да әсәр турындагы хәлиткеч фикерен кулъязманы тәмам укыганнан соң гына әйтә иде. Әгәр кулъязманы өенә алып кайтып игътибар белән укып чыккан булса, автор белән бик төпле, тәфсилле итеп сөйләшә, әсәрнең аерым моментларына, образларына, теленә, сюжетына җентекләп туктала, аларны анализлый, уңышлы якларын, кимчелекләрен күрсәтә, киңәшләр бирә. Язучылар аның сүзенә, киңәшенә колак салалар, күп очракта тәнкыйтен кабул итәләр, әсәрләрен алып китеп, төзәтеп китерәләр иде.

Киңәшләренә колак салмаучылар да була иде, билгеле. Бәхәсләшәләр, аның фикерен кире кагалар, кемнәрнеңдер авторитетлы сүзләренә, чәй янында биргән бәяләренә таяналар, әсәрләрен тәмам эшләнеп беткән, камилләшкән итеп санYйлар, бастырып чыгарырга тырышалар.

Әле дә хәтердә. Утызынчы еллар башында бер йөгәнсез «шагыйрь» бар иде, үзен өлгергән, танылган, зур шагыйрь итеп саный, үзеннән башка берәүне дә танымый иде. Шул «шагыйрь» бер көнне Г. Галигә гаилә темасына язылган бик озын бер поэма алып килде, аны тиз арада бастырып чыгаруны үтенде. Үтенде дип әйтсәк, дөрес булып бетмәс,— таләп итте. Аның фикеренчә, поэма иң соңгы алымнар белән оста, яхшы язылган, каләм төртерлек урын да калмаган. Аны бары тиз арада бастырып чыгарырга да яхшы әсәрләргә сусаган укучыларга таратасы гына икән.

Г. Гали поэманы укырга өенә алды, автор белән иртәгесен редакциядә очрашырга булдылар. Әлеге очрашу тыныч узмады, каты бәхәскә әйләнеп китте. Гомәр поэманың буен буйга, аркылысын аркылыга сүтеп, аның шигъри әсәр булып җитмәвен әйтте, басарлык түгел, диде. «Шагыйрь» гасибиланып, үҗәтләнеп, үрә торды, әсәрнең камиллеген дәлилләр белән түгел, ә бугазы белән исбат итәргә кереште. «Син талантларны кысасың, менә дигән яхшы әсәрләрне бастырып чыгарырга теләмисең,— диде.— Чын пролетар язучыларга яшәргә ирек бирмисең... Юлаучыларны, вак буржуаз язучыларны үз канат астыңа туплыйсың. Моның өчен бик үкенерсең әле син! Беләсеңме нәрсә,— дип өстәде ул ахырда,— поэманы журнал баса, ә син...»

Ул елларда Казанда төп ике әдәби оешма бар иде: берсе — ТАПП, икенчесе — Татар совет язучылары оешмасы, Г. Камал, Ф. Бурнаш, М. Гали һәм башка шуның кебек каләм осталары бу оешмаларның икенчесендә торалар, юлаучылар дип аталалар иде. «Шагыйрь» бу сүзләре белән шундый язучыларны истә тотып әйтә иде.

Дуамал автор чыгып киткәч, бүлмәбез тынып калды, беркадәр вакыт бу турыда сүз кузгатучы булмады. Яңадан эшкә тотындык. Гомәр дә кулъязмалар актара, яза, сыза, редакцияли башлады. Бераз бөдрәләнеп торган кара чәче тузгыган, кәефе киткән. Аның мондый чаклары сирәк була иде.

Бүлмәдә утыручылардан Фәтхи Бурнаш беренче булып тынлыкны бүлде:

— Әгәр сез әйткәннәрнең барысы да дөрес булса, поэманы журналда да басмаска кирәк,— диде.— Сез бит редколлегия члены. Шулай булгач, аны журналда бастырырга да каршы булырсыз дип уйлыйм,— диде.

Гомәр Ф. Бурнашка бераз көлемсерәп, күтәрелеп карап торды да:

— Юк, каршы килмим,— диде.

Без эшебездән туктадык: «Нигә каршы килми? Әле генә каты тәнкыйтьләде ич...»

Ф. Бурнаш та шул ук сорауны бирде.

— Күрдең бит, кеше сүзенә берничек тә колак салырга теләми,— диде Г. Гали аңа.— Башына имән күсәк белән тукып торсаң да, поэмасының яраксыз икәнен аңла-

тып булмый. Әсәр журналда басылып чыга калса, җәмәгатьчелек аңа бик яхшы аңлатачак.

Поэма чыннан да журналда басылып чыкты. Әйтүләренә караганда, бераз кыскартылып, төзәтелеп басылган икән. Шулай да матбугат аны каты тәнкыйтьләп каршы алды. Бу турыда җыелышларда күп сүз булды, авторга каты сүзләр әйтелде. Ул үз хатасын төшенгәндерме, юкмы,— анысын белмим, әмма шуннан соң әлеге авторның поэмаларын, шигырьләрен матбугатта очратмадым шикелле.

Йогәнсезлеге аркасында ул үзенең кешелеклелек сыйфатларын югалтты, шул заман сүзләре белән әйткәндә, «вак буржуа сазлыгына батып, черен таркалды».

Г. Гали бик сизгер, таләпчән, югары зәвыклы тәнкыйтьче иде. Ул акны карадан, яхшыны яманнан оста аерды. Шуның белән бергә ул әдәбият баскычларыннан менеп килә килгән яшь язучыларның киләчәк әдәби язмышларын да күз алдына китерә алды. Нинди генә жанр вәкиле булмасын, чыннан да талантлы, өметле яшь язучы икән, аның иҗатына аеруча игътибар итә иде. Ул аның басылып чыккан әсәрләре белән генә түгел, язылу процессындагы әсәрләре белән дә, шулай ук яшь авторның җәмгыятьтәге урыны, үз-үзен тотышы белән дә кызыксына. Аның карашынча, язучы — халыкның алдынгы вәкиле, иҗади-мәдәни байлык тудыручы кеше. Ул яхшы сыйфатлары, тирән эчтәлекле әсәрләре белән киң катлау укучыларны коммунистик рухта тәрбияләргә тиеш. Ә моның өчен язучының үзенә, иң беренче чиратта, марксизм-ленинизм тәгълиматын тирәнтен үзләштергән, шуның белән рухи сугарылган булу кирәк.

Г. Гали әдәбиятыбызның сафлыгы, пакълеге, халыкчанлыгы, коммунистик идеялелеге өчен бөтен күңелен биреп көрәште. Аның бер кредосы бар иде: «Һәрбер күренекле тәнкыйтьченең бер шагыйре булырга тиеш»,— ди торган иде ул. Яратуны ул коры симпатия, шагыйрьнең басылып чыккан әсәрләрен укып бару, шуннан эстетик ләззәт алу итеп кенә түгел, ә аның иҗади-әдәби дусты, ярдәмчесе, булышчысы булу итеп күз алдына китерде.

Авыр еллар иде, каты сыйнфый көрәш еллары. Кешенең аңы, рухы, җаны өчен каты көрәш бара. Шуңа күрә бу әдәби иҗади дуслыкның нигезенә ул, коммунист тәнкыйтьче буларак, беренче чиратта идея дуслыгын салган иде.

Һади Такташ исән чакта ул аның дусты, киңәшчесе, ярдәмчесе булды. Соңыннан Фатих Кәримне үз канаты астына алды, аның һәр язылган әсәрен басылып чыкканчы ук укып, күзәтеп барды. Фатих үсеп җиткәч, камилләшкәч, әдәбият бакчасына кереп киткәч, ул яшь шагыйрь Галим Мөхәммәтшин белән шөгыльләнә башлады. Г. Мөхәммәтшин, чыннан да, талантлы, өметле, игътибарга лаеклы шагыйрь иде. Кызганычка каршы, ул арабыздан бик иртә китте, Гомәр аны тәрбияләп, үстереп, аякка бастырып өлгермәде.

Г. Гали үз гомерендә шигырь язганмы, юкмы,— анысын белмим, басылып чыккан шигырьләрен күргәнем юк, әмма аның шигырь төзелешен яхшы белүе күп язучыларны сокландыра иде. Шигырьләрне бик оста редакцияли иде ул.

Гомәр өметле яшь язучыларның иҗатларына гына түгел, хәтта аларның фамилияләренә дә игътибар итә иде.

— Язучының фамилиясе кешеләрнең игътибарын җәлеп итәрлек булырга тиеш,— ди торган иде ул.— Мәсәлән, бездә Котбетдинов, Гайнетдинов, Шәйхетдинов һәм башка шуның кебек «этдинов» белән тәмамлана торган фамилияләр күп. Әйтегез әле, зинһар, шундый фамилияле шагыйрь булу мөмкинме? Юк, билгеле.

Шул карашыннан чыгып, ул яшь язучы Фатих Хөснетдиновка фамилиясен кыскартырга киңәш итте. Фатих карышмады, матбугатта Фатих Хөсни булып таныла башлады.

Г. Гали талантларга бик игътибарлы иде. Талантны ул табигатьнең һәр кешегә дә бирелми торган бик зур бүләге итеп саный, аны кадерләп тотарга, үстерергә һәм халыкка хезмәт итүгә багышларга өнди иде.

Ул елларда язучылар әдәби иҗатларына карап түгел, ә күп очракта социаль чыгышларына карап бүленделәр. Мәсәлән, кайберәүләр пролетар язучылар булып, ә икенчеләр юлаучылар, ягъни пролетариат идеологиясе белән тәрбияләнеп җитмәгән, әлеге вак буржуа позициясендә торучылар булып санала иде. Менә шундый шартларда да Г. Гали талантларга бик игътибарлы, бөтенесен дә бердәй ярата иде дип әйтергә җыенмый. Юк, алай түгел иде. Язучыларны ул, беренче чиратта, талантлыларга һәм талантсызларга аерып карады. Кайбер талантсыз язучылар турында ачык-

тан-ачык: «Әдәбият арбасындагы балластлар алар. Кайчан да булса бер барыбер төшеп калачаклар»,— ди торган иде. Вакыт үзенекен итте, тәнкыйтьченең сизгерлеге расланды, ул талантсыз дип санаган язучыларның хәзер күбесен укучылар бөтенләй белмиләр.

Яшь сәләтләрне ул укучы балалар арасыннан да эзли иде. 1933 елның апрелендә хәзерге Укытучылар йортында язучыларның балалар әдәбиятына багышланган бер зур җыелышы булды. Шунда күренекле язучылар, галимнәр, укытучылар белән берләттән 11—12 яшьләрендәге, Ләлә исемле бер укучы кыз да чыгып сөйләде. Ул «Пионер каләме» журналының аерым саннарын тәнкыйтьләде, анда басылган материалларга, аларның эчтәлекләренә, теленә тукталды, кимчелекләрен күрсәтте.

Җыелышта Г. Гали председательлек итә иде. Башта ул бу кечкенә кызның чыгышына әллә ни игътибар итмәде, балаларны да катнаштыру өчен алдан өйрәтелеп куйган гадәти бер чыгыш дип уйлады булса кирәк. Ләкин кызчыкның сүзләрен тыңлый төшкәч, күзләре ялтырап китте, кызның күңелен күтәреп, бер-ике тапкыр кул да чабып куйды, аннары урыныннан торды да, аны күтәреп алып, өстәл өстенә бастырды, чөнки чыгыш ясаучы кечкенә буйлы булып, трибунадан аның башы гына күренә иде. Кызның һәр сүзен болай да кызыксынып тыңлаган зал шуннан соң, бөтенләй тынып калды.

Бер-ике көннән «Кызыл Татарстан» газетасында Г. Галинең бу чыгыш турында кызыклы гына мәкаләсе басылып чыкты. «Лилипутның тәнкыйте» дип атала иде ул. «Пионер каләме» журналының әле моңарчы бер тәнкыйтьче тарафыннан да бу кадәр тәфсилле, бу кадәр каты тәнкыйтьләнгәне юк иде, дип язды Г. Гали.

Соңыннан берничә ел буена ул әлеге кызның укуы, уңышлары турында сорашкалап торды, «Пионер каләме» журналында берәр нәрсәсе басылса, аны бик кызыксынып укый торган булды. Хәтта ул аны еракларда йөреп кайтканнан соң да исенә төшерде. «Теге, Ләлә исемле кыз кем булды?» — дип сорашты. Ул аны тәнкыйтьче булыр дип көткән икән, ләкин кыз әдәбият буенча китмәде, ә врачлыкка укыды, татар кызларыннан беренче булып, бик яшьли фәннәр докторы дигән гыйльми исемне яклады. Хәзер ул — Ләлә Мөхәммәтхановна Ишимова — Мәскәү медицина институты профессоры, күренекле галим, җәмәгать эшлеклесе, берничә чит ил фәнни җәмгыятьләренең почетлы член-корреспонденты һәм күп кенә гыйльми хезмәтләр, югары мәктәп дәреслекләре авторы.

Г. Гали яшьләрнең үсешен күзәтеп бару белән генә чикләнми, аларның уңышларын күреп, чын күңеленнән шатлана да иде. Заманында ул әдәби тәнкыйтебезне өйдәп баручыларның берсе, күренеклесе, аңа рух бирүчесе булды.

Гомәр яхшы оратор да иде. Җыелышларда докладлар ясый, әһәмиятле мәсьәләләр каралган чакта чыгып сөйли, үз фикерен әйтмичә калмый. Аңа сүз бирелгәч, ул гадәтенчә, трибунага ашыгып менә, алдан әзерләнгән тезисларын, кесәсеннән чыгарып, алдына куя, гадәтенчә башын кашып ала, аннары, күзләрен залның бер читенә, югары почмагына текәп, сөйләргә керешә. Сүзләре чишмәдәй агып чыга, җөмләләре, бау ишкәндәй, бер-беренә тыгыз бәйләнеп бара, фикере тирәнәя, киңәя һәм залның игътибарын үзенә җәлеп итә. Оста сөйли иде ул, янып, ялкынланып сөйли иде. Мин аның докладларны язып укыганын хәтерләмим. Хәер, ул елларда күпләр докладны тезисларына карап кына ясыйлар иде.

Шаян, күңелле кеше иде Г. Гали. Шаянлыгы эш вакытында да сизелеп тора иде.

Уң колагы начарrак ишетә иде аның. Шуның аркасында ул кайчак күңелсез, кирәксез сөйләшүләрдән котылып кала. Берәрсе аңа телефоннан кирәкмәгән нәрсә сөйләргә керешсә яисә артык озын сүз куертырга тотынса, Гомәр ул кешегә:

— Әй, ишетмим мин сине... ишетелми!...— дип кычкыра иде.

Аның бу кылынышын күреп баштарак мин:

— Нигә алай әйтәсең, Гомәр, ишетәсең ич,— ди торгалый идем.

— Кирәкмәгән сүз сөйли. Шуңа «ишетмим» мин аны,— дип җавап бирә иде.

Бу колак болай да тынычсыз бүлмәбезнең кайчак тагын да шаулабрак, гөрләбрәк торуына сәбәпче дә булгалый иде.

Нәшриятка ара-тирә Казан университеты профессоры, СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты Василий Алексеевич Богородицкий килгәләп чыга. Гыйльми әсәрләрен бастырырга йөри иде ул. Утызынчы еллар башында аның Казанда, Татарстан

дәүләт нәшриятында бик әһәмиятле ике хезмәте басылып чыкты. Икесе дә татар һәм төрки телләрен өйрәнүгә багышланган иде. Ул елларда андый китапларны бастырып чыгару эше матур әдәбият секторына йөкләтелгән иде. Василий Алексеевич шуңа күрә безнең редакциягә, Г. Гали янына килә иде.

Дөнья күләмендә танылган бу галим килгәч, без барыбыз да, мәктәп балалары сыман, тынып калабыз. Тел белеме фәненә гаять зур өлеш керткән В. А. Богородицкийны без гыйлемлеге өчен дә, шулай ук безгә карата яхшы, җылы мөнәсәбәте, мөлаем карашы өчен дә ихтирам итә идек. Бик югары культуралы, ачык күңелле, гади кеше иде ул. Өсте-башы да ул заман өчен бик яхшы: кышларын өстендә төлке тун, башында хәтфә түбәле камчат бүрек, аягында озын балтырлы галош; җәйләрен бик яхшы көрән костюм, башында ак камыш эшләпә, аягында ялтырап торган кара ботинка, кулында көмеш белән бизәлгән таяк. Шуның өстенә үзе дә матур карт иде ул. Тик бер кимчелеге бар — колаккка сак, шуңа күрә аның белән сөйләшкәндә, каты кычкырып сөйләшергә туры килә. Югарыда әйткәнемчә, бу яктан Г. Гали дә кимчелексез түгел. Алар икәү сөйләшә башласалар, бөтен бүлмәбез — бүлмәбез генәме, бөтен нәшрият шаулап, гөрләп тора. Хәтта В. А. Богородицкий чыгып киткәннән соң да тиз генә тынлык урнашмый. Кычкырып сөйләшергә күнегеп калган Гомәр, Богородицкий белән сөйләшкәндәй, безнең белән дә бик каты кычкырып сөйләшә башлый. Без дә, гомуми тонга бирелеп, китеп, ул ишетсен дигән сыман, аңа шулай ук кычкырып җавап бирәбез. Кыскасы, бүлмәбез шаулап, гөрләп торуында дәвам итә иде.

Гомәрнең шат чагын да, кайгылы көннәрен дә күргәнем бар минем. Кайгыны да, шатлыкны да ирләрчә үткәрә белә иде ул. Шатлыктан башын югалтмас, кайгыдан коелып төшмәс. Г. Гали белән бергә төрле хәлләрне кичергән кешеләр аның тыныч холыклы, түземле, күтәренке рухлы, кешеләргә игътибарлы булуын искә алалар.

Тормышында берәр күңелсезлек туса, шул хакта үзенең иптәшләренә сөйләп, уфтанып, борчылып, аларның кәефләрен бозмый иде ул. Андый күңелсезлекләрне уен-көлке белән уздырып җибәрә иде ул. Мәсәлән, бер вакыйга бүгенгедәй хәтердә. 1935 елны Г. Гали каракүл якалы бик яхшы бер пальто тектерде һәм аны бик яратып, шатланып киеп йөри башлады. Шатланмаслык та түгел, чөнки аның мондый яхшы пальто кигәне юк иде әле. Аннары ул елларда пальто тектерү — бик зур проблема, магазиннарда да андый товар юк диярлек. Кешеләр гади генә күлмәк сатып алсалар да, чын күңелдән шатланалар иде.

Гомәр пальтосын бик кадерләп, саклап киде. Ул аны, урлаулары мөмкин дип, вешалкага да бирмәде. Шуңа күрә Гомәр кадерле пальтосын үзе белән бергә дүртенче катка алып менә (нәшрият Матбугат йортына күчкән иде), кабинетында сала, шунда саклый, берничә минутка гына чыкса да, бүлмәсен бикләргә онытмый.

— Пальтомның үз янымда булуы ышанычлырак,— ди торган иде ул.

Кызганычка каршы, бу «ышанычлылык» озак дәвам итмәде. Көннәрнең берендә пальто бикле бүлмәдән дә юкка чыкты. Бөтен Матбугат йортын карап, тикшереп чыктылар,— табылмады.

Бу бик күңелсез вакыйга иде, билгеле. Шуңа карамастан, Г. Гали аны уен-көлке белән уздырып җибәрде. Кайгысын уртаклашырга теләүчеләргә ул, кулын селтәп:

— Шәп булды әле, котылдым. Төймәләре матур түгел иде, аннары җиңе дә бераз озынрак иде,— дип кенә җавап бирә иде.

Икенче пальто тектерә алмады, кыш буе демисезон пальто киеп йөрде. Каты салкыннар, бураннар булды, өшеде, туңды, әмма шулай да зарланмады.

...Була шундый шәхесләр,— син аларны гомер юлында очратасың, алар белән бергә эшлисең, бер үк максатлар, бер үк теләкләр белән янасың, көясең, һәм алар турындагы матур хатирәләреңне үзең белән бергә киләчәк елларга алып барасың.

Язучы, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе Гомәр Гали дә минем күңелдә шундый матур хатирәләрне калдырган кешеләрнең берсе иде.

# КАМИЛЛЕК ҺӘМ ТИРӘНЛЕК

Җәлил иҗатын өйрәнү совет әдәбият белеме фәненең мөстәкыйль һәм шактый киң өлкәсенә әверелде. 1976 елда төзелгән һәм 1919 елдан алып 1973 елга кадәрге чорны колачлаган библиография күрсәткечендә Җәлил исеменә тегe яки бу рәвештә бәйләнеше булган 2690 исемдәге китап, мәкалә һәм башка төрле басмалар теркәлгән. Шагыйрь иҗатының төрле аспектлары буенча тугыз кандидатлык диссертациясе якланды, егермедән артык фәнни монография һәм фәнни-популяр характердагы китап басылды.

Бу исемлек тулыланып тора. Муса Җәлилнең тууына 75 ел тулу уңае белән Татарстан китап нәшриятында басылган өч яңа китап характерлары белән дә, анализлау алымнары һәм максатлары белән дә бер-берсеннән аерылып торалар.

В. Воздвиженский Җәлилнең иҗат портреты итеп язган бу китабында Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» (М., «Наука», 1969); «Муса Җәлил» («Татар совет әдәбияты тарихы» китабында. М., «Наука», 1965) дигән хезмәтләрендә һәм шулай ук «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» һәм сугыш чоры әдәбиятында аларның тоткан урыны» дигән кандидатлык диссертациясендә (1968 ел) әйтелгән төп фикерләрне дәвам итә һәм үстерә.

В. Воздвиженский шагыйрьнең бөтен иҗат юлын гомумиләштереп ала, чагыштырмача кечкенә күләмле хезмәттә Җәлил иҗатының төп үзенчәлекләрен үсеш һәм формалашу процессында карый. Шул уңайдан ул төп игътибарын Моабит циклына юнәлтә, аңа кагылышлы тирән фикерләр әйтә, мөһим күзәтүләре белән уртаклаша. «Моабит дәфтәрләре»нең шигъри көчен автор шагыйрьнең гадәттән тыш язмышы, шәхес буларак зурлыгы, гражданлык һәм кешелек батырлыгының бөеклеге белән бәйли. Мөкәммәллек һәм тирәнлек — шагыйрьнең шәхси йөзен дә, иҗат йөзен дә билгеләүче сыйфатлары. Шушы фикер В. Воздвиженский китабының лейтмотивы булып яңгырый.

Куплардән аермалы буларак автор Җәлил биографиясендәге һәммә кешегә мәгълүм фактларны сөйләп чыгу белән мавыкмый һәм шагыйрьнең иҗади мирасында гына да чикләнеп калмый. Ул Җәлилнең художестволы фикере һәм поэтикасы үзенчәлекләрен милли поэтика үсеше һәм традицияләр җирлегендә, күп милләтле совет поэзиясе фонында тикшерә.

Элегрәк басылган кайбер мәкаләләрендә, аерым алганда, кандидатлык диссертациясендә В. Воздвиженский Җәлилнең романтик сурәтләү чараларын яратуын күпертебрәк күрсәтә, Моабит циклының реалистик конкретлыгын бәяләп җиткерми иде. Яңа китабында ул татар шагыйренең кабатланмас эчке дөньясына күбрәк игътибар бирә һәм Моабит циклының шактый өлешенә хисси-психологик конкретлык хас булуы турында бик гадел яза. Тикшеренүче шулай ук күтәренке тәэссоратка ирешү, тормыш турында югары дулкында уйлануга, гомумиләштерүче фикерләүгә күчү өчен еш кына шагыйрьнең авыр кичерешләр чынлыгыннан, тормыш детальләре дәрәҗәсеннән читкә китүен дә билгеләп үтә.

Моабит циклының поэтик үзенчәлекләрен анализлауга багышланган битләр мин(ч)а китапның иң яхшы урыннары кебек тоела. В. Воздвиженский Җәлил иҗатындагы романтик шартлылык, образлар символикасы, гипербола һәм аллегория чыганакларын

---

Вячеслав Воздвиженский. Муса Җәлил поэзиясе. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты, 1981.

Әмир Мәхмүдов. Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал. Рус телендә. Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Миләүшә Маннурова. Батырлар җыры. Татарстан китап нәшрияты, 1980.

барлый һәм аларны татар поэзиясе традицияләрендә һәм, киңрәк алганда, бөтен көнчыгыш поэтикасында таба. Ул бик хаклы рәвештә, М. Җәлил поэзиясендәге хисси-психологик дөреслек белән зур гомумиләштерү һәм шартлылык арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр яхшы әзерләнгән җирлектә барлыкка килгән, дип билгели.

В. Воздвиженский китабы Җәлилгә хас иҗат алымнарының асылын нечкә сиземләү, анализ тирәнлеге, киң эрудиция белән җәлеп итә, ә авторның үз шәхесе нык сизелеп тору — бусы да гаять әһәмиятле — аның хезмәтенә хис-ялкын өсти һәм дәлилләрнең ышандыручанлыгын арттыра төшә. Шушы ифрат кызыклы һәм кирәкле хезмәт авторына белдерергә мөмкин булган бердәнбер җитди дәгъва — яңалык җитенкерәмәү, вакыт-вакыт гомуми урыннарда, Җәлил иҗатын өйрәнүчеләр тарафыннан инде күптән чыгарылган әзер формулалар тирәсендә таптана башлау. Хәер, шагыйрь турындагы гомумиләштерүче хезмәттә бу кимчелектән котылу бик читен. Хәтта мөмкин түгел диярлек.

Ә. Мәхмүдовның «Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал» исемле китабы — диссертация рәвешендәге теоретик тикшеренү. Автор Җәлил поэзиясен бер аспектта — эстетиканың иң мөһим категорияләреннән берсе булган эстетик идеал күзлегеннән карый. Нәкъ менә сәнгать әһеленең эстетик идеалында шул заманның зәвыгы, идеяләре һәм урнашкан карашлары синтезлана. Һәр язучының иҗатында бу идеяләр үзенчә гәүдәләндерелә, кабатланмас төсмер ала һәм, кешеләр аңына тәэсир итеп, меңнәрнең күңел байлыгына әверелә. Җәлил эстетик идеалының үзенчәлеген һәм үзгәлеген билгеләгәндә, автор татар шагыйренең иҗат методын, стилен төшенергә, поэтик дөньясының иң яшерен почмакларына үтеп керергә омтыла.

Ә. Мәхмүдов хәзерге совет әдәбият белеме фәненең үсеш дәрәҗәсенә туры килердәй методикага нигезләнергә омтыла — бу — уңай күренеш. Әмма китапның диссертация төсендә язылуы тискәре йогынтысын да сала. Бу — стильнең катлаулы фәнниләгендә: сөйләү рәвешенең битарафлыгында, тикшеренү предметына авторның шәхси мөнәсәбәте бөтенләй диярлек сизелмәүдә, мондый төр хезмәтләр язуда урнашкан кануннарга иярүдә чагыла. Болар бөтенесе дә китапның киң катлам укучыларга аңлаешлылыгын кимәтә.

Шушындый кимчелекләре булуга карамастан, Ә. Мәхмүдов китабы безнең Җәлил поэзиясен күзаллавыбызны әһәмияткә лаек берничә момент белән тулыландыра. Автор анализ материалы итеп Җәлилнең моңа кадәр тикшерүчеләр күзеннән читтәрәк калып килгән гаять бай әдәби тәнкыйть мирасын ала. Бу аңа Җәлилнең эстетик идеалын ике яссылыкта — теоретик чагылышында һәм практик гәүдәләнешендә күздән үткәрергә мөмкинлек бирә. Ә. Мәхмүдов шагыйрьнең эстетик карашларын үсештә һәм формалашу процессында карый, шагыйрьнең ялгышуларын яшерми, сугышчан һәм һөҗүмчән Җәлил лирикасы традицияләренең хәзерге татар поэзиясендәге чагылышын эзли.

Аерым алганда, ул патриот шагыйрьнең эстетик позициясе дәвамын И. Юзеевның «Соңгы сынау», М. Шабаевның «Кәтәм сине», «Җирән Конрат», Р. Харисның «Мулланур», Р. Фәйзуллинның «Керәшчеләр», Р. Мингалимовның «Күз карасы», Г. Рәхимнең «Буыннар елъязмасы» кебек бер-береннән бик үзгә, ләкин шул ук вакытта идея пафослары ягыннан Җәлил рухына кардәш әсәрләрдә күрә. Тирән һәм ышандырырлык итеп, методологик нигездә язылган «Муса Җәлилнең эстетик идеалында милли һәм интернациональ яклар» дигән бүлек аеруча кызыклы.

М. Маннурованың «Батырлар җыры» китабы Ә. Мәхмүдов китабындагы әлеге бүлекнең логик дәвамы булып тора кебек. Ә. Мәхмүдов Җәлил поэзиясенең интернационализмын теоретик планда тикшерсә, М. Маннурова Моабит циклының мотивларын һәм образларын Германия, Франция, Польша, Болгария, Чехословакия һәм Венгриядәге фашизмга каршылык күрсәтү хәрәкәте поэзиясенең киң панорамасы белән янәшә куеп карый. Бу исә татар халкының герой шагыйре поэзиясендәге бик күп идея-эчтәлек моментларының башка антифашист шагыйрьләр иҗаты белән уртаклыгын да, бары Муса Җәлилгә генә хас, аныкы гына булган кабатланмас якларны да төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирә. Бәя бирү — чагыштырып карау ул, дип юкка гына әйтмиләр бит.

Дөрес, вакыт-вакыт М. Маннурова башка басма чыганаклардан алынган мәгълүматлардан артыграк файдалана, ә кайчагында иң гади, гомуми төстәге аналогияләр китерү белән чикләнә. Ләкин, шуңа да карамастан, Җәлил поэзиясен испан Федерико Гарсиа Лорка, француз Робер Деснос, литвалы Витаутас Монтвила, норвег

Нурдель Григ, чех Юлиус Фучик, болгар Никола Вапцаров һәм башкаларның антифашистик рухтагы иҗаты белән бер сафка куеп анализлау татар шагыйре талантының тикшеренүчеләр күзеннән читтә калып килгән яңа якларын ачыкларга ярдәм итә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: бу — шушы рәвешле киң чагыштырмалы анализ ясарга беренче омтылыш. Әә беренчеләргә һәрвакыт кыенгарак килә бит! М. Маннурова хезмәтендәге кимчелекләрнең күбесе әнә шуның белән аңлатыла.

М. Маннурова очерк-публицистика алымнарын куллана, халык демократиясе илләрендә булганда, герой антифашистлар белән очрашканда алган тәэсирләренә нык таяна, үзенең уйлануларын, күзәтүләрен, истәлекләрен уртаклаша. Менә шул хәл аның китабын җанлы һәм аңлаешлы итә.

Шулай итеп, безнең алда — өч авторның мөнәсәбәте, анализның өч аспекты... Авторларның өчесе дә Муса Җәлил иҗатына бирелгән гомуми югары бәядә, аның иҗат йөзенең төп үзенчәлекләрен билгеләүдә уртак фикердә торалар. Китаплар бер-берсен кабатламый, ә бәлки тулыландыралар гына.

Шулай да теге яки бу мәсьәлә буенча карашлар үзгәлеге дә сизелеп куя, ә кайчакта ул яшертен яки ачыктан-ачык полемика төсен ала. Бусы да табигый: Җәлил иҗатын өйрәнү — туктаусыз хәрәкәттә, үсештә булган яңа өлкә, биредә капма-каршы фикерләр һәм тенденцияләр көрәшеннән башка һич мөмкин түгел.

Муса Җәлилнең сугышка кадәрге иҗаты хакында ике төрле фикер яшәп килде. Беренчесенең тарафдарлары (үзенең мәгълүм монографик хезмәтләрендә Г. Кашшаф, Муса Җәлилнең поэмалары турындагы һ. б. тикшеренүләрендә Н. Юзиев), минемчә, Җәлилнең сугышка кадәрге иҗатының татар һәм бөтен совет поэзиясе өчен әһәмиятен беркадәр арттыра төшәләр, бу чорда аңа хас булган кайбер кимчелекләрне күрмиләр яисә күрергә теләмиләр. Р. Бикмөхәммәтов, В. Воздвиженский һәм аларның тарафдарлары исә, минем уйлавымча, Җәлилнең сугышка кадәр язган поэмаларын һәм шигырьләрен объективрак бәялиләр, шагыйрьнең иҗади җитлегү этапларын төгәлрәк һәм тирәнрәк тикшерәләр.

Ә. Мәхмүдов беренче карашны үз итә, Җәлилнең әсәрләрен кызып-кызып яклый, һәр әйтелгән тәнкыйть сүзе белән бәхәскә керә, үзгә фикердә торучыларны «әдәби схематизмда гаепли (98 бит). Авторның тикшеренү предметы белән мавыгып китүе аңлашылса да, В. Воздвиженский позициясе хакыйкатькә якынрак кебек тоела. Ул Җәлилнең егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында язган әсәрләрендә индивидуаль, үз «мине» әйтерсең лә гомуми башлангычта, меңнәрчә замандашлары белән бергә кичергән уртак хис-омтылышларда эреп бетә дигән фикерне алга сөрә. Шагыйрьнең кабатланмас индивидуальлеге гүя ул үзе табынган олы идеаллар, омтылышлар артында югалып кала. Бу чорда Җәлил барча хис һәм мөнәсәбәтләрне бердәнбер үлчәү — көрәш һәм хезмәт микъдары белән генә бәяли кебек. Егерменче еллар — утызынчы еллар башы Җәлил поэзиясендә булган күпмедер берьяклылыкны, кайчак поэтик фикернең схематик чишелешләргә нәрүен күрмичә, Ә. Мәхмүдов ясалма рәвештә шагыйрьнең иҗади үсеш юлын турайта. Ә Җәлил моңа мохтаҗ түгел!

Әйе, Җәлилнең сугышка кадәрге поэзиясендә еш кына лирик агым ачыктан-ачык декламация белән бүленә, ә образлы сурәтләр алдан ук билгеләнгән хакыйкатькә тасвирлама гына булып калалар. Ләкин бит үз-үзеңнән баш тартырга әзер торуны, заманның социаль заказын шатланып кабул итә алуны шагыйрьгә мөстәкыйльлек җитмәү дип кенә бәяләү дөрес булыр микән? В. Воздвиженский дөрес искәртә: әлеге кимчелекләр Җәлилнең заманга тугрылыклы булуы, аның көрәшен, казанышларын һәм идеалларын йөрәгенә якын алуы нәтиҗәсе дә әле ул. Ләкин, кон-заман ихтыяҗы ничек кенә тәэсир итмәсен, Җәлилнең лирикасы, аның шәхесе кебек үк, бай мәгънәле булып кала. Максатчан һәм кырыс булган килеш, ул күңеленә интим кичерешләрне һәм авыр уйлануларны да сыйдыра.

Җәлилне «аклау» омтылышыннан чыгып (ә асылда аның иҗат йөзен төссезләндерә төшеп), Ә. Мәхмүдов Җәлил иҗатында җитлеккәнлек чорын 1927 елдан башлап билгели. Хәлбуки, күпчелек тикшеренүчеләр аны утызынчы еллар уртасы дип исәпли. Ә бу үз чиратында шуңа китерә: автор Җәлил өчен үтелгән этап булган әсәрләрдә аермачык ярылып яткан художество кимчелекләрен дә күрми үтә, соңыннан шагыйрь үзе үк баш тарткан иҗат принципларын яклый.

Әйтик, Җәлил эстетик идеалының ярым алганда, мәхәббәт матурлыгын күзаллавы-

ның һ. Такташ һәм Г. Кутуй идеалыннан кайсы ягы белән аерылып тору мәсьәләсен кузгатып, Ә. Мәхмүдов: «Җәлилнең эстетик идеалы башлыча мәхәббәт һәм производство проблемалары бердәмлеге белән аерылып тора. Такташ һәм Кутуйның эстетик идеалының асылы әхлак һәм мораль проблемаларын хәл итү, яраткан кешеңнең язмышы өчен борчылу, җаваплылык тойгысы аша билгеләнә, ә Җәлил поэмаларында бәхет, геройларның бер-берсенә мәхәббәте хезмәткә аңлы мөнәсәбәт җирлегендә ачыла»,— дип яза (23 бит). Миңа калса, бу буталчык һәм таркау формулада Җәлилнең эстетик идеалын да, Такташ белән Кутуйның эстетик карашларын да гадиләштереп күрү чагыла. Мәгълүм булганча, «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу», «Мокамай» авторы да, «Тапшырылмаган хатлар» авторы да үз геройлары тормышының шәхси һәм хезмәт даирәсен кытай стенасы белән аерып куймыйлар, үз әсәрләрендә «саф» әхлак һәм мораль проблемаларын хәл итү белән чикләнеп калмыйлар. Иң мөһиме шул: Ә. Мәхмүдов моның белән Җәлилнең шул чордагы иҗат алымына хас схематизм һәм чикләнгәнлекне, аның бигрәк тә «Зәйнәп» поэмасында ачык чагылган мәхәббәт белән производство өлкәсен турыдан-туры бәйләргә омтылышын аклый.

Бу поэманы бәяләгәндә, беркадәр елмаеп, мәхәббәт графигы производство планын үтәү графигы белән тулысынча тәңгәл килә, дип язган В. Воздвиженский хаклырак төсле. Егет норма үтәлешен йөз проценттан киметү белән үк Зәйнәп аннан йөз чөерә һәм, үтәлеш йөз егерме процентка җитү белән, яңадан ягымлылана. Мондый гадиләштерүләргә шагыйрьнең ихтыяри-мәҗбүри барганлыгын, һәм соңрак аның бу чирдән арынуын әйтеп үтәргә кирәк.

Моабит чорындагы Җәлил иҗатын бәяләүдә фикер аерымлыклары юк дәрәҗәсендә — өч автор да әлеге шигырьләр заманыбыз өчен төкәнмәс әһәмияткә ия дигән карашта торалар.

В. Воздвиженский, минемчә, «Моабит дәфтәрләре»н башкалардан нечкәрәк һәм тирәнрәк анализлый. Ул шагыйрь күңелендәге капма-каршы хисләр көрәшен дә, әсирлек ачысын да, ирекке сусау газабын да, хәсрәт авазларын да күрә. Ә. Мәхмүдов, аның белән үткәндәге басмалары буенча бәхәскә кереп: «В. Воздвиженский күзаллавынча, М. Җәлил — кайгы-хәсрәт шагыйре, көрәштән читләтелгән кеше. Моның белән «Моабит дәфтәрләре»нең сугышчан, һөҗүмчән рухы инкарь ителә», — дип яза. (46 бит).

Ә. Мәхмүдов биредә арттыра төшә бугай. В. Воздвиженский Җәлилнең кайгысы— «туган җиренә, халкына турылыклы хезмәт иткән, тормышка, кешеләргә юмарт рәвештә, сөенеп гашыйк булган һәм үзе өчен газиз бөтен нәрсәдән читләтелгән кеше кайгысы ул» дип, аермачык итеп әйтә бит. Җәлил төрмә камерасында көрәштән читләтелгән дигәндә Воздвиженский рухи көрәшне түгел, ә бәлки яшерен оешма эшендә турыдан-туры катнашуны күздә тота.

Шагыйрьнең эчке дөньясын гадиләштереп күз алдына китерү Ә. Мәхмүдовны Җәлилдәге трагизм категориясен дә гадиләштереп аңлатуга китерә. Китапның әлеге темага багышланган бүлеге аеруча тотрыксыз, тәнкыйтькә урын калдыра торган булып чыккан. Автор Моабит циклындагы трагизмны ике моментка гына кайтарып калдыра: үлем җәзасына хөкем ителгән шагыйрьнең шәхси фаҗигасе һәм фашизм тарафыннан алданган немец халкының трагик язмышы. Әмма «Моабит дәфтәрләре»ндәге трагизм моның белән генә чикләнеп бетәрлекме соң? «Вәхшәт», «Ышанма», «Кичер, илем!», «Үлемгә», «Палачка» һ. б. шигырьләр бүтәнчәрәк уйларга нигез бирә. М. Маннурова, мәсәлән, Җәлил поэзиясен башка антифашист шагыйрьләрнең әсәрләре белән чагыштырып (гәрчә бу мәсьәләне махсус тикшерү максатын куймаса да), Җәлил шигырьләрендәге трагизмның асылын аңлауга якынрак килә.

Шулай итеп, Җәлил иҗатын өйрәнүнең бәхәссез уңышлары нәтиҗәсе булган өч яңа китап карашлар бердәмлеге дә, кайбер мәсьәләләрдә фикер-мөнәсәбәт аерымлыклары да яшәп килүе турында сөйли. Гомумән алганда, әлеге тикшеренүләрне бу юлда яңа адым дип бәяләргә була. Алар Җәлил иҗатын өйрәнүнең күбесенчә фактлар җыю һәм туплаудан торган фазасыннан тупланган мәгълүматларны тирәнтен һәм һәрьяклап өйрәнү-төшенүдән гыйбарәт булган яңа фазага керүен ышандырырлык итеп раслыйлар.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ДУЛКЫННАР НИ СӨЙЛИ...

Язасым килмәгән иде бу мәкаләне. Күңелне тырнап торган борчуларны дөньяга чыгарасы килмәгән иде... Уңгылыксыз авторны кызгану да, аны рәнҗетүдән сагаю да сәбәпче булгандыр моңа. Аннары, «Дулкыннар ни сөйли?»— Вергазовның беренче китабы, димәк, әдәбиятка заявкасы гына әле дип тә ташлама ясарга мөмкин иде. Ни дисәң дә, сайлап алган материалын яхшы ук үзләштереп, шома гына бәян итеп чыга алган икән, үз-үзенә тәнкыйди күз белән карарга, беренче уңышсызлыгыннан гыйбрәт алырга да сәләтле булырга тиеш ул...

Бәлки хәтерегездәдер, «Дулкыннар...»— тегүчелеккә укучы кызларның «дөнья белән танышып йөрүе» турында сөйләүче әсәр. Аның геройларын намус һәм сафлык, булачак һөнәреңне ярату һәм тормышта үз урыныңны табу кебек мөһим мәсьәләләр борчый. Укучы күз алдыннан төрле вакыйгалар тезелеп үтә. Фәрданә исемле кызның бер-бер артлы намусын, дусларын һәм киләчәккә ышанычын югалтуы... Илүзәнең күптән аерылышкан әтисе белән әнисен, һөнәр һәм кешеләр матурлыгын, ниһаять, беренче мәхәббәтен аңларга омтылуы... Автор тегү эшенең үзенчәлекләрен белеп тасвирлый, күп очракта тормышчан детальләр төгәллегенә ирешә. Балет карарга җыенган кызларның фабрика заказын үтәү өчен дәрестән соң эшкә калуы, бөтен дөньясына кул селтәгән Фәрданәнең авыру кызчык янында утыруы кебек эпизодлар истә калырлык.

Ләкин әсәрне тулысынча укып чыккач, андагы вакыйгалар агышы әле әдәбият факты булып җитешә алмаган тормыш фактларын теркәү, аерым фикерләргә тасвирлама рәвешен хәтерләтә башлый. Персонажлар күңелендәге тирән һәм каршылыклы хисләр, уйланулар дип тәкъдим ителгән урыннар күп очракта гади генә күренешләрне, әһәмияте дә булмаган күзәтүләрне артык юмарт «фәлсәфә» белән сыегайту булып чыга. Болай да вак тойгылар, кичерешләр кат-кат шәрехләп бирүләр нәтиҗәсендә тагын да ваклана. Шуның өстенә ясалма киртәләр, юри буташтырулар белән конфликтны тирәнәйтергә тырышу әчпошыргыч тәэсирне тагын да көчәйтә генә. Кызларның үзара мөнәсәбәтләрен сурәтләгәндә дә, егетләр арасындагы «конфликт»ны ачыклаганда да бу хәл нык комачаулый авторга.

...Әсәрнең тулаем уңышсызлыгы зур мәсьәләләрне әнә шулай — тәбәнәк калančадан торып хәл итәргә азаплануда.

А. Вергазовның беренче китабына болай озаклап тукталуның ике сәбәбе бар. Беренчедән, үз вакытында аның хакында матбугатта фикер әйтелми калды шикелле. Мирсәй ага Әмирнең иң соңгы чыгышларыннан берсендә әлеге повестьны да күздә тотып әйткән сүзләре хәтердә: «Кайбер әсәрләрнең тиешенчә эшләнеп җитмәгән хәлдә, иң югары таләпләрдән чыгып редакцияләнмәгән килеш матбугатка чыгулары да түгел, шундый әсәрләр уңае белән җитди тәнкыйть сүзе җитәрлек булмавы күңелне борчый», — дигән иде ул! Икенчедән, «Дулкыннар ни сөйли?» әсәрендә ярылып яткан кимчелекләргә без тәҗрибәсезлек җимеше дип ташлама ясап торган арада, автор икенче повестен «бүләк итәргә» дә өлгерде һәм баштагы ялгышларыннан күзгә чалынырлык нәтиҗә ясамаганлыгын күрсәтте.

Үзенең асылы белән бу әсәр дә хәлиткеч бер ноктада сүтелә башлаган хатирәләр чылбырыннан гыйбарәт. Тышкы формасыннан башлап, геройлар күңелендәге кичерешләрне, уй-фикер хәрәкәтен сурәтләүгә кадәр таныш юлдан — «Дулкыннар...»да сыналган, әмма укучыга юл таба алмаган алымнарын кабатлау юлыннан бара ул. Кыскасы, бер үк ачкыч икенче повесть йозагына да ярап куйган.

«Ташу»[1] повесте күмәкләшү чорында татар авылында барган вакыйгаларны сурәтләүгә багышланган. Халкыбыз язмы-

---

[1] Азат Вергазов. Ташу. Татарстан китап нәшрияты, 1980.

шындагы героик сәхифәләрне терелткән әсәрләр шактый... Бүген шул хакта сүз әйтергә алыну үзе зур җаваплылык йөкли. Изге көрәш кайтавазының яңа аһәңнәрен ишеткәнме автор? Шул елларга бүгенге көн биеклегеннән карап, замандашларын уйландырырлык яңа сүз әйтергә җыенамы ул?

Беренче карашка ук, әсәрдә әлеге катлаулы көрәшнең яңа төсмерләре ачыла дип булмый: ул шактый тапталган юлдан бара, кайбер очракларда схема дәрәҗәсендә гадиләштереп сурәтләү белән дә мавыгып китүләр бар. Бер якта — кулак Минай һәм аның иярченнәре, икенче якта — япа-ялгыз дип әйтерлек Сәгадәт. Кулак дигәнен аерып алу читен түгел: моңарчы безгә билгеле әсәрләрдән үк таныш «кызгылт чырайлы» образ күз алдына килә. Сәгадәт язмышы исә азмы-күпме кызыксыну уятырлык. Бер ел гына бергә яшәп калган ире сугышта һәлак була, яшь баласы ачлыктан шешенеп үлә. Коточкыч ялгызлыгы һәм үз-үзен корбан итүе ничектер акланып, аңлашылып җитмәсә дә, бу хатынның һәртөрле изүгә, искелеккә каршы чыгу сәбәпләре шактый эзлекле тасвирлана.

Әсәрнең эчтәлеген сөйләп тору хаҗәте юктыр. Аның асылына — шәхси милекчелек шаукымыннан арына алмаган ир белән колхоз өчен җанын да аямаган хатын арасындагы конфликтка игътибар итик. Дөрес, Җамалиның күңелендә тарткалашкан ике «мин» кебек үк, бу конфликт та әдәбият өчен яңа түгел. Бәлки биредә мәсьәләгә яңа караш, яңа мөнәсәбәт белән очрашырбыз?

Кызганычка каршы, повесть катлаулы чорның катлаулы проблемаларын читләтеп узарга тырыша, аларны психологик яктан гына түгел, иҗтимагый тамырлары белән дә ачып күрсәтергә батырчылык итми. Аның каравы, мал кайгысы белән булашып, үзенең якын кешесен югалтуын да сизми калган Җамали әсәрнең буеннан-буена принципиаль рәвештә үзгәрешсез калдырыла. Еллар үткәч кенә, имештер, шул бәндәне вөҗданы Үтәмеш кыясына алып менә һәм Сәгадәт кыяфәтенә кереп сүз алырга карар кыла. Әлеге диалог, бердән, кычкырып торган ясалмалыгы белән күңелне кайтарса, икенчедән, хәтта вөҗдан уянуның да, әхлакый әһәмиятеннән бигрәк, сюжет кору өчен бер трюк сыйфатында хезмәт итүе гаҗәпләндерә. Вөҗданың әрәк булып купсын да, якаңнан эләктереп алсын әле!.. Әнә шундый ясалма конструкцияләргә ябышып, очы-очка ялганып җитмәгән фикерләр тернәкләнә. Бер кечкенә генә мисал. Авторга ышансаң, Җамалиның Сәгадәттән соң эшләгән эшләре бер ук вакытта аннан «качып тору» һәм аңа «якынаер өчен» булып чыга.

Гомумән, геройларны сөерлек томаны белән өретеп алырга тырышу, кайдадыр нәрсәнедер әйтеп бетермәү һәм аерым күренешләргә «купкырлы» мәгънә бирү — проблеманы бөтен җитдилеге белән чишәргә алынмау, мәсьәләнең асылына төшәргә теләмәү билгесе. Иң хәтәре шул: күзгә фәлсәфә тәтене җибәреп, әйтер сүзең булмауны, дулкынландырырлык язмышлар ача алмавыңны капларга азаплану бер генә авторның бәласе түгел. Әйтик, соңгы еллардагы әсәрләребездә рәссам геройларның күбәеп китүе һәм аларның бу дөньяны «рәссамнарча» күрүенә тырышыптырмашып басым ясавыбыз да — шушы хәлнең бер чагылышы түгелмени!

А. Вергазовның Мәләге, әнә, — ачык социаль максаты булмаган ат карагы, хәтта нәзерен үтисе булса да, активистка Сәгадәтнең үзе килгәнен көтеп, Кирәмәт чокырында ята. Холык-фикер үзенчәлеге аңлашылмаган геройны тасвирлавы бик кыен авторга: ул бу хәлдән Мәләкне сүз саен «тфү» дип төкертеп кенә котылырга чамалый. Хәер, Җамалины да асылда «җә, җук, җарый» дип сөйләнүләре белән тешкә тиюеннән, Исмайны исә дулкынланган чакта тотлыгуыннан гына танып калса калыр укучы!

Тел турында сүз чыккан икән, күп санлы төгәлсезлекләрне атап тормастан, Вергазов каләменә хас тагын бер үзенчәлеккә һичшиксез күз салып үтәргә кирәктер. Кайвакыт ниндидер ым-ишарәләр, турыдан-туры характеристика бирү ялыктыра башласа, хикәяләүне озын-озын диалоглар белән төрләндереп җибәрергә ярата ул. Диалогларга сүзне жәлләп тормый, шунлыктан, теләк булганда, аларны кыскартырга да, яисә дәвам итәргә дә мөмкин. Вакыт-вакыт геройлар укучы ишетсен, белеп калсын өчен генә сөйләшә башлыйлар. Гомумән, Азат Вергазов үзенең күпчелек геройларын икегә аерырга һәм алар арасында капма-каршы уйлар бәрелеше оештырган булып, асылда икесеннән бер үк сүзне сөйләтергә ярата. Шулай да, әйтелгән кимчелекләренә дә карамастан, геройларның үзләренә сүз бирү гомуми фонда җанлырак, сәнгатьлерәк булуы белән аерылып тора.

«Ташу» әсәрендә кызыксынып укыла торган аерым эпизодлар да бар. Детальләштерергә, тәфсилләргә яратуы белән үзе сурәтләгән вакыйгаларга укучының ышанычын арттыра автор. Әмма күп кенә детальләр, күренешләр ахыргача уйланып җитмәгән. Нәтиҗәдә, аларның әһәмияте бермә-бер кими, яисә бу хәл әсәрнең гомуми агышын аңлауга комачаулый башлый. Җамалиның ат суюы, Сәгадәтнең баласы үлү, Сәгадәтнең үтерелүе кебек күренешләр чеп-чи натурализмы белән тәннәрне чымырдатып җибәрә. Хәтта, безнең шул урында тетрәнәсебезне алдан күреп, автор бертөрле ләззәт кичермиме икән, дигән шик тә төшә күңелгә. Бер үк вакытта кичерешләр тирәнлеген тасвирлаудагы көчсезлек, дәрмансызлык ярылып ята. «Дулкыннар ни сөйли?»дә үк Илүзәнең бер-ике тапкыр «күкрәгеннән кайнар дулкын күтәрелгән» иде. «Ташу»да да Сәгадәтнең бөтен халәтен «күкрәге эченнән күтәрелеп килгән кайнар дулкын» һәм язгы ташу белән аңлатып бару эчне пошыра башлый. Гомумән дә, «хәсрәт утын имән баганага кысып сүндергән иде», «эче тулы ялкын дөрләде. Тәтене ургылып авызыннан чыгар төсле иде», кебек чагыштырулар өс-өстенә өелеп, бик ишеп киткәч, мондый кичерешләрнең чынлыгына шикләнә башлыйсың.

Соңгы чиктә бу — авторның сүз стихиясенә баш бирүе генә түгел, тормыш дәреслегенә хилафлык итүе булып аңлашыла. Беренче әсәренең композиция алымыннан гына чыгып «Дулкыннар ни сөйли?» дип аталуы, журнал вариантында «Нәзер» булып укылган повестьның, китапка әверелгәндә, ташу хакындагы сүзнең сузыла төшүе исәбенә генә «Ташу» дип исем алыштыруы да — күбрәк әнә шул тышкы билгеләр турында кайгырту җимеше. Икенче төрле әйткәндә, нәзернең һәм ташуның мәгънәви йөкләмәсе бик аз; әсәрнең буыны шактый сыек булуы аның исемен үзгәртүдә, «нәзер» төшенчәсен яңабаштан аңлатырга маташуда һәм китап вариантында ташу турындагы фәлсәфәне махсус куерта төшүдә дә күренә. Иң аянычы шунда: сурәт һәм хикәяләү төгәлсезлеге тормышны анализлаудагы ялгышлардан, фикер төгәлсезлекләреннән килеп чыга. Тәҗрибәсезлек өстенә, ачык максат һәм ориентирлар булмаганда, йокысыз төннәр хисабына башкарган хезмәтнең дә нәтиҗәсе без көткәнчә барып чыкмый икән. «Ташу» һәм «Дулкыннар...» әнә шул хакта сөйли.

Соңгы сүз итеп нәрсә әйтергә мөмкин?

Телгә алынган ике әсәрдәге кимчелекләр бүтән яшьләргә кагылмый дип йомып куюда, башкалар да хатадан хали түгел дип, бөтен капкага дегет сылап чыгу да гаделлек булмас иде. Ләкин, беренче генә адымы бит дип, башта авторның кыек басып китүен күрмәмешкә салышу, ә бераздан аның «яссы табанлы» булып чыгуын күрә торып, белә торып, «үзенчәлекле язучы килә» рәвешендәге юмарт бәяләр өләшү дә яшьләр иҗатында һәм гомумән иҗатта җаваплылык критерийларын түбәнәйтә. Киеме белән түгел, асылы белән кызыклы яшьтәшләребез әдәбиятка килә тора. Алар хуплауга да, киңәшкә дә мохтаҗ.

**САЛИХ МАННАПОВ.**

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**КАЗАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ХАЛЫК ЖЫРЛАРЫ.** Будапешт, 1980.

Әлеге китап Венгрия Фәннәр Академиясе тарафыннан чыгарыла торган махсус сериядә дөнья күрде. Тюркология фәненә күркәм өлеш кертерлек яңа хезмәтне профессор Жужа Какук әзерләгән.

Китапның язылу тарихы да кызыклы гына. Билгеле булганча, Беренче бөтендөнья сугышының канлы көннәрендә Австро-Венгрия биләмәләрендә урнашкан хәрби әсирләр лагерьларына Россия империясеннән төрле милләт кешеләре эләгә. Төрки халыклар иҗаты белән кызыксынган венгр галиме Игнац Кунош шушы бигүк табигый булмаган мөмкинлектән файдаланып калырга уйлый. 1915—1918 елларда ул Эгер һәм Кениермезё лагерьларына, төрле төрки телләрдә сөйләшүче мөселман хәрби әсирләре янына еш килә. Кениермезё лагерендагы әсирләрнең күпчелеге тумышлары белән Кырымнан, Кавказ, һәм Идел буе районнарыннан икән. Эгер әсирләре арасында исә Казан татарлары, калмыклар, ногайлар һәм төрекмәннәр күбрәк булып чыга. И. Кунош ике лагерьда барлыгы 1200 битләп гаять әһәмиятле фольклор материалы туплый. Аның зур өлеше әлегәчә басылмаган иде. Менә шул хәзинәнең бер өлеше махсус том рәвешендә басылып чыкты. Кереш өлештә искәртелгәнчә, бер И. Кунош кына түгел, халык музыкасы белгечләре Р. Лах белән Г. Вайль да Вюнсдорф (Австрия) һәм Эгер (Богемия) лагерьларындагы әсирләрдән фонограф ярдәмендә халык көйләре, этнографик мәгълүматлар язып алганнар.

И. Куношның «Казан татарларының халык жырлары» җыентыгына кергән язмалары 212 биттән тора. Һәр биттә татарча дүртәр юллы өч шигъри строфа немец теленә, күпчелек очракларда шулай ук венгр һәм төрек телләренә дә сүзгә-сүз тәрҗемә ителгән. Басмада алфавит тәртибендә урнаштырылган барлыгы 634 жыр бар.

Жыр-шигырьләрне сөйләп бирүчеләр турында бернинди мәгълүмат та юк. Әмма жырларның теленә игътибар иткәндә, аларның төрле диалектта сөйләшүче кешеләрдән жыелуын абайлау кыен түгел.

Безнең өчен бу жырларның нинди әһәмияте бар соң? И. Кунош архивында сакланган шигъри дүртьюллыкларның гомуми хәзинәгә кушылуы, әйләнешкә керүе үк игътибарга лаек түгелмени?! Һәрбер жырның сүзләрендә һәм моңында халкыбызның уй-фикере чагыла, аларның үзенчәлекле аһәңендә халыкның тормышы, идеаллары, характеры гәүдәләнә.

Жужа Какук тарафыннан хәзерләнгән жыентык татар халык поэтикасын өйрәнүче белгечләр өчен аеруча кыйммәтле чыганак булып тора. Жырларның эчтәлеге әсирлекнең авырлыгына, язмышның ямьсезлегенә туры килә, аларда ят мохитка ачык мөнәсәбәт белдерелә.

Күпчелек жырлар мәхәббәт турында. Әсирләр күңелендә хәсрәтле аерылышу, якыннарын сагыну хисләре яңгыраш таба, гомернең гүзәл чаклары, мәхәббәт хисләре янара:

Безгә кызы матур булсын,
Кызыкмыйбыз без малга,

— дип жырлыйлар алар.

Жыентыкта Туган илгә бәйләнешле, дуслык һәм яшьлек турындагы жырлар да шактый:

Бәхетле бала шул була,
Торса туган илендә.

Кайбер жырлар күрәсең, Беренче бөтендөнья сугышына кадәр үк һәм аның башлангыч чорында халык арасында таралып өлгергәннәр. Аларда гражданлык мотивлары — әсир солдатның туган илен сагынуы («Мәгәр дөньяда булсак та, кабердә кебек жаннар»), исән калучыларны да үле жанга әйләндергән, иректән, Туган илдән аерган сугышны каһәрләү ачык ишетелә:

Ялгыз башым, юк юлдашым,
Ят илләрдә йөрим ирексез.

яисә:

Солдат ятадыр койкада
Одеалын ябынып,
Солдат мескен саргая бит,
Туган илен сагынып.

Күпчелек жырларда Казан, Идел, Агыйдел телгә алына, Уфа, Әстерхан, Ык исемнәре атала.

Халык сөйләм шигыренең бер үзенчәлеге — аның музыкаль яңгыраш белән аерылмас бәйләнеше. Кызганычка каршы, без хәрби әсирләр лагерьларында язып алынган көйләрне тыңлый алмыйбыз. Әмма Р. Лах һәм Г. Вайль тарафыннан эшләнгән фонографик язмаларның нинди язмышка дучар булуы да безне битараф калдырмый.

Венгриядә басылган жырлар жыентыгы филолог-диалектологлар, өлешчә фонетика өлкәсендә тикшеренүчеләр өчен дә кызыксыну уятырлык.

Жырларның немец теленә тәрҗемәсе турында әйткәндә, аларның яхшы дәрәҗәдә, татар фольклоры нечкәлекләрен истә тотып эшләнүен билгеләп үтәргә кирәк. Шулай да милли атамаларны, төшенчәләрне тәрҗемә итүдә табигый төгәлсезлекләр киткән.

Бу китап — Игнац Куношның күп көч талап иткән тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Профессор Жужа Какук эшчәнлеге дә аерым игътибарга лаек. Әлеге җыентыкта дөнья күргән материаллар киләчәк фәнни-тикшеренүләргә бер нигез булыр дип ышанырга кирәк.

Халик **ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

---

**БАТУЛЛА. ТАШЛАМАМ, ҖАНКИСӘГЕМ.** Татарстан китап нәшрияты, 1980.

---

Батулла — балалар һәм зурлар әдәбиятында эшләүче, төрле жанрларда иҗат итүче һәм һәр йөкне тигез тартырга омтылучы автор. Ул соңгы ун-унбиш ел эчендә балалар өчен «Исемем минем Дүрткүз», «Куян баласы Нуяк», «Каникуллар дәвам итә», «Гөлчәһрә» исемле повестьлар, «Курай уйный бер малай», «Куян тотучы Мырый», «Тычкан баласы Такыл», «Сак белән Сок кавышканда», «Салават күпере кайда йоклый», «Балавыз», «Миркәй бабай» шикелле әкиятләр, сәхнә сөючеләр өчен «Өчәү юлга чыктык», «Туйлар узгач», «Өйләнер чак» исемле драма һәм комедияләр бүләк итте.

«Ташламам, җанкисәгем» җыентыгына автор соңгы елларда зурлар өчен язылган 14 хикәясен бергә туплап биргән. Хикәяләрдән күргәнчә, Батулла һәр әсәрен диярлек драматик сюжетка корырга, характерлар үсешенә тиң үзенчәлекле интонация табарга омтыла. Язучыга бу җәһәттән драматургия алымнары да ярдәмгә килә. Ул хикәяләүне үткен, тыгыз диалоглар белән җанландырып җибәрә, шул рәвешле, әсәренең җылылыгын арттыра, укылышын җиңеләйтә, геройларының үзләренә генә хас сыйфатларын ачып сала. Батулланың күп кенә хикәяләре катлаулы язмышлар турында сөйләүче тоташ диалоглардан гыйбарәт.

Җыентыкта үзәк урынны «Салкын оя», «Китек күңел», «Кайту», «Яшенле яңгыр көткәндә» хикәяләре алып тора. Автор аларда геройларның гадәт-холкын, яшәү максатын, тормышка мөнәсәбәтен ачык күрсәтергә, вакыйгалар агышын эпик планда бәян итәргә омтыла.

«Салкын оя» хикәясендә Ихлас, Морат, Хәбир, Гөлфирә, Фатима образлары эш өчен җаны-тәне белән янып йөрүчән индивидуаль йөзле кешеләр итеп гәүдәләндерелгәннәр. Укучы Ихлас белән Гөлфирәнең тормышларын күңелле һәм тату итеп дәвам итәчәкләренә, үзләренә матур дәвам тәрбияләячәкләренә ышанып-шатланып, ә Мирзахан белән Рәсиханың мәхәббәте авыр сынауларда таркалачагына борчылып, ачыргаланып кала. Аерым эпизодларда гына чагылып киткән персонажлар да истә калырлык итеп эшләнгән. Рәсүл, Сания киләчәкләрен, яшәү рәвешләрен билгеләүдә җиңел карашлы, Хәдичә белән Салих үз даннары һәм бәхетләре өчен балаларын да онытучы күке табигатьле, Әхмәт әрсез, доносчы, ялагай характерлы бәндәләр булып күз алдына баса.

Башка хикәяләрдә дә кешеләр арасында катлаулы мөнәсәбәтләр, олы мәхәббәт дулкынландыргыч һәм тетрәндергеч ситуацияләрдә ачыла. Аңардагы үзенчәлекле характерлар, катлаулы язмышлар күңелдә уелып кала. Бөек Ватан сугышы елларында тылда калган өлкән буын, хатын-кызлар, бала-чагаларның фидакарь хезмәтен игътибар үзәгенә алып, психологик тәгәллеккә омтылып сурәтләгән «Офыклар алсу иде», батырларча һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерүче «Ташламам, җанкисәгем», романтик рухлы, якты сагышлы «Соңгы чабыш» хикәяләре аеруча җылы тәэсир калдыра.

Гомумән, «Ташламам, җанкисәгем» җыентыгының нигезендә тормыш, заман, ил-көн каршында гражданлык бурычы турында уйланулар ята.

Әзһәр **ГАБИДИ.**

---

**К. М. ФАСАХОВ. С ЖИЗНЬЮ В НОГУ.** (Периодическая печать Татарии в восстановительный период.) Казань, 1978.

---

Татарстан партия-совет матбугаты илебезнең күп милләтле журналистика тарихында сизелерлек урын били. Шуны истә тотып, 70 нче елларда республикабыз көндәлек матбугаты тарихын өйрәнүгә игътибар шактый көчәйде. Республика матбугатының халык хуҗалыгын торгызу елларындагы эшчәнлеген тикшерүгә соңгы елларда К. М. Фәсахов шактый күп көч куйды.

Аның яңа монографиясе дүрт башламнан тора. «Иң куәтле» дигән беренче башламда автор партия-совет матбугатының ленинчыл нигез принциплары турында сөйли. Татарстан матбугаты тарихын өйрәнүдә ирешелгән уңышларга һәм хәл итүне көтә торган мәсьәләләргә туктала. Аерым алганда, бу башламда ул әлегрәк дөнья күргән хезмәтләр нигезендә Татарстанда совет матбугатының барлыкка килүе турында кыскача мәгълүмат бирә. Шул уңайдан, француз буржуаз тарихчыларының Парижда басылып чыккан китапларында татар совет матбугаты тарихын бозып күрсәтергә маташуларын конкрет фактлар белән фаш итә.

«Иң алдан барырга» дип исемләнгән икенче башлам биш бүлектән тора һәм монографиянең үзәк өлешен тәшкил итә. Беренче бүлектә Татарстан АССР оештырылгач республикада партия-совет матбугатының фәнни нигезләнгән киң челтәре булдырылуы һәм аның әһәмияте яктыртыла. Автор хаклы рәвештә егерменче еллар башында Казанның илебездәге зур нәшрият үзәкләреннән булуын һәм бирегә күрше тугандаш халыклар, (чуваш, удмурт, мари һ. б.) телләрендә дә газета-журналлар чыгарылуын билгеләп үтә. 1920 елда Казанда уздырылган Көнчыгыш халыклары ара-

сында эшләүче журналистларның Бөтенроссия конференциясе, Казанда һәм өязләрдә полиграфия базасының ныгытылуы, редакцияләрне һәм типографияләрне кадрлар белән тәэмин итү буенча күрелгән чаралар матбугатка партия җитәкчелеген ачык яктырталар. Бу бүлектә Татарстан матбугатын үстерүгә зур көч куйган партия өлкә, өяз комитетлары һәм совет органнары җитәкчеләре, шулай ук күренекле журналистлар, аерым алганда А. П. Таняев, Н. Я. Яруллин, Б. Х. Мансуров, В. М. Бахметьев, В. Шәфигуллин һ. б. турында кайбер өстәмә мәгълүматлар бирелә.

«Сугыштан тынычлыкка күчкәндә» дигән бүлек республика матбугатының РКП(б)ның X съездыннан соңгы эшчәнлегенә багышлана. Архив материалларыннан, республика һәм өяз газета-журналлары хәбәрләреннән файдаланып, автор намуслы хезмәткә рухландыруда һәм туплауда матбугат органнары уйнаган рольне күрсәтә. Ул Татарстан партия оешмасының татар телендәге газета-журналларга ярдәм йөзеннән башкарган күпкырлы эшен дәлилле тасвирлый, шул ук вакытта матбугат органнары эшендәге төп кимчелекләргә анализ ясый. Бу бүлектә НЭП заманында шактый җанланган вак буржуаз элементларның үз карашларын пропагандалау өчен матбугаттан файдаланырга маташулары республика партия оешмасының шушы хәлгә принципиаль бәя биреп, вакытында чик куюы конкрет мисалларда күрсәтелә. Әлеге фактлар халык хуҗалыгын торгызу елларында матбугат үсешендәге кыенлыклар, партия оешмаларыннан газета-журналларның идея-политик юнәлеше хакында даими кайгыртучанлык таләп ителүе турында сөйли.

Әйтергә кирәк, К. М. Фәсәхов хезмәтенең уңышлы якларыннан берсе — матбугатка партия җитәкчелеген зур игътибар белән өйрәнү, һәр бүлектә бу мәсьәләнең үзәк урынны алып торуы. Икенче башламның «Көч һәм илһам чыганагы» дигән бүлеге, мәсәлән, тулысынча матбугатка партия җитәкчелеге мәсьәләсенә багышланган. Биредә китерелгән материаллардан күренгәнчә, партиянең Татарстан өлкә һәм өяз комитетлары газета-журналларның хезмәт ияләренә тәэсирен көчәйтү, редакцияләрнең эшен камилләштерү юнәлешендә зур эш башкарганнар. Аерым алганда, редакцияләрнең эш планнары һәм отчетлары партия өлкә һәм өяз комитетлары бюролары һәм секретариатлары утырышларында тикшерелгән, матбугатка җитәкчелекне яхшырту максатында коллегияләр һәм даими эшләүче махсус киңәшмәләр оештырылган. Редакцияләрнең финанс хәлен яхшырту, аларның полиграфия базасын ныгыту буенча күп төрле чаралар күрелгән. Журналист кадрлар һәм полиграфия эшчеләре әзерләү мәсьәләсе даими игътибар үзәгендә торган. Автор өяз партия оешмаларының һәм совет органнарының матбугат эшенә игътибарларын көчәйтүләренә дә туктала. Моңа кадәр өяз газеталарының җитәрлек өйрәнелмәвен искә алсак, Касыйм Фәсәховның әлеге юнәлештәге тикшеренүләре хуплауга лаек. Бу хезмәттә партия Үзәк Комитетының милли матбугатны үстерүгә даими әһәмият бирүе, аерым алганда Татарстан партия оешмасына һәрьяклы ярдәм күрсәтүе дә җитәрлек фактлар нигезендә дәлилләнә.

Татарстанда эшче һәм авыл хәбәрчеләре хәрәкәтенең барлыкка килүе һәм киң колач алуы, аңа партия җитәкчелеге «Матбугатның таянычы» дигән бүлектә тикшерелә. Анда игътибар үзәгенә куелган материаллардан Татарстанда бу хәрәкәтнең ныгый һәм көчәя баруы, матбугатның ышанычлы таянычына әверелүе ачык күренә.

Татарстан матбугатының республика промышленностен торгызуда һәм авыл хуҗалыгын күтәрүдә, культура төзелеше мәсьәләләрен хәл итүдә уйнаган роле китапның «Иң тәэсирле көч» дигән өченче башламында тикшерелә. К. М. Фәсәхов халык хуҗалыгын торгызу чорының катлаулы мәсьәләләрен хәл итүдә республика матбугатының өлкә һәм өяз партия оешмаларына ярдәм итүен ышандырырлык итеп тасвирлый, бу эштә матбугат органнары кулланган конкрет формаларны һәм ысулларны анализлый һәм гомумиләштерә.

Монографиянең «Яңа күтәрелештә» дигән соңгы башламында Татарстан матбугатының 1920—1926 елларда ирешкән уңышларына йомгак ясала һәм аның яңа шартларда иҗади үстерелеше гомумиләштерелә.

Хезмәттә В. И. Ленин әсәрләре, партия съездлары һәм Үзәк Комитет карарлары, партия һәм дәүләт архивлары документлары, матбугат материаллары, әлеге проблемалар буенча күп санлы басма фәнни тикшеренүләр киң файдаланылган. Бу исә аның фәнни тирәнлеген көчәйтергә, дөрес нәтиҗәләр һәм гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек биргән.

Монографиянең тагын бер уңай ягын күрсәтергә кирәк: автор 1920—1926 елларда республикада нәшер ителгән газета-журналларның һәм башка төр көндәлек басмаларның тулы исемлеген төзегән, һәр басманың төгәл чыганакларын ачыклаган. Китап соңында китерелгән башка кушымталар да игътибарга лаек.

Хезмәтнең кайбер йомшак якларын да күрсәтеп, шул уңайдан кайбер киңәшләр белән уртаклашасы килә. Аерым алганда, икенче башламда Татарстан АССР оештырылу мәсьәләсенең матбугатта ничек яктыртылуына, бу өлкәдәге кайбер ялгыш моментларга да тукталу кирәк иде кебек. Өченче башламда татар телендәге газета-журнал битләрендә милли культура мәсьәләсе хакында барган фикер алышуларга да тукталу һәм принципиаль бәя бирү сорала. 20 нче еллар уртасындагы журналистлар турында тулырак мәгълүматлар китерелсә, эшче һәм авыл хәбәрчеләре эше анык мисаллар белән киңрәк як-

тыртылса, республикада хәбәрчеләр хәрәкәтенең үсешен күрсәткән таблица да бирелсә, китап тагын да тулырак булыр иде.

**Тәлгать НАСЫЙРОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

---

Илдус ИЛДАРХАНОВ. ОЛИМП ТАВЫНА НИЧЕК МЕНӘРГӘ? Татарстан китап нәшрияты, 1980.

---

Хәтерегездәдер, «Гарәфә кич төшемдә» дигән мәгълүм хикәя герое төшендә ул заман өчен гадәти булмаган җиргә — татар клубына эләгә. Имеш, ул анда килгән кешеләр арасында хокук белеме, медицина, математика, философия, экономика буенча татар профессорларын, инженер-архитекторларын, композиторларын, артистларын, язучыларын һәм башка талант ияләрен очрата. Аларның хезмәтләре һәм әсәрләре чит илләрдә дә яхшы мәгълүм, имеш... Революциягә кадәр мондый үсеш мөмкинлекләре, чыннан да, төшкә генә керә алган. Социаль, рухи һәм милли яктан изелеп килгән татар халкының уллары һәм кызларына культурага, мәгариф хәзинәләренә юл ябык булган. Бөек Октябрь революциясе, ленинчыл милли политиканың тормышка ашуы нәтиҗәсендә генә халык талантлары чын мәгънәсендә чәчәк атты. Хәзер республикабызда 500-ләп фән докторы булуы шуның ачык бер дәлиле. Аларның берсе—техник фәннәр докторы, Казан химия-технология институты профессоры Габделнур Мөхәммәтҗанов, химия фәненә, яшь белгечләр тәрбияләүгә гаять зур өлеш керткән галим. Әмма кояш нурларында асылташ бөтен кырлары белән дә ялтырып киткән кебек, Габделнурның таланты да бары фән өлкәсендә генә чагылып калмый. Ул— илдә, дөньяда танылган спорт судьясы да. Баскетбол буенча өч олимпия уеннарында, Европа һәм дөнья күләмендәге дисталәрчә ярышларда судьялык иткән кеше. Менә шуңа да олимпияче якташларыбызга багышланган очерклар китабын кереш сүз белән Г. Мөхәммәтҗановның ачуы аерата мәгънәле һәм табигый. Чөнки ул үзенең тормышы белән үк гомуми культураның аерылгысыз бер өлеше булган спортның азат илдә шәхескә үстерүдәге гаять зур мөмкинлекләргә ия булуын раслый.

Менә шуңа күрә андый талантлар — корыч беләкле егетләр, житез кызлар безнең Татарстанда да бик күп. Олимпия уеннарында гына да барлыгы кырыклап якташыбыз катнашкан икән! Бер төбәктән чыккан шул чаклы чемпион турында сөйләүче махсус китапның әлегәчә булганы юк иде. Аның бездә башлап чыгуын иң әүвәл республикабызның әдәби һәм спорт традицияләре бай булу белән аңлатырга кирәктер. Спорт дөньясын яхшы белүче журналист Илдус Илдархановның һәр чемпион үткән юлны үтә җентекләп өйрәнүе, бу мөһим эшкә зур көч куюы нәтиҗәсе дә ул. Автор спорт кануннарын тирәнтен аңлап яза. Чемпион якташларыбыз турындагы һәр очеркта олимпия уеннары, спорт төрләре турында аңлаешлы итеп сөйләп бара, сүзне олимпиячеләрнең үзләренә бирә. Үзенчәлекле форма китапны баета, җанлырак итә, очерк героен вакыйгаларның үзәгендә тотарга, аның тормышын бүгенге көн белән бәйләргә ярдәм итә.

Журналист һәр очерк башында чемпионнар турында кыскача биографик белешмә, төп мәгълүматлар биреп тә бик дөрес иткән. Шул рәвешле ул башта ук укучының игътибарын җәлеп итә. Күп санлы һәм кызыклы очеркларның берсенә — «Аркадий Воробьев» дип исемләнгәненә генә тукталып үтәсе килә. Авыр атлетика буенча биш тапкыр дөнья һәм Европа чемпионы, ике олимпиада герое А. Воробьев Тәтештә туып үскән дип кем уйлар?! Чемпион үзенең балачактан спортка тартылуы, беренче тренеры һәм укытучысы, Бөек Ватан сугышында катнашуы, спортта тәүге җиңүе, халыкара турнирларда совет спорты данын ничек яклавы, көндәшләре һәм дуслары турында кыска, ләкин мавыктыргыч һәм ышандырырлык итеп сөйли. Спортның Аркадий өчен үзмаксат булмавын да аңлыйсың. Ул башта медицина институтын тәгаллли, аннары фән кандидаты һәм, ниһаять, докторы да була. Моның өстенә якташыбызның Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Почет Билгесе орденнары белән дә бүләкләнүе турында мәгълүмат алгач, күз алдына олы биографияле чын совет кешесе, баһадир шәхес килеп баса. Башка геройларның тормыш һәм спорт юллары да яшьләр өчен гаять гыйбрәтле үрнәк булып тора.

Китапның тагын бер отышлы ягы — аның энциклопедик характерда булуында, Татарстан спорты тарихының барлык әһәмиятле этапларын яктыртуда. Очерклар җанлы тел белән язылган, аларны кызыксынып укыйсың. Күп кенә спорт терминнары ана телендә беренче тапкыр кулланыла һәм матур тәэсир калдыра.

Илебездә физкультура-спортны үстерүгә гаять зур игътибар бирелә. Партиябез съездында кабул ителгән «СССРның экономик һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре»ндә «массовый физкультураны һәм спортны актив үстерергә, аларны кешеләрнең көндәлек тормышына кинрәк кертүгә булышлык итәргә» дигән юллар бар. Бу олы бурыч спортны пропагандалау эшен дә нык көчәйтүне таләп итә. Татарстан китап нәшрияты киләчәктә дә «Олимп тавына ничек менәргә?» кебек бай мәгълүматлы китапларга урынлы түрдән бирер, дип ышанасы килә.

**Дамир ШӘРӘФЕТДИНОВ.**

# ХӘНИФ ХӘЙРУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Бу исем әдәбиятта кинәт танылды шикелле. 1973 елда «Казан утлары» журналында аның «Канатлар талмасын» повесте басыла башлады һәм әлеге әсәр шунда ук киң җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итте. Моңа кадәр «Бакыр базының серләре» (1961), «Хуҗида үскән батыр» (1972) һ. б. хикәя, очерклар бастырган булса да, Хәниф Хәйруллинның иҗат юлындагы иң матур сәхифә — әлеге повесть иде.

Сарман районы газетасында эшләп яткан бу журналист үзенә хас уңганлык һәм сабырлык белән тормыш календарен өйрәнеп барган. Янәшәсендә яшәгән кешеләр дә артык күп түгел, күз алдында барган вакыйгалар да бер төбәк белән генә бәйле. Ил картасына куеп караганда, зур Иделгә коя торган бер инеш кенә. Ләкин никадәр якын, кадерле ул кешеләр, ул язмышлар Хәниф Хәйруллинга! Бу инешнең һәр борылмасын белә, тирәнлеген, матурлыгын тоя язучы.

Соңгы елларда авылның бүгенге хәле, киләчәк язмышы турында кемнәр генә уйланмый! Экономистларны аның яшәү чыганаклары кызыксындыра. Җитәкчеләрне авыл хуҗалыгы белән идарә итү принциплары һәм формалары уйландыра. Социологлар урбанизация дигән исем алган шәһәрләшү процессын өйрәнәләр. Язучыларны боларның барысы өстенә, авылның рухи үсеше мәсьәләләре борчый.

Әйе, «Канатлар талмасын» повесте авыл турында, аның бүгенгесе, киләчәге турында. Укучы аны колхоз председателе Рамазан Вилданов күрүе, аңлавы аша кабул итә. Шәһәр уңайлыкларын авылга механик рәвештә күчереп куярга түгел, аларны үз нигезендә булдырырга, эшләү һәм яшәү шартларын яхшыртырга кирәк. Авыл үз матурлыгын саклаган хәлдә, җиреннән аерылмыйча чәчәк атарга тиеш.

Хәниф Хәйруллин үзе яхшы белгән, якын күргән кешеләр, якташлары турында яза. Әсәрнең уңган һәм ярдәмчел геройлары һәркайсы үз кыяфәте, йөз-торышы белән җанлы булып истә кала. Аларны ихлас күңелдән якын итәсең. Нык исәпле, колхоз файдасы дигәндә һәр киңәшне, фикерне эшкә җиге белә торган, кирәк икән Мәскәвенә дә җитә, министрына да керә алган Шәкүр карт, тыштан гына беркатлы күренгән, әмма үзенең акылын, кадерен бик белеп яши торган Заман карт, җанына урын тапмаганга бәргәләнүче һәнүз, авылның күз алдында йөзенә кер кундырмаслык итеп тормыш итә белгән Мәрьям, тыйнак, тырыш Дамирларга киң күңелле, рәхимле булган өчен җылы сүз әйтәсе килә.

Бу кешеләрнең авыл халкына хас әдәп-низам кагыйдәләре бар: җиңел акыллылыкны, каударлануны, җилбәзәклекне кабул итмиләр. Шуңа күрә алар башта һәнүзне дә малайсытыбрак, «өлә утырып җитмәгән» диебрәк саныйлар, әмма берьюлы гына күтәрелеп бәрелмиләр. Рамай — авылдашлары каршында тырышып-тырмашып колхозны алга чыгарган намуслы, төпле җитәкче, аны хөрмәт итәләр, шул ук вакытта күз алларында үскән, үзләре акыл, тәрбия биргән кеше буларак яраталар, ышаналар. Крестьянча егәрле, үзсүзле, тормышны авызлыклап тота алырлык уңган Рамай иртәгәге көнне бүгеннән кайгыртә, җиргә нык басып йөри.

Әсәрне укыганда аның авторы өчен дә куанасың: матур кешеләр, олы җанлы кешеләр арасында, шулардан илһам алып яши икән ул.

Беренче повестеннан соң ике ел үткәч, Хәниф Хәйруллин яңа әсәрен бастырды. Аның исеме — «Картлык... кемгә шатлык?»— мәгънәле дә, моңсу да иде.

Укыганда күңелдә ниндидер моң кала, әсәрнең картлык турында гына түгеллеге дә ачыла бара. Яхшылык һәм явызлык турында хикәяли язучы.

Яхшылык, явызлык шундый зур төшенчәләр, тормышта аларны «менә ул!» дип күрсәтү шулкадәр кыен,— язучы сурәтләү объекты итеп гадәттән тыш язмышларны алырга, аларны гадәти дә, катлаулы да булган тормыш эчендә янәшә куеп карарга мәҗбүр. Янәшә нигездә туып үскән, холыклары да бер-берсенә охшаган Хәсән белән Асылның язмышлары да бер булыр кебек... Ләкин юк, тормышлары төрле юлдан китә, гомерләре бөтенләй төрлечә үтә бу кешеләрнең. Бер төптән үсеп чыккан пар кәүсәләрдәй, аерылып та китә алмыйлар үзләре, күңелләре, рухлары белән кушылып, тыныч кына яши дә алмыйлар. Нәрсә аера соң аларны — язмышмы, яшәү шартларымы?

Асыл, әнкәсе дә, сеңелләре дә ачтан үлгәч, Габдрахман байга батрак булып дүрт ел бил бөгә. Яхшылыкка явызлык — бае аны имгәткәнче кыйнатып ташлый. Менә шул явызлык гариплəндерә Асылның җанын. Ышанып, таянып кеше юк бу дөньяда дигән нәтиҗәгә килә ул һәм ялгыз «бүре» булып көн күрә башлый. Шул ялгызлыктан, күңеленә кереп оялаган явызлыктан үзе үк интегә. Хәсәннең хәр күңеленә, кешеләр турында кайгырта алуына кызыгып гомере үтә. Нинди генә хәлләр кичерми, әмма кеше булып яшәргә дип яратылган җаны сыкрап, елап яши. Бу дөньяга әйтеп калдырган соңгы теләге — үзен Хәсән күмсен, ул килсен, ул янда булсын!

Яшәү, үлем... менә шундый зур төшенчәләрне күтәргән, фәлсәфи яңгырашлы әсәр. Әйе шул, картлык кемгә шатлык?! Асыл, егет чакта ук, күңелен кешеләрдән биклəп куйгач, үзен яхшылыктан, кешелектән мәхрүм иткәч, явызлыкка әсир төшкән көнен үк картая. Еллар саны түгел, яшәү рәвеше, рух көче билгелидер картлык белән яшьлек чиген.

Дулкынландыра, уйландыра торган әсәрләр язган Хәниф Хәйруллинның иҗаты— яшь иҗат, кырлары иркен, күге биек булган иҗат. Картаймасын ул, канатлары талмасын!

ФЛЕРА ГАНИЕВА.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VII СЪЕЗДЫ

Халык интереслары белән яшәргә, тормыш дөреслеген расларга, коммунистик төзелештә актив катнашырга — күп милләтле совет әдәбияты осталары үзләренең төп бурычларын әнә шунда күрәләр.

Әдипләребезнең заман һәм халык алдындагы җаваплылыгы мәсьәләсе 30 июньдә Мәскәүдә, Кремльнең Зур сараенда ачылган СССР язучыларының VII съезды делегатларының игътибар үзәгендә торды.

«КПССның XXVI съезды карарлары яктылыгында коммунизм өчен көрәштә совет әдәбияты һәм аның бурычлары» турында СССР Язучылар союзы идарәсенең отчет докладын идарәнең беренче секретаре Г. М. Марков ясады. Ул үткән бишьеллыкта күп милләтле совет әдәбиятының төп үсеш тенденцияләрен җентекләп анализлады, аның тәрбияви әһәмиятенә, югары идея-художество сыйфатларына тукталды.

Г. Марков съезд һәм барлык совет язучылары исеменнән ленинчыл КПСС Үзәк Комитетын, Совет иле әдәбиятчылары Коммунистлар партиясе байрагы астына тагын да тыгызрак тупланырлар һәм коммунизм төзүче совет кешесе, безнең героик заманыбыз турында талантлы, чын мәгънәсендә партияле, халыкчан әсәрләр тудырырлар, дип ышандырды.

Иҗади фикер алышуларда хәзерге әдәби процесска җентекле анализ ясалды, бүгенге нәфис сүз сәнгатенең үсеше партия позицияләреннән торып, зур таләпчәнлек белән тикшерелде.

Съезд үзенең эшен сигез комиссиягә бүленеп дәвам итте. Комиссия утырышларында әдәби иҗат эшенең аеруча актуаль проблемалары буенча үткәрелгән сөйләшүләрдә Татарстан язучыларыннан Гариф Ахунов һәм Шәүкәт Галиев чыгыш ясады.

Аннары Язучылар союзының җитәкче органнарын сайлау үткәрелде. Татарстаннан Г. А. Ахунов һәм Р. И. Вәлиев СССР Язучылар союзы идарәсе членнары итеп сайландылар.

## СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ ПЛЕНУМЫ

Съезд сайлаган идарәнең беренче пленумы СССР Язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре итеп Г. М. Марковны сайлады. Ә яңа сайланган идарә секретарьлары арасында автономияле республикалардан А. М. Мирзаһитов (Башкортстан), Р. Ә. Гамзатов (Дагстан), А. П. Кешоков (Кабарда-Балкария), Г. А. Ахунов (Татарстан) иптәшләр бар.

## ДУСЛЫК БӘЙРӘМЕ КӨНДӘЛЕГЕ

Республикабызда Каракалпакстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре зур оешканлык һәм туганлык хисләре белән, илебез халыклары дуслыгының бер гәүдәләнеше рәвешендә үтте.

18 июньдә Казан ерак Каракалпакстаннан килгән якын дусларны якты йөз, чәчәкләр һәм музыка белән каршы алды. Кунакларны каршылауга багышланган митингта КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы председателе Г. И. Усманов, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, республиканың һәм Казан шәһәренең партия, совет оешмалары җитәкчеләре, хезмәт коллективлары һәм иҗат оешмалары вәкилләре катнашты. Анда кунакларга сәламләү сүзе белән ТАССР культура министры И. Н. Алиев мөрәҗәгать итте. Ул ике автономияле республикалардагы әдәбият һәм сәнгать көннәренең КПСС Үзәк Комитеты секретариаты карары белән үткәрелүенә, партиябезнең милли культураларны үстерү турында даими кайгыртучанлык күрсәтүенә басым ясап әйтте.

Үзенең җавап сүзендә Каракалпакстан АССР культура министры А. Х. Ходайбиргәнов туганнарча җылы каршылаган өчен кайнар рәхмәт белдерде. Бу әдәбият һәм сәнгать көннәре ике халык бәйрәме генә булып калмаячак, илебездәге барлык халыкларның дуслыгы тантанасына әвереләчәк, диде ул.

Шул ук көнне Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате бәйрәмендә катнашучылардан бер төркем Казанның В. И. Ленин исеме белән бәйле һәм башка истәлекле урыннары белән танышты.

19 июньдә М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында Татарстанда Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрен ачуга багышланган тантаналы кичә булды. Кадерле кунаклар белән очрашуга эшчеләр һәм фәнни коллективлар вәкилләре, язучылар, сәнгать эшлекләре, укучы яшьләр килде.

Тантаналы кичәне ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев ачты. Советлар Союзы Гимны яңгырады. Көчле алкышлар астында иптәш Л. И. Брежнев җитәкчелегендә КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы составында почетлы президиум сайланды.

Тантаналы кичәдә КПССның Татарстан

өлкә комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин һәм Үзбәкстан Компартиясенең Каракалпакстан өлкә комитеты секретаре К. Е. Юсупов иптәшләр чыгыш ясады.

Аннары ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, Каракалпакстан АССРның халык шагыйре Ибраһим Юсупов сүз алды. Кунакларны Казан дәүләт университеты студенткасы Г. Кудрявцева, ТАССРның атказанган тәэүчесе, Ленин комсомолы премиясе лауреаты В. Мәүликов котладылар. Кичә Каракалпакстан АССР сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

19 июньдә ТАССР Художниклар союзының күргәзмәләр залында Каракалпакстан АССР рәссамнары, сәнгать осталары иҗатына багышланган күргәзмә ачылды. Күргәзмәне ачу тантанасында Татарстан Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. Тумашев, ККАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Ж. Изентаев, «Каракалпакстан» китап нәшрияты директоры Х. Жумашев, Каракалпакстанның халык шагыйре Т. Сәетжанов иптәшләр чыгыш ясады. Бу тантанада КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, Үзбәкстан Компартиясенең Каракалпакстан өлкә комитеты секретаре К. Е. Юсупов иптәшләр катнашты.

Шул ук көнне Казанның «Родина» кинотеатрында Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәренә багышланган кинофестивальне ачу тантанасы булды. Аны кереш сүз белән Казан кинохроника студиясе директоры, ТАССР Кинематографистлар союзы идарәсенең беренче секретаре И. Н. Алексеев ачты. Кунаклар исеменнән җавап сүзе белән «Узкинохроника» студиясенең Каракалпакстан филиалы директоры Н. Н. Дәукәров чыкты. Ул Совет Каракалпакстаны сәнгатькәрләренең киеренке хезмәте, алар яулаган үрләр турында сөйләде.

20 июньдә Каракалпакстаннан килгән кунакларны Түбән Кама шәһәре хезмәтчәннәре каршылады. Составында Үзбәкстан Компартиясенең Каракалпакстан өлкә комитеты секретаре К. Е. Юсупов, ККАССР культура министры А. Х. Ходайбиргәнов, әдәбият һәм сәнгать әһелләре булган делегацияне КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР культура министры И. Н. Алиев, республика җәмәгатьчелеге вәкилләре озатып йөрде.

Каракалпакстан әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре шәһәр төзелешләре, нефть химиясе һәм шин житештерү промышленносте гигантлары белән таныштылар. Очрашу бәйрәме кичен Түбән Каманың Техника йортында дәвам итте. Нефтьчеләр, шинчылар, төзүчеләр һәм монтажчылар Бердах исемендәге Каракалпакстан дәүләт филармониясенең «Айкулаш» ансамбле концертын карадылар.

Минзәләдә Каракалпакстаннан килгән дусларны район хезмәт ияләре исеменнән КПСС райкомының беренче секретаре Г. Ш. Гыйлаҗев сәламләде. Җавап сүзе белән Үзбәкстан ССР Фәннәр Академиясенең Каракалпакстан филиалы президиумы председателе, Үзбәкстан ССР Фәннәр Академиясе академигы Сабир Камалов чыкты. Очрашу чын дуслык, туганлык тантанасына әверелде. Кунакларны ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов озатып йөрде. Шул ук көнне Минзәлә район культура сараенда Дуслык кичәсе булды.

21 июньдә Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате бәйрәменә килгән кунаклар группалары Казанның Киров районында, Әлмәттә, Актаныш, Арча районнарында һәм Чаллыда халкыбызның традицион Сабан туенда катнаштылар.

Чаллыда, шәһәр Советы башкарма комитеты карары белән, яңа төзелә торган зур бульварга Каракалпакстан әдәбияты классигы Бердах исемен бирүгә багышланган тантаналы митинг булды.

Митингта халык депутатларының Автозавод район Советы башкарма комитеты председателе Р. М. Бәдгытдинов, Каракалпакстан АССР культура министры А. Х. Ходайбиргәнов, Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев, Үзбәкстан ССР һәм Каракалпакстан АССРның халык шагыйре Җолморза Айморзаев чыгыш ясады. Шул ук көнне кичен Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате бәйрәме Тукай районының «Гигант» совхозы культура йортында дәвам итте.

22 июньдә Каракалпакстаннан килгән кунакларны халык депутатларының Чаллы шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Р. Гыйлаҗев кабул итте.

Татарстанда Каракалпакстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучыларның аерым группалары шулай ук Сарман, Азнакай, Мөслим районнары хезмәт ияләре, «Полимерфото» заводы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Теплоконтроль» производство берләшмәсе эшчеләре, инженер-техниклары һәм хезмәткәрләре белән очраштылар.

Республикабыз хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтү буенча зур эш башкарулары өчен һәм әдәбият-сәнгать көннәре уңаеннан, Татарстан АССР Верховный Советы Указы белән, Каракалпакстанның бер төркем артистларына һәм культура работникларына ТАССРның мактаулы исемнәре бирелде.

23 июньдә В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсендә Каракалпакстан

һәм Татарстан язучыларының әдәби очрашуы үткәрелде. Аны ТАССР Язучылар союзы партия оешмасы секретаре, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев ачты.

Әдәбиятта тарихи һәм тарихи-революцион тема турында иҗади сөйләшүдә ККАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, Каракалпакстанның халык язучысы Түләпбиргән Каипбиргәнов, әдәбият галиме Аденбай Тажиморатов, Үзбәкстан һәм Каракалпакстанның халык шагыйре Теләүбиргән Җомаморатов, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Рафаэль Мостафин, прозаик Атилла Расих, әдәбият белгече Фәрит Хатыйпов чыгыш ясады. Алар ике тугандаш әдәбиятта тарихи һәм тарихи-революцион теманың гәүдәләнеше, бу юнәлештә язучыларыбызның иҗади хезмәттәшлеге турында уй-фикерләре һәм теләкләре белән уртаклаштылар.

Очрашуның икенче өлешендә Каракалпакстан әдипләре Җолморза Аймурзаев, Ибраһим Юсупов, Теләүбиргән Җомаморатов, Тажетдин Сәетжанов, татар шагыйрьләре Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Илдар Юзеев халыклар дуслыгына багышланган шигырьләрен укыдылар.

Әдәби очрашуда Үзбәкстан Компартиясенең Каракалпакстан өлкә комитетының пропаганда бүлеге мөдире Б. И. Исмаилов, КПССның Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

Каракалпакстаннан килгән кунаклар белән иҗади очрашулар шулай ук Казан дәүләт консерваториясенең кече залында — республикабыз композиторлары белән булды. Каракалпакстан сәнгатькәрләрен ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. З. Яруллин һәм ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев тәбрикләде.

23 июньдә Татарстанда халыклар дуслыгының гүзәл бәйрәме — Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре тәмамлануга багышланган тантаналы кичә булды. Аны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты.

Кичәдә катнашучылар ТАССР Министрлар Советы Президиумы Председателе Г. И. Усманов һәм Үзбәкстан компартиясенең Каракалпакстан өлкә комитеты секретаре К. Е. Юсупов чыгышларын зур игътибар белән тыңладылар.

Тантаналы кичәдә шулай ук «Теплоконтроль» производство берләшмәсе слесаре Социалистик Хезмәт Герое Н. М. Гыйлаҗев, Каракалпакстан АССРның халык язучысы, ККАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Каипбиргәнов чыгыш ясады. Үзбәкстан ССР һәм Каракалпакстан АССРның халык шагыйре Т. Җомаморатов үзенең Казанга багышланган яңа шигырен укыды.

Кичә Каракалпакстан сәнгате осталарының зур бәйрәм концерты белән тәмамланды. Кунакларның һәр чыгышы көчле алкышлар белән бүленде. Дуслар яңа очрашуларга кадәр саубуллаштылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНДӘ

Идарәнең киңәйтелгән утырышында СССР язучыларының VII съезды һәм Татарстанда үткәрелгән Каракалпакстан әдәбияты һәм сәнгате көннәренең йомгаклары каралды. Ике утырыш арасында идарә башкарган эшләр турында отчет тыңланды һәм союз идарәсенең, Чаллы һәм Әлмәт язучылар оешмалары, иҗат секцияләре, җәмәгать комиссияләре, әдәби консультантлар, әдәбиятны пропагандалау бюросы һәм Г. Тукай исемендәге клубның 1981 елның икенче яртысында эш планнары, шулай ук юбилей һәм мирас комиссияләре составы расланды.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Билгеле булганча, сентябрь-октябрь айларында вакытлы матбугатка, шул исәптән «Казан утлары» журналына да, 1982 ел өчен язылу бара. Укучыларның барысы да яхшы белгәнлектән, бу хакта кабат искә төшереп тормасак та ярар иде. Әмма, кызганычка каршы, һәр елны, эш узганнан соң, журналга языла алмый калган иптәшләрдән дәгъвалы хатлар яварга тотына. Шунлыктан язылу шартлары белән таныштырып куюны кирәк таптык.

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән, журналның күрсәткеч саны, ягъни индексы — 73210. Димәк, аңа Советлар Союзының теләсә кайсы шәһәр яки авылында язылырга мөмкин. Бу эшне почта бүлеге һәм «Союзпечать» агентлыгы хезмәткәрләре башкаралар.

Язылуда төрле аңлашылмаулар чыкмасын өчен, аның чарасына алдан керешү яхшы.

Инде журналга язылган укучыны нинди шатлыклар көткәнен дә әйтеп үтик. 1982 ел — «Казан утлары» журналы тарихында аерылып торачак, чөнки шушы елның май аенда аның чыга башлавына 60 ел тула. Бу — әдәбиятыбыз һәм, гомумән, республикабыз культурасы үсеше тарихында зур вакыйга. Татарстан язучылары бу тантанага багышлап иң яхшы әсәрләрен тәкъдим итәрләр, әлбәттә. Редакциядә аннан тыш та шактый мул кулъязмалар тупланды. Алар арасында укучыларга яхшы таныш өлкән әдипләрнең проза әсәрләре дә, шигъри көлтәләр дә, яшьләр иҗатыннан күркәм үрнәкләр дә бар.

Укучылар хәтерлиләрдер: үткән ел журналның аерым бер санында илнең башка өлкәләрендә яшәүче якташларыбыз иҗатына багышланган сәхифәләр бирелгән иде. Бу традиция алда да дәвам иттереләчәк, якташлар иҗатына да, аларның хезмәттәге батырлыкларын чагылдырган язмаларга да игътибар зур булачак.

Очерклар бүлеге укучыларны Татарстанның промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм культурасындагы яңалыклары, мөһим мәсьәләләре, шул өлкәләрнең уңганнары белән таныштырып торачак.

Тәнкыйть мәкаләләрен язуга әдәбиятыбызның иң сәләтле белгечләре тартылачак.

Җыр яратучылар республика композиторларының яңа әсәрләре белән танышып барачаклар.

Кыскасы, журналның 1982 елда чыгачак һәр саны укучыга бай мәгълүмат, зур рухи байлык китерер. Шулардан мәхрүм булып калмас өчен, журналга язылу чарасын алдан кайгыртырга киңәш бирәбез.

Редакция үзе исә подписка белән шөгыльләнми. Бу эштә килеп чыккан низагълар хакында редакциягә хатлар язу урынсыз.